РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ
АЛАБУГА ИНСТИТУТЫ

ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ КАФЕДРАСЫ



# ТАТАР ТЕЛЕ, ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ ТАРИХ: ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ, КИЛӘЧӘГЕ

## УКУЧЫЛАРНЫҢ ҺӘМ СТУДЕНТЛАРНЫҢ VIII БӨТЕНРӘСӘЙ ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ МАТЕРИАЛЛАРЫ

АЛАБУГА – 2017

24 ноябрь

ББК 81.632.3
УДК 811.512. 145.
Т 23

*Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты Редакция нәшрият советы карары белән басыла (23.11.2017, беркетмә № 16)*

**Җаваплы мөхәррир:**

**Хәйруллина Әлфирә Сәлихҗан кызы** – филология фәннәре кандидаты, татар филологиясе кафедрасының өлкән укытучысы

**Бәяләүчеләр**:

Даутов Г.Ф. – филология фәннәре кандидаты, доцент
Камаева Р.Б. – филология фәннәре кандидаты, доцент

**Редколлегия:**

Галләмов Ф.Г., филология фәннәре докторы, профессор
Даутов Г.Ф., филология фәннәре кандидаты, доцент
Камаева Р.Ф., филология фәннәре кандидаты, доцент
Габидуллина Ф.Ф., филология фәннәре кандидаты, доцент
Әхмәдгалиева Г.Г., филология фәннәре кандидаты, доцент
Мөхәммәтҗанова А.Х., филология фәннәре кандидаты, доцент
Хәйруллина Ә.С., филология фәннәре кандидаты, өлкән укытучы
Саттарова Г.Г., ассистент

**Т23 Татар теле әдәбияты һәм тарихы: үткәне, бүгенгесе, киләчәге:** укучыларның һәм студентларның VIII Бөтенрәсәй фәнни-гамәли конференциясе материаллары (Алабуга, 24 ноябрь, 2017ел). – Алабуга: КФУның Алабуга институты нәшрияты, 2017 – 210 б .

*«Татар теле, әдәбияты һәм тарихы: үткәне, бүгенгесе, киләчәге» фәнни-гамәли конференциясенең материаллары тупланган әлеге җыентыкка укучыларның һәм студентларның фәнни тикшеренү язмалары кертелде. Рәсәй Федерациясенең Пермь крае, Башкортостан һәм Чуаш республикаларында яшәгән укучыларыбызның мәкаләләрендә татар теле һәм әдәбиятының актуаль проблемалары, тарихның күпләрне борчыган һәм дулкынландырган мәсьәләләре, татар әдипләре иҗатында милли яшәешнең ни дәрәҗәдә яктыртылуы хакындагы уйланулары урын алган.*

©Авторлар коллективы, 2017
© К(И)ФУ Алабуга институты нәшрияты, 2017

# КЕШЕ ТОРМЫШЫНДА ТЕЛНЕҢ РОЛЕ

*Абдуллин Ранэль,*
*Әлмәт шәһәре 17нче урта мәктәбенең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Абдуллина Гөлнара Вәзир кызы*

Син югалтма, татар, үз кыйблаңны,
Кычкырып әйт, татар, үз сүзеңне!
Якла, Ходай, якла татарыңны!
Сакла, татар, сакла үз-үзеңне!
(Р. Миңнуллин)

Теләсә нинди милләтнең теле ул сүздә гәүдәләнеш алган тарихи ядкәр. Халыкның мәңгелек язмышы, рухи мәдәнияте кабатланмас һәм үзенчәлекле булып төрле жанрлы һәйкәлләрдә чагылыш таба. Телнең, сүзнең мәдәнияте бик күп буыннар өчен өзелмәс бәйләнеш булып тора. Туган тел – милләт рухы, иң мөһим бәхәссез билгесе. Телдә һәм аның аша милләтнең психологиясе, халыкның холкы, аның фикерләү сәләте, кабатланмас матур иҗаты, әхлаки торышы һәм эчке рухи күрсәтелә.

Тел – төрле авазлар һәм билгеләр ярдәмендә тормышка ашырыла торган аралашу системасы, ләкин аның билгеле бер системасы бар.

Тел – ул иҗтимагый күренеш тә. Телне кеше белән аралашмыйча гына үзләштереп булмый. Иҗтимагый үсешнең байтак өлеше мимика (елмаю, үпкәләү, борчылу һ.б.), ишарәләүгә бәйле булуына карамастан, бары тик тел генә мирасны тапшыручы чара булып тора. Әгәр телнең сүз байлыгы, аның кагыйдәләре һәм структурасы 7-8 яшьләрдә өйрәнелгән булса, тел онытылмый. Һәм бу да бик мөһим үзенчәлек булып санала.

Тел – ул кагыйдәләр тупланмасы. Дөрес һәм дөрес булмаган сөйләм бар. Телдә формаль һәм күз алдында тотылган кагыйдәләр бихисап, шуның өчен грамматик кагыйдәләрдән тайпылабыз.

Телне кулланганда аның грамматик кагыйдәләрен саклау таләп ителә. Тел кешеләрнең тәҗрибәсен оештыра. Аралашу бары тик шул очракта гына уңышлы санала, әгәр аның гадәти әһәмияте аралашуда катнашучыларга аңлаешлы һәм алар тарафыннан кулланылса гына.

Телнең төп функцияләре булып аралашу, аны белү һәм тыңлаучыга йогынты ясау санала. Тел ул үзе һәрвакыт матур, бары тик сөйләм һәм сөйләүче үзе генә ямьсез була ала. Теләсә нинди тел шул телне кулланучының тормыш тәҗрибәсен безнең көнгә җиткерә. Һәр яңа буын, аның вәкиле конкрет халыкның телен үзләштергәндә, аның тәҗрибәсенә, социаль байлыкларына тартыла. Моннан чыгып, тел кешенең үз-үзенең тотышына, мәдәниятенә, аерым шәхеснең тәҗрибәсенә турыдан-туры йогынты ясый дип әйтә алабыз.

Тел кешеләргә бер-берләрен аңларга, теләк белдерергә, максат-уйларын чагылдырырга ярдәм итә. Туган телендә кеше үсә, Ватанның тарихы белән таныша, милли сәнгатен аңлый.

Туган телгә килгәндә, ул һәркем өчен бик якын һәм газиз! Чөнки ул тормыш чыганагы, белем чишмәсе. Туган телеңне ярату Ватанны, әти-әниеңне яратып, хөрмәт итүгә тиңләр идем мин. Минем туган телем – татар теле. Бүгенге көндә безнең татар телебез тагын көчле сынауга дучар булды. Телебез бетсә, милләт бетә! Ә аны саклап калу безнең үзебездән тора. Бекемгә, бернәрсәгә карамый, үз ана телебездә сөйләшергә тиешбез, үзебезчә яшәргә безгә беркем комачау итәргә тиеә түгел.

## БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫНДА ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ МӘКТӘБЕ

*Айдашев Камил,*
*Алабуга шәһәре 4 нче гимназиянең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Фәттахова Раушания Минниәхәт кызы*

Балалар өчен шигырьләр иҗат итү – шагыйрьләрнең иң зур бәхетедер ул. Шигырьләре, экиятләре ана сөте белән бергә бала күңеленә сеңеп калган әдипләрнең әдәби язмышлары да күпкә баерак, кызыклырак, әдәби гомерләре дә күпкә озынрак, әсәрләре дә бермә-бер күбрәк укыла.

Сабый чакта тыңланган, укылган, ятланган шигырьләр күңелдә гомерлеккә саклана шул. Олыгайгач укылган шигырьләр күпме генә бөек булмасын, балачак шигырьләре белән алар берничек ярыша алмый. Беренче карашка гади генә, беркатлы гына тоелган ул шигырьләр, экият – хикәяләр безне гомер буе озата бара. Алар – безнең балачак хатирәләре! Балалар шигърияте – халкыбызның иң затлы рухи хәзинәләренең берсе, ә шагыйрьләре – шигъриятебезнең йөзек кашлары.

Аларның шигырьләре аша балалар дөньяны танырга, матурлык белән ямьсезлекне, яхшылык белән яманлыкны, мәхәббәт белән нәфрәтне аерырга өйрәнә.

Әдипләребезнең балаларга язган шигырьләре туган халкыбызның тарихын, гореф- гадәтләрен, мәдәниятен өйрәнергә булыша, туган җиребезгә, аның кешеләренә, әти-әниләребезгә, туганнарыбызга, дус–ишләребезгә мәхәббәт һәм хөрмәт хисләре тәрбияли. Кешелеклелек, намус, дуслык, тугрылык, әдәплелек, тырышлык, хезмәт сөючәнлек кебек төшенчәләр дә сабыйларыбызга иң элек балачак шигырьләреннән иңә.

Кемнәр сон ул балалар шигъриятен тудыручы әдипләр?

Кайчан, кайда туганнар, кайларда эшләгәннәр, ниләр язганнар?

Аларның иҗатлары турында без нәрсәләр беләбез соң?

Шәүкәт Галиев – балалар шагыйрьләреннән иң танылганнарыннан берсе, балаларга адресланган ике дистәгә якын китап авторы. Көнкүрештәге гади нәрсәләр шагыйрьнең каләм көче белән җиңел, тапкыр, тирән мәгънәле шигырьгә әйләнә. Аның “Витаминлы хәрефләр”, “Көпчәкләр ни сөйлиләр?”, “ Тырма, торма һәм торна”, “Язгы экият” кебек шигырьләрен балалар бер укуда истә калдыралар. Шуңа күрә иҗатын тулаемы белән балаларга, яшүсмерләргә багышлаган язучылар арасында ул үзенә бер аерым урын алып тора. Ш.

Галиевның балалар өчен язган шигырьләре Туган илгә тугрылыклы булырга, табигатькә, хезмәткә мәхәббәт белән карарга, тынычлык өчен көрәшергә чакыралар. Ул – табигать ямен, аның матурлыгын тирән сиземләүче шагыйрь. Челтерәп аккан чишмәләр, йомшак җилдә тирбәлүче яфраклар, сандугачлар җыры – һәммәсе күңеле аша шигырьгә күчә. Ул балачак хатирәләрен матур итеп, сәнгатьчә үз шигырьләрендә ачып күрсәтә.

Табигать күренешләре шагыйрьне ил, җир хуҗасы – хезмәт кешесе турында да уйланырга мәҗбүр итә. Нәтиҗәдә югары әхлакый сыйфатларга ия, күркәмлеге һәм тыйнаклыгы белән аерылып торган хезмәт кешесе аның иҗатында төп геройга әверелә:

Җиргә якын кеше гади була.
Купшы сүзләрне ул ятламый;
Йөргәндә дә йөри хуҗа булып,
Кунак кебек көяз атламый.

(“ Җиргә якын”)

Туган – үскән җире, Татарстан табигате аңа якын, кадерле, ул аның белән горурлана:

Улы булып һәм шагыйре булып,
Бик яратам һаман авылны.

(“Шәһәр керде басу капкасыннан”.)

Шагыйрьнең күңелне очындыра, шаярта, көлдерә торган, көләч, шул ук вакытта көтмәгәндә ачы итеп чеметеп ала торган шигырьләре балаларның гына түгел, хәтта олылырның да күңеленә хуш килә. Аның “Шәвәли”, “Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр”, “Кызык”, “Мыеклы бозау”, “Тылсымлы көзге”, Тавыклар көлә” кебек китапларын һәркем яратып укый. “Шәвәли” шигырен генә карыйк әле. Кем соң ул Шәвәли? Аның прототибы бармы? Әллә инде ул уйлап кына чыгарылган геройммы? Юк икән шул! Шәвәли чыннан да булган. Ул авторның балачак дусты Шәвәли абзый икән. Ш.Галиев аны балачак истәлекләреннән алып язган.

Шагыйрьнең туган авылы Олы Бакырчыда аның балачак дусты Шәвәли абзый яши. Бала чакта ул, чыннан да, шук, мәзәкчән, эшчән малай булган. Аны дуслары: “Шәвәли, көлдән ипи әвәли” дип үрти торган булганнар. Шәвәли образында күп малайларның холык- фигыльләре чагылыш тапкан.

“Шәвәли шәҗәрәсе” шигырендә Шәвәлинең гади татар малае икәнлеге искәртелә. Ул авылда туган, аның туган ягы – Тау ягы. Ул җилкуар җилбәзәк түгел, эшчән; үзенең татар баласы булуы белән горурлана. Лирик герой халык авыз иҗатындагы тапкыр Хуҗа Насретдинны. Шомбайны һәм Котбетдинне үзенең бабалары дип атый. Шагыйрь (лирик герой авызыннан) безгә дә үз тарихыбыз, милләтебез белән горурланырга; шук булсак та, эшчән булырга куша. Кешенең табигате гел үзгәреп тора: “бер давыллап ала, бер тына”, әле яшьлеге күкрәп узган туган ягын сагына, әле тезгенсез яшьлек хыялларына бирелеп, мәхәббәтен эзли, я күңеле тулы сагышын онытa да елмаеп-көлеп ала, иреннәрендә елмаю югалып өлгерми, шаян сүзләр ачу-нәфрәткә күчә. Ш.Галиев

– кеше күңелендәге әнә шул үзгәрешләрне, тирбәнешләрне үзенә бер осталык белән тотып ала белүче.

Әдәбият ул – тылсымлы дөнья. Язучыларыбызның күбесе ул дөньяга шигырьләр язып кереп китә.Тора-бара прозага, драматургиягә, тәнкыйтькә күчә. Ни дисәң дә, шигърият – хисләр ташкыны, кеше туктаусыз ул ташкында кайный алмыйдыр. Ә Шәүкәт абый фикеренчә, кеше кайчагында үз-үзен дә аңламый, язучы исә үзенең кайчан кайсы жанрга күчәсен дә белми. Ул аның эзләнүләренә, табышларына бәйле. “Ә минем тапканым – шушы балалар дөньясыдыр”, – ди ул.

Һәр шигырьнең үз драматургиясе. Дәреслекләргә кергән “Камырша”ны, берсеннән-берсе кызыклы маҗараларга юлыгып йөрүче Хәлим, Сәлим Мәсәлимне һәм, әлбәттә инде, “шук малай, өлгер малай, ут малай” Шәвәлине хәтеребездә яңартыйк. Юк, алай гына түгел, кабат укып чыгыйк! Ул шигырьләр, беркадәр мәзәк булып, укыганда көлдерсә дә, күңелдә калып уйландыра, акыл сатмый гына матур гадәтләргә, әдәп- әхлакка өйрәтә.

Шәүкәт абыйлар буыны (Илдар Юзеев, Рәшит Гәрәй...) шигърияткә сугыштан соңгы елларда килгән. Фатих Кәримнәрен, Муса Җәлилләрен югалткан халыкның күңеленә шагыйрьләр бик кирәк чакта килгән. Шул чордагы моңны, әрнүләрне, үзәк өзелүләрне шигырьләрендә чагылдырган алар. Башкача була да алмаган. Чөнки халкы кичергән тетрәнүләрне үзләре аша үткәргән буын бит ул.Бүгенге көндә шагыйрьләр күп. Әдәбиятка яңа агым булып килгән һәр буын аңа кабатланмас үзенчәлекләр өсти, яңа заман сулышын өрә. Ләкин, аларның иҗаты бөреләнеп кенә килгән чорда Шәүкәт абыйлар, Илдар абыйлар буыны булмаса, татар шиъгриятенең алтын чылбыры өзелгән булыр иде.

Шәүкәт Галиевның шигырьләрендә шагыйрь фантазиясе тудырган гаҗәеп дөнья – яңа теле ачылган нәниләрдән алып мәктәп яшендәгеләргәчә булган кыз-малайларның күпкырлы һәм кызыклы тормыш: уеннары, укулары, шатлыклары-борчылулары, шаянлыклары-батырлыклары, уйлары-хыяллары – кыскасы, кеше һәм шәхес буларак җитлегү процессындагы катлаулы мөнәсәбәтләре сәнгатьчә нәфис буяуларда һәм тормышчан ситуацияләрдә тасвирлана. Юмор катыш җор-йөгерек тел, шиъри тапкырлык һәм фантазия, балалар табигатен тирән тою һәм аларга карата ышаныч-хөрмәт – менә бу сыйфатлар шагыйрьгә балалар белән ихлас мөгаләмәгә керергә һәм, бернинди үгет- нәсыйхәтсез, иң җитди темалар турында да бала күңеленә уңай йогынты ясарлык чын сәнгати әсәрләр иҗат итәргә мөмкинлек бирә.

Ш. Галиевның балаларга атап язган шигырьләре тулы мәгънәсендә олы, гуманистик фикерләр, туган халкыңа тугрылыклы булу, табигатькә һәм хезмәткә мәхәббәт хисләре белән сугарылган.

# ТУФАН МИҢНУЛЛИН ДРАМАЛАРЫНДА ҖӘМГЫЯТЬ

*Аркатова Анна,*
*Алабуга шәһәре 4 нче гимназиянең VII сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Айдашева Кадрия Әмирҗан кызы*

Айгыр тауның айлы җиле
Юата төн карасын.
Тауга карап, тау булалган
Туфан булып кара син!.

Татар драматургиясенең күтәрелеш чоры 70 нче елларга туры килә. Әлеге күтәрелешнең кыйммәте шунда иде – ул гомумкешелек мәсьәләләрен күтәрде. Әсәрләр тормышчанлык, бүгенге татар тормышының четерекле мәсьәләләрен яктырту, заманча кичерешләр белән сугарылган. Илнең бик күп театрлары кризис кичергәндә, татар драматургиясе, татар театры үзара гаугаларга бирелмәде, кыска гомерле модаларга ияреп, үзенең милли йөзен югалтмады. Ләкин шулай да татар драматургиясендә дә төрлечә язучылар булды.Татар мәдәниятенең үсеше, аеруча әдәбият һәм театр, җәмәгатьчелектә һәрвакыт зур кызыксыну уята килде.Соңгы вакытларда бу хакта әледән-әле кайнар бәхәсләр дә булып тора. Буыннар чылбыры, ныклыгы,традицияләрне саклау һәм яңалыкка омтылу, һаман хәрәкәттә,үсештә булган зур тизлек замана куйган таләпләрне үзенә генә хас нәфислек, гүзәллек, дөньяга карашлар җыелмасы аша хәл иткәндә татар театры үз асылын вә миллилеген саклап кала алыр. Бүгенге заман театр сәнгате киләчәкне матур итеп күрү дәрте белән рухланып яши. Туфан Миңнуллин менә шундыйлардан. Бүгенге көндә Туфан Миңнуллин драматургиясе замандашларыбызның күңел дөньясына тагын да тирәнрәк үтеп керү сыйфаты белән үзенчәлекле. Ә аның геройлары күңел көрлеге, эчке дөньяларының киңлеге белән аерылып тора.

Бүгенге шәхес язмышына якын килү, гомумән драманың үтә дә серле, әлегә кадәр ачылмаган якларын ачыкларга, драманың асылын, аның чын мәгънәсен тирәнрәк һәм киңрәк аңларга ярдәм итә.

Туфан Миңнуллин – татар әдәбиятында әйдәп баручы язучы. Язучы иҗатында иң актуаль проблемаларны күтәреп чыга. Шул проблеманың берсе – җәмгыять. Соңгы елларда драматург кеше язмышын җәмгыять вә милләт язмышы белән тыгыз бәйләнештә алып сурәтләүдә, татарның милли йөзен саклап калу өчен көрәш юлларын тасвирлауда яңа баскычка күтәрелде.

Туфан – гарасатлы мәгънәгә ия исем. Шушындый саллы исем гөмбәзе астында яшәп тә, олылык иясе булырга омтылмау замана каршында гөнаһ булыр иде. Туфан Миңнуллин холкындагы туры сүзлелек, кыю-үҗәтлек, кискен-кырыс шартларда да үз-үзен аямау гаярьлеге, гомумән, аңа хас сыйфаттыр. Туфан Миңнуллинның таланты иҗат үзенчәлеге -кешеләрне, табигатьне, тормышны, гомумән, бар дөньяны ярата белүендә. Язучының һәр әсәрендә, әсәрнең үзәгендә, бәгерендә ихласлык һәм халык язмышы өчен борчылу ята. Иң беренче чиратта кешенең иң авырткан урынын, иң тирән

ярасын эзләп табарга, үз әсәрен дару үләне итеп шул ярага капларга ашыга ул. Язучы үз янәшәсендәге кешеләрнең борчу-кайгыларын, үз халкының язмышын һәрдаим күңеле аша үткәреп яши. Ә моның өчен иң беренче чиратта шәхес була алу кирәк.

Драмаларында, хикәяләрендә, әдипнең уйланулары туган як турында. Ә туган як турында язу, ул, яхшылык белән явызлык, бәхет һәм бәхетсезлек, чын вә ялган, яктылык һәм караңгылык, куаныч һәм сагышлар, тагын әллә никадәр төшенчәләрне үз эченә ала. Драматургка әдәбиятны, аның нечкәлекләрен аңларга мөмкинлек бирү белән бергә, тормышны тагын да якынрак аңларга, кешеләрне, аларның проблемаларын тагын да тирәнрәк тоярга мөмкинлек тудыра.Туфан Миңнуллин һәрдаим белемен тирәнәйтеп яшәде.

Татар милләтенең киләчәге турында уйланулар, халкыбызның бишек җырлары, йолалары, бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре, ата-ана догасы, чисталыгы, саф күңеллелеге, хезмәт кешесенә, ата-анага, өлкәннәргә, үткәннәргә хөрмәт, изгелек хисләре тәрбияләү тәҗрибәсе һәм моны яшь буынга да тапшыру өчен омтылып яшәү, башкалар белән аралашу рәвеше-әдипләрне яңадан-яңа әсәрләр язуга рухландыра торган кыйммәтле һәм затлы рухи хәзинә ул. Аның әсәрләрендә халкыбызның милли йөзе, үзенә генә хас матур сыйфатлары, рухи кыйммәтләребезнең язмышы өчен җан атып торган кеше образлары һәркемне сокландыра, ләззәтләндерә, уйландыра, борчый. Асылда авылда сакланган милли традицияләребезне бөтен нечкәлегендә беләсе килгәндә, кешеләр, Туфан Миңнуллин драмаларын укып, сәхнәдән карап, үзләренә гыйбрәт алалар, киләчәккә ышаныч белән карыйлар.

Соңгы елларда драматург кеше язмышын җәмгыять вә милләт язмышы белән тыгыз бәйләнештә алып сурәтләүдә, татарның милли йөзен саклап калу өчен көрәш юлларын тасвирлауда яңа баскычка күтәрелде.Җәмгыять язмышын драматург, башлап, халыкның рухи көчен үстерү, моның өчен аның әхлакый-этик йөзен ачыклап, җитешмәгән якларны алга сөрү белән бәйләп карый. Авторның соңгы әсәрләреннән «Кулъяулык», «Җен алыштырган», «Шүрәле - җанкисәгем», «Сөяркә» пьесалары асылда шуңарга багышланган. Мәсәлән, «Сөяркә» драмасында кешенең рухи дөньясы, Аллаһе тәгалә һәм кешеләр алдында вөждан сафлыгын саклау һәм шәхси рәхәтлеккә омтылудан туган көчләр арасындагы бәрелеш үзәккә куелган. Шулай итеп, драматургиядә бу традицион бәрелеш-каршылыкта өченче һәм бөек көч булган Хак Тәгалә дә исәпкә алына башлады. Ә бит безнең Ходаебыз алдында да кире каккысыз бурычыбыз, җаваплылыбыгыз бар. Бу мөһим конфликтны сәнгатьчә хәл итә башлауда да Т.Миңнуллин беренчеләрдән берсе булды.

Шунысы характерлы, драманың үзәк геройлары Хәбир һәм Әнисә алдында торган катлаулы сорауга – мондый ярату хисе белән гөнаһлымы мин? дигәнгә әсәр дәвамында ачык җавап бирелми. Гаилә – изге, һәркем бу җәһәттән Аллаһ каршында җаваплы дип карасаң, әйе, гөнаһлы, дигән җавап сорала. Ә инде акыллы һәм тәҗрибәле ир белән ихлас һәм саф рухлы хатынның никахсыз яратышуы... Кайсы дөрес? Әсәр шул сорауны тамашачы алдына куюы белән үк

сәнгати бурычын үти. Иң мөһиме, үзеңнең һәр адымыңны Илаһи кагыйдәләр белән үлчәү кирәк, дип куюы белән...

Татарстан Республикасының һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия федерациясенең Станиславский исемендәге, Татарстанның Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, хезмәте өчен орденнар һәм башка дәрәҗәле бүләкләр белән бүләкләнгән Туфан Габдулла улы Миңнуллин иҗаты татар әдәбияты тарихында кабатланмас күренеш булып тора. Милли драматургиянең күркәм традицияләрен дәвам итеп, автор сәхнә әдәбиятын яңадан-яңа идея-эстетик казанышлар белән баета. Туфан Миңнуллин иҗаты хәзерге татар әдәбиятының, милләтнең сәнгатьчә фикерләвенең алдынгы сафында бара.

## “ИДЕЛ” ЖУРНАЛЫНДА ЭМОЦИОНАЛЬ-ЭКСПРЕССИВ СҮЗЛӘРНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

*Әминов Фаил,*
*Зәй шәһәре 7 нче урта мәктәбенең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Сәлимҗанова Лилия Әхнәф кызы*

Сүз кешенең икенче берәүгә, теге яки бу күренешкә, вакыйгага, фикергә, эш-хәрәкәткә булган мөнәсәбәтен чагылдыра. Эмоциональ-экспрессив сүзләр тискәре, уңай мөнәсәбәтләрне, иркәләп әйтүне, кадерләүне һәм башкаларны белдерәләр [Сафиуллина 1999:117].

Тикшерү чыганагы итеп алынган “Идел” журналының тел тукымасында эмоциональ-экспрессив сүзләр шактый күп урын алып тора.

Журналда эмоциональ яктан нейтраль, гади сөйләм һәм китап теле лексикасын да очратып була. Беренче катламга тукталып тормыйча, икенче катламга хас (китап теле) сүзләргә тукталыйк: *дәүләт, мәйдан, мирас, план, белем, гакыл, татар милләте, мөнәсәбәт, мәнфәгать, варис, мәгърифәтче, дәлил* һ.б.

Анализлаган журналда уңай мөнәсәбәтне белдерә торган эмоциональ-экспрессив лексика, тискәре мәгънәле сүзләргә караганда күпчелекне тәшкил итә. Бу төр сүзләр бигрәк тә журнал укучысына мөрәҗәгать иткәндә кулланыла: *Иң башта, дустым, уйлап карыйк. (“Идел”, 2013, № 12) Бу турыда киләсе санда сөйләрбез, дустым. (“Идел”, 2013, № 4)*

Иркәләп әйтү сүзләрен журналда урын алган матур әдәбият әсәрләрендә дә очратырга мөмкин: *-Ай улым, һай балам... Ай бәгырем!.. (“Идел”, 2013, № 4) –Инде синнән яшергән юк, Айсылу җаныем. (“Идел”, 2013, № 2)*

Уңай мөнәсәбәтне белдерә торган сүзләр арасында, беренче чиратта, сүзнең мәгънәсендә үк позитив мәгънә салынган лексик берәмлекләрне атарга кирәк. Мәсәлән, *сөю, ярату, хөрмәт* сүзләре һ.б. [Хаков 1999: 70]. *Венера Ганиеваның бөтен җырлары мәхәббәт турында. Әмма нинди мәхәббәт! (“Идел”, № 12)*

Күргәнебезчә, бу төр сүзләрдә төрле сүз төркеменә караган сүзләр урын алган.

Сөйләмдә экспрессияне белдерүдә, билгеле булганча, ымлыклар да катнаша [Курбатов 1961:122-123]. Без тикшергән журналда мондый төр кулланылыш та бар. *Ул белеме буенча география һәм биология укытучысы. Сөйләшкәндә, "Оу-у-у" ымлыгын куллана. Ничек инде укытучы андый авазлар чыгарырга мөмкин, диярсең син. ("Идел", 2013, № 12) –Ура! Кыш җиткән! – дип кычкырып җибәрде малай, үзе дә сизмәстән. ("Идел", 2013, № 5)*

Тискәре мәгънә мөнәсәбәтен билгели торган эмоциональ-экспрессив лексика мәкалә авторына кешеләрне төрле яктан характерларга ярдәм итә: *Көчсез, ярдәмгә мохтаҗ, черкиләр янында бик мескен җан ияләре без. ("Идел", № 11)*

Тикшерелгән журналның телендә тискәре эмоциональ төсмергә ия булган метафоралар булуы да теркәлде. Без тикшергән чыганаклардан мисал: *Дәрестә гел миннән генә сорамасыннар өчен нәрсә эшләргә? Дәрес "тозлау" гөнаһлар дәфтәренә язылamы? ("Идел", № 11)*

Мондый сүзләрнең төп үзенчәлеге – контекстта гына образлылык функциясен үти алуында.

1. Эмоциональ-экспрессив төсмергә ия булган сүзләрнең бер төркеме – ул кушаматлар. Аларда кушамат иясенә хас булган мөнәсәбәт тасвирлана [Абдуллин 1968: 152].

Тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, журналлардагы гади сөйләм сүзләре, нигездә, яшь авторларның әдәби әсәрләрендә (бигрәк тә хикәя һәм пьесаларында) урын ала: *Я, күп лыкылдамый гына сал әле. ("Идел", 2013, № 2) Күземнән югал, эт баласы. ("Идел", 2013, № 3)*

2. Эмоциональ-экспрессив сүзләр сөйләмне тәэсирле, образлы, сурәтле итеп, фикерне ачык, төгәл итеп җиткерергә ярдәм итәләр [Хаков 1999: 70].

Күргәнебезчә, эмоциональ-экспрессив сүзләр әсәрнең тел тукымасында гаять әһәмиятле вазыйфа башкаралар.

Татар телендә "*җенләнү*" сүзе бар. Контекстка карап, ул тискәре мәгънә дә, нейтраль мәгънә дә белдерергә мөмкин: *Әле менә соңгы вакытта сайтлар эшләү белән бик нык «җенләндем». ("Идел" № 12)*

*Җенләнү* сүзе егетнең үз шөгыле белән көчле мавыгуын белдерә һәм сөйләмгә эмоциональ-экспрессив төсмер бирә. Аңа йөкләтелгән төп стилистик функцияләрнең берсе – сөйләүченең объектка мөнәсәбәтен күрсәтү. Бу сүзләрдә сөйләү теленә хас гадилек тә, үткенлек тә, сурәтлелек тә ачык чагылыш таба. Шуңа күрә сөйләү тормышчан, җанлы тәэсирле яңгырый.

Шушы ук күренеш белән алдагы җөмләдә дә очрашабыз: *Шайтан кебек кара мәче татар кешесендә негатив тойгылар уята икән, расизмның теркәлмәгән бер очрагы бу, күрәсең. ("Идел", 2012, № 7)*

3. Гади сөйләм сүзләре текстта стильләштерү максатына җавап биргәндә генә үзләрен аклыйлар. Киресенчә булганда һәм куллануда чамалык сакланмаганда, алар телне чуарларга, тел культурасызлыгына китерәләр

[Абдуллин 1968: 152]. Тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, “Идел” журналы теленә хас чамалык, тел сиземләү сәләте монда да үзенең уңай ягын күрсәтә.

Шулай итеп, публицистик әсәрләре теленә, рәсми эш кәгазьләре һәм фәнни әдәбияттан аермалы буларак, төрле бәяләү төсмерен белдергән сүзләр киң агым булып килеп керәләр һәм анда үзенә бертөрле идея эчтәлеген һәм публицистика стиленең үзенчәлеген билгели торган стилистик функцияләр башкаралар.

Әдәбият

Абдуллин И.А. Г.Камал драмаларында эмоциональ-экспрессив лексика / Китапта: Г.Камал драмаларының теле. – Казан, 1968. – Б.151-152.

Курбатов Х. Сүз һәм стиль // Совет әдәбияты. – 1961. – № 6. – Б. 122-123.

Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. (югары уку йортлары студентлары өчен). – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле (стилистика) – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 304 б.

## ТЕЛ ЯЗМЫШЫ – МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ

*Әхмәдиев Азат,*
*Норлат гимназиясенең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчеләр: Мостафина Рузалия Госман кызы,*
*Мостафина Нәзилә Камил кызы*

Тел – кешеләрнең иң мөһим аралашу-аңлашу чарасы. Укырга-язарга өйрәнү, белем һәм тәрбия алу, дөньяны танып белү, һөнәрле булу, тәҗрибә туплау, фән, техника, сәнгать һәм башка яңалыклар белән танышу, уйлап табу, иҗат итү эшләре - барысы да тел ярдәмендә генә тормышка ашырыла.

Тел кешеләргә бер-берсе белән аралашырга, бер-берсен аңларга, бер-берсенең теләк-максатларын, уй-фикерләрен белергә ярдәм итә. Тел турында яңадан-яңа китаплар чыгып тора, радиодан, телевидениедән кызыклы тапшырулар алып барыла,  интернет челтәрендә яңадан-яңа ресурслар барлыкка килә.

Тел  кеше томышында иң мөһиме нәрсә дип саныйм.

Туган телебез татар теле борынгы төрки телләрнең берсе.Ул мул сүзлек хәзинәсенә ия. Белгәнебезчә, татар теле – ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья халыкара аралашу теле дип саналган ундүрт телнең берсе. Бу – туган телебез белән горурланырлык мөһим фактор. Туган тел  туган җир кебек кадерле һәм газиз, чөнки ул – кеше күңелендә иң нечкә, иң күркәм сыйфатлар тәрбияләүнең иң көчле чарасы. Ул – әби-бабай, әткәй-әнкәй теле, әйләнә-тирәне танып белергә, чиксез матурлыкларны  аңларга, тоярга ярдәм итә торган тел. «Һәр илнең ачкычы – тел» дигән мәкаль тирән мәгънәгә ия. Без рус телен яхшы беләбез, шуның белән рус халкының мәдәнияте, яшәү рәвеше, әдәбияты белән яхшы таныш. Ә менә Татарстаныбызга килгән кунаклар «түбәтәй», «чәк-чәк»,

«читек» дигән сүзләрне тәрҗемә итеп тә тормыйча аларның мәгънәсен аңлыйлар. «Сабантуй» кебек милли бәйрәмебезне белмәгән кеше юктыр. Татарстанда төрле милләт халыклары дус, тату яши. Аларның күбесе татар телен аңлап, татар халкының гореф-гадәтен хөрмәт итеп, бәйрәмнәрне бергә күңелле итеп үткәреп яши.

Тел язмышы – милләт язмышы. Моны аңлап, 90 нчы еллар башында бездә шактый күп эш эшләнгән: милли мәктәпләр, балалар бакчалары ачылган, телгә игътибар да арткан, киләчәккә өмет белән карарга нигезләр дә барлыкка килгән. Ләкин, ни кызганыч, бүгенге көндә хәл кисенләште. Соңгы вакытта республикабызда телгә караш тискәре якка үзгәрә. Матди проблемаларны чишкән вакытта без тел мәсьәләсен онытып җибәрәбез түгелме?! Ә бит туган телебез – халкыбызның зур казанышы һәм байлыгы! Бүгенге көндә татар халкы өчен бик кызганыч хәл күзәтелә: республикабызда икенче дәүләт теле буларак кабул ителгән татар теленең киләчәге куркыныч астында калды. Бу хәл милләт язмышына битараф булмаган кешеләрне зур борчуга салды. Туган тел мәсьәләсе иң актуаль, иң җитди социаль, сәяси-иҗтимагый проблема булып торып басты. Чөнки тел - халыкның бөтен яшәү гомерендә тапкан иң кадерле зиһен байлыгы. Шул байлыкны саклап калу өчен, без – татарлар, мәктәп укучысымы, укытучымы, галимме, студентмы, урта яки өлкән яшьтәге татармы, көчебездән килгәннне эшләргә тиешбез.

Милли телне күтәрү өчен матбугат-нәшриятны киңәйтү, радио-телевидение аркылы аралашу, эш кәгазьләрен ике дәүләт телендә дә алып бару, төрле милләт кешеләре өчен татар телендә аралашу ихтыяҗы булдыру кирәк дип уйлыйм мин.

Татар тарихы белгече, галим, педагог Искәндәр Аяз улы Гыйләҗев [Гыйләҗев 2010: 55] телебезне саклап калу өчен шушы юнәлешләрдә хәрәкәт итәргә тәкъдим итә:

– шәһәрдә чын татар мохитен булдыру;

– сыйфатлы, зәвыклы, шәһәр халкына да, авыл халкына да кызыклы, яхшы татар телевидениесен булдыру – телне саклауда зарури бер шарт. Хәзерге көндә «Татарстан Яңа Гасыр» бу юнәлештә эшли, «ТНВ-Планета» дигән канал да барлыкка килде. Ләкин кайвакыт бу каналларны карагач, татар тормышы бары тик җыр-биюдән генә тора дигән фикер туа. Тагын бер актив үсә торган юнәлеш – интернет һәм компьютер технологияләре. Татар телен саклауда интернет гаҗәеп роль уйнарга мөмкин, чөнки яшьләрнең күбесе көне-төне интернетта аралаша. Бу күренешне без үз файдабызга куллана алабыз. Тулы канлы, нәтиҗәле эшли торган, балаларны һәм ата-аналарны җәлеп итәрлек татар мәгариф системасын булдыру бик мөһим.

Татар телен оныткан, ләкин татар үзаңын югалтмаган, үзләрен татар дип саный торган милләттәшләребез белән эш алып бару бик тә актуаль бурыч булып күренә, чөнки аларның йөрәкләрендә, күңелләрендә татар рухы әле сүнмәгән.

Мин бу юнәлешләр белән килешәм. Иң мөһиме, туган телгә ихтирам хисен һәркем үзеннән, үз гаиләсеннән башларга тиеш дип уйлыйм мин. Әгәр без үз

милләттәшләребез белән туган телебездә аралашмасак, башка милләт кешеләре безнен телебезне хөрмәт итәр микән?! Шушы көнгә кадәр нинди авырлыклар аша үтеп сакланып калган телебезне югалтырга безнең хакыбыз юк! Телебезне югалта калсак, ата-бабаларыбыз хәтере алдында бүгенге буын чын мәгънәсендә хыянәт кылган булачак!

Татар теле! Тугач та иң газиз кешеңнән ишетә башлаган, күп гасырлык тарихы булган, Каюм Насыйрилар, Тукайлар нигез салган, 7 миллион халык сөйләшкән, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәтелә торган, бүгенге көндә җитлеккән, камилләшкән, теләсә нинди катлаулы фәнне өйрәтергә мөмкинлеге булган, Моабитның таш диварлары эчендә дә тынмыйча, анның калын стеналарын тишеп чыгып, бөтен дөньяга яңгыраган, утларга-суларга салсалар да, чукындырсалар да, ассалар-киссәләр дә исән калган, иң-иң авыр кимсетүләргә дә түзгән, сынмаган-сыгылмаган, баш имәгән горур татар теле!

Язучыларыбыз, шагыйрьләребез татар теле турында нинди матур сүзләр әйткәннәр! “Берәр кеше башка телне өйрәнмәкче булса, башта үз телен белсен”, – дигән бөтен гомере буе халыкка фидакарьләрчә хезмәт иткән олуг галимебез Каюм Насыйри.

“Безнең телебез – матур, күркәм тел. Әгәр милләтнең теле кулланылмый башласа, ул юкка чыга. Моның өчен сугыш та, кан кою да кирәкми. Телен бетерден исә, үз халкыңның әдәбияты да, мәдәнияте дә бетә”, – дигән М.З.Зәкиев [Зәкиев 1977: 23]. Татар халкы теленең барлыкка килүе. Без бу тел кайчан да булса бетәр, юкка чыгар дип күркып яшәмик.

Безнең бурыч – халкыбызда милли аң, милли горурлык уяту, телебезне саклап калу. Тел өчен көрәш – милләт өчен көрәш ул.

Мин ышанам: бай тарихлы, зур үсешкә ирешкән туган телебез бүгенге көндә җәмгыятьтә килеп туган сынаулардан исән-сау калып, киләчәктә тагын да зуррак унышларга ирешер, республикабызда, Россия җөмһүриятендә һәм дөнья күләмендә хөрмәткә ия тел булып сакланыр!

Әдәбият

Гараев Ф.М. Языковая политика на современном этапе // Татар теле һәм этносы тарихи мәсьәләләре. – Казан: ИЯЛИ, 2000.

Гыйләҗев И.А. Татар теле язмышы турында кайбер уйланулар// Безнең мирас, 2010 – № 7.

Зәкиев М.З. Татар халкы теленең барлыкка килүе. –Казан: Татар. кит. нәшр., 1977 . – Б 23.

Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: “Хәтер” нәшрияты, 2001. – Б. 15.

Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – Б. 16

# ЯКТАШ ЯЗУЧЫБЫЗ КЛАРА БУЛАТОВА ИҖАТЫНДА БЕЗНЕҢ АВЫЛ КАҺАРМАННАРЫ

*Әхмәтҗанова Алсу,*
*Әлмәт районы Яңа Нәдер урта мәктәбенең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Җиһангирова Римма Мирхәт кызы*

Якташ язучыбыз Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Р. Төхфәтуллин һәм С. Сөләйманова исемендәге әдәби бүләкләр иясе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә ия булган мөгаллимә-шагыйрә Клара Булатованың Яна Нәдер авылында яшәгән һәм яшәүче кешеләргә багышланган әсәрләре бик күпләргә таныш. Шагыйрәнең шигырьләре туган ягыбызга, аның хезмәт сөюче кешеләренә, газиз туфрагына тирән мәхббәт белән сугарылган. Данлыклы, тырыш, хезмәт сөючән, батыр, фидакарь халкына мәдхия кебек аның әсәрләре. Ул үзе дә шушы Җир кызы, шигырьләренә дә шушы яктан, шушы туфрактан килеп керә. Язучы-шагыйрә өчен шушы як кадерле, чөнки “мәтрүшкәләр монда хуш ислерәк, ромашкалар монда эрерәк”. Клара Булатова иҗаты белән безнең туган ягыбызга да мәдхия укый, аның халкы белән горурлана.

Клара Булатованың иҗаты турында соңгы елларда газета-журналлар аша бик күп мәгълүматлар белән танышу мөмкинлеге булды. Шулай да бу олы шагыйрәнең иҗатын һәр яклап ачып бетерергә мөмкин түгелдер инде. Безнең кулга 2013 нче елның азагында гына килеп кергән “Сөембикә” журналындагы “Булатова барыбер бер генә” дигән исемдә бирелгән бер мәкалә миндә шушы язмам белән әлеге институт оештырган конференциядә катнашу теләген тагын да көчәйтеп җибәрде. Ул мәкаләнең авторы Наилә апа Кашипова, үзе дә Клара апа кебек үк укытучы булгандыр инде, шагыйрәнең иҗатын хаклы рәвештә бик олы бәяләгән, әмма ул аның туган җиребезне, туган төбәгебезне нинди кешеләр, нинди язмышлар аша сурәтләп бирүен тәгаен ачыклап бетермәгән кебек тоелды миңа һәм мин бу эшне үземнең авылым мисалында булса да ачыклауны үземнең бурычым дип уйладым. Минем шагыйрәнең бик күп әсәрләрендә үзебезнең якын кешеләребез тасвирланган булуы турында язасым килде. Дөресен әйткәндә, аның шигъри әсәрләрендә зурлап олылап сурәтләнгән бу каһарманнар үзләренең гадел яшәешләре, тырыш хезмәтләре белән безнең туган якны җырга теркәп калдырырлык шәхесләр бит инде, шулар турында тудырылган шигъри әсәрләрне нәкъ менә “Гадиләргә гимн” дип атап булыр иде.

Безнең Яңа Нәдер Әлмәт районындагы иң олы авылларның берсе булып исәпләнә. Клара Булатова 42 ел инде шушы авыл килене. Әмма ул Нәдергә килен булып төшкәнче үк бу авылны күреп яши: чөнки Клара апа Казан Дәүләт Университетын 1969 нчы елда тәмамлап кайту белән, Нәдердән сигез генә чакрым ераклыкта булган Яңа Кәшер урта мәктәбендә укыта башлый. Кәшер мәктәбенә Нәдер авылыннан йөреп укучылар 9 нчы, 10 нчы сыйныфларда әдәбият дәресләрен Клара Булатовадан алалар. Клара апага үз укучыларының

нинди шартларда тәрбияләнүләрен, авыл сигезъеллык мәктәбендә ничек укыган булуларын белү-өйрәнү өчен безнең Нәдергә килеп йөргәләү, әлбәттә, шул вакыттан ук зарур була инде. Бу турыда шагыйрәнең чыккан китапларында берничә мәртәбә кабатлап басылган “Унсигезенче маршрут” дигән шигыре бик үзенчәлекле. Ул шигырь Клара Булатованың 1961нче елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган “Миләш Кагы” китабында басылган.

Шагыйрәнең безнең авыл каһарманнарын чын мәгънәсендә шигырь героена күтәреп язган беренче әсәре 1972 нче елда “Социалистик Татарстан” газетасында басылып чыккан “Урман җыры “ поэмасы була. Әсәрнең төп герое – Нәдердә яшәүче, урман хуҗалыгы белгече Харис абый Галиев. Әйтергә кирәк урманчы Харисның өлкән улы Ринат Харисович Галиев бүгенге көндә безнең илдә генә түгел, дөньякүләм танылган галим уролог. Икенчесе ВДНХ члены булган орденлы механизатор Әхәт Рафигуллинга багышланган тарихи җыентыкта бу поэма тулысы белән бирелгән, аның янында шагыйрәнең ире Нәфис абый һәм улы Марс белән бергә төшкән рәсеме дә бар. Шунысы кызык: алар анда өчесе дә хәрби киемнән (Клара апа да запастагы шәфкать туташы бит!). Бу әсәрдә, сугыш башлангач, фронтка киткән ир – атларны алыштыручы үсмер малайлар язмышы чагылыш таба. Чирек гасыр буе тракторда эшләгән “Почёт билгесе” ордены кавалеры Әхәт Рафигуллин шул буынның бер вәкиле.

Ә “Олы юлда колхоз машинасы” дигән әсәрдә “Зәй” колхозында озак еллар шофёр булып эшләгән Йосыф абый Гәрәев турында язылган. Бу шигыри “Гимн” сугышка кадәр үзе йөргән машинага сугыштан үзе исән-сау кайтып ничәмә-ничә еллар үзенең шул машинасында колхозга тырышып хезмәт куйган шофёрга шигъри һәйкәл булып 1978 нче елда “Социалистик Татарстан” газетасында басылып чыга. Клара апаның үзенчәлекле бер ягы бар: ул үз каһарманнарын нинди генә эштә эшләсәләр дә роботлар итеп түгел, җанлы-йөрәкле, ярата да, эшли дә белә торган шәхесләр итеп күрсәтә. Аның шофёры да гаиләсе белән бергә кайгысын-шатлыгын уртаклашып яшәү барышына куанып, уртак тел табып, гаилә бәхетен тоеп, саклап гомер итә белүче буларак хәтердә кала.

Клара апа Булатова авыл кешеләренә чын ихластан хезмәт күрсәтүче һөнәр ияләрен шигырьләрендә генә түгел, чәчмә әсәрләрендә дә әдипләрчә хөрмәтләп тасвирлый белә. Аның дистә еллар буе Нәдер авылына медицина хезмәтен күрсәтеп яшәгән Әхәт абый Әхмәтовка багышланган “Доктор бабай” дигән әдәби очеркы моның бик яхшы мисалы.

Клара апа шигыри репортажлар да иҗат итә. Нәдернең иң актив җәмәгать эшлеклесе булган Банат апа Идрисова турында “Аны әле әби димиләр” дигән шигъри репортажы шуның бер ачык мисалы.

“Ипекәйне зурлап” шигыре “Зәй” колхозының легендар рәисе Һади абый Рахмановка багышланган үзе бер мәдхия булып тора.

Нәдер халкы телендә “Җылы чокыр” дип аталган тау уентыгындагы алмалыкка җиләк-җимеш җыярга йөрүче әбиләребез ул бакчаны Бәкер исемле кешенең утырткан булуы турында сөйлиләр. Ә менә сугыштан соңгы елларда

үз кул астында эшләүче хатын-кызлар белән анда барып үсентеләрне карап-тәрбияләп йөргән Сәлмән абый Госмановның ул өлкәдә куйган хезмәтен авыл халкы истә тота. Клара Булатовагның Сәлмән абый турында “Нәдер Әлмәндәре” дигән күләмле шигыре гади хезмәт кешесенә гимн булып яңгырый.

Клара Булатованың Нәдер каһарманнарын сурәтләп язган шигырьләре, бер сүз белән әйткәндә, санап бетергесез. Аның байтагы газета – журналларда төрле елларда басылган. Мәсәлән, 1978 нче елда “Татарстан яшьләре” газетасында чыккан “Шигъри букетта” Клара апаның “Карны ярып тракторлар йөри” дигән кыска гына күләмле шигырендә шул елларда “Зәй” колхозының “Ленин ордены”на лаек булган тырыш хуҗасы (рәисе – председателе) Алмас абый Минһаҗетдинов турында тасвирланган.

Челтәр оя ясап буразналар
Аркылыга-буйга сузылган.
Ызаннарның тирәнлеген карап
Алмас атлый сабан юлыннан.
“Зәй” кырлары быел коры калмас,
Кар мул ятса – уңыш буласы.
Шундый уйлар белән йөри Алмас.
Бу җирнең ул тырыш хуҗасы.

Ә икенче бер әсәрендә шагыйрә шул ук геройның (Алмас абыйның) көне буе кырда эшләүче улы һәм оныгына яшел төенчеккә төйнәп, чүлмәк белән кайнар аш китерүе турында сөйли. Сугыштан кайтмый калган ире Гыйльфанның, улы Алмасның һәм оныгының туган туфрагы булган Нәдер җирләрен олылап, өлкән яшьтәге хатын-кызның дулкынлануын шигырь каләме ничек зурлап- хөрмәтләп сурәтли ала.

Атлый - йөгерә килә Җиһан әби,
Күңелендә кайнар бер ярсу:
Гыйлфанның, Алмас улкаеның
Оныгының җире бу басу.

Нәдер урта мәктәбе каршында 2013 нче елда авылның беренче нигезен тудырган тарихи шәхес Нәдер Урәзмәтовка һәйкәл куелды. Менә шул Нәдер нигезен тудырып калдырган авылбашыбызның токымыннан булган Нәдерлеләр хәзер дә яши Нәдер авылында. Клара апаның шуларның берсе булган Надыйров Шамил турында 1983 нче елның март аенда “Хезмәт байрагы” газетасында басылган “Үрнәк булырдай гомер” исемле бик тирән эчтәлекле мәкаләсе безнең авыл китапханәсендә саклана.

Шулай итеп, 40 елдан артык Нәдер авылында яшәп иҗат итүче Клара Булатованың туган җиргә, аның кешеләренә гадел рәвештә дан җырлап иҗат иткән әсәрләрен, шигырьләрен кайта-кайта укыйсың. Һәм гаҗәеп хәл: укыган саен алар үзләренең яңа яклары белән ачылалар. Югыйсә гап-гади алар-аяктан егарлык чагыштырулар да, оригинальлеккә омтылып язылган ясалма юллар да юк. Нәкъ менә шул гадилеге, тиз аңлаешлы булулары белән дә җәлеп итәләр икән ул шигырьләр. Уйландыра, моңландыра, сөендерә, көлдерә торган

әсәрләрен укып рухи азык аласың. Шуның өчен дә аңа зур иҗаты өчен рәхмәт әйтәсе килә.

Әдәбият

Булатова К. Үзеннән үзе туа җыр. – Казан "Раннур", 2002.

Булатова К. Әрнү. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.

Булатова К. Яшел каләм. – Казан: " Рухият", 2003.

## Р. МИҢНУЛЛИННЫҢ БАЛАЛАР ӨЧЕН ЯЗЫЛГАН ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ ТЕЛ-СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ

*Әхмәтшина Ильвина,*

*Түбән Кама шәһәренең Б.Урманче исемендәге*

*2 нче гимназиянең XI сыйныф укучысы*

*Фәнни җитәкче: Шәймөхәммәтова Фәнзилә Мирзанур кызы*

Сүзләр гаҗәеп серле дә, четерекле дә. Сүз – кешелекнең яшәү шарты булган телнең төп берәмлеге. Ләкин хәзерге көнгә кадәр сүзгә төгәл генә, тулы гына билгеләмә бирелмәгән. Шуңа күрә аларны тикшерү хәзерге вакытта да әһәмиятен югалтмый. Моның өчен без шагыйрь Роберт Миннуллинның балалар өчен язылып, төрле елларда басылган "Күчтәнәч", "Дөньяда иң зур алма", "Акбай цирк карый", "Җәйнең яшел аты" һ.б. китапларындагы шигырьләрдә тел-сурәтләү чараларын тикшерергә булдык.

Татар әдәбияты дәресләрендә Р.Миңнуллинның иҗатын өйрәнгәндә, әсәрләрне тел-сурәтләү чаралары ягыннан тикшергәндә, татар теле дәресләрендә лексикология бүлеген үзләштергәндә һәм кабатлаганда, бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләрендә кулланыла.

Троплар яки ассоциатив сурәтләү чаралары, – дип күчерелмә мәгънәне төрле әйберләр, күренешләр, предметлар арасындагы бәйләнеш аша барлыкка китерә торган гыйбарәләргә әйтәләр. Алар әдәбиятта образ тудыру, текстның тәэсир көчен арттыру, сурәтләнә торган күренеш-халәтне укучы күз алдына төгәл китереп бастыру өчен хезмәт итәләр" [Заһидуллина 2005: 92]. Галимә Д.Ф.Заһидуллина тропларга чагыштыруларны, эпитетларны, метафораларны, фразеологизмнарны, гипербола, оксюмороннарны, юмор һәм иронияне кертә. Без әлеге тропларны Р.Миңнуллин шигырьләрендә бирелешен өйрәндек.

"Чагыштыру – нинди дә булса күренешне башка күренешкә охшату ярдәмендә барлыкка килгән сурәтләү чарасы. Чагыштыру *-дай /- дәй,-рак / -рәк, -ча / -чә* аффикслары; *кебек, шикелле, төсле* бәйлекләре; *дәрәҗә, рәвеш* кебек бәйлек роленд килгән сүзләр; *бул, ит* кебек ярдәмче фигыльләр; *гүя, әйтерсең лә* һ.б. теркәгечләр; *ничек, шулай* формасындагы мөнәсәбәтле сүзләр һ.б. ярдәмендә ясалалар" [Заһидуллина 2005 : 92].

Мәсәлән: шагыйрьнең "Мактанырга яратмый...", "Минем таныш автобусым", "Мөгезсез бозау", "Бутаган", "Әни эштән кайтканчы" һ.б. шигырьләрен күз салыйк:

1) ***Җилдәй җитез,***

Йөртә бик тиз
Минем таныш
Автобусым –
Ул бит минем
Авто-дусым! ( “Минем таныш автобусым”)
2) ***Чын баһадир кебек*** мин,
***Чын матадор кебек*** мин!   (“Мөгезсез бозау”)
3) ***Савыт-сабалар*** өстәлгә
***Таудай өелсен*** әле.
Чиста савытларны күреп
Әни...сөенсен әле! (“Әни эштән кайтканчы”)

Мисаллардан күренгәнчә, бу чагыштырулар күренешкә предметлылык, җанлылык бирәләр. Эмоциональлелек өстиләр. Беренче,  икенче мисалларда - мактану , өченчесендә - гаҗәпләнү, хисләре чагыштырулар ярдәмендә калкурак итеп бирелә. Шигырьләр балалар өчен иҗат ителгән, ә алар бар нәрсәне дә чагыштырырга ярараталар. Димәк, чагыштырулар куллану шагыйрьнең балалар психологиясен яхшы белүен, тормышны алар күзлегеннән бәяли алуын күрсәтә. Бу исә әдипнең уңышы турында сөйли.

“Эпитет – әдәби ачыклау ярдәмендә образ тудыручы сурәтләү чарасы. Ачыклаучы сүз әйбер яки күренешнең тотырыклы, төп сыйфатын белдереп килсә, эпитет-бизәк хасил була. Әгәр ачыклаучы сүз очраклы, нәкъ менә конкрет сурәт өчен әһәмиятле булган сыйфатны белдереп килсә, характерлаучы яки индивидуаль эпитет ясала” [Заһидуллина 2005 : 94].

“Елның дүрт төсе” шигырендә  Р.Миңнуллин ел фасылларының матурлыгын ***ак*** (кыш), ***зәңгәр*** (яз), ***яшел*** (җәй), ***сары*** (көз) эпитетлары аша бирә.

“Әйберләрнең һәм күренешләрнең күләмен, санын реаль чынбарлыктагыдан зурайтып, күбәйтеп күрсәтү гипербола  дип атала” [Хаков 1999: 73 ]. Әдәби әсәрләрдә ул күренешне, характерны, ситуацияне гадәттән тыш күпертеп, сурәтнең тәэсир көчен арттыра. “Беренчегә” шигырендә Алмаз беренче тапкыр беренче класска укырга бара. Бу көнне ул, әлбәттә, зур түземсезлек белән көтеп ала. Әнә бит китапларын, дәфтәрләрен көнгә ***мең*** таратып, ***мең*** җыя; өр-яңа портфелен дә кулына ***мең*** кат ала; өр-яңа киемнәрен дә ***мең*** кат киеп каралта. Алмазның укучы булырга җыенуын шагыйрь чамадан тыш арттыра, күпертә. Без дә малайның мәктәпкә әзерләнүен елмаеп күзәтәбез. Автор, шулай итеп, ***мең*** саны ярдәмендә геперболa барлыкка китерә.

Р.Миңнуллинның шигырьләрендә тел-сурәтләү чараларыннан чагыштыруларны, эпитетларны метафораларны, фразеологизмнарны, гипербола, оксюмороннарны, юмор һәм иронияне өйрәндек. Эзләнү-тикшеренүләрдән соң түбәндәге нәтиҗәгә киленде:

1 Р.Миңнуллин – сүз уйнату остасы. Шагыйрь юктан да кызык таба кебек. Юктан түгел – сүздән таба, безне дә сүз эчендәге хикмәтне табарга өйрәтә.

2 Р.Миңнуллин шигырьләрен юмордан башка күз алдына китереп булмый. Шагыйрь җиңелчә шаярта, якын, шаян мөнәсәбәт белдерә. Аның

шигырьләрен укыгач, ирексездән елмаясың. Р. Миңнуллинның балалар шагыйре буларак осталыгы сүз сөрешен яки вакыйгаларны бер дә көтелмәгәнчә тәмамлавында, моның көлкеле хәл - әхвәл барлыкка китерүендә. Шул рәвешле, ул шигырьнең финалын аеруча нечкәләп эшли. Әсәрдәге барлык сүз сөреше кинәт бөтенләй яңа ягы белән ачылып китә. Фразеологизмнар һәм оксюмороннар да юмор тудыруга хезмәт итәләр.

3 Р.Миңнуллин иҗатында чагыштырулар, эпитетлар һәм гади метафоралар еш кулланылган. Өйрәнүләрдән күренгәнчә, бу троплар күренешкә предметлылык, җанлылык бирәләр, эмоциональлелек өстиләр.

4 Р.Миңнуллинның популярлык сере – балалар белән уртак сыйфатларында – ихласлылык, тапкырлык, шаянлыкта. Моңа ул тел-сурәтләү чараларын дөрес һәм урынлы куллану нәтиҗәсендә ирешә.

Әдәбият

Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма./ Д.Ф.Заһидуллина, М.И.Ибраһимов, В.Р.Әминева. – Казан: Мәгариф, 2005 – 99 б.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле (стилистика) – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 154 б.

## ЮНЫС ӘМИНОВ ИҖАТЫНДА ЮГАРЫ ӘХЛАКЫЙ КЫЙММӘТЛӘР

*Байбулатова Эльвира,*
*Яр Чаллы шәһәре 7 нче урта мәктәбенең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Шәйхетдинова Гүзәлия Заһит кызы*

“Юныс Әминов... Тамашачыга үзе еш күренеп йөрергә, премьералардан соң чыгып залга баш иярга бик үк яратмый торган, артык тыйнак, хәтта артык оялчан, сабыр кеше. Шуңа да карамастан, күп меңләгән укучыга һәм тамашачыга яхшы таныш язучы. Татар театрларының барысында да, шул исәптән Г.Камал исемендәге үзәк сәхнәдә пьесалары уйнала торган, үзешчән артистлар өчен иң якыннардан берсе булган драматург. Егермедән артык пьеса авторы...” [Вәлиев 2004: 90].

Әдәбиятта үз сукмагын һәркем үзенчә эзли һәм үзенчә таба. Иҗат мәйданына урау-урау юллардан килүчеләр дә бар. Юныс Әминов әллә ни катлаулы язмышлы шәхес түгел, ул әдәбиятка Юныс Әминов пьесалары белән килеп керә. Аның 50 нче елларда, хәтта 60 нчы елларда язган әсәрләренең иҗат ителү урыны дип Барҗы авылы күрсәтелә. Монда автор озак еллар укытучылык итә. Димәк, Юныс Әминов әдәбиятка укыту аша, ягъни әдәбияттан килгән дип әйтергә тулы нигез бар шикелле. Авторның беренче әсәрләре дә моны раслый кебек: аларда сюжет йомшаклыгы да, конфликт схемачылыгы да, образлар сайлыгы да юк түгел. Ләкин аларда, хәтта кече күләмле пьесаларда һәм иң

беренче скетчларда ук бер әйбер мондый кимчелекләрне каплап тора: тормыш дөреслегенә омтылыш зур, тормышчан җирлек көчле.

Юныс Әминов язганнарның барысы да дип әйтерлек сәхнәдә уйнала. Дөрес, егермедән артык пьеса арасында профессиональ сәхнәдә куелмаган бары тик үзешчәннәр репертуарына гына кергәннәре дә бар. Бигрәк тә авторның кечкенә күләмле әсәрләре. Ләкин әле бу һич тә андый пьесаларның әһәмияте аз дигән сүз түгел. Алар жанр таләпләренә җавап бирерлек, сәнгатьчә эшләнеш җәһәтеннән җитешле әсәрләр. Кеше характерын ямьсезли торган саранлык, ялкаулык, физик эшне сөймәү кебек кимчелекләрне ышандырырлык һәм көлкеле ситуацияләр ярдәмендә күрсәтеп биргән “Тикшерү”, “Латыйфа”, “Саран малы саранның үзен ашый” һ.б. комедияләре – шундыйлардан. Болар нигездә илленче елларда иҗат ителгәннәр.

Алда әйтелгәнчә, драматургның беренче зур күләмле әсәре 1947 елда языла башлап та, камилләшкәннән камилләшә барып, “Яктыдан-яктыга” дигән баштагы исемен җуеп һәм икенче исем алып, ун елдан соң гына дөнья күрә. Бу – сәхнәләрдә соңыннан еш уйналган “Тамырлар” сатирик комедиясе. Автор сәхнә сәнгатенең үзенчәлекләрен төшенүгә шушы әсәр аша килә, “Тамырлар” – аның өйрәнү, тәҗрибә туплау мәктәбе.

Шулай да, авторга беренче зур уңышны алып килгән әсәр – “Язылмаган законнар” драмасы. Минзәлә театрының 1957 елда Мәскәүдә уздырылган татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнашып, югары бәя алган. “Язылмаган законнар”да Юныс Әминов каләменең көчле яклары, аның драматургия кануннарын аңлавы чагылган.

Юныс Әминов – гаилә ныклыгын һәм туганлык җепләренең сафлыгын һәм ныклыгын барлыкка китерүче сыйфат һәм нормаларга төп игътибарын юнәлткән драматург. Аның сәхнә әдәбиятына алып килгән яңалыгы да, бу юлда куйган хезмәте дә, барыннан да бигрәк, менә шуның белән билгеләнә [Вәлиев 2004: 92].

Илленче елларда ук ачыкланган бу иҗат юнәлешенә Юныс Әминов гомере буе тугрылык саклап килә. Мораль-этика мәсьәләләрен сәнгатьле хәл итүдә ул аерата эзлеклелек күрсәтә.

Кешенең гаиләдә үз урынын дөрес билгеләве аның җәмгыятьтәге үз урынын табуына да тиешле тәэсир ясый, ди драматург. Ягъни әхлак кагыйдәләренә тугрылык саклаганда гына кеше җәмгыятьнең дә файдалы булып җитешә. Әхлак нормалары яшәү принциплары белән берлектә генә тулы була ала, алар бер-берсе белән органик берлектә яшиләр. Безнең җәмгыятебез кешелекнең үсешен тәэмин иткән иң алдыгы мораль-этика законнарына нигезләнгән булырга тиеш. Шунда гына ул чын гуманлы һәм шәхес чәчәк атар өчен бөтен шартларны тудыра торган җәмгыять булачак. Ләкин бу нормалар үзлегеннән урнашмый һәм яшәми, алар өчен көрәшергә дә аларны якларга да кирәк. Кимчелекләргә килешмәүчән булырга, аларга карата тыелгысыз үчле булырга кирәк. Юныс Әминов иҗаты, тулаем алганда, менә шундый көрәшкә өндәүче иҗат. Кимчелекләрне фаш итәргә, тамырлары үткәнгә барып тоташкан,

шулардан тукланып алга үсүче яңалыкны, матурлыкны күрә белергә һәм яклый белергә чакыручы иҗат.

Юныс Әминов иҗатында җәмгыятьтә үз урынын эзләүче, аны табарга тиеш һәм мәҗбүр булган, шунда гына үз шәхси бәхетен дә тулы татыган, кимчелекләреннән арына барган шәхескә җитди игътибар бирелә. “Өти балак” (1968) комедиясендә үзәк персонаж Гөлүсә “йоклап” һәм “үчләшеп” яшәү авыруыннан акрынлап котыла. Монда аңа иң шифалы дару ролен физик хезмәт үти. Шәхеснең үз-үзен табуы, аякка басуы, формалашуы процессы тамашачы күз алдында уза.

Шәхеснең җитлегүе, хезмәтне тану аша үз эчтәлеген табуга килү темасы Юныс Әминов әсәрләрендә чагылыш таба. Моны “Кошның үз канаты була” (1967) музыкаль комедиясендә дә, “Уҗым бозавы” (1968) комедиясендә дә, “Минем җинаятем” (1971) һәм “Кан кардәшләре” (1974) драмаларында да очратырга мөмкин. Бигрәк тә “Гөлҗәннәтнең җәннәте” (1972) психологик драмасында тема тулы яктыртыла.

Бу – Юныс Әминов иҗатының бер юнәлеше, фаш итүче юнәлеш. Юныс Әминов драматургиясенең өчтән ике өлеше комедиядән тора, көлүдән һәм фаш итүдән гыйбарәт.

Әдәбият

Әминов Ю.Ш. Гөлҗәннәтнең җәннәте. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. – 262 б.

Әминов Ю.Ш. Драмалар, комедияләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 384 б.

Валиев М.Х. Тормыш дулкыннары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – Б. 89-96.

## ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

*Бакунова Эмилия,*
*Пермь крае, Бардым районы,*
*Каенавыл урта мәктәбенең IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Чурмаева Гөлшат Ясәви кызы*

Безнең татар халкы борынгыдан ук инде җырга бай. Шатлыгын да, сагышын да җыр аша белдерә ул. Татар халкы моңнан яралгандыр, ахрысы. Шулай булмаса, халкыбызның “Кара урман”, “Шахта”, “Гөлҗамал”, “Тәфтиләү”, “Әллүки”, “Зиләйлүк”ләре булмас иде. Әйтерсең, халык җырларында бөтен үткән фаҗигале татар халкының күңелен нечкәртеп, җанына рәхәтлек бирүче аһәң булып яңгырый, аның йөрәгенә барып җитә дә күңелендәге изге хисләрне уята, тетрәндерә.

Халык җырлары бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле мирастыр. Халык җырларына зур әһәмият бирергә кирәк. Аларны кадерләргә, югалтмаска, буыннан буынга тапшырырга кирәк. Халык җыры, халык көе – ул,

халык авазы, халык тойгысы һәм фикеренең турыдан-туры чагылышы, аның музыкаль теле.

Кеше, үзенең көндәлек тормышында, сагыш, кайгыдан арынасы, яки, киресенчә, эченә сыймаган шатлыгын, куанычын белдерәсе килсә, җырлап җибәрә. Күптән ишетелгән, күңелендә сакланган, үзенең хис-тойгыларына туры килә торган көйне суза.

Җыр туа, җыр яши, җырлаучысы булганда, җыр мәңге яши. Җыр– яшәү чарасы. Җыр – ул халыкның җаны. Үзенең теле булмаган халык булмаган кебек, үзенең җыры, музыкасы һәм музыка уен-кораллары булмаган халык та дөньяда юк.

Кешенең туганнан алып бөтен гомере җыр һәм музыка белән тыгыз бәйләнештә уза. Ул иң элек бишек җыры тыңлап үсә. Соңрак кеше тормышында уен, хезмәт һәм көнкүреш җырлары киңрәк урын алып бара.

Җыр – ул рухлану, җыр – ул матурлыкка соклану. Җыр – кешенең юлдашы. “Җырсыз кеше – канатсыз кош” – ди халык.

Җыр – кешенең балачагыннан алып соңгы гомеренә кадәр аерылмас юлдашы. Җыр яраткан кеше матурлыкны ярата. Ул нечкә күңелле, мәрхәмәтле була. Ә нечкә күңелле, матурлыкны яраткан кеше беркайчан да начарлык эшләми. Ул кешеләрне ярата, чит җирләрдә яшәгәндә дә туган ягын сагынып яши, йомшак бәгырьле кешеләргә ярдәмчел, мәрхәмәтле була.

Халык җырларын, халыкның милли көйләрен, уен җырларын бөтен нечкәлекләре белән оста һәм матур итеп башкару – ул үзе бер сәнгать. Халкыбызның уен җырлары элек бик киң таралган булган. Картәнием сөйләгәннәреннән чыгып, мин шуны беләм: кич белән болыннарда, авылның елга буйларында, клубларда “Наза” уены, түгәрәкле җырлы уеннар, кара-каршы җырлап уйный торган уеннар, “Йөзек салыш”, “Йолдыз санау” һ.б. уеннар киң таралган булган. Заманалар үзгәрү белән бу җырлар, уеннар акрынлап онытылып баралар.

«Халык иҗатын белми торып, хезмәт халкының чын тарихын белеп булмый», – дигән бөек рус язучысы М.Горький.

Үз халкыңның улы яки кызы булу өчен аның гореф-гадәтләрен, җыр-моңнарын, әкият-дастаннарын, күп гасырлы тарихын, әхлак, тәрбия тәртипләрен ана сөте белән сендереп үсү кирәк. “Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән кермәс” – дип халык юкка гына әйтми.

Музыка – хисләр теле ул. Күп кенә тикшерүче музыка белгечләре татар халык җырлары репертуарын өч төргә: озын көй, кыска көй, катнаш көйләрнең элементлары катнашуында туа. Мәсәлән, “Салкын чишмә”, “Сибелә чәчәк” һ.б.

Халык җырлары балалар күңелендә кече яшьтән үк тирән эз калдыра. Татар халкының сөекле шагыйре Г.Тукайның бөтен биографиясе моның ачык мисалы булып тора. Шагыйрь бала чактан ук халык җырларын бик ярата. Аларны бөтен нечкәлекләре белән аңлап сабый күңеленә сеңдерә, үзе дә җырларга ярата. Ул истәлекләрендә алты яшеннән үк халык җырларын башкаруын әйтә. Халык җырлары моңлы һәм озын көй булуларына карамастан,

аларда халыкның шат күңеллеге тормышка гашыйк булулары, дәртле омтылышлары яңгырый.

Җыр – татар халкының иң таралган, иң хөрмәтле иҗат җимеше. Җыр – бер-берсенә тыгыз бәйләнгән ике өлештән – көйдән һәм поэтик сүзләрдән тора. Җыр сөйләр өчен түгел, ә көйләр өчен чыгарыла. Әгәр халыкның моңлы, аһәңле матур көйләре аның тиңдәшсез һәм оста композитор булуы турында сөйләсәләр, шул көйләрнең нәфис сүзләре аның акыллы һәм талантлы шагыйрь булуын раслый.

Татар халкының җыр хәзинәсе үзенә күрә бер тарих ул. Анда без ерак гасырлар тавышын да, бүгенге көннәр аһәңен дә ишетәбез. Җыр безгә яшәргә көч бирә.

Әдәбият

Бишек җырлары. – Казан: “Мәгариф” нәшр., 1993

Зарипова Ф. Бала бишеге – гомер ишеге. – Яр Чалы: “Идел-йорт” нәшр., 2000.

Закирова К.В. Иң матур сүз / Хрестоматия. – Казан: “Мәгариф” нәшр., 2000.

## ЗЕМФИРА МУЛЛАГАЛИЕВА ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ ТӨСЛӘР

*Бибакова Илмира,*
*Стәрлетамак шәһәре 3 нче гимназиянең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Габбасова Гөлназ Зиләвир кызы*

Башкортстан татар әдәбиятында Земфира Муллагалиева иҗаты аерым урын алып тора. Аның исеме республикабызда күпләргә билгеле. Талантлы шагыйрә Башкортстанның һәм Рәсәйнең Язучылар союзы әгъзасы. Тумышы белән ул Әлшәй районыннан, хәзерге вакытта Стәрлетамак шәһәрендә яши һәм иҗат итә. Иҗади уңышлары, шәһәрнең мәдәнияте һәм сәнгате өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре өчен Башкортстанның күренекле язучысы Гали Ибраһимов исемендәге премиягә лаек.

Земфира Мөхәррәм кызы – тормышка гашыйк, сәләте ташып торган, шигъри җанлы, нечкә күңелле шагыйрә. Аның шигырьләре туган авылга, балачакка, туган халкына, гомумән, кешеләргә карата мәхәббәт хисләре белән сугарылган. Мондый хис-кичерешләрне сурәтләүдә автор телебезнең төрле мөмкинлекләреннән оста файдалана. Мәкаләбездә шуларның кайберләренә тукталып үтәбез.

Татар әдәбиятында төсләр белән сурәт ясамаган автор юк. Бигрәк тә поэзиядә төсләр куллану зур әһәмияткә ия. Земфира Муллагалиева кулланган эпитетларга килгәндә, ул дөнья гамен төсләр белән күрсәтә белгән шагыйрә дип әйтергә мөмкин. Чөнки сүздән сурәт ясауда телдәге төсләр символикасына нигезләнеп, ул предмет һәм күренешләрнең төсен белдерә торган сыйфатламаларны күп кулланып кына калмый, төсле сурәтләрнең тагы да яңарак төсмерләрен дә эзли. Шунысын да әйтергә кирәк: З. Муллагалиева бер

шигырь текстында гына да берничә төс белдерә торган эпитетны куллана. Мондый очракларны кайбер мисалларда карап үтик:

*Кояш баткан чакта китә икән*
*Яшел поезд - яшел көннәрем.*
Сары вокзал бигрәк моңсу икән, -
Моңсу икән синең күзләрең!
Хушлашырга, диеп, Кояш белән,
Ак болытлар килгән офыкка.
Әйтеләсе бер сүз әйтелмәгән,
Тынып калган күктә болытлар.
Яшел поезд менә китеп бара,
Күздә кала яшел дым-томан.
Сары вокзал, үтеп китеп торган
Җәйдән калган сары көз сыман. (Сары вокзал)

Күрүебезчә, өзектәге эпитетларны шагыйрә әйбернең төсен белдерү өчен түгел, ә лирик геройның халәтен төгәлрәк күрсәтеп бирү өчен кулланган.

Көйгә салынган “Ак кар” шигырендә дә төс белдерә торган эпитетлар янәшә кулланылган:

Аклыгы тәүге карның,
Сафлыгы тәүге карның.
Син генә, дип, бу дөньяда,
Ак кардан атлап бардым.
Кар күмгән юлларга карап
Инде күзләрем талды.
Күңелемә кара төшсә,
Ак кардан аклык алдым. (Ак кар)

Биредә дә эпитетлар табигать тасвирын тулырак күз алдына китерү өчен файдаланылган. Шигърияттә, белгәнебезчә, ак төскә дан җырлана. Ак эпитеты, шигырьләрдән күренгәнчә, З. Муллагалиева шигъриятенә дә ят түгел.

Бүгенге көн шагыйрьләре яратып куллана торган “зәңгәр” эпитетына килгәндә, ул Земфира Муллагалиева иҗатында шактый очрый һәм янәшә килгән сүз белән берлектә сүз-сурәт ясый.

Айның тулган мөлдерәмә чагы,
мөлдерәмә зәңгәр күк йөзе.
Айга әллә гашыйк булганнармы,
гашыйк булган мәллә ай үзе?!
Айның тулган чагы – мөлдерәмә,
Мөлдерәмә зәңгәр чишмәләр.
Бер моңлысы, әнә, җырлап килә,
Хыялланган мәллә, дисеннәр...

Монда зәңгәр төс сафлык белән бәйле. Земфира Муллагалиева шигырьләрендә сары эпитеты, нигездә, сагыш төсен белдерә һәм *сагыш, көз, моң* сүзләре белән бәйләнешкә керә:

*__Сары вокзал бигрәк моңсу икән, –__*
*__Моңсу икән синең күзләрең!__*

Шул рәвешле, Земфира Муллагалиева предмет һәм күренешләрнең төсен белдерә торган сыйфатламаларны үзенең иҗатында бик яратып, мулдан кулланып, шигъри образлар тудыруга ирешә.


Әдәбият

Курбатов Х.Р. Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 354 б.

Муллагалиева З. Кыйблаларым. – Стәрлетамак, 2010. – 259 б.


## ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ИҖАТЫНДА АГАЧЛАРНЫҢ РОЛЕ


*Бухарова Ирина,*
*КФУның Алабуга институты студенты*
*Фәнни җитәкче: Хәйруллина Әлфирә Сәлихҗан кызы*


Төрле культураларда күп кенә агачлар изге һәм магик итеп саналган. Шуңа күрә аларга зур әһәмият биргәннәр. Юкка гына язучылар да хис-кичерешләрне, яисә берәр төсмерне күрсәтергә агачларга таянганнар. Гадәттә каен зәгыйфьлекне, чибәрлекне һәм хәтта ялгызлыкны тасвирлый. Имән агачын күзаллаганда гыйлемлелек ассоциацияләнә. Татар әдәбиятында боларга мисаллар байтак күрергә мөмкин.

Галимҗан Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр” романында карт имән хәтта ике функция башкара. Беренчедән, ул ике гашыйк Зыя белән Мәрьям өчен арадашчы ролен үти. Алар бер-берсенә язган хатларын карт имәннең куышлыгында калдыралар. “Язып тәмам итте дә, мөмкин кадәр белдермәскә тырышып, аны теге карт имәнгә кыстырып керде” [Шамов 1975: 231]. Икенчедән, карт имән үзе нидер халыкка җиткерергә тели: “Инде кабер өстендәге карт имән төн җиле белән шауларга тотына... Ул кемнедер шелтәли, ни нәрсә хакында... дәһернең кызганычсызлыгы тугрысындадыр...” [Шунда ук : 318].

Закир Һадиның “Бәхетсез кыз” әсәрендә агач кыз тормышының өзелү мизгелендә катнаша: “...дөньяда тормактан өмиде киселде, урманга барып, Кирелмар елгасы буенда бер агачка асылды” [Гайнуллин 1957: 92]. Ә Марсель Галиевның “Нигез”ендә киресенчә тормыш кайнаганы, агачның үз гомер агышы бар: “Өянкенең дә бала чагы, үткәне була” [Галиев 1996: 4].

Иҗатларында агачларга зур мәгънә бирүчеләр – шагыйрьләр. Алар үз хис-тойгыларын табигатькә мөрә, алмагҗәгать итеп белдерә. Мисал итеп, Рәдиф Гаташ шигырьләрендә каен, тал, кипарис кебек агачларны күзаллый, алар белән әңгәмә кора, чагыштыра. Ул агач атамаларын кулланып, кызларның уңай сыйфатларын, тагын да азсызыклый төшә: “***Каеннарны*** кочаклап үп,

***Талларны*** сөй” [Гаташ 1978 :44]. Бу очракта шагыйрь гади генә итеп каен, тал, − дип язса, икенче шигырендә төз, ак каеннар, кызыл таллар, − дип

күрсәтә. “***Төз, ак каеннар, кызыл таллар***,/Төньяк һәм көньяк бергә кушылганнар” [Шунда ук : 50].

Шагыйрь буларак әдәбиятка 60 нчы елларда килеп кергән һәм шуннан соң бер-бер артлы берничә шигырь китабы бастырып чыгарган шагыйрь − Фәнис Яруллин. Аның шигырьләре гади сүзләр, җөмләләр, строфалар аша укучы күңелен били алды. Аларда якты хисләр, пакь уйлар, саф мәхәббәт чиксез. Шагыйрьнең шигырьләрендә дә агачлар атамалары күп икәненә инанырга була: “Гөлләр сиңа сокланынсыннар,/ ***Алмагачлар*** көнләшсен.” [Яруллин 1988: 91]. Фәнис Яруллин өчен һәрбер агач әңгәмәдәш һәм алар җөмләдә эндәш сүз булып киләләр: “Әй ***имәннәр, имәннәр***!/ Сезгә быел ни булган?/ Әйтерсең лә һәммәгез,/ Үле суда коенган” [Шунда ук: 122]. “***Ак каеннар*** селкенергә куркып торасыз,/ Яңа кием киеп чыккан бала кебек.” [Шунда ук: 174]. “Ян бакчада карт ***нарат***,/ Ботаклары ап-ак кар” [Шунда ук: 188]. Шагыйрь татар халкына хас сыйфатларны нарат атамасына сала. Татар халкының нинди генә авырлыкларга очрамаса да, яшәүгә омтылышны югалтмавын күрсәтә.

Ильдар Юзеевта агач атамаларының күпләп очравы, аның туып-үскән табигатьнең матурлыгы белән аңлатырга мөмкин булыр иде. Ул табигатькә гашыйк шагыйрь. Шигырьләрендә иң күп очраган агач атамасы – каен. Бу турыда Ильдар Юзеев үзе болай дип яза: “***Каеннар***” ны мин телим!/ “***Каеннар***” ны!/ Андый җыр бездә юк! Дисез?/ Табыгыз! Мә − мең булсын!/ Ул җыр булмаса, башкасын./ Но... Безнеңчә моң булсын,/ Барыбер ***каен*** булсын” [Юзеев 2002: 32]. Шагыйрь хәтта үзен дә каен итеп күрсәтә: “Мин бер яфрак ярган/ Әнкәй дигән ***каеннан***,/ Язмышым тик изгелектән,/ Ак нурлардан коелган” [Шунда ук : 84].

Димәк, агачны гади генә бер үсемлек итеп карарга кирәк түгел. Ул татар халкының тормышын күрсәтү “коралы”. Аны язучы ни дәрәҗәдә куллануга карап, әсәр шул кадәр баерык, мавыктыргыч һәм нәфисрәк була. Моны аңлар өчен, әсәргә зур игътибар бирү зарури.

Әдәбият

Галиев М. Нигез/ Родной очаг. Повести и рассказы (на татарском языке). – Казань: Тат.книгоиздат., 1996. – 368 с.

Гаташ Р. Ирләр булыйк. − Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. −281 б.

Гайнуллин М. Закир Һади сайланма әсәрләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1957. – 186 б.

Шамов А.Ш., Гобәйдуллин Х.Я. Галимҗан Ибраһимов әсәрләр: 8 томда.− Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – Т.2. – 478 б.

Юзеев И. Сайланма әсәрләр. − Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Т.5. − 383 б.

Яруллин Ф. Тозлы тамчы. − Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. − 351 б.

# БҮГЕНГЕ КӨНДӘ ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘТҮДӘ БУЛГАН ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘР, ЯШЬ БУЫНДА МИЛЛӘТАРА ДУСЛЫК ТӘРБИЯЛӘҮ

*Васильева Регина,*
*Мамадыш политехник көллияте студенты,*
*Фәнни җитәкче: Ахметшина Айгөл Дамир кызы*

Туган тел! Һәркем өчен иң газиз сүз бу. Чөнки, иң кадерле, бернәрсә белән дә алыштыргысыз “Әни”, “Әти”, “Әби”, “Бабай” сүзләрен без туган телдә әйтәбез. Туган-үскән илнең якынлыгы, Ватанның газизлеген тоярга да безгә әнә шул туган тел ярдәм итә. Кеше доньяга беренче аваз салуга, аны тудырган ана үзенең сабыена туган телендә «балам» дип дәшә. Баланың беренче әйткән сүзедә, туган телендә яңгырый. Бөек шагыйребез Габдулла Тукай юкка гына үзенең иң кадерле кешеләре әти-әниләренә рәхмәт сүзләрен, Ходай рухына багышлаган догаларын – туган телендә белдермәгән.

Тел – халыкның кадерле хәзинәсе. Ул бу телдә уйлый, сөйли, яза. Кешенең бөтен аңлы тормышы аның туган теле аша уза.

Тел – халыкның, милләтнең иң беренче, иң әһәмиятле билгесе. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телеңне кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү һәр кешенең изге бурычы.

Яшь буынны мәгърифәтле итү процессында тәрбиягә өстенлек бирү Россия педагогик традициясенең үзенчәлеге.Татар теле үзенең үсеш дәверендә төрле кыенлыкларны, киртәләрне үтте. Халык күпме изелсә дә, ана телен саклап калды. Милләтнең саклануы турыдан-туры телгә бәйле. Чөнки гыйлем алу, аңны үстерү, доньяны танып белү һәм аралашу – туган тел аша тормышка ашырыла. Тел бетсә, милләт бетә, халык бетә. Безнең телебез – бик моңлы тел. Матур итеп сөйләшә белгән кеше, матур итеп уйлый белә, матур итеп уйлый белгән кеше – матур эшләргә омтыла.

Телнең нечкәлекләрен белү өчен, аны һәрвакыт куллану кирәк. Күңел байлылыгы җанга телебез аша туплана. Әгәр син үз телеңне белмисең икән, үз халкыңның мәдәниятен, аның рухи байлыгын үзләштерә алмыйсың. Күп акыл ияләре, галимнәр, язучылар тел турында төрле фикерләр әйтеп калдырганнар. Мисал өчен, рус язучысы К.Г.Паустовский болай дигән: “Үз илеңә булган мәхәббәтне, үз телеңә булган мәхәббәттән башка күз алдына китереп булмый”. Татар теле – иң матур тел, иң нечкә, ягымлы, йомшак, татлы һәм туган тел! Яратыйк аны, пычратмыйк! Безнең буында саф, чиста, бөек татар телендә горурланып сөйләшсеннәр иде!

XXI гасыр шәхесен үстерүдә мәктәп һәм, билгеле булганча, тәрбия зур әһәмияткә ия. Мәшһүр татар гуманисты, мәгърифәтче Каюм Насыйри үз вакытында тәрбия – һәрнәрсәнең ачкычы аның белән хәл итеп була, ул кешене кеше итүдә иң дөрес юл – дип бик дөрес язган.

Кешелекнең иң зур байлыгын милләтләр тәшкил итә. Һәр милләт үз теле, мәдәнияте белән яшәешне бизи, баета һәм үзе дә башка халыклар белән аралашып үсә, алга китә.

Татар теле дәресләрендә мәгълүмати технологияләрне кулланунын нәтиҗәле булуы бәхәссез. Компьютер белән эшләү күрсәтмәлелекне тәэмин итүе, контрольне көчәйтүе һәм зур күләмдәге мәгълүмат җиткерүе белән укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә һәм ул, ниһаять, белем алу белән кызыксындыру чарасы булып тора.

Аралашуның, укыту алымнарының күптөрлелеге, мультимедиа, интерактив технологияләрне куллану – болар барысы да дәреснең эчтәлеген баета, аны уздыру темпын тизләтә, татар телен өйрәнүгә кызыксыну уята, активлыкны арттыра.

Укучыларда милләтара дуслык, хөрмәт, түземлелек тәрбияләүгә дәресләрдә генә ирешеп булмый, әлбәттә. Сыйныфтан тыш чараларның мөмкин булган барлык төрләрендә кулланырга тырышлык итәргә кирәк. Әйтик, әдәби – музыкаль кичәләр әзерләү, концертлар оештыру, экскурсия, очрашу кичәләре, бәйрәм, конкурс, тәрҗемә секцияләре, олимпиадалар, фестивальләрдә катнашу.

Халык авыз иҗаты - әдәби һәм тарихи мирасыбызның гүзәл бер хәзинәсе ул. Без анда бик ерак гасырлар авазын ишетәбез, безнең чор бизәкләрен дә күрәбез. Борынгы бабалырыбыз акылы, зирәклеге, моңы, җорлыгы, матур йолалар, гореф – гадәтләр тудырган. Зирәк акыллы, киң күңелле, шаян телле халкыбыз күңелендә яшәгән телгә сак караш уята, туганнарга, авылдашларга, бөтен кешеләргә хөрмәт тәрбияли.

Безнең фикер буенча, тырышлыгыбыз бушка китми. Безнең көллият укучылары һәм укытучылары бердәм һәм дус яши. Саф татар телендә матур итеп аралашучы, шәһәр һәм район күләмендә төрле милли бәйрәмнәрдә, бәйгеләрдә катнаша алучы укучыларыбыз бар безнең.

Бездә күп төрле милләт (татар, рус, удмурт, мари, төрек) балалары белем ала. Балалар үзара дус һәм тату яшиләр. Укытучыларыбыз яңа шартларда яшәргә, эшләргә, сәләтле үз телен яратучы шәхесләр тәрбияләү өчен бөтен тырышлыкларын куеп эшлиләр. Теле барның – иле бар. Телебез булса – киләчәгебез дә булыр.Туган теленә битараф кеше – кыргый. Ул үзенең табигате белән үк зыянлы. Чөнки, аның телгә карата битарафлыгы үз халкының үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә битараф булуы белән аңлатыла». Шулай ук, Туган тел турындагы фикерләребезне шагыйрь Искәндәр Гыйләҗев сүзләре белән йомгаклыйсы килә:

Ул булганда адашмабыз-<br>
Юлым туры, нурлы көнем.<br>
Күз карасы кебек саклыйк<br>
Анам телен – Татар телен! [Гыйләҗев1993: 15].

Әдәбият

Гыйләҗев И.Өмет ае: Шигырьләр. – Казань: Татар.кит.нәшр., 1993. – 104 б.

# Ә.ЕНИКИНЕҢ “РӘШӘ”ӘСӘРЕНДӘ ТЕЛ-СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ

*Вәлиева Вилүзә,*
*Әлмәт районы, Яңа Кәшер урта мәктәбенең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Габдракипова Айгөл Ильдар кызы*

Татар халкы бик борынгы заманнардан ук үзенең барлык хис-кичерешләрен, теләк-омтылышларын матур әдәбиятның чишмә башы булган моңлы җыр, тылсымлы әкият, үткен мәкаль, илаһи бәет, серле риваятьләр аша чагылдырган. Матур әдәбият исә җәмгыять тормышының күп өлкәләрен үз эченә ала. Ул тел чараларын сайларга, әдәби тел нормаларын билгеләргә, аны эшкәртергә, ныгытырга, үстерергә ярдәм итә. Матур әдәбият әсәрләрендә тел-сурәтләү чараларын күпләп куллану әсәрнең кыйммәтен, укучының хисенә тәэсир итү көчен арттыра [Татар әдәбияты 2006].

Әмирхан Еники иҗатының мөһим бер үзенчәлеге әсәрләрнең телендә күренә. Үз алдыбызга Ә. Еникинең “Рәшә” әсәрендәге барлык тел-сурәтләү чараларын күрсәтү максатын куйганлыктан, әсәрләрне бик җентекләп, һәр сүзен бөртекләп укып чыктык һәм тикшереп анализлау яхшы нәтиҗәләрне күрсәтте.

“Рәшә” әсәре образларының яңалыгы, күтәргән темасының мөһимлеге белән генә түгел, сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсе, сюжет-композиция төзелеше, тел-сурәтләү чараларының үзенчәлекле булуы белән дә аерылып тора. Анализлау нәтиҗәсендә Ә. Еникинең “ Рәшә” әсәрендә мин берничә типтагы тел-сурәтләү чаралары таптым.

Тел хәзинәсе байлыгының 1 төре – мәгънәләре ягыннан охшаш яки якын, ә әйтелешләре ягыннан төрле булган сүзләр синонимнар була. Татар теле мәгънәдәш сүзләргә гаҗәп бай, кайбер атамаларының дистәгә якын синонимы бар. Әмирхан Еники шуларны урынлы файдалана алган, нечкә сиземли белгән, иң отышлысын сайлап ала белгән.

*Дала буш, дала тын, үзе тип-тигез һәм очсыз-кырыйсыз (283 бит); Ләкин тора бара очы-кырые күренмәгән дала аны борчый, шомландыра башлады (283 бит); Ияреп барган юлдашы да бик мәкерле, явыз булып чыкты (283 бит))[Еники 1894: 283]*

Тел хәзинәсе байлыгының 2 төре – капма-каршы мәгънәле сүзләр. Капма-каршы күренешләрне, билгеләрне янәшә куеп, Әмирхан Еники әйтәсе фикерен калкурак итеп белдерә, аны эстетик йогынтылы итә.

*Менә тиздән-тиздән ул барып җитәр, тукталып тормастан шабыр-шобыр күлгә кереп китәр, ут капкан башын суга тыгар, куш учлап якты суын, салкын суын эчәр, көлә-көлә, елый-елый эчәр...* (284 бит); *Зөфәр күпме колагын салып ятса да, аның сүзләрен аера алмады, тик ахырдан көлепме, елапмы җибәрүен генә ишетеп калды* (284 бит)

Татар әдәби телендә халыкка хас сөйләмне якын иткән әдипнең лексикасын укучыга якын һәм аңлаешлы булган фразеологизмнар, чагыштырулар, мәкаль һәм әйтемнәр, диалектизмнар, архаизмнар, алынма

сүзләр әсәр теленең сурәтлеген чагылдыра. Бик көчле стилистик чара буларак, Әмирхан Еники әсәрләрендә чагыштырулар аерым урын ала.

*Үләннәре саргаеп кипкән, кара туфрагы, чатнаган чуендай, яргаланып беткән* (283 бит); *Зөфәр аның көзге яфрак кебек калтыранган юка гәүдәсен сыңар кулы белән генә кочып алды* (286 бит); *Ә буе-сыны – гөл сабагы инде, гөл сабагы* (412 бит)

Текстта чагыштырулар төрле эпитетлар белән баетылып, эмоциональ фонны тагын да көчәйтәләр. Алар әдип иҗатына бик актив хезмәт итәләр: яшел үлән, зәңгәр төтен, аксыл сакаллары, соргылт яңаклары, ап-ак кояш , астыртын суык һ.б. Әмирхан Еникинең чагыштыруларына тагын метафоралар да якын тора: борын салындырдың, эттән алып эткә салу, тетмәсен тетү.

Лексик берәмлекләрнең көчен арттыру максатыннан, Әмирхан Еники әсәрендә гиперболалар куллана: мәңге иркәләп туймаслык назлы, сулышы утын кисәведәй кайнар. Шулай ук гиперболага капма-каршы булган литота кебек сурәтләү чараларын күрергә мөмкин: *Тик авыртулар егетләр өчен бары төкерек кенә* ))[Еники 1894: 46]

Әмирхан Еники, җырда җырланган кебек, әсәрләрен бик ачык аңлаешлы сүзләр белән хикәяли. Шул ук вакытта аның стилендә элеккерәк дәвердәге сүзләр ишетелеп китә. Ул, мәсәлән, сирәк булса да архаизмнар (кузла, үрәчә,вәкарь, гасабиланып, арык) куллана. Заманында бу сүзләр актив булганнар, ә кайберләре (михнәт, гасабиланып) яңадан сөйләмдә еш очрый башлады.

Диалектизмнар хисабына әдәби тел байый, тулылана (җәренгә, мөгәричен, әмәлләрбез, ичмасакайларым, әртичләр һ.б.). Автор алынма сүзләрне дә ирекле куллана (гарәп-фарсы алынмалары: мөгамәлә, ләбаса, фәлән, вәкарь, вәхши, рус теле аша кергән чит тел сүзләре: фляга, фронт, трамвай, фуражка, портрет, филармония, вокзал, поезд.). Рус алынмалары шундый еш күзәтелә, алар адым саен очрый. Мәсәлән: самовар, комиссия, отставной, интерес, ревизия, мороженое һ. б. Алынма сүзләр сүз уйнату, шаярту чарасы булып та килә ала.

Әмирхан Еники теленең тагын бер әһәмиятле үзенчәлеге бар, әсәрдә уңай эмоциональ, тискәре эмоциональ сүзләрне дә еш куллана: җанашым, җаныкаем, матурым, абзыкаем, очар кошым һ.б. Битараф сүзләр: авызыңа төкерим, җир йотсын, чәнчелеп киткере, томана, сатлык, шайтан алгыры)

Әмирахан Еники мирасының кыйммәте безгә калдырган хикәяләр, повесть һәм романнар саны белән генә исәпләнми. Әмирхан Еники коеп куйган язучы гына булмый. Ул тел, әдәбият, тарих мәсьәләләренә караган күп санлы мәкаләләр, фәнни хезмәтләр яза, татар мәктәпләре өчен дәреслекләр төзи.

Тел-сурәтләү чараларына килгәндә, Әмирхан Еникинең «Рәшә» повестендә без метафоралар, эпитетлар, риторик сорау, һәм башка фонетик, лексик, синтаксик тел-сурәтләү чараларын анализладык. Шулай итеп, бу тел-сурәтләү чаралары әсәрне тулыландыра, ямьләндерә. Карап үтелгән күпсанлы мисаллардан күренгәнчә, Ә.Еники сүзнең бөек көчен, тасвирлау мөмкинлекләрен тоеп, үзенә генә хас иҗат стилен тудырган, сүзнең

үзенчәлекле мәгънә төсмерләрен тоеп сурәтли бергән. Аның әсәрләре халыкчанлыгы белән аерылып тора.

Әдәбият
Еники Ә. Сайланма әсәрләр. – Казан:Татар.кит.нәшр, 1984 – 507 б.
Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле.– Казан: Мәгариф, 1994 – 405б.
Татар әдәбияты. Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2006

## БАР ХАЛЫКНЫ ТУГАН ТЕЛЕНӘ БУЛГАН МӘХӘББӘТ БЕРЛӘШТЕРӘ

*Вәлеева Лиана,*
*Алексеевск районы,Чишмә мәктәбенең XI сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Рәхмәтуллина Рәмзия Рафик кызы*

Нәрсә соң ул туган тел? Аның эчендә нинди мәгънә, нинди рухи сафлык ята? Бу сорауга һәр кешенең жавабы, фикере төрле. Ләкин шулай да бар кешене берләштерүче бер нәрсә бар: ул да булса ана теле! Туганнан алып сабый бала теле нинди телдә ачылса,шуны тоеп, аның киләчәген кайгыртып яши. Мин- татар баласы. Татар телендә телем ачылды, милләтемне, динемне, әби-бабаларымның үткәнен белеп, аңлап үсмер яшемә җиттем. Билгеле ки, татарча сөйләшү проблемасы миндә тумады, чөнки кечкенәдән шул телдә иркен аралашам, шул мохиттә яшим, аны үз итәм. Ләкин бер нәрсә бар, ни өчен татар теле хәзер югалып бара соң? Һәм шул фикерне чынга ашырырга хыялланып йөрүчеләр дә күбәеп китте? Хәзерге вакытта рус телен дә, татар телен дә - икесен дә дәүләт телләре итеп кабул иттеләр. Ни өчен телне шулай тормыш-көнкүрештән алып атып, мыскыллау дәрәҗәсенә төшерергә? Шундый хәлдә телне саклап калып буламы? Аны өйрәнү,тирәнтен белү урынына киресен эшлибез түгелме соң? Үз кулларыбыз белән барын да атып, җимереп юкка чыгару куркынычы туа. Ике телне тигез күреп, тигез эш алып барып яшәргә дә була бит ?! Шул сүзләрне чынга ашыру идеялары яшәп килсәләр дә, кызганычка каршы бүгенге көнгәчә ул һаман хыялда гына кала, үз урынын шунда гына таба. Тик ни өчен шулай? Тагын сорау артыннан иксез-чиксез сорау ява...

Һәр кешегә газиз ана, үз төбәге, туып-уйнап үскән киң дала-кырлары якын булган кебек,туган теле дә якын, кадерле булырга тиеш.Аны саклап, тирәнтен өйрәнеп яшәргә кирәк. Һаман да шул тигезсезлек хөкем сөрә. Моңа минем үз карашым. Бәлки минем белән килешмәүчеләр, кире кагучылар, сүзләремне читкә этәрүчеләр табылыр?! Тик шулай да үз фикеремне әйтәм. Бу дөньяда хәзерге вакытта кешенең ышанычы бары тик үзендә генә.

Икетеллелек бик борынгы чорларда ук барлыкка килгән. Аны төрле кабилә һәм халыкларның үзара бәйләнешкә керүләре тудырган. Икетеллелек шартларында туган телне өйрәнү буенча теләгән кеше барында эшли ала. Нәрсә

дә булса эшләр өчен бары саулык һәм теләк кенә кирәк. Әйткәнемчә, рус теле татар теленнән өстен бара. Барча халык, хәтта татары да рус телен үз итте. Хәзер бар нәрсә рус телендә. Укуы да, язуы да, инде менә ничәмә-ничә еллар буе татар телендә бирелеп килгән имтиханнар да рус телендә бирелә башлады. Бер яктан караганда бу яхшы, ә икенчедән, шул татар телен кимсетү кебегрәк кала. Ике телне дә тигезләштерү кулдан килмәслек эш түгел бит?!

Туган телне саклап калу, аны өйрәнү, тирәнтен үзләштерү өчен иң беренче чиратта, әйтелгәнчә, ике телне дә тиешенчә хөрмәт итәргә кирәк. Берсен алга, икенчесен артка куеп карау дигән нәрсә турында сүз дә булырга тиеш түгел.Ә күп очракта шундый тигезлек хөкем сөрә. Кайчанда булса (Мин моңа ышанып әйтәм!) мондый хаксызлык бетәр дип уйлыйм.

Ярар, ике телне дә беләбез ди, тагын ни кирәк соң диючеләр бардыр? Өйрәнү өчен сөйләм генә җитеп бетми икән шул. Шул өлкәдә бер-бер артлы үз эшчәнлегеңне дәвам итмәсәң,синең өчен кем килеп эшләр? Әгәр аңа алынгансың икән инде, азагынача эшләп, нәтиҗә ясa.

Телне белдек, ә нәрсә эшләргә? Нинди ысуллар белән өйрәнүне,эзләнүне башкарырга? Күп кенә галимнәр үз буынынын шәҗәрәләрен төзиләр.Кирәгенчә тырышалар, архивлар дисең ме, туган як музейлары мы, чит төбәкләргә кадәр белешмә эзләп чыгып китүчеләр бар.

Тагын шунысын әйтәсе килә: үз ана телебездә китаплар чыгару мәсьәләсе. Хәзер китап киштәләрендә бик сирәк кенә татар телендә үзенә кирәкле китапларны табып була. Әле аның өчен дә берничә җиргә керергә, эзләнергә кирәк. Ә дәреслек диюгә тәннәр калтырый башлый. Татар мәктәпләре рус телендә басылган китаплар белән укый бит! Менә шуннан башлана инде ул туган тел дигәннәре.Татар баласы татар мәктәбендә урыс телендә укыгач, нәрсә була соң ул?!

Иң беренче чиратта бала, татар баласы, үз ана телен хөрмәт итәргә тиеш. Кимсенү дигән нәрсә булырга тиеш түгел.Әгәр ирекле сөйләшсә, оялмаса, (ә бу беренче урында тора) теләге һичшиксез чынга ашачак. Мин үз телемне хөрмәт итәм, аның белән горурланам. Мин әби-бабаларыма вакытында татар телен, динне саклап калганнары өчен рәхмәтле. Шул теләккә ирешү өчен ни генә күрмәгәннәр дә, ни генә кичермәгән бит алар? Татар телендә иркен аралашуым белән горурланам. Чит төбәкләрдә яшәп тә, үз телләрен саклап калучылар бихисап бит! Моңлы татар җырларын башкарып, төрле юнәлештә иҗат итеп яшәүче ватандашларыбызга сокланасы гына кала.Ә безгә нәрсә комачаулый? Бары теләк юк, шул гына. Үз туган телеңне өйрәнү бер, ә ике телне бергә өйрәнү инде монысы башка мәсьәлә. Ләкин аерма милләттә һәм үткән буында гына түгел, шәхсән мин шулай уйлыйм. Чөнки һәр милләт башкалардан чыгып, үзенә хас булган гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре белән бик нык аерылалар. Киләчәктә дә шулай булачак. Ләкин бар халыкны туган теленә булган мәхәббәт беләштерә. Алар киләчәк өчен ни дә булса эшләп калырга, борынгыдан сакланып килгән изге йолаларны югалтмаска, ата-бабаларның һәм бүгенге көнгә кадәр яшәп килгән авылны –туган йорт нигезен саклап калу һәм

иң мөһиме телне югалтмас өчен үз өлешләрен кертергә тырышалар. Көнен-төнен, иртәләрен-кичләрен йокламыйча, кайдадыр нидер эзләнеп, нәрсәне дә булса раслау ягында тора безнең халык. Шул исәптән без – мәктәп укучылары да бу өлкәгә үзебезнең өлешебезне кертәбез. Мәктәбебездә төрле милләт балалары укый. Бер-береңә хөрмәт, ихтирам хисе яшьтән үк тәрбияләнә. Мин укыган Чишмә урта гомуми белем бирү мәктәбендә төрле бәйрәмнәр “Нәүрүз”, Сөмбелә”, “Карга боткасы”, “Каз өмәсе”, “У нас в гостях”, “Масленица» һ.б. бик күңелле рухта үткәрелә. Апрель аенда ел саен Габдулла Тукай туган көне билгеләп үтелә. Мондый эшләр алып барылганда телебез югалмаячак, яшәячәк. Татар теле – ана теле яшәвен дәвам итсен өчен, татар халкы бернидән дә шикләнмичә алга атларга тиеш!!

Әдәбият

Ахунзянов Э.М. Двуязычие и лексико-семантическая интерференция. – Казань, 1968. – 112 б.

Вәлиев Р. Белемебез ачкычы // Мәгариф, 2003. – №2. – Б. 8-10.

Вәлиева З. Теле барның – иле бар // Мәгариф, 2003. – №2. – Б. 5-6.

Миңнуллин Р. Телебез булса, киләчәгебез дә булыр // Мәгариф, 2006. №2. – Б. 7-8.

Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: «Хәтер» нәшр., 2001. – 432 б.

Таһиров И. Чигенүләр булмасын // Мәгариф, 2004.- №3. – Б.10.

Шәймиев М.Ш. Татар теле – дәүләт теле // Мәгариф, 2003. – №2. – Б. 4-5.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА АТ ОБРАЗЫ

*Вәлирахманов Дәнис,*

*Әлмәт районы Яңа Кәшер урта мәктәбенең IX сыйныф укучысы*

*Фәнни җитәкче: Валеева Гөлнара Габделәхәт кызы*

Татар әдәбиятында кешенең атка мәхәббәте, гомумән, ат образы киң таралган. Ат, колын белән күбрәк малайлар кызыксына. Кайсы авыл малае үз колынын булдыру, аны башкалар белән көтүләү, су коендыру, Сабан туенда беренче килү турында хыялланмый икән?

Ат турында язылган әсәрләрнең үзәгендә ат белән малай арасында ихлас ярату һәм атны югалту тарихы ята. Шуның аша авторлар татар кешесе өчен атның – бик якын җан иясе, ат чабыштыруның – матур гадәт булуын ассызыклыйлар, ярышның гадел булырга тиешлеген, җиңү хакына гаделсезлеккә бару ярамаганлыгын искәртәләр.

Әдәбиятта чабышкы атка мәхәббәт мотивын иң беренче “Хәнҗәр” (1914) хикәясе белән Шәйхулла Сибгатулла улы Алкин башлый. Бу әсәрдә Хәнҗәр кушаматлы колынның фаҗигале язмышы сурәтләнгән. Кыргызның киң далаларында иркенләп уйнап үскән, әнисенең иркә улын, Хәнҗәрне язмыш бердә белмәгән ерак татар авылына китереп куя. Колын татар җирлегендә

үзенең үлемен таба: Сабантуйда ярышта беренче булып килгән ат, басу капкасын чыккач, имән баганага бәрелеп үлә. Биле сынган атның үлем алдыннан булган газапларын һәм малайның кичерешләрен автор менә ничек тасвирлый: "Вилданга Хәнҗәрнең үләсен әйткәннәр иде инде. Ул үзенең газиз көчле дустын шулай мескен, гарип хәлдә күреп кызганды. Хәнҗәрне муеныннан кочаклап, башыннан сөйде. Аның матур күзләрен үпте, егълый башлады. Ул арада Хәнҗәр өстенә беренче килгән атка бирәсе яшел чапанны китереп яптылар..." Алга таба бу сюжетны үз иҗат фантазиясе аша үткәреп Г.Ибраһимов "Алмачуар" хикәясе белән дәвам иттерә һәм баета.

Галимнәр кеше атны үзенә күп мең еллар элек ияләштергән дип фараз итәләр. Шул чордан башлап ат – кешенең азык чыганагы һәм ярдәмчесе. Авыл кешесе җилкәсенә төшкән барлык авырлыкларны ат уртаклаша, шуңа кеше белән атның язмышлары да уртак. Г.Тукайның "Арба, Чана, Ат" шигырендә Ат үзенең авыр тормышыннан зарлана. Чана, Арба елның алты аен гына эшләп үткәрсәләр, "Хәл җыймыйм ел тәүлегендә, ичмасам, бер көн генә!" – ди ул [Тукай 2003].

Г.Бәшировның "Туган ягым – яшел бишек" автобиографик повестенда "Җирән кашка сагышы" дигән бүлек бар. Монда да Гомәр исемле малайның колынлы булу, аны ярату һәм югалту тарихы бирелгән. Сабан туенда ярышып, беренче килү хыялы белән яшәгән сабыйның өмет-хыялларын тормышның җитмәгәнлеге чәлпәрәмә китерә: әтисе колынны базарга алып барып сата. Әсәрдәге колын образы авыл баласының тормыш гаделсезлеге аркасында киселгән өметләре символы булып тора.

Ф.Хөснинең "Йөзек кашы" повестенда әсәр герое Айдар җир астында күмер ташып, бер көндә якты кояшны, яшел иркен болыннарны күрмәгән, караңгылыктан сукырайган атларны күреп сыкранса, А.Гыйләҗевның "Язгы кәрваннар" повесте геройлары Ибраһим, Дамир сугыш вакытында ачлыктан күтәрәм булган атларны кызгана. "Озын ялым үлмәгән икән үлүен... Дүрт җиреннән юанар каннар белән өрлеккә асылган ат мине танымады, мин аны... Ул зур күзләрен тутырып миңа карады, таныды, нәзек тавыш белән ыңгырашып сәлам бирде. ...Фураж да, солы да юк иде атларга, күгәрә башлаган салам белән торалар икән бичаралар", – ди Ибраһим. Сугышта да ат кеше белән янәшә атлый, Туган җирдән аерылу сагышын ул да кичерә.

Татар әдәбиятында тулпар яисә дөлдел образы киң таралган. Тулпар дип кыпчак мифологиясендә канатлы атны атаганнар. Ул – батырның ярдәмчесе, киңәшчесе. Алар зур түгел, ләкин батыр егетнең аны иярләве була, бик шәп чапкын аткаә верелә. Тулпарлар кайбер мифларда диңгез, кое төбеннән чыга яисә әкият герое аларны күл һәм башка сулыклар ярында тотып ала. Беркемдә, хәтта хуҗасы да, атның канатын күрергә тиеш булмаган, юкса ат үлгән. Мостай Кәримнең "Озын-озак балачак", Г.Бәшировның "Туган ягым-яшел бишек" повестьларындагы мифлардаТулпар ат бәхет символы буларак бирелсә, М.Җәлилнең "Ана бәйрәме", И.Юзеевның "Йолдыз кашка турында баллада"сында җиңү хакына гомерендә кызганмаган киң күкрәкле батыр

көрәшченең юлдашы ул. Мифларда Тулпарның тагы бер үзенчәлеген күрергә була: ул, тоягы белән тибеп, җир астыннан чишмә чыгара, атылып чыккан су чичәннәргә илһам бирә. Шуңа канатлы ат поэзия символы да булып тора. Бүгенге фән-техника заманында ат образын сурәтләгән әсәрләрне белү, өйрәнү милләтебезнең бер кисәге булган атка мәхәббәт уятуда зур роль уйный. Шәүкәт Галиевның "Ат “йөртүче” малай шигырендәге герой кебек атның “фара”сына карарга вакыт җитте.

Ат кадерен белеп үсмәгәнир машина кадерендә белә алмый. Шуңа күрә ул бер мәгънәсез “встречный полоса”га чыгып, елына кырык меңлек корбан бирә. Шушы дисгармонияне тигезләми торып, милләт бәхетсез булачак.

Әдәбият


Бәширов Г. Әсәрләр. 4 томда – Казан: Татар.кит.нәшр., 1982.

Тукай. Г.Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.


## ФӘРИТ ИМАМОВ – ЮМОРЕСКАЛАР ОСТАСЫ


*Вәлишина Алсу,*

*КФУның Алабуга институты студенты*

*Фәнни җитәкче: Хәйруллина Әлфирә Сәлихҗан кызы*


Фәрит Имамов – Мамадыш районының Катмыш авылында укытучы гаиләсендә туып үсә. 1977 нче елда урта мәктәп тәмамлаганнан соң, һич икеләнмичә, әлеге һөнәрне сайлый. 1984 нче елда Алабуга институтын тәмамлагач, Мамадыш районы Албай авылында укытучы булып эшли. Берничә елдан гаиләсе белән Түбән Камага барып урнаша. Анда да хезмәт юлын мәктәп тормышы белән бәйли. Шулай да  авыл тормышын, туган ягын сагынып кулына каләм ала һәм кызыклы гына хикәяләр яза. 1991 нче елда “Туган як” исемле татар газетасы нәшер ителә башлагач, редакциядә эшли башлый. Хәзерге вакытта чыгарылыш редакторы вазифасын башкара. Фәрит Имамов Татарстан һәм Россия журналистлар берлеге әгъзасы. Әдәби эшчәнлек белән шөгыльләнүен дәвам итә.

Әдәби әсәрне язучының тормыш-яшәеш хакындагы сүзе, тирәлеккә мөнәсәбәте дип карыйлар. Чыннан да, язучының укучыга җиткерер фикере-сүзе булмаса, әдәби әсәр языла алмый.

Фәнзаман Баттал аңа: “Төшенке күңелле һәм аптырауга-йөдәүгә калган халыкның караңгы карашын бары тик менә шушы Фәрит Имамов  кебек юморлы, сатиралы язучылар гына күтәрсә һәм яктыртса гына инде, дип тә уйлыйсың ара-тирә... Әле бит шунысы да бар: хәзерге китап яратучы, әдәбият сөюче укучыларны килде-китте генә язылган, “сукыр тавыкка бар да бодай” дип кенә  язылган, укый башлауга ук кызык булмый башлаган һәм  йокыга талдыра торган китаплар белән генә  җәлеп итү мөмкин түгел. Шул фикердән чыгып сөйләүгә калса, миңа бу автор сүренке кешеләрне дә терелтеп җибәрә торган җорлыгы, әдәби телне гади халыкның да теле белән көчәйтеп, баетып җибәрә белүе белән күптәннән таныш” – дип бәя бирә.

Әйе, нәшер ителгән һәрбер китабы күпләрнең күңелен күтәрә, елмайта, көлдерә! Чөнки, аның һәр юморескасында укучы үзен яисә таныш кешесен таный ала. Һәм бу юлы да Ф.Батталның фикере белән килешми мөмкин түгел: “Автор үзеннән дә көлә белүче зат сыман тоела. Әле кыска күләмле бу әсәрләре сәхнәләргә, радио һәм телевидениегә эләксәме?! Тыйнак кына әйткәндә дә, халыкның күңеленә яшәү дәрте бирәчәк!”

“Экологик чиста агу” юморескасында “гупчем”, “маминт”, “калын кесә”, “эш пешми” һәм тагын башка әллә никадәр сүзләр бар. Алар барысыда кеше тормышыннан алынган, шуна күрә дә укучы аны рәхәтләнеп кабул итә, җиңел аңлый. Ә менә “Без дә яшибез инде” һәм “Авыл гүзәле”ндә гап-гади тормыш ситуациясе. Хадичәнең, ахирәтенә иреннән зарлануы, эшләгән эшләре өчен дә, эшләмәгән эшләре өчен дә һаман шул “тормыш иптәше” гаепле. Хәтта иренең хезмәт хакына алынган 40 меңлек тунга акча “еле-еле” акча җиткерүләренә дә ире гаепле икән. “Авыл гүзәле”ндә, автор Галәветдинне көлке хәлендә калдыра. Ул сәхнәдәге авыл хатыннарын мактап, сокланып тора.Ә бактың исә, иң гүзәле, иң чибәре – Галәветдиннең үз хатыны икән.

Әйе, Фәрит абый көлке ясауга гына кайтарып калдырмый әсәрләрен. Көлүләр аша бу дөньяның гыйбрәт йорты булуын да еш аңлыйсың һәм тормышыбыздагы гаделсезлекләрне дә җаның белән тоясың. Шуңа күрә дә: “Көлкесе дә көлкесе! Кая соң моның төлкесе?” дияргә урын калмый. Чөнки автор әдәби әсәрләр укып мавыгучыларга кызык аша акыл да өстәлергә тиешлегенә иман китергән!

Әдәбият

Имамов Ф.Ф. Дөньяның кеме юк...: юмористик хикәяләр. – Казан: “Яз” нәшр., ТФА, 2014. – 172 б.

Имамов Ф. Югалган эзләр. Роман. – Казан: “Ихлас”, 2012. – 208 б.

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ИҖАТЫНДА МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ ПРОБЛЕМАСЫНЫҢ КУЕЛЫШЫ

*Габдинова Эльнара,*
*Пермь крае, Октябрь районы*
*Енапай урта мәктәбенең XI сыйныф укучысы.*
*Фәнни житәкче: Гафуева Дания Фәнәви кызы*

Гаяз Исхакый – татар әдәбиятына нигез салучыларның берсе , атаклы прозаик, драматург, ялкынлы публицист,журналист,җәмәгать эшлеклесе, милләтебезнең горурлыгы.Аның әсәрләре чын мәгънәсендә татар дөньясының энциклопедиясе булып тора. «Татарлар, – ди Гаяз Исхакый, – борынгы заманнан бирле уңган, акыллы, укымышлы халык, киң күңелле һәм максатка омтылучан горур табигатьле милләт. Ул, дөньяның башка халыклары кебек үк, тигез хокуклы булып дөньяга килгән һәм шул принциплар нигезендә яшәргә тиеш. Моның өчен, әлбәттә, фикердә, уйда һәм гамәлдә азатлыкка ирешергә

кирәк». «Моңа ирешү өчен язучы җавапны борынгы тамырларыбыздан, гореф-гадәтләребездән, ислам диненнән, төрки кардәшләребездән һәм тарихи хәтеребездән эзләргә чакыра. Иң асыл рухи – әхлакый кыйммәтләрнең, дөрес яшәү кануннарының ислам тәгълиматында һәм татар халкының тәрбия тәҗрибәсендә тупланган булуын искәртә.

Гаяз Исхакый әсәрләрендә гаилә тормышын, гаиләдә бала тәрбиясен, милли тәрбияне сурәтләүгә аеруча зур игътибар бирелә. Аның фикеренчә, җәмгыятьтә кешене тәрбияләүдә төп чара булып милли тәрбия, акыл, гыйлем тора.

Әдипнең беренче әдәби әсәре – «Тәгаллемдә сәгадәт». Әсәрнең төп герое - урта хәлле крестьян гаиләсендә туган авыл малае.Хәлим шәһәр мәдрәсәсендә укырга тели һәм теләгенә ирешә.Зур тырышлык куйганга күрә, ул мәдрәсәдә беренче укучы дәрәҗәсенә күтәрелә Рус, гарәп, фарсы ,төрек телләрендә сөйләшә. Ул гаиләдә дә ныклы тәрбия алган, динне, өлкәннәрне хөрмәт итә, аң – белемгә омтыла. Тырышып укый, мәдрәсәне тәмамлый. Яхшы гаиләдән чыккан тәрбияле Казан кызына өйләнеп, матур гаилә корып җибәрә һәм бәхетле тормыш кора. Өлкәннәрне хөрмәт итүе, динне зурлавы, тырышлыгы аркасында милләт хадиме булып җитешә һәм шәхси тормышында да бәхеткә ирешә.

Әсәрдә «белем алу мөселманнар өчен фарыз» дигән фикер уздырыла. Гаиләдә, тормышта бәхетле булыр өчен, аң-белемле булуның, төпле тәрбия алуның кирәклеге күрсәтелә.

Әдипнең «Бай углы» исемле әсәрендә шулай ук гаилә тәрбиясе проблемасы күтәрелгән.«Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясендә аң-белемле ата-ананың төпле тәрбиясе балага уңай тәэсир иткәнлеге сурәтләнсә, «Бай углы»нда исә, киресенчә, Фатыйх бай белән хатыны Сәгыйдә бердәнбер уллары Кәримне бозуга, һәлакәткә китерүгә төп сәбәпче булалар. Улларының бозылуында алар аның яшь хатыны – Бәдрияне гаеплиләр. Әсәрдә үзләрен «чын мөселман» дип күрсәтүче, ә чынлыкта бозыклык белән шөгыльләнүче имче-томчы, багучы карчыклар, надан остазлар фаш ителә. Алдынгы карашлы, тырышып укытучы галимнәр һәм тырышып укыган укучылар – язучы тарафыннан мактала.

Язучы бала тәрбияләүдә ананың иң зур роль уйнавын билгели: бала тәрбияли белми торган, надан Сәгыйдә улының бай тормышта үсүенә шат, ә килене Бәдрия үз улы Рәфгатькә рухи тәрбия бирә, яхшы мәктәптә укыта. Рәфгать акыллы, белемле, тәрбияле, бала булып үсә.

1912 нче елда иҗат ителгән “Кәҗүл читек” әсәрендә автор бик күп тәрбияви моментларны истә тота. Хикәянең төп герое – Әхмәдулланың киеменә игътибар итик. Аның чапаны этисенең чапаныннан тегелгән. Әтисе – мулла, димәк, мулла чапаныннан тегелгән, яңа да түгел. Язучы бу урында безне сакчыл булырга өнди. Иске, бөтенләй таушалмаган әйберләрне, бераз эшкәртеп, яңаларын җитештерү мөмкинлеген искәртә.

Әхмәдулланың чалмасына игътибар итсәк, ул – чуар. Чалма гадәттә ак була. Автор моңа да тирән мәгънә салган. Аңлашылганча, малай әле кечкенә, уйлары тәртиптә түгел, шуңа чуардыр. Димәк, малай, гаиләдәге тәртипләрне күреп, аңлап, үзендә дә шул гүзәл гадәтләрне булдырырга тиеш. Әнә бит аңа

чалманы абыйсы чала. Ә ул укымышлы, зыялы егет. Шулай булгач, Әхмәдулла да белемле булырга тиеш.

Г.Исхакый өлкән буынны хөрмәт итәргә өнди. Бу очракта өлкән буын вәкиле – Әхмәдулланың әбисе. Ул тәҗрибәле, акыл, киңәш бирә. Хикәядән өлкән буын – тәрбияче, ә үсеп килүче буын укымышлы, көчле ихтыярлы хуҗа булырга тиеш дигән фикер аңлашыла.

Татар халкы элек – электән уңган, булган халык, шунлыктан аларның табыннарында тир тамызып, көч түгеп үстергән икмәк булган. Бәйрәмнәргә яңа киемнәр кигәннәр. Бу – чисталык, пөхтәлек билгесе. Татарларның сакчыл булулары ассызыклана. Динебез уңган, булдыклы булырга, булганны әрәм итмәскә өнди. Безнең милли гореф – гадәтләребез горурлык, рух һәм тән чисталыгы, сакчыллык һәм булдыклылык кебек сыйфатлар тәрбияли.

Шулай итеп, Г.Исхакый халык күңелендә мәңге яшәячәк, тәрбияви әһәмияткә ия булган әсәрләр тудырып, гаделлек, тынычлык, югары әхлак, нык иманлы нәсел дәвамчыларының булуы, милләт язмышы кебек мәңгелек проблемаларны күтәреп чыга һәм әсәр укучыларны да шул хакта уйлануга мәҗбүр итә. Язучы бик ныклы рәвештә милләтнең киләчәге булган яшьләрнең милли рухын һәм йөзен саклап калу мәсьәләсен күтәрә. Балалар гаиләдә, аннан килеп мәктәптә милли рухта тәрбияләнергә тиеш дип саный. Шулар сакланып калса, халык милләт булып яши.

Әдәбият

Исхакый Г. Әсәрләр. – Казан, 1998.

Мусин Ф. Исхакый Г. – Казан: Татар. кит.нәшр, 2008.

## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ҮЛЕМСЕЗ ӘСӘРЛӘРЕ

*Габделхаков Илнур,*

*Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең X сыйныф укучысы*

*Фәнни җитәкче: Гарданова Хәлимә Вәзир кызы*

Мең елдан артык тарихы булган татар әдәбиятында күренекле ядкарьләр гаять күп. Әмма алар арасында “Кыйссаи Йосыф” кебек озак гасырлар буе укылып, халыкның рухи юлдашы, сердәше булып килгән килгән әсәрләр, мөгаен, юктыр.

“Кыйссаи Йосыф” – борынгы төрки поэзиянең сюжетлы беренче әсәре. Аның сәнгатьчә эшләнешендәге үзенчәлекләр дә шуңа бәйле. Әлеге сюжетлы әсәр коруда төрки әдәбиятның мөстәкыйль казанышлары җитәрлек булмаганлыктан, шагыйрь фольклор тәҗрибәсенә таяна. Образларны эшләү, сюжет борылышларын кору, стилистик ялгамнарны тәэмин итүдә ул тылсымлы әкият һәм каһарман эпос тәҗрибәсеннән файдалана. Аның сәнгатьчә фикерләве дә нигездә эпик поэтика кысаларында бара.

Менә әсәрнең иң әһәмиятле эстетик мәсьәләләреннән уңай герой проблемасын хәл итүне алыйк. Монда шагыйрь эпик идеаллаштыру кануннарына буйсына, Йосыф мисалында идеал кеше образын тудырырга омтыла. Бу максатка ирешүдә төп

каһарманның мәгълүм пәйгамбәр булуы авторга иҗади мөмкинлек тудыра. Пәйгамбәр кем ул? Иң беренче чиратта, ул алдан күрүче, тирән фикерләүче, башкаларга юл күрсәтүче, үрнәк кеше; матур сыйфатларга, эш-гамәлләргә ия булган мөхтәрәм инсан. Йосыф та әсәрдә нәкъ әнә шул рәвештә тасвирлана. Алланың берлегенә, барлыгына, ислам диненең хаклыгына ышану – аның төп сыйфаты. Ул күп аллачылыкка, сыннарга табынуга каршы. Әмма Йосыф башка дин тотучылар белән дә әдәплелек, кешелеклелек кагыйдәләрен саклап эш итә, аларны рәнҗетми, эзәрлекләми. “Көферләр” белән мөнәсәбәттә аның төп чарасы – дәлилләү, ышандыру, аңлату.

Йосыфтагы хәлиткеч сыйфатларның берсе – тугрылык. Йосыф кемгә тугрылыклы? Иң беренче чиратта – гаделлек, кодрәт, намус кебек күркәм сыйфатларның символы булган Тәңрегә. Илаһияткә тугрылык – ул үз намусыңа да тугрылык дигән сүз. Димәк Йосыф үз намусына да тугрылыклы.

Йосыф сабый чакта ук әнисез кала. Йагъкуб – аның өчен ата гына түгел, ана да. Шуңа күрә Йосыф һәрчак атасына хөрмәт, ихтирам белән карый, аңа тугрылыкны үзе өчен иң изге гамәлләрнең берсе дип саный. Атага тугрылык әсәрдә туган җиргә, туган илгә, туган халкына да тугрылык булып аңлашыла.

Сабырлык – Йосыфның табигатен, һәр эш-гамәлен бизи торган янә бер күркәм сыйфат. Ул кыен чакта гына түгел, чагыштырмача имин вакытта да сабыр итә белә. Аның фикеренчә, сабырлык кешене намуссызлыктан саклый, рухи яктан үстерә, баета. Йосыф бу мөһим сыйфатны башкаларда да күрергә тели.

Кол Гали фикеренчә, идеал кешенең тышкы кыяфәте эчке дөньясы белән туры килергә тиеш. Шуңа күрә, Йосыфның искиткеч гүзәл, нурлы булуына басым ясый. Төп геройның матурлыгы – эчке, илаһи гүзәллекнең тышкы гәүдәләнеше ул.

Әсәрнең төп каһарманы, экиятләрдәге кебек, төрле кыенлыклар, сынаулар аша зирәклеге, алдан күрүчәнлеге ярдәмендә хакимияткә килә. Автор фикеренчә, ил белән Йосыф кебек һәрьяктан камил затлар, пәйгамбәрләр, идарә итәргә тиеш. Бары шул вакытта гына халык төрле авырлыкларны, шул исәптән ачлыкны да, исән-имин кичерә ала. Йосыф – игелекле, кодрәтле, гадел хөкемдар. Ләкин ул, хакимият башлыгы буларак, кирәк вакытта кырыс та, каты куллы да, хәтта хәйләкәр дә була белә. Бу бигрәк тә ачлык елларында, агалары белән мөнәсәбәттә, сарай салдыру күренешләрендә ачык күренә.

Әсәрдә авторның уй-ниятләрен сәнгатьчә гәүдәләндерүдә, төп каһарманнан кала, Зөләйха да зур урын тота. Аларның әдәби бирелешендә билгеле бер охшашлык та бар. Зөләйха да, Йосыф кебек, искиткеч гүзәл. “Тулган айдай балкыр иде аның йөзе” сурәтен автор аларның һәр икесенә дә куллана. Зөләйха да – этисенең яраткан баласы. Ул да төш күрә. Бу төш һәм Йосыфның, һәм Зөләйханың гомер юлларын икенче якка борып җибәрә: аталарыннан аера, кайгы-шатлыкларга дучар итә. Әмма Йосыф акыл, сабырлык белән эш итә. Зөләйха – хис-тойгы кешесе. Аның бөтен күңелен, яшәешен мәхәббәт хисләре биләп алган. Йосыф белән кавышу – Зөләйха тормышының төп максаты. Бу юлда ул бик күп шаһзадәләрдән килгән яучыларны да кире бора, атасы йортын калдыра, сөймәгән кешесе Кыйтфир белән торырга мәҗбүр була, байлыгын сарыф итә, гайбәттән дә курыкмый.

Автор фикеренчә, бәхетле тормышның нигезе – бердәмлектә, татулыкта, иминлектә һәм кешелекле мөнәсәбәттә. Күңелендә Йосыф сурәте генә булып, аның турында уйлар белән генә яшәгән Зөләйха Йосыф белән гаилә корып, балалар үстерә, иминлектә яши.

Әсәрдә Зөләйхә – Йосыфның бердәнбере. Шагыйрь бу фикерне ассызыклап әйтә. Әсәрнең каһарманнары мисалында мәхәббәт һәм гаилә мәсьәләсен хәл итеп, ул үз чоры Көнчыгышындагы күп хатынлылыкка каршы чыга.

Автор кешеләрне табигатьнең һәм яшәешнең зур байлыгы дип саный. Һәр кеше үз гамәле өчен үзе җавап бирә, игелек – игелек булып, яманлык яманлык рәвешендә, иртәме-соңмы, барыбер кабат үзенә кайта. Бу – Йосыф агалары образында ачык күренә.

Автор фикеренчә, начарлык кылган агаларына җәза бирү – ул Алла эше. Җәза бирүнең максаты үч алу түгел – кешене төзәтү. Хатасын таныту, үкендерү, тәүбә иттерү, гафу иттерү. Шуңа күрә автор Йосыфны рәнҗеткән агаларыннан да, коллардан да, Малик Дәгыйрдән дә гафу иттерә.

Әсәрдәге вакыйгалар барышында пәйгамбәрләрдән башка дини-мифологик образларның урын алуы да бик урынлы. Алла, Җәбраил, пәриләр уңай образ буларак сурәтләнсәләр, иблис, шайтан һәр очракта тискәре итеп бирелә. Алла - илаһи көч, югарыдан юл күрсәтеп, өйрәтеп торучы; Җәбраил – җир белән күк арасындагы, ягъни югары көч белән кешеләр арасында элемтәче, арадашчы.

Кол Гали әсәре – үзенең идея проблематикасы, поэтикасы һәм тел-сурәтләү чаралары белән гаять кызыклы һәм тормышчан әсәр. Кол Галинең хис-фикерләргә бай әсәре үлмәгән: ул халкыбыз белән бергә яшәгән, яши һәм яшәячәк.

Әдәбият

Татар әдәбияты: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәбенең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия (татар балалары өчен)/ Х.Й.Миңнегулов, Н.С.Гыймадиева. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2012.

Татар әдәбияты: теория. Тарих / Д. Ф. Заһидуллина, Ә. М. Закирҗанов, Т. Ш. Гыйләҗев, Н. М. Йосыпова. Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

## «СӘЛӘТ» – ТАТАР ТЕЛЕ САГЫНДА

*Гайнетдинова Индира,*
*Яр Чаллы педагогия көллиятенең I курс студенты*
*Фәнни җитәкче: Минһаҗева Резилә Әбүзәр кызы*

Татарстаныбызның киләчәге акыллы, тырыш, актив һәм сәләтле яшьләр кулында! Менә шундый яшьләрне үзенә туплаучы, аларның сәләтләренә канат куеп, үстерергә ярдәм итүче «Сәләт» иҗтимагый яшьләр үзәге турында булыр язмам.

«Сәләт» үзәге турында күпләрнең ишеткәне бардыр, мөгаен. Күпләр, аны

төрле аланнардан торган, күп кеше җыйган җәйге лагерь дип уйлый. Юк, бу ял итү урыны гына түгел, ул тулы канлы бер дәүләт, дияр идем. Татар мәдәнияте, сәнгате, әдәбияты һәм теленә, гомумән, татар дөньясына гашыйк сәләтле балалар дәүләте... Әлеге илдә тормыш кайный, ул бертуктаусыз хәрәкәттә, үсештә. Монда ялкауларга һәм татар телен санга сукмаган кешеләргә урын юк.

Бүгенге көндә «Сәләт» хәрәкәте Татарстанның дистәләгән район-шәһәрләрендә генә түгел, хәтта Рәсәй һәм чит илләрдә дә уку-укыту аланнарын җәелдерде. Бүген ул күпсанлы фәнни-гамәли конференцияләр оештыручы, меңләгән татар яшьләрен һәм татар телен өйрәнергә теләге булганнарны ел дәвамында төрле чара-форумнарга җыючы һәм зур фестивальләрдә кайнатучы иң оешкан яшьләр хәрәкәте. «Сәләт-Прага», «Сәләт-Австралия», «Сәләт-Монреаль» аланы яшьләрен Татарстанның Биләр шәһәрендә узучы форумга чакырып, республикабызның истәлекле урыннары, актив яшьләре белән таныштыручы да ул.

Сәләт иленең максаты – татарлар яшәгән һәр төбәктә «Сәләт» аланчыклары булдыру, мәдәниятебезне, телебезне үстерү. Мин үзем, шәхсән, «Сәләт» дөньясы белән күптәннән таныш булсам да, 2016 елдан башлап, аның актив әгъзасына әверелдем һәм бүгенге көнгә кадәр ул дөньядан бер дә аерылганым юк. «Сәләт» елдан ел минем яңадан-яңа сәләтләремне ача, мөмкинлекләремне сыный.

Беренче елны миңа «Сәләт – Яр Чаллы» аланында булырга насыйп булса, икенче елны  дусларым белән «Сәләт − Болгар» аланында очрашуыма чиксез шат идем. Ике ел дәвамында «Сәләт» миңа татар телен тирәнтен өйрәнергә булыша, бөек шәхесләр белән аралашып, фикер алышырга, иҗади сәләтемне ачарга, үстерергә ярдәм итә.  Бу мәктәпне узуымның нәтиҗәсе буларак,  ябык булып тоелган ишекләр дә ачылып киткәндәй була, көннән-көн хыял-максатларымны чынга ашырырга, үземне төрле өлкәләрдә сынап карарга, фәнни эшләр белән шөгыльләнергә теләгем арта бара. Кыскасы, «Сәләт» оешмасы өметле яшьләргә үзләрен табырга, үзләре кебек, татар телен югары дәрәҗәдә белергә омтылучы дуслар белән очраштыра, зыялы шәхес буларак камилләшү өчен зур мөмкинлекләр тудыра.

Ел двамында Казанда урнашкан «Сәләт» йортында һәм Биләрдә урнашкан «Фәнсар» уку-укыту базасында төрле иҗади, фәнни, интелектуаль, спортка һәм белемгә кагылышлы сессияләр, кичәләр, тантаналар, ярышлар уза. Иң төп көч, беренче чиратта, татар телен үстерүгә, аны саклап калуга, ана телебезгә карата сакчыл һәм ихтирамлы караш тәрбияләүгә юнәлтелә. Ел дәвамында яшьләр белән Рәсәй һәм Татарстан төбәкләренең күренекле шәхесләре, КФУ ның тәҗрибәле мөгаллимнәре, алдынгы студентлары эшли.

Җәйге аланнарда узучы сменалар бик кызыклы һәм файдалы үтә. Анда татар телен төрле дәрәҗәдә белгән яки бөтенләй белмәгән, әмма аны өйрәнергә зур теләге булган яшьләр портфолио буенча сайланып алына. Аланда татар мохите хөкем сөрә, татар телен өйрәнү, ана телебездә аралашу өчен барлык шартлар да тудырылган.  Идел буе территориясендә яшәүче халыклар һәм татар

халкы мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән танышу, өйрәнү, сәләтле шәхес тәрбияләү өчен мәгълүмати технологияләрне эшкә җигү, балаларны һәрьяктан камил, толерантлы шәхес буларак тәрбияләүгә аерата игътибар бирелә. Ел да гөрләп узучы «Сәләт» форумы – чын-чынлап татар һәм рус телләре дуслыгы мохите, чөнки монда бар мәдәни һәм белем алу чаралар ике телдә алып барыла.

Сменадагы ике-өч атна бик тиз үтеп китә, чөнки көнлек расписание минутлап язылып куела. Көн дә дәресләр, мастер-класслар, милләтебезнең танылган шәхесләр белән очрашулар, кичке чарага һәм Биләрдә узачак форумга әзерлек... Шулай ук халкыбызның бай тарихын өйрәнәбез: Болгар-дәүләт тарихи-архитектура музей тыюлыгына сәяхәтебез, Анда борынгы Алтын Урда чорыннан калган Җәмигъ мәчете, зур манара, көнчыгыш төрбә, кече манара, ак пулат, кара пулат, хан мунчасы, хан төрбәсе, кече шәһәрчек, Габдрахман коесы, Рабига күле, борынгы ата-бабаларыбызның кабер ташларын, искиткеч матур Ак мәчет һ.б корылмаларны карадык, күп мәгълүмат алдык. Биредә Бөтендөнья ЮНЕСКО оешмасына кергән милли-тарихи хәзинәләрне, дөньядагы иң зур Коръән китабын күреп кайту насыйп булды. Берьюлы Биләр шәһәренең музей-тыюлыкларына да

Сәләтле балаларны, танылган шәхесләр: язучылар, депутатлар, шагыйрләр, җырчылар, театр-сәхнә кешеләре, галимнәр белән, таныштыру, алга таба тормышларында сәләтләренә тәңгәл һөнәр, яшәү рәвеше сайларга ярдәм итә. Әйтик, Энгель Фәттахов, Рабит Батулла, Фәнис ҖиҺанша, Константин Руденко, Илшат Рахимбай, Антон Грачев, Васил Шәйхразыев, Вадим Реуцкий, һ.б булган очрашулар күңелемдә бик озак сакланыр. «Сәләт» яшьләр үзәге татарлар дөньясына яңа сулыш кертүче, Татарстаныбызга гашыйк сәләтле яшьләрдән бөек шәхесләр үстерүче мохит! «Сәләт» яши икән, димәк, татар телебез һәм халкыбызның гореф-гадәтләре, мәдәнияте яши, онытылмый, үсә!

Йомгаклап, «Сәләт» хәрәкәтенең илһамчысы, оештыручысы һәм җитәкчесе, галим һәм шагыйрь Җәүдәт Сөләйманның түбәндәге юллары белән тәмамлыйм: Әй, чит-ят кавемнәр! / без – исән! / «....» / без күк төрк өммәте – / дәүләтле татарлар! / дәүләтле татарлар! [Сөләйман 1997: 61].

Әдәбият

Сөләйман. Күләгәләр: шигырьләр. – Казан: «Идел» журналы китапханәсе, 1997. – 139 б.

## ЛЕНАР ШӘЕХ ИҖАТЫ – МИЛЛИ ТӘРБИЯГӘ НИГЕЗ

*Гайнуллина Айгөл,*
*КФУның Алабуга институты студенты*
*Фәнни җитәкче: Хәйруллина Әлфирә Сәлихҗан кызы*

Кешене гомере буе балачагы озатып килә. Балачагыннан бирле яшәргә өйрәнә, балачактан ук тәрбия ала, үзенә нииндидер сыйфатлар туплый. Бала

күңеле ак кәгазь бите кебек саф, чиста, тигез. Ә бу битләрдә бит теләсә нинди эз калдырырга мөмки. Шуңа күрә балаларга дөрес тәрбия бирү бик мөһим.

Ленар Шәех иҗатына игътибар итсәк, аның балаларга якын булган шигърияте – милли, дөрес тәрбиягә нигез сала. Чыннан да, аның шигърияте табигать гүзәллеген күрә белергә, экологик проблемалар белән якынырак танышырга, үзебезнең төбәктәге хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын ныграк өйрәнергә, чиста күңелле, зирәк фикерле, сәнгатьле булырга, тирә-юньгә яктылык аша карарга, дөньяны яратырга өйрәтә. Аның сүзләре ягымлы, ипле, моңлы бер шигъри тәртиптә, ыгы-зыгылы тормышта укучысын тетрәндергән мәсьәләләрне затлы сөйләм белән җиткерә. Әлеге халәт, аның чын шагыйрьлек сыйфатын ача. Күп кенә әсәрләре монын ачык дәлиле: “Яз җыры”, “Җылытасы килә дөньяны», «Гасырда фасыллар буталган», “Мәхәббәт турында шигырьләр”, Балалар өчен: «Алдамыйм», «Безнең ишегалдында», “Авылдан килгән мендәр”, “Керпе ничек энәле булган?..”, “Балдан бала” һ.б.

Билгеле булганча, балалар әдәбияты – аерым фидакарьлек һәм гражданлык хисе таләп итә торган өлкә. Чөнки, баланы уйландырырлык, аның аңына барып җитәрлек итеп язар өчен, аерым бер сәләт кирәк. Ленар Шәех шундыйларның берсе. Ул – сабыйлар күңеленә якын, хыялый, самими, сабыйларча гаҗәпләнә, соклана, сөенә белә.

Көзгегә карап сокланам:
Нинди чибәр икәнмен!
Әнием юкка әйтмидер,
Тәмле-татлы шикәр мин!

Шагыйрьнең кызыклы, шаян шигырьләре балаларга, бер яктан, куаныч алып килсә, икенче яктан яхшы тәрбия чарасы да. “Яхшы гамәл” шигырендә егетләргә кызларның чәчен тартмаска, ә киресенчә аларга яхшылык эшләп, дәресләрдән соң сумкаларын тотып кайтырга киңәш бирә.

Ленар Шәехнең иҗатында туган ил, туган халкы, татар теленең бүгенгесе һәм киләчәге турында уйланулары да бер урын алып тора. “Татарстан - Ватаным”, “Туган телем”, “Татарлык” шигырьләре аша шагыйрь балаларда туган илгә, туган телгә, милли кыйммәтләргә хөрмәт уята, үзеңнең ана теле, мөселман дине белән горурланырга, хөрмәт итеп яшәргә кирәк дигән фикер үткәрә.

Үз милләтең хөрмәт иткән
Башкаларны кимсетмәс.
Татар булып калсаң гына,
Газиз милләтең бетмәс!

“Гел “биш”ле булыр, әни!..” дигән шигырендә Айсылу көн буе уйнап, өй эше эшләмичә йөреп, икенче көнгә «икеле» ала һәм өенә кайткач әнисеннән оялып, өйдәге эшләрен дә эшли, дәресләрен дә карап, икенче дәрескә бишле алып кайта. Шушы шигыре аша шагыйрь нәни укучысын кечкенәдән тормыш тәҗрибәсен тупларга, эшләгән начарлыкны төзәтергә, дөрес эш итә белергә, әти-әни сүзен тыңларга өйрәтә.

Шагыйрь «Көпә-көндез бакча басучылар турында шигырь»ендә җиләк урлаган малайларны тәнкыйть уты астында тотып урламаска ярамаганлыгын аңлата.

Әдипнең нинди генә шигыренә тукталсаң да, алар самимилеге, җылылыгы белән үзенә җәлеп итә, әйтергә теләгән фикерләре бала күңеленә үтеп керә, күңелләрен ачып җибәрә. Димәк, аның иҗаты балалар өчен чын мәгънәсендә шифалы.

Ленар Шәехнең шигырьләре эш яратырга өнди, гади генә итеп, дөрес сүзләр белән сөйләшергә өйрәтә. Аның шигырьләрен укыганда балалар нәрсәнең яраганын,ә нәрсәнең начар икәнен үзеннән үзе аңлый. Шигырь укып тәрбия сәгате дә җиңел үткәрелә. Шагыйрьнең тормыш тәҗрибәсен үзенә генә хас шигъри юллар белән укучы күңеленә җиткереп, милли хисләр тәрбияләү .

Шулай итеп, Ленар Шәех иҗаты балаларга экологик һәм милли тәрбия бирү; табигатьтә үзеңне тота белү, йорт һәм урман җәнлекләренә игътибарлы булырга, аларны яратырга; шигырьләре ярдәмендә сабыйларда әхләк, әдәп кагыйдәләрен формалаштырырга ярдәм итә.


Әдәбият

Шәех Л. Алдамыйм!: балалар өчен шигырьләр, табышмаклар, әкиятләр – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 96 б.

Шәех Л. Җылытасы килә дөньяны!..: шигырьләр, поэмалар / Кереш сүз авт. Зөлфәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 255 б.


## ҺӘЙКӘЛ КУЯР ИДЕМ....


*Гайнуллина Гөлия,*

*Алабуга районы Иске Юраш урта мәктәбенең XI сыйныф укучысы*

*Фәнни җитәкче: Юнысова Лилия Мирза кызы*


Тарихны өйрәнмичә, үткәнне белмичә, хәзерге тормышны аңлап, яңаны төзеп булмый. Чөнки бүгенге тормыш – меңнәрчә елларның нәтиҗәсе. Тарих – ул еллар шаһиты, халык хәтере. Ул элек булган ялгышларны кабатламаска, азатлык өчен көрәштә башларын куйган җаннарны онытмаска, бердәм булырга өйрәтә. Тарихыбызга күз салсак, әле кайчан гына коточкыч канлы сугыш – Бөек Ватан сугышы булып узган, илебез күгендә дүрт ел буе үлем шәүләсе эленеп торган. Сугыш бер генә кешене дә читләтеп узмаган, һәр кешенең йөрәгендә төзәлмәслек яра, ачы күз яшьләре калдырган. Инде Бөек Җиңүгә дә 72 ел тулды, әмма хатирәләр онытылмый. Аны кеше хәтере мәңгеләштерә.

Мин “Һәйкәл куяр идем...” Әйе, бүгенге көндә ветераннарыбызның саны көннән-көн кими бара. Алабуга районы Иске Юраш үзидарәсе җирлегендә 12 тыл ветераны исәпләнә, Җиңүнең 70 еллыгын каршылаганда алар 28 булган. Әйе, өлкән яшьтәге авылдашларыбызның саны көннән-көн кими бара Димәк, берничә елдан аларның эше онытылачак. Шуңа күрә безгә, сугыш каһарманнары исән чакта, аларның үткән юлын, тормыш тәҗрибәсен өйрәнеп,

туплап калырга  кирәк. Ә аларда күпме тормыш тәҗрибәсе, күпме асыл әхлак сыйфатлары...

Ә бит авылдашларыбызның шәхси тормышы аша,  Бөек Ватан сугышы чорындагы тыл тормышы турындагы белемнәрне тирәнәйтү; әби-бабаларыбызда булган татар халкына хас күркәм әхлак сыйфатларын ачу; патроиотик хисләр булдыру, ныклы тормыш позициясе формалаштыру; авылдагы тыл каһарманнары белән очрашу, истәлекләрне язып алу, ”Һәйкәл куяр идем...” дип исемләнгән чара уздыру, материалларны туплап, китапчык бастыру,  музейга тапшыру; укучылар белән әңгәмәләр уздыру, анкеталар тутырттыру болар укучыларыбыз алдында торган зур бурычларыбыз булып тора.

Еллар үтә, буыннар алмашына. Без – бәхетле чор балалары. Тыныч тормышта яшибез. Дөньяның, табигатьнең матурлыгына сокланабыз. Табыннарыбыз тулы ризык, өстебез бөтен, әти-әниләр назын күреп яшибез. Белем алып, киләчәк тормышта хыялларыбызны тормышка ашыру өчен дә безгә дәүләт тарафыннан бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Без боларны “шулай тиеш” дип кабул итәргә күнеккән. Ә шушы матур тормышны безгә бүләк итүче халкымның Бөек Ватан сугышы чорындагы батырлыгын, алар аша үткән авырлыкларны бөтенваклыклары белән беләбезме соң без?

Әйе, без бу турыда беләбез: сугыш турында кинолар да карыйбыз, китаплар да укыйбыз. Аңлыйбыз да: сугыш коточкыч нәрсә, безгә мондый хәлләрне күрергә язмасын. Әмма сугыш китергән михнәтне күз алдына китереп бетерә алмыйбыз икән.

Күптән түгел без тыл  каһарманнары белән очрашу үткәрдек, аларның хатирәләрен тыңладык.  Менә монысы бөтенләй башка нәрсә... Алар сугыш чорында күргәннәрен бүген күргәндәй сөйләделәр, гүя бу 72 ел аралык бөтенләй булмаган. Бу хәлләр аларның йөрәкләренә еллар үтеп тә җуелмаслык булып кереп калган. Каршыбызда утырган, без күреп белгән бу – чәчләренә ак бәс сарган әби-бабайларыбыз безгә зур батырлык ияләре булып күренделәр. Чыннан да, бу шулай.  Аларның һәркайсы, Җиңүне якынайтам дип, нинди генә зур батырлыкларга тиң эшләр эшләмәгәннәр! Ә үзләре нинди тыйнаклар. Без “менә шулай эшләдек” дип күкрәк кагып та йөрмиләр. Булган хәлләрне сөйләгәндә дә, “Җиңүдә безнең дә өлешебез зур”, – дип тә мактанмыйлар. Аларның исемнәре батырлар исемлегендә дә юк. Ә үзләре Бөек Җиңүгә үзләреннән нинди зур өлеш керткәннәр!

Аларның хатирәләрен тыңлау  күңелдә тыеп булмаслык хисләр өермәсе куптарды. Я, Хода, әсәр һәм кино геройлары безнең арадагы әби-бабайлар икән бит! Минем кызыксынуым чиксез иде. Моннан соң инде мин алар турында мәгълүмат тупламыйча кала алмадым.

Сугыш чоры турында 12 тыл ветераныннан, 3 сугыш чоры баласыннан мәгълүматлар тупладым. Илне бомбага тота башлаганда, аларның күбесе әти-әниләренең итәгеннән төшкән сабый балалар, яшүсмерләр генә булган. Сугыш ачысы һәм югалтулары аларны бик иртә олы тормышка алып кереп киткән. Бу

хәлләргә 72 елдан артык вакыт үтсә дә, вакыйгалар әби-бабайлар күңеленә мәңгелеккә язып куелган. Аларның һәрберсе үзенчәлекле, берсе дә кабатланмый. Әмма нинди генә авыр шартларда калсалар да, кешелекнең күркәм сыйфатларын – тырышлык, уңганлык, уен-көлке белән яшәү, авырлыклар алдында каушап калмау, аларны җиңә белү, ярдәмләшеп яшәү кебек сыйфатларны югалтмаганнар алар.

Миңа авылдагы тыл каһарманнары белән очрашу, аларның сугыш чорында кылган эш-гамәлләрен белү тарихны, сугыш вәхшәтен яхшырак күз алдына китерергә булышты. Тыныч тормышның, өлкәннәрнең кадерен белергә ярдәм итте.

Бүгенге көндә илебез, нәкъ менә шундый бай рухлы, иле һәм халкының бәхетле тормышы өчен, җанын корбан итәргә әзер булучыларга мохтаҗ. Авылымдагы тыл ветераннарының батырлыгына һәйкәл куярлык!

## КЕШЕ ТОРМЫШЫНДА ҺӘМ МАТУР ӘДӘБИЯТТА ЙОРТНЫҢ РОЛЕ

*Галиуллина Зәлия, Сәйфутдинова Алсу*
*Кукмара 3нче урта мәктәбенең X сыйныф укучылары*
*Фәнни җитәкчеләр: Нәҗмиева Вәсилә Госман кызы,*
*Демухаметова Гөлшат Мехаматнакыйп кызы*

Татар әдәбиятында тарихи-мифологик дәверләрдән бирле сакланып килгән, халык тормышын, аның яшәү фәлсәфәсен чагылдырган образ-символлар бик күп. Шулар арасында йорт образы да бар. Татар әдәбиятында йорт – иң еш кабатланучы, эмблема, символ, мотив һәм башка дәрәҗәләрдә кулланылышта йөрүче бөтенлек. Шулай ук ул милли мәдәниятнең урын хакындагы күзаллауларында мөһим элемент булып, милли менталитетны, халыкның дөньяга карашын, мөнәсәбәтен барлыкка китерүдә зур роль уйнаучы мөһим бер элемент.

Һәр галим һәм язучы йорт образына төрлечә аңлатма бирәләр. Мәсәлән, рус әдәбиятчысы И. Б. Роднянская: «Йорт» кебек аерымланып, төрле яклап киртәләнеп алынган традицион ябык пространство модельләре..., матур әдәбиятта элек-электән «дөнья моделенең» төгәл һәм аңлаешлы билгесе булып санала»,– дип яза үзенең бер хезмәтендә.Татар язучысы Галимҗан Гыйлманов та: «Һәр йорт, өй-нигез-Тәңре дөньясының кечкенә моделе кебек», – ди. Фрейд, Юнг кебек философ-психологлар йорт образын шәхеснең эчке дөньясының якты бер маягы итеп күрәләр. Өй образы тормыш-көнкүренешне тасвирлап язган күп кенә әсәрләрнең төп үзәге, кеше язмышын билгеләүче бер чыганак.

Йорт – гаилә яши торган һәм ул гаилә тормышы хакында мәгълүмат бирүче корылма. Чыннан да, кеше тормышын, кешелек тарихын йорттан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Бик борынгы кешене яңгырдан һәм салкыннан, ерткычлардан, һөҗүмнәрдән саклаган куыш, урта гасырларда алтын белән бизәлгән патша сарайлары һәм хәерчеләрнең җимерек өйләре, бүгенге

җәмгыятьтәге шулай ук төзелеше, бизәлеше белән аерылып торган йортлар – бар да кеше өчен кадерле, аның яшәү һәм эшләү урыны буларак, тормышының аерылгысыз бер өлеше.

Татар әдәбиятында исә, бу образны без фольклор әсәрләрендә үк очратабыз. Йорт образы татар халык авыз иҗатыннан башлап бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән, актив кулланылыштагы образлардан санала. Борынгыдан ук ул тирәлекне үзеңнекенә һәм чит тирәлеккә аеру билгесе кебек кулланылып килә. Татар халык авыз иҗатында йорт, нигездә, вакыйгалар урыны вазифасын башкарган. Фольклор жанрларыннан, аеруча, экият, бәетләрдә еш очрый. Шулай ук, мәкальләрдә, әйтемнәрдә, фразеологик гыйбарәләрдә дә күзәтелә. Мәсәлән:

*Өйсез йорт мисез баш кебек.*

*Өй салмыйча мал булмый. ...*

Фольклор әсәрләрендә «йорт» образы – ил, халык, туган җир, дәүләт мәгънәсендә килгән очраклары да бар. Әйтик «Идегәй» дастанында мондый юллар бар:

*И Идел йорт, Идел йорт!*
*Идел эче имин йорт,*
*Атам кияү булган йорт—*
*Иелеп хөрмәт кылган йорт;...*

Халык авыз иҗатында чагылыш тапкан йорт образы язма әдәбиятта да сакланып кала һәм үзенең мөһимлеген югалтмый, язучыларның әсәрләрендәеш кулланыла.

Мәсәлән, Ә.Еники үзенең «Матурлык» хикәясендә йорт образын хуҗаларның матди хәлен сурәтләү өчен бик уңышлы файдаланган.

*Без фәкыйрь кешеләргә керәсебезне белеп килә идек, әмма бу кадәр ярлы хуҗалыкны күрербез дип һич тә көтмәгән идек. ....* [Исхакый 2003]

Г.Исхакыйның «Сөннәтче бабай» хикәясендә дә йортны сурәтләгән өлешләр шактый һәм алар символның аерым мәгънәләрен ачыкларга ярдәм итә. «Йорт» сурәтеңдә, иң әүвәл, Сөннәтче бабайның портретын күрәбез: «Бөтен җире, бөтен төсе Сөннәтче бабайга охшаган иде». Такта белән ябылган түбәсе-битен-йөзен, түбә кырыйларыннан үскән үләннәр-таралмаган сакалын, тәрәзәнең яшәргән пыялалары-яшьле күзен, тышкы яктан сыланган күк балчык-киемнәрен хәтерләтә. Әлеге охшашлык турында әсәрдә кат-кат ассызыклана: «Монда һәр нәрсә Сөннәтче бабайга охшаган. Сөннәтче бабай үзе дә һәр нәрсәгә охшаган иде». Кыскасы, Сөннәтче бабай һәм йорт образлары тәңгәл, аерылгысыз. Йорт образында без Сөннәтче бабай образын күрәбез.

Йортны да ишек, тәрәзәдән башка күз алдына китереп булмый. Ябык пространство буларак, аның әйләнә-тирә, тышкы дөнья белән тоташу, бәйләнешкә керү өчен ишек, тәрәзәләрнең булуы бик мөһим. Чөнки дөнья белән элемтәдә тору- кеше яшәешенең мөһим шарты.

Ишек – бина, бүлмә яки корылманың стенасына кереп-чыгып йөрер өчен ясалган уем һәм шул уемга беркетелгән ачылмалы-ябылмалы җайланма. Р.Харис та бу сүзне иң элек шушы мәгънәсендә куллана:

Көн саен йөз тапкыр
ачылган ишек тә
бераздан әйләнә
упсалы тишеккә. (“Ун кадак”)

Ишек әдәбиятыбызда йөрәккә үтеп керү юлы буларак та сурәтләнә. Шагыйрь Р.Харис бу образны бик яратып куллана:

Аның сулу кысылуы,
Бәлки, мине күргәчтер,
Йөрәк ишегемне ачып,,
Шигыремә кергәчтер?! ("Сыгылмалы сылу")

Тәрәзә – өйнең күзе. Тәрәзәсе булган өй ябык пространство булудан туктый, ул тышкы дөньяга ачыла.

Ә авыл өйләрендәге тәрәзәләр халык тормышында бик мөһим роль башкарган. Элек-электән үк татар авылы халкы тормышын, хәлен йортка бәйле детальләр ачыклап биргән. Тәрәзәләр - ул шушы йортта яшәүчеләрнең йөзе. Әлбәттә, ул матур, гүзәл булырга тиеш. Авыл урамы үзенең күз явын алырлык чәчәкләп-чуклап «чигелгән» тәрәзә йөзлекләре, кәрнизләр, ай-йолдызлы капкалар белән күргәзмә залы, сынлы сәнгать музее вазифасын үтәгән. Күзәтүләремнән чыгып, шуны әйтәсем килә: хәзер исә аны элекечә үк матур дип әйтерлек түгел. Тәрәзә читләрен, кәрнизләрне челтәрләп ясау юк дәрәҗәсендә. Булсалар да , аларда әби-бабайларыбыздан килә торган матурлык сакланмаган. Бу үз чиратында, халык күңелендә матурлыкка, гүзәллеккә, сәнгатькә омтылыш кими баруын күрсәтә, минемчә.

Ә хәзер исә, әсәрләрдә дан җырланган, күпләрне таңга калдырган йортлар борынгыдан килгән, гасырларны кичкән сәнгатьлелек юкка чыгарга тора. Бүгенге көндә халык тормышны матди яктан гына кайгыртырга , бер-берсен уздырырга тырышкан роботка әйләнеп бара. Алга таба да шулай дәвам итсә, кеше күңелендә матурлык булырмы. Байлык, муллык белән генә дөнья барырмы?

Элек-электән үк, кешенең кем икәнен, аның чын йөзен киеменә генә карап түгел, ә өенә һәм хуҗалыгын ничек алып баруына карап та билгеләгәннәр. Матур, чиста йортлар хуҗаларының уңганлыгын, осталыгын ачык күрсәтеп торалар. Тәрәзә, капкага ясалган кояш, төрле чәчәк бизәкләре, бу өйдә кунакчыл кешеләр яшәгәннәрен әйтәләр сыман. Ә бит мондый оста, матур итеп бизәлгән йорт-капкалар яныннан узып баруы үзе бер рәхәт һәм күңелле. Бик борынгыдан ук йорт, йортның капкасы, аның тәрәзә йөзләре хуҗасының көзгесе булып саналган. Ә хәзер мондый күренешләр бик сирәк.

Шулай да, киләчәктә, татар әдәбияты белән беррәттән яшәештә халыкның рухи дөньясын чагылдыручы йорт образын төзек, матур, мәһабәт итеп күрергә язсын иде!

Әдәбият

Татар әдәбияты: теория. Тарих / Д. Ф. Заһидуллина, Ә. М. Закирҗанов, Т. Ш. Гыйләҗев, Н. М. Йосыпова. Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.

Еники Ә. Сайланма әсәрләр. – Казан: ТаРИХ, 2002.

Исхакый Г. Сөннәтче бабай // Казан утлары, 2003. – № 10.

## ТАТАР, РУС ҺӘМ ИНГЛИЗ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРЫНДА СОМАТИК АТАМАЛАРНЫҢ МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Галәветдинова Диләрә,*
*КФУның Алабуга институты студенты*
*Фәнни җитәкче: Әхмәдгалиева Гүзәлия Габдрәүф кызы*

Кайсы гына телне алып карасак та, аның башкалардан аерылып торган үзенчәлеге була. Бер телдә синонимнар күп, икенче телнең лексик запасы аз булганлыктан, фигыльләр янындаярдәмче сүзләр килеп, гомумән икенче мәгънә сугарылган берәмлек китереп чыгаралар, өченче тел үзенең хәрефләр саны күп булу белән аерылып тора һ.б.Барлык телләрдә дә тотрыклы сүзтезмәләр, әйтемнәр, мәкальләр, җырлар, риваятьләр, әкиятләр бар. Бу гаҗәп түгел, чөнки санап үтелгән жанрлар халык иҗатына керә. Ә халык иҗат итми тормый. Бу жанрлар арасында иң кызыклысы, сөйләмебезне аеруча үтемле итүчесе – фразеологизмнар. Аларны өйрәнү безгә теге яки бу халыкның характерын, көчен, яшәү рәвешен халыкның фикерләү сәләтен, акыл дәрәҗәсен, зирәклегенбелүгә ярдәм итә. Акыл, зирәклек турында бик күп тотрыклы сүзтезмәләр бар. Наданлыкны, ялкаулыкны хурлап, тырышлык, белемгә омтылу кебек сыйфатны күтәреп чыкканнары да юк түгел. Кешенең бу сыйфатларын күрсәтү өчен, гәүдәнең баш өлешен бик киң кулланалар.

Фразеологик берәмлекләрдә кешенең бер әгъзасы аша өч телдә дә бер үк мәгънәне белдергән тотрыклы тезмәләр барлыгын күрә алабыз. Мәсәлән:

*авыз йомдыру (авыз ачтырмау)/затыкать рот/stop smb's mouth; тел тешләү/прикусить язык/hold one's tongue;акыллы баш/светлая голова/to have head screwed on, to have a clear head on one's shoulders;күз түбәгә менү (күзе маңгаена менгән, ике күзе дүрт булу)/глаза на лоб полезли/his eyes are popping out of head; колагына да элмәү/пропускать мимо ушей/turn a deaf ear to; борын төбеннән ары күрмәү/не видеть дальше своего носа/not see an inch before one's nose; кабак баш/дубовая голова/blockhead; караңгы чырай (йөз) белән утыру/иметь лицо мрачнее тучи/to have a face like thunder; каш җыеру/нахмурить брови/knit one's brows*[Гарифуллин 2010: 6,11,46,105,134, 213].

Санап үтелгән тотрыклы сүзтезмәләрдән күренгәнчә, һәр өч телдә дә кешенең бер үк әгъза аркылы бер үк мәгънә белдергән берәмлекләр ясалган. Бу төркемгә кергән фразеологизмнарның күп икәнен игътибарга алырга кирәк. Димәк, татар, рус, инглиз халкында баш, тел, күз, борын, колак, авыз, теш кебек

сүзләр бер үк вазыйфаны башкаралар һәм шул фунцияләре аша кешегә хас уңай һәм тискәре сыйфатларны күрсәтәләр.

"Баш" сүзен генә алыйк. Кешенең бу әгъзасы фикерләү, уйлау өчен кирәкле. Өч халык та шушы әгъза атамасын бер үк функциянең башкарылу сыйфатын күрсәтү өчен куллана:*кабак баш/дубовая голова/blockhead*тотрыклы сүзтезмәсен аерып карыйк. Ләкин аларның семантик төсмере,янында торган сүзгә карап үзгәрә. Татарлардагы "кабак", урыслардагы "дуб"ка (имән) караганда тизрәк чери, ә инглизләрдәге "block" сүзе дүрт ягы тигез булган, таш яисә нык агачан ясалган зур материалны аңлаткан сүз, гомумән, чермәскә мөмкин [Гарифуллин 2010: 94].

Шулай итеп, без бер мәгънәне белдергән, бер үк атамалар белән бирелгән сүзтезмәләрнең янында килгән сүзләргә карап, аларның семантик төсмерләре үзгә булуын күрәбез.

Икенче төркемгә без ике телдә генә мәгънәләре белән туры килгән сүзтезмәләрне алабыз. Татар һәм инглиз телендә эквивалент булырдайберәмлекләр бар: *күзе каты/the evil eyes;* рус һәм инглиз телендә:*око за око (зуб за зуб)/an eye for an eye (a tooth for a tooth); водить кого-то за нос/to lead smb by the nose; видеть невооруженным глазом/to see with the naked eye; делать что-либо с закрытыми глазами/to do smth with one's eyes closed;* рус һәм татар телендә:*авыз ачып тору/стоять разинув рот; баш белән җавап бирү/отвечать головой; башны катыру/морочить головуһ.б.*Бу исемлекне әле дәвам итеп була [Гарифуллин 2010: 5, 31, 33; Образовательные ресурсы интернета].

Күзәтүләребездән чыгып, шуны әйтә алабыз: татар һәм рус телендә булган фразеологизмнарның мәгънәви чагылышыбулган берәмлекләр инглиз һәм рус, яисә инглиз һәм татар телендәге эквивалентларга караганда шактый күп. Моннан чыгып, без татар һәм рус халкының бер территориядә яшәп килеп, ике халыкның бер-берсе белән тыгыз мөнәсәбәткә керүе һәм бер-берсеннән нинди дә булса сыйфатларның күчүе күзәтелә. Бу үз чиратында телгә дә йогынты ясый. Бу мәгънәви охшашлык шуның белән аңлатыла да инде.

Өченче төркемгә кергән тотрыклы сүзтезмәләрдә бер мәгънәне белдерү өчен кешенең баш өлешенә кергән әгъза атамаларын гына түгел, ә бөтен гәүдә атамалары кулланылган. Аларга *борын салындыру/повесить нос/to lose heart; тел әйләнмәү/язык не поварачивается/he won't have the heart to say it; теше тырнагы беләнябышу/ухватиться руками и ногами (ухватиться зубами)/cling like glim death; күз йому/смотреть сквозь пальцы/look through one's fingers at smth*кебек фразеологик әйтелмәләр керә. Мәгънәне җитерер өчен, бер телдә баш өлешенә кергән әгъза атамалары, әикенче телдә гәүдәнең башка өлеш атамалары аша бирелә. Мисал өчен, *"борын"*– *"нос"* (борын) – *heart* (йөрәк);*"тел" – "язык"* (тел) – *"heart"* (йөрәк); *"теш", "тырнак" − "руки"* (куллар), *"ноги"* (аяклар); *"күз" − "пальцы"* (бармаклар) − *"finger"*(бармак) [Гарифуллин 2010: 46, 132, 213, 219; Образовательные ресурсы интернета].

Тикшерүләр вакытына без шундый кызыклы очракка юлыктык: телләрдә фразеологизмнар синонимик рәт барлыкка китергәннәр. Татар телендә: *ике күз дүрт булу – күз маңгайга менү, күз түбәгә менү, күз шакмак булу* – болар барысы да шаккатуны, аптырауны белдерәләр. Рус телендә фразеологизмнар төзегән синонимик рәт:*ухватиться руками и ногами – ухватиться зубами*. Бу фразеологизмнар барлык игътибарны бер эшкә юнәлтүне аңлата. Инглиз телендә: *smb'sfacefell – hiseyesarepoppingoutofhead*. Бу фразеологизмнар шаккатуны, аптырауны белдерә. *To have a good (clear) head on one's shoulders – to have head screwed on*. Бу синонимик тотрыклы сүзтезмәләргә зирәклек, акыллы булу кебек мәгънә салынган.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк, татар, рус һәм инглиз телендә булган фразеологизмнарда бер үк әгъза атамасы аша бер үк мәгънәне белдергән сузтезмәләр күп. Бу күренеш үз чиратында әгъзаның фунциясенә бәйле. Шулай ук халыкларның бер территорияда яшәп килеп, аларның бер-берсеннән үзләштерелгән тезмәләр барлыгын әйтә алабыз.


Әдәбият

Гарифуллин С.Ф. Татарча-русча-инглизчә фразеологик сүзлек. Казан: Татарстан Республикасы "ХӘТЕР" нәшрияты, 2010. – 296 б.

Образовательные ресурсы интернета. Английский язык. [электронный ресурс] – URL: http://www.alleng.ru/d/engl/engl825.htm (дата обращения: 11.10.2017).


## КАЗАН ХАНЛЫГЫ


*Гамиров Алмаз,*
*Яр Чаллы шәһәре 54 нче гимназиянең XI сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Шәйхетдинов Рафил Сәлимҗан улы*


Казан ханлыгы элеккеге Алтын Урданың төньяк төбәгендә ярыйсы ук зур мәйдан биләгән. Аның территориясе көнбатышта Сура елгасына, ә көнчыгышка таба Агыйделнең Чулманга тоташкан урынына кадәр урынны биләп торган. Төньякка таба Казан ханлыгы мәйданы бүгенге Пермь крае якларына кадәр җиткән. Анда моны раслаган XIV-XV гасырдагы библиографик язмалар сакланып калган. Көньякта Казан ханлыгы биләмәләре Зур Чирмешән елгасы башына кадәр сузылган.

Казан ханлыгының мәйданы, аның гомуми җире, татарларны һәм Казанга буйсынып яшәгән башка халыкларны берләштергән бер дәүләт җире булып саналган.

Әмма Казан ханлыгы мәйданы территориаль чикләр белән билгеләнмәгән. Дәүләт чикләре ханлыкка салым түләүче җирлекләр белән исәпләнгән. Мордва, мари, чуаш, удмуртлар Казан ханлыгына ясак түләгән.

Ханлыкның иң зур шәһәрләре – Казан, Арча, Чаллы, Иске Казан. Казан ханлыгында ярты миллион кеше яшәгән.

Хан хакимияте чиксез дип саналган, тик аның янында морзалардан торган диван булган, ул күпмедер күләмдә ханның эшчәнлеген күзәткән. Бу диван вәкилләре "карачылар" (урыс чыганакларында – карачи) исемен йөрткән. Мондый шуралар Кырым, Себер, Касыйм дәүләтләрендә дә булган.

Тарихчылар фикеренчә, Казан ханлыгында Кырымдагы кебек үк дүрт карачы булган, ләкин бу тарихи яктан дәлилләнмәгән. Шулай ук тарихчылар ханлыктагы әмирләр шул ук карачылар статусы белән тигез булган дип аңлата.

Казан ханлыгында 30-50 мең кеше хәрби хезмәттә булган дигән мәгълүмат бар. Кайбер тарихчылар бу санны 7-10 мең сугышчы дип бирә. Яуга барганда яки саклану вакытында Казан ханлыгына Нугай Урдасы сугышчылары ярдәмгә килгән. Татар гаскәриләрнең төп көче – җайдаклар. Казан ханлыгының флоты да көчле була, XV гасырда татар дәүләтенең хәрби кораблары дошманнарга каршы торырга сәләтле була. Бишбалта бистәсе урынында Казан верфе була.Татар гаскәриләре кылыч яки уклар белән генә сугышкан дигән фикерне татар тарихчылары кире кага. Татарлар утлы корал да кулланган.

Казан ханлыгы тарихында унике сугыш була, шуларның дүртесе – татарларның һөҗүме. Тарихчылар фикеренчә, бу сугышлар җир биләмәләрен яулау өчен оештырылмый, ә һөҗүм итәргә уйлаган дошман гаскәриләрен көчсезләндерү максатыннан эшләнә.

1552 нче елда татарларның җиңелүенә китергән төп сәбәпләрне санап үтәргә кирәк. 1.Казан ханлыгының Рус дәүләте алдында дошманы булу, Россиянең агрессив сәясәте. 2.Свияжск крепосте төзелү һәм бер үк вакытта ханлыкның көнбатыш җирләрен аерып алу. 3. Шәһәрне һәм ханлыкны саклап калуның хәлиткеч вакытында патша хөкүмәте кушуы буенча хыянәтчеләр тарафыннан Казандагы утлы корал юкка чыгарылуы. 4. Татарларның ил җитәкчеләре арасында бердәмлек булмау. 5. Көнбатыштан басып керүгә каршы уртак көрәштә Казан-Нугай, Казан-Кырым, Казан Себер татар төрек берләшмәләре төзелүгә комаучаулау максаты белән Мәскәү актив рәвештә эш алып бара.

Әдәбият

История культура родного края /сост. Мифтахов Б.М., Исламов Ф.Ф. – Казань: Магариф, 1993. – 143 с.

Фәхретдинов Р.Г. Татар халкы һәм Татарстан тарихы. Тулыланд. 2 басма. – Казан: Мәгариф, 2001. – 287 б.

## М.МАЛИКОВАНЫҢ «КАР СУЛАРЫ», «САРЫ ТЮЛЬПАННАР» ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗ ОБРАЗЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

*Гарипова Наилә,*
*Яр Чаллы шәһәре 49 нчы кадет мәктәбенең VIII сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Фатыхова Әлфия Фәнәвил кызы*

Татлы да, газаплы да иҗат юлына Мәдинә Маликова очерклар, хикәяләр аркылы килә. Аның «Юлдашлар» исеме белән басылган беренче хикәяләренә күренекле тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин түбәндәгечә бәя бирә: «Хикәяләре шактый җыйнак һәм бөтен, һәркайсында истә калырлык образлар, матур эпизодлар» [Миңнуллин 1984: 251].

«Кыр ягы», «Күрше бәхете» кебек беренче хикәяләре арасында иң бәхетлесе – *«Кар сулары».* Ул хикәя татар укучылары тарафыннан шигъри әсәр кебек кабул ителә. Үсмер кыз Зәйтүнәнең күңел дөньясы искиткеч чиста, Рафиска булган тәүге мәхәббәте гаҗәеп саф. Әби-бабаларыбыздан килгән күркәм гадәтләргә булган игътибары, тыйнаклык һәм кешелеклелек сыйфаты бизи Зәйтүнәне.

Без авторның беренче әсәрләреннән үк хатын-кызның ир-ат ярдәменә мохтаҗлыгын күрәбез. Зәйтүнә дә Рафистан яклау көтә. Бәхетенә аның өмете аклана. Шулай бервакыт Зәйтүнәгә партадашы Нур бәйләнә башлый: әле бишмәт җиңеннән тарта, әле мыскыллы сүзләр әйтә, әле көлә. Рафис, кызны яклап, үзеннән шактый калку Нурның якасына ябыша һәм ачулы тавыш белән: «Син аны ник обижаться итәсең? – ди. Минем дә яклаучым табылды. Абыем кебек якын итүче, кирәк икән, минем өчен утка керүче кешем булды» [Маликова 1985:108].

Бу вакыйгадан соң Зәйтүнә үзендә ышаныч артуын тоя. Ә ышаныч һәм өмет булганда теләсә кайсы киртәләрне дә атлап үтәргә мөмкин. Төрле хәйләләр табып, йон юнәлтеп перчатка бәйләү һәм аны иясенә тапшыру шуның ачык мисалы.

Кечкенә генә хикәя. Ә аңа күпме матурлык салынган. Еллар аралыгында да «Кар сулары» хикәясе үзенең актуальлеген югалтмаган. Ул әле дә зур кызыксыну белән яратып укыла. Бу инде автор уңышы.

М. Маликова татар халкының гомер-гомердән килә торган яхшы әхлакый-этик сыйфатларының хәзерге яшьләрдә ни рәвешле дәвам итүен, үстерелүен, яңа төсмерләр белән баетылуын күзәтергә ярата. Автор кайнарлык белән кешеләр мөнәсәбетендәге сафлыкны, эчкерсезлекне яклый. Аның үткен күзләре беренче карашка зыялылык аңкып торган, яхшы холыкка ия булган кешеләрдәге буш күңеллелекне, әхлакый бозыклыкны тиз шәйли, ул аларга әдәп киртәләренә сыйган күләмдә җәза бирә.

*«Сары тюльпаннар»* хикәясе – язучының иң уңышлы хикәяләренең берсе. Монда да М. Маликова: «Бер нәрсәне һич кенә башыма сыйдыра алмыйм – ул да булса мәхәббәт өлкәсендә хыянәтнең, ялганның, мәрхәмәтсезлекнең,

шәфкатьсезлекнең җәзасыз калуы», – дип борчыла, үрсәләнә [Галимуллин 1985: 163]

Җәмгыятьтәге кешеләр үз эш-хәрәкәтләрен нигездә ике төрле үлчәүгә туры китереп карыйлар – хокук кануннары һәм әхлак таләпләре. Аларның беренчесе мәгълүм закон җыелмалары белән беркетелгән булса, икенчесен, гадәттә, язылмаган, әмма күпчелек тарафыннан һич шикләнми кабул ителгән гореф-гадәтләр тәшкил итә. Әлеге таләпләрне яхшы белү, ягъни хокук һәм әхлакый яктан грамоталы булу безгә туры юлдан баруда юнәлеш бирүче хезмәтен үти. Тик тормыш катлаулырак, ул бернинди кагыйдәләргә дә сыеп бетә алмый. Кайвакыт беренче карашка яхшы дигәнең начар, начар дигәнең яхшы булып чыгуы да бик мөмкин икән. «Сары тюльпаннар» әсәрендәге Люциядә яхшы сыйфатлар берничә кешегә бүлеп бирерлек. Югары уку йортын бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаган, аспирантурада калдырылган, егерме биш яшендә фәннәр кандидаты булган, хәзер докторлык диссертациясе өстәлендә ята. Кыз үзенең бик эшлекле булуы, җитди кыяфәте белән егетләрне дә бераз куркыткан, читләштергән. Әсәрнең үзендә үк аңа бик яхшы, дөрес бәя бирелә: «Һәрнәрсәне артык җитди кабул итә. Бер егетнең үзенә күзен төшкәнен сизде исә, бу миңа гомерлек яр була алырмы, мәхәббәте чынмы моның, юкмы дип тикшеренә башлый, егетне микроскоп асытына салгандай итә. Кемгә ошасын микроскоп астына керү!» [Маликова 1985:38].

Шушылай сайлану аны ялгызлыкка дучар иткән. Әгәр аны ярата калсалар, егетнең ямьсезлегенә дә ризалашыр хәлгә җиткән ул. Көннәрдән беркөнне кыз үзеннән сигез яшькә кече егеткә гашыйк була. Кешеләрне җентекләп өйрәнергә сәләтле кыз, егетнең гашыйк булучы ролен оста башкаруын абайламый кала. Әлеге егет, үзенең уенын уйнап туйгач, икенче бер кызга өйләнә. Бүгенге тормышта үз рәхәтлеге өчен генә яшәүчеләр аз түгел.

Әлеге хикәя төзелеше, вакыты белән салмак, кирәк чакта өермәле, кеше язмышының гыйбрәтле яклары күрсәтелү белән истә кала. Кыскасы, «Сары тюльпаннар» хикәясенең күпләргә сабак булуы бик ихтимал.

Язучының кайсы хикәясенә генә тукталсак та, без анда тормыш фәлсәфәсен күрәбез Алар шуның белән үзләренең актуальлеген югалтмый, укучыны үзенә тартып, кызыксындырып тора.

М. Маликованың хикәя жанрындагы табышлары турында күп язарга мөмкин булыр иде. Язучы Ринат Мөхәммәдиев та моны бик хаклы билгеләп үтә: «Һәр яңа әсәрендә язучы яшәү мәгънәсенең гасырлар дәвамында формалашып, камилләшеп килгән фәлсәфи нигезләре хакында уйга бирелеп, үз җавабын эзли, тормышка үз мөнәсәбәтен белдерергә ашкынып иҗат итә» [Галимуллин 1995: 106].

М.Маликованың без тикшереп үткән «Кар сулары», «Сары тюльпаннар» хикәяләрендә укучы үзен таба, үзен тапмаса, яшәү өчен сабак ала. Вакыт үткән саен тормыштан алып язылган әсәрләрнең рухи кыйммәте тагын да арта төшәр. Шунысы мөһим: бүгенге тормышыбызның чагылышы әдәби әсәрләрдә ачыграк күренә.

Әдәбият

1.Галимуллин Ф.Г. Офыкларны алдан күреп. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 106 б.

2.Галимуллин Ф. Такыялар балкышы // Казан утлары. – 1985 – № 9. – Б.163

3.Миңнуллин Ф. Талантлар юлы: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 251 б.

4.Маликова М.Г. Бер күрүдә яраттым. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 108 б.

5.Низаметдинов Ә. Кузгалды уйларым // Казан утлары. – 1993. – №3. – Б.152 .

## МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ТАБИГАТЬ КҮРЕНЕШЛӘРЕ

*Гарипова Элина,*
*Әлмәт шәһәре 13нче урта мәктәбенең XI сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Гарипова Айзирә Шамил кызы*

Беркемне дә кабатламый торган иҗат йөзе. Проза телен дә җырлатып торырлык иткән “Халык язучысы” дигән мактаулы исем, халкыбызның иң югары бүләге – Тукай премиясенә лаек булган танылган язучы-прозаик, үткен телле публицист, тәнкыйтьче, әдәбиятчы-галим, педагог...

Болар – татар әдәбиятына алтын хәрефләр белән язып куярлык исемгә лаек талантлы шәхеснең бу фани дөньяда кылган гамәлләренең кайберләре. М. Мәһдиевның прозада беркемне дә кабатламый торган үз язу манерасы бар. Аның йөгерек метафоралы, шаян, шук, җор һәм шул ук вакытта итагатьле стилен башка берәү стиле белән дә бутау мөмкин түгел.

Аның әсәрләрендә табигать һәм кеше мөнәсәбәтләре зур урынны алып тора. “Фронтовиклар” әсәрендә сандугач сайравы турында язучы менә болай яза: “Бакчада нибары бер сандугач сайрый. Аның кеп-кечкенә тамак төбеннән, бөтен авыл өстендәге атмосфераны дерелдәтеп, дөньяга моң тарала. Бу кош сайравы гына түгел, бу – гашыйкларның үзләре әйтеп бирә алмаган хисләренең авазга әйләнгән куәте, аһәңе. сандугач үзенең шул нәни тамагыннан чыккан куәтле музыканы ярып-ярып, катлау-катлау итеп авыл өстенә тарата, әйтерсең лә монда бармак башы кадәрле бер соры кошчык сайрамый, ә оста дирижер җитәкчелегендәге куәтле уйныйҗиз торбалардан бөтен планета халыклары өчен уртак булган сагыш көен уйный, бер тыңласаң, бу көйнең гаммасына аз гына соңга калып дистәләгән трубаларның көмеш чыңы өстәлә, икенче тыңласаң, бу көй – органда башкарылган Бах әсәре...”

М. Мәһдиевне укыганда, һәр фразаның интонацион рәсеме ап-ачык, фраза яңгырый, күңелгә генә түгел, бөтен тавыш күчешләре белән ишетелә кебек. Автор, күп язучыларга хас булганча, хикәя җөмләләр белән генә язмый. Җөмләләр төрле-төрле формадагы хәбәрләргә тәмамланалар, инверсия еш

очрый. Ул фразаның яңгырашын бик нечкә тоя, һәм һәр сүз үзенең табигый һәм бердәнбер кирәкле урынында урнаша: "Чү, кояш катыш рәшә, еракта, тугай артында сузылып яткан тау бите...үлән исе, тыгыз җил-су кинәт кенә күңелне кузгаттыгыз.

Тукта, исмә, җил, болын исе алып киләсең дә тын юлларын кытыклыйсың; хәтерне тирәнәйтәсең, элеккеге кадерле минутларны, йөрәк җәрәхәтләрен яңартасың.. ул вакытта ничек җырлыйлар иде әле?

Минем ямансу көннәрем, сайрама, кош, исмә, җил...

Кайда сез, ул кызлар? Кайда сез, ул егетләр?"

Авторның лирик герое – табигать баласы. Ул урмандагы агачларны күңел белән, йөрәге белән аңлый, казларның кемнедер чакырып, кемнәрнеңдер күңелләрен җилкетеп очып үтүләрен, торналар уяткан балачак хатирәләрен моңсу-сагышлы итеп әйтеп бирә белә. Урмандагы агачлар тормышын, наратлар шаулавын, язгы ташуны, табигатьнең яз көне уянуын, кар сулары, гөрләвекләр шаулавын, язның беренче көнен, язгы авылның һәр сулышын М.Мәһдиев шундый итеп сурәтли, укучының үзен шул урында, шул вакытта дип хис итә. Сүзебезне мисаллар белән дәлиллик:

Кояш чыгышын сурәтләү

"Әнә кар диңгезенең күк белән тоташкан урыныннан тәгәрәп кенә кызгылт-сары кояш чыгып килә. Кояш җир йөзенә һәр көн үзенчә чыга. Ул үзенең төслрен кабатларга яратмый. Бүген ул каты бураннардан соң беренче мәртәбә күренә. Шуңа, ахрысы, ул йончыган, арган кыяфәттә. Иртәнге салкынча җил иренеп кенә басу өстеннән кар сыпырып йөртә. Ул – кояш чыгуны тереклек дөньясына хәбәр итә. Кар дәрьясы өстендәге салкынча тыгыз һава аркылы узган кояш нурлары зәгыйфь, саргылт төскә кергәннәр. Кояш тирәсендә ниндидер бакр бөҗра. Ул бөҗра офыктагы аксыл томанга асып куелган кебек..." ("Фронтовиклар")

Язучы бу табигать күренешләрен сурәтләү белән беррәттән аларга җан өрә, кеше язмышлары, психологиясе белән чагыштыра. Мәсәлән: "Карт имәннәр салмак кына шаулыйлар. Җил имән агачларына кагыла, ахрысы. Имән тарихчы ул. Имән – урманның тарих укытучысы. Юкә, миләш, каен – алар җыр, әдәбият, рәсем укытучылары. Өрәңге кем? Белмәссең. Ихтимал, ул – изиктыр. Каты. Конкрет. Бәлки, математиктыр? Төгәл, гармонияләр белән исәпләшми.. әнә шуңа күрә аның орлыгы кыш көне оча. Янәсе, үз вакыты бар. Ә кышкы суык рәхимсез – синең орлыкларың өшер. Имән – тарихчы, монысы бәхәссез. Әнә карт имәннәр тирә-юньне шаулатып, нидер сөйлиләр. Сөйләгез, агачлар, сөйләгез. Бу якның халкы газаплы сугыш елларында ниләр күрде? Халыкның аһ-зарлары кайларга сеңде?" ("Фронтовиклар")

Шулай итеп, М. Мәһдиевнең әсәрәрен "милли байлыгыбыз" дип атарга мөмкин. Аның образлы теле, стилистик образлы чаралары, поэтик бизәкләре, телнең эчке җепләрен белеп эш итү – укучылар өчен туган телебезнең иксез-чиксез байлыкларыннан файдалану үрнәкләре ул.

Әдәбият

Авдеев А. С доброй улыбкой// Советская Татария, 1982. – 28 февраля.

Миңнуллин Ф. Якты юллар. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1975

Мәһдиев М. Фронтовиклар: Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. – Б. 43-46.

Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр. 3 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994, 1996, 1996.

## ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР МУЗЕЕ ТАРИХЫ

*Гарипова Юлия,*
*Түбән Кама шәһәре Баки Урманче исемендәге*
*2 гимназиянең VIII Б сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Моратова Лариса Миншаех кызы*

Бүгенге көндә кечкенә Ватан тарихларын өйрәнүгә игътибар арта. Тәрбия юнәлешендә алар мөһим чара булып торалар. Ә музейлар туган як тарихын чагылдыруда алыштыргысыз мәгълүмат чыганагы. Шуның өчен дә алга киткән кешелек дөньясын музейлардан башка күз алдына китереп булмый, чөнки аларда безнең үткәнебез. Ә үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк.

Музейлар тарихы бик еракка барып тоташа. Алар халыкларның рухи һәм матди культурасын саклыйлар. Музейларда без борынгы экспонатлар белән гына түгел, ә халыкларның мәдәнияте, менталитеты, тарихы, яшәеш үзенчәлекләре белән дә танышабыз.

Түбән Кама 2016 нчы елда үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Шуның өчен дә без хезмәтебезне Түбән Кама шәһәр музее тарихы дип атадык, чөнки төбәгебез тарихы шәһәр музее белән үрелеп бара.

Хезмәтебездә музей оешу тарихын барлау, бу эшкә күп өлеш керткән шәхесләребезнең хезмәтен бәяләү, гражданлык патриотик тәрбия бирүдә музейларның ролен күрсәтүне максат итеп куйдык. Моңа ирешү өчен берничә бурыч та билгеләдек:

1) музейлар тарихына багышланган фәнни әдәбият белән танышу;

2) Түбән Кама шәһәр музее тарихын өйрәнү;

3) шәһәр музее төзелешен өйрәнү һәм анда булган кешеләрнең фикерләре белән танышып нәтиҗә ясау.

Бүгенге көндә яшь буын шәһәр музей тарихы белән якыннан таныш түгел. Шуның өчен дә бу тема безнең өчен яңалык булып тора. Ә бит шәһәребез тарихында үзләренә аерым бер игътибар таләп итүче моментлар күп. Музей әнә шулардан берсе, чөнки ул-тарихи чыганак, анда күп кенә сорауларга җавап табарга мөмкин. Ә тарихны белү, һичшиксез, үткәнгә хөрмәт уята, фәнни-әхлакый якны баета, кешеләрнең уй-теләкләрен тирәнрәк чагылдырырга мөмкинлек бирә, халкыбызның зыялылык дәрәҗәсен билгели.

Шәһәр музее тарихын өч этапка бүлеп өйрәнүне күздә тоттык.

1 этап: 1976-1978 нче. 1976 нче елда музей беренче тапкыр үзенең ишекләрен ача. Музейнын беренче директоры Галина Николаевеа Зотина. Бу әле эшнең башы гына була. Шулай да таш кузгала. Шәһәр тарихында иң кирәкле моментлар, шәхесләр язмышы тарихка кереп калалар.

2 этап: 1978-2004нче. Ә 1978-2004нче елларда музейның тагын да зураюын, экспозицияләрнең артуы турында әйтә алабыз. Иң төп эш бу вакытта башкарыла. Музей директоры итеп Надежда Григорьевна Голоцан билгеләнә. Күргәзмәләр төрлелеге, эчтәлеге ягыннан аларның бай булуы күпләрне шәһәр тарихы белән кызыксынуга этәргеч ясый. Экспонатлар саны,14224 житә.

3 этап: 2004 нче ел һәм бүгенге көн. Ә инде туган шәһәребезнең көннән-көн үсүе, заман таләпләренә җавап бирерлек кала булуы 2004нче елда яңа музей ачылуга сәбәп була.

Бүгенге көндә музей заман таләпләренә тулысынча җавап бирә дип әйтә алабыз. Залларның саны беренче музейда 3 булса, хәзер 9га җитә. Мәйданы 4 тапкыр арта. Музей төзелеше һәм эчтәлеге ягыннан башкала музейларыннан һич кенә дә калышмый. Музей директоры вазифасын Атяпина Татьяна Влидмировна башкара. Экспонатлар саны 27112 тәшкил итә.

Түбән Кама үткән заманда,Бөек Ватан сугышы чоры, Ретро зал.Төп экспозиция – “Түбән Кама – нефтехимиклар каласы” дип атала, ул 4 залга урнашкан.

Фәнни тикшерү эше барышында соңгы 10 ел эчендә музейга килүчеләрнең саны буенча статистика уздырдык һәм шуның нәтиҗәләрен диаграммада күрсәттек. Соңгы елларда музейга килүчеләрнең саны арта димәк, халыкның культура дәрәҗәсе үсә, шунысы безне бик сөендерә.

Сыйныфташларымның да 90% артыгы музейда булган. Иң кызыктырган экспозиция “Бөек Ватан сугышы чоры”. Музейдагы күп материаллар, документлар, экспонатлар бер көндә генә жыелмаган. Алар 40 елдан артык тупланып килә һәм бүген дә музей хезмәткәрләре бу өлкәдә армый-талмый хезмәт итә. Фәнни эш барышында фәнни җитәкчем белән шәһәр музеенда еш булырга туры килде.

Музей хезмәткәрләренең тырышлыгына, сабырлыгына таң калып тордым.Һәр килүчене алар ачык йөз белән каршы ала, кирәкле мәгълүмат бирә. Бер дә авырсынмыйча халыкка хезмәт итә алар.

Музейлар күпме кешеләрнең аң, белем, физик хезмәт нәтижәсе ул. Шәһәрдәшләребезнең киләчәк буынга житкерергә теләгән күпме мәгълүматны таба алабыз без анда. Шуның өчен дә дәүләт тарафыннан музейларга игътибар күбрәк булсын дип ышанып каласы килә.

## Әдәбият

Загидуллин И.К. История татарского народа (XVII- начало XX вв.): учеб. пособие для 11 кл. шк. с рус. яз. обучения (профильный уровень). – Казань: «Мәгариф», 2010. – 319 с.

Мушарова В.М. История культуры Татарстана: Учеб.пособие для учащихся общебразоват.учреждений, студентов спец. ивысш. учеб. заведений. Казань: «Мәгариф», 2010. – 287 с.

Пашков Б.Г. Русь – Россия – Российская империя. Хроника правлений и событий 862-1917гг. – 2-е изд. –М.: Центрком, 1997. – 640 б

## ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕ

*Гарифуллина Алия,*
*Әлмәт шәһәре, 13 нче мәктәбенең IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Борһанова Рамилә Ринат кызы*

Әкият – халык авыз иҗатының борынгы, киң таралган һәм мавыктыргыч җанрларның берсе. Әкиятләрдә халыкның күп гасырлык тормыш тәҗрибәсеннән туган зирәклеге, тапкырлыгы, яхшылык һәм явызлык, киләчәккә өмет һәм хыяллары чагылган. Әкият кешеләрне игелекле, тугры һәм мәрхәмәтле булырга өйрәтә, явызлыкны гаепли, гаделлекне хаклыкны яклый. Әкиятнең туу вакыты – ул нәкъ менә изге хикәянең нәфис хикәягә әверелеп киткән чагы. Йоладан аерылган хикәя шулай ук үзенең “изге”леген җуя һәм барлык кешеләр өчен дә сөйләнелә башлый. Әкиятнең мөстәкыйль жанр булып формалашып җитүе борынгы община строеның таркалу чорына туры килә. Шул чордан башлап әкиятэстетик вазифа үти башлый.

“Әкият” гарәпчә хикәят сүзенең фонетик яктан үзгәрүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Өлкән буын вәкилләре арасында әкиятне хикәят дип атаучылар бүген дә очрый.

Әкият – фольклорда катлаулы күренеш. Әкият – ул халык поэтик авыз иҗатының төп жанрларының берсе булып, уйдырмага таянган, тылсымлы, маҗаралы яисә көнкүреш характерындагы эпик, башлыча чәчмә сәнгать әсәре. Фәнни-тикшеренү максатларында әкиятләр күп халыкларда өч төргә бүлеп карала:

1. Хайваннар турында әкиятләр;
2. Тылсымлы әкиятләр;
3. Көнкүреш әкиятләре.

Татар халык әкиятләрендә хайваннар турындагы әкиятләр күп түгел. Язмалар саны буенча исәпләгәндә, алар чама белән әкият репертуарының 5 процентын тәшкил итә. Бу әсәрләрнең күләмнәре дә зур түгел. Хайваннар турындагы әкиятләр әкият жанрының гына түгел, бәлки гомүмән фольклорның иң борынгы күренешләреннән санала.

Тылсымлы әкиятләрнең нигезендә могҗизалы уйдырма ята. Галим М.Бакиров фикеренчә, “ул ике төрле башлангычка – тылсым һәм фантастикага нигезләнә. Тылсым борынгыларның мифологик карашлары нигезендә барлыкка килгән төрле саклану чараларын һәм ниндидер теләк максатка ирешүдә ярдәм итәргә исәп ителгән магик предметларны һәм сүз-догаларны, шулай ук магик гамәл-йолаларны да үз эченә ала” [Бакиров, 2008:119]Төрле серле предметлар:

каурый, көзге, тарак һ.б. тылсым көченә ия әйберләр әкият героена батырлыклар кылырга һәм дошманны җиңәргә ярдәм итәләр.

Тылсымлы әкиятләрнең бер тармагы булган батырлар турындагы әкиятләрдә("Ак бүре", "Камыр батыр", "Таң батыр" һ.б.) геройның икенче дөньяга – еш кына җир асты дөньясына сәяхәте һәм аннан кыз алып кайту – шаманның үлеләр дөньясына барып авыру кеше җанын алып кайтуын гәүдәләндерә. Димәк, бу төр әкиятләренең шаман легендаларының да сизелерлек роле булган дип әйтергә була. Без әкиятнең дин белән бәйләнешен күрәбез. Тылсымлы әкиятләргә шулай ук вакыйгаларның күп мәртәбә кабатлануы хас. Бу – әкият композициясенең үзенчәлекле законы, һәр кабатлауда каршылык арта, катлаулана. Бу бигрәк тә геройның авыр бурычлар башкаруы вакытында күренә.

Тормыш-көнкүреш әкиятләренең эчтәлеге, исеменнән үк күренгәнчә, тормыш-көнкүешкә якын тора. Алар күләм ягыннан кыска булалар. Бу төр әкиятләренең нигезендә аерым кешеләр яки гаилә әгъзалары арасындагы конфликт, яки иҗтимагый мөнәсәбәтләргә бәйле конфликт ята. Көнкүреш әкиятләрен М.Бакиров түбәндәге төркемнәргә бүлеп карарга тәкъдим итә:

1. Гаилә-шәхси көнкүреш әкиятләре.
2. Социаль -көнкүреш әкиятләре.
3. Гыйбрәтле әкиятләр.
4. Маҗаралы әкиятләр.

Бу төр әкиятләрдә һәрвакыт ниндидер көлкеле ситуация туа һәм еш кына вакыйгалар акылга сыймаслык чишелештә тасвирлана. Геройлар да, вакыйгалар да гадәттән тыш күпертелеп сүрәтләнә. Төрле образлар капма-каршы куела. Еш бу төр әкиятләрнең исемендә үк антоним төшенчәләр күзәтелә.

Әдәбият

Бакиров М. Татар фольклоры. Әкиятләр – Казан: Мәгариф, 2008.-359 б. – Б.116-135.

Урманче Ф. Татар халык иҗаты: Әкиятләр. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 81-107.

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ТЫЛСЫМЛЫ ӘКИЯТЛӘРЕНДӘ ОБРАЗЛАР СИСТЕМАСЫ

*Гарифуллина Лия,*
*КФУның Алабуга институты студенты*
*Фәнни җитәкче: Хәйруллина Әлфирә Сәлихҗан кызы*

Әкият – халык иҗатының бик борынгы жанры. Аның тамырлары кешеләрнең әле ыруг-кабилә булып берләшеп яшәгән чорларына барып тоташа. Барыбызга да билгеле булганча, борынгылар табигатьтән куркып, явыз көчләргә ышанып яшәгәннәр. Шуңа бәйле рәвештә төрле легенда-риваятьләр туган. Ә алар исә, үз чиратында, әкиятләрнең нигезен тәшкил иткән. Хәзер инде

без тылсым сүзенә килеп җиттек. Тылсымлы әкиятләргә күз салыйк. Еш кына легенда-риваятьләр үзәгендә нинди дә булса могҗиза, тылсым ята. Аларның үзәгендә – сихри сәләтләргә ия булган кеше, яисә фантастик образ була. Шушы фантастик күзаллаулар, табигать көчләренә ышанудан татар халкы иҗатында зур күпчелекне биләп торган тылсымлы әкиятләр формалашкан.Зур күләмгә ия булуга да карамастан, аларны укучы – олысы да кечесе бик яратып укый. Бу тылсымлы әкиятләрнең сыйфатларына бәйле. Әлеге төр әкиятләрнең нигезендә могҗизалы уйдырма ята, һәм ул ике төрле башлангычка – тылсым һәм фантастикага нигезләнә [Бакиров М.Х. 2008:119]. Әйтик, мәсәлән, әкиятләрнең күпчелегендә гади егет Дию пәриен дә, аждаһаны да җиңә, кешеләр төрле образларга керә алалар, кошлар, хайваннар сөйләшә беләләр. Тылсымлы әкиятләрдәге вакыйгалар куркыныч, гаять шомлы күренешләр булу белән бергә, мавыктыргыч, маҗаралы да. Икенчедән, тылсымлы әкиятләр үзенчәлекле образларга ия. Хәзер инде менә шул образлар системасын карап үтик.

Күп кенә тылсымлы әкиятләрнең үзәгендә патша образы, аның гаиләсе тора. Һәм, кагыйдә буларак, ул гаилә әһелләренең кайсысына булса да ниндидер зыян килә. Шул күңелсез вакыйгалар үзе белән тагын бер үзәк образ – батыр егет образын китерә. Ул дөньяда булмаган фантастик алымнар белән явызлык корбанын коткара, яисә ниндидер усал көчләр белән көрәшеп, аларны җиңә. Мисал өчен, “Алтын алма” әкияте [Бәширов Г., Ярми Х. 1956: 75]. Патшаның алтын алмалар үстерә торган бакчасындагы алмагачлар өч елга бер тапкыр гына җимеш биргән. Бервакыт алтын алмалар югала башлагач, патша шул бакчаны саклап кала алган кешегә ярты патшалыгын вәгъдә итә. Бу бәладән патшаны кече улы коткара.

Тылсымлы әкиятләрдә еш кулланылучы Дию – гадәттә, кеше аягы басмаган ерак җирләрдә яшәүче образ. “Өч күгәрчен” әкиятендә без танышкан дию [Бәширов Г., Ярми Х. 1956:1] җиде диңгез артындагы сигезенче диңгез утравында яши. Күп әкиятләрдә, “Мәрмәр тавы башында” әкиятендә, мисал өчен, кирегә кайтыр юллар юк: “аннан кайтмак юк инде”. Дию образы татар халык авыз иҗатына фарсылардан килгән дигән караш яши. Бу хакта А.А.Семенов болай дип яза: “Аларның торагы – таулар эчендә, җир карынында һәм күлләр төбендә. Диюләр анда җир асты хәзинәләрен саклыйлар. Диюләр бөтен кешелекне дошман күрәләр һәм кешеләр белән беренче очрашуда аларны үтерәләр яисә үзләренең чирканыч торакларына алып китәләр” [Гамбәров Н.Г. 1978:10].

Дию белән бергә татар халык авыз иҗатында өч, алты, җиде, тугыз һәм унике башлы Аждаһа да яши. Әлеге образ, гадәттә, тискәре сыйфатларга ия. Ул кешеләрне ашый, патшаларга зыян китерә. Кагыйдә буларак, Аждаһалар куе урманнарда, диңгез төпләрендә яшиләр. Мондый үзенчәлекле образ белән без “Аучы” әкиятендә очрашабыз. Аның гамәлләрен егеткә патша кызы сөйләп бирә: “Безнең шәһәрне Аждаһа харап итә. Көн дә бер кешене ашап китә. Бүген

Аждаһа мине ашарга килә. Моңарчы чират белән тордылар. Бүтән кешеләр ашалып бетте” [Гамбәров Н.Г. 1978: 56].

Тылсымлы әкиятләргә “җалмавыз”, “сихерче карчык” яисә “карчык” дип исемләнгән явыз карчык образы хас. “Көнгә күренмәс Сылу – көмеш” әкиятендә өч карчыкның берсе явыз була: этенә сөяк бирми, печән ашата. Кечкенә Сылу – көмешне урлап алып китә. Карчыкның явызлыгын Сылу түбәндәгечә сурәтли: “кечкенә чагымда мине бер бай карчык, урлап алып китеп, айга – көнгә күрсәтмичә, шушы яшемә хәтле җиде капка, җиде кат стена эчендә асрады” [Бәширов Г., Ярми Х. 1956: 186].

Әкиятләр кешеләрнең табигатьтән куркып, сихер – тылсымга ышанып, төрле образлар уйлап табуыннан туган дидек. Ул әкиятләрдә сихер зур урын алып тора. Төп образлары булып сихерче кешеләр күзаллана. Шундый әкиятләр арасына “Агачка әйләнгән егет” әкияте дә керә. Анда без сихерче карчык белән танышабыз. Ул бер патша улын сихерләп, аны агачка әйләндергән [Гамбәров 1978: 94].

Тылсымлы әкиятләр зур күләмгә ия булуга карамастан, укучы күңелен тиз яулый, аларны укыган саен укыйсы килә. Димәк, әлеге әкиятләрнең тылсымлы образлар системасы могҗизалы сюжетка бәйле рәвештә барлыкка килә. Тылсымлы әкиятләр кешеләрне фантастика иленә, гади тормыштан читкә алып китә, беркадәр тормыш авырлыкларыннан арынып торырга ярдәм итә. Әкиятләрнең яхшылык белән тәмамлануы исә аларны тормышта яңа үрләр яуларга, сынаулар алдында сыгылмаска, җиңеп чыгарга өнди. Тылсымлы әкиятләр заман яңалыклары арасында чуалган гади тормыш кешесенә ял, рухи байлык бирүче чыганак булып тора.

Әдәбият

Бәширов Г., Ярми Х. Татар халык әкиятләре, икенче китап – Казан: Таткнигоиздат, 1956 – 390 б.

Гамбәров Н.Г. – Татар халык иҗаты. Әкиятләр (икенче китап) – Казан: Татар.кит. нәшр., 1978. – 445 б.

## ЯЗУЧЫЛАР ИҖАТЫНДА ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ

*Гарифуллин Ришат,*
*Яр Чаллы шәһәре 13 нче урта мәктәпнең IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Латыпова Эльвера Гыйлемҗан кызы*

Әдәбиятның һәм сәнгатьнең кеше тормышы өчен әһәмияте чиксез. Рухи камиллеккә омтылган кешелекне тәрбияләү чарасы буларак әдәбиятның, сәнгатьнең, театрның роле бәяләп бетерә алмаслык зур. Без бер генә минутка үзебезне Тукайсыз итеп күз алдына китереп карыйк. Яки бөек Салих Сәйдәшевсез? Тиңдәшсез Кәрим Тинчуринсыз? Яки Җәлилсез?! Тагын бер генә минутка үзебезне «Шүрәле»сез, «Зәңгәр шәл»сез, «Моабит дәфтәр»сез

итеп уйлап карыйк. Шушы бер минут эчендә дә без үзебезнең ни кадәрле ярлы икәнлегебезне чамалап өлгерер идек. Илебездә булсын, чит җирләрдә булсын, танышканда үзебезнең исемнәрдән элек без Тукай, Җәлил исемнәрен атыйбыз, халкыбызның героик үткәне белән, матур бүгенгесе белән хаклы рәвештә горурланабыз. Шушы горурлык хисе безгә сәнгать аша, әдәбият аша сеңә.Бер генә минутка үзебезне, бүгенге татар театрын, драматургиябезне Туфан Миңнуллинсыз күз алдына китереп карыйк әле?! Шул минут эчендә дә без үзебезнең шактый фәкыйрь икәнлегебезне, бик күп уйлардан, шатлыклардан, сөенечләрдән мәхрүм икәнлегебезне бәяләп өлгерер идек!

Туфан Миңнуллин безнең өчен тагын да зураеп, олпат Ил агасы, милләт язмышы өчен кайгырып, ил борчуы белән борчылып яшәүче һәм иҗат итүче олуг зат, фидакарь шәхес булып күз алдына килеп баса. Бу сүз, бу исем тарих чоңгылларында бата-чума мең бәлаләр кичеп бүгенге көнгә килеп җиткән татар язмышына бик тә аваздаш шәхес...

Туфан Миңнуллин әсәрләренең барысы буенча да кызыл җеп булып барган проблема — туган телне, гореф-гадәтләрне саклау проблемасы. Автор бүгенге җәмгыятьтә бик актуаль булган татар милләтенең язмышы турында сөйли, аның киләчәген кайгырта.. Үзгәртеп корулар чоры тудырган проблемаларны Туфан Миңнуллин алдан күрә һәм сәхнәгә чыгара белде. Шундый проблемаларның берсе – аны һәрвакыт борчып-бимазалап торганы, ул – халкыбызның бүгенге язмышы, үткәне һәм киләчәге.

Гомумән, безнең язучыларның күпчелеге милләтебез язмышына борчылмый калмаган һәм ул бүген дә шулай. Моның сәбәбе дә ачык, билгеле. 1952 елда мөстәкыйльлеген югалткан халык, бетәргә хөкем ителгән саналып,эзәрлекләнә, сыегая, вагая, милли асылын җуя бара. Нинди генә акыл иясе моңа битараф калсын?! Гаяз Исхакыйны гына алыйк. Иҗатын иҗтимагый тормыш корылышы, сыйнфый тигезсезлек мәсьәләләрен үзәккә куеп башлаган (“Тартышу”, “Алдым-бирдем” әсәрләрендә ) автор тора-бара беренче урынга милләтебез язмышын чыгара. Без моны “Зөләйха”, “Мөгаллимә”, “Олуг Мөхәммәд” әсәрләрендә ачык күрәбез.

Болар, әйтерсең лә, Туфан Миңнуллинның кырык еллык иҗатының нигез ташлары булып тора. Чөнки бүгенге заманда үтә дә кискен төс алган күренешләр – милләт, тел язмышының аянычлылыгы, кешеләрдәге әхлаклылык-әхлаксызлылык сыйфатлары кинәт кенә туган әйберләр түгел.Аларның яралгылары күптән барлыкка килгәннәр.

Үзгәртеп корулар чорына килеп кергәч, Туфан Миңнуллин кеше язмышын җәмгыять һәм милләт язмышы белән тыгыз бәйләнештә алып сүрәтләүдә, татарның милли йөзен саклап калу өчен көрәш юлларын тасвирлауда яңа баскычка күтәрелде.

Милләтебезнең эреп югалуына алып барачак төп сәбәпләрнең берсен Гаяз Исхакый динебезне югалтуда күргән иде. “Әүвәл әхлак бозыла, икенче, дин бетә, өченчедән, ул халык үзе бетә”, – дип язган. Мәсәлән, “Зөләйха” драмасы белән ул көчләп чукындыруга каршы чыккан. Туфан Миңнуллин бу фикерне

дәвам итә, алай гына да түгел, тирәнәйтә. Милләтебезнең акрынлап сыегая баруын ул рус һәм татар арасындагы катнаш никахларда да күрә.Әгәр дә урыс татарны катнаштырган никахлары белән канәгатьләнә һәм горурлана алса, без, "кече милләт" вәкилләре, моны әйтә алмыйбыз. Ни өчен? Моңа ачык җавапны Т.Миңнуллинның үзгәртеп корулар чорындагы иң көчле әсәрләреннән берсе булган "Илгизәр +Вера"(1992) пьесасында табарга мөмкин.

Телне саклау мәсьәләсенә килгәндә дә, без тулысы белән Туфан аганың сүзләре белән килешәбез: «Телне саклау җәмгыятьнең әйдәп баручы кешеләреннән тора. Безнең моңа иң комачаулый торган кешеләр – чиновниклар. Чөнки чиновниклар белән каракларның милләте булмый», – ди ул [Миннуллин 1997].

Т.Миңнуллин иҗатында халкыбызның милли өметләре, хисләре, бай образлар дөньясы искиткеч тирән һәм тулы чагылды. Чынбарлыкны сурәтләүдә һәрвакыт тарихи дөреслеккә омтылган иманлы милли әдип ул Т.Миңнуллин. Ил язмышы, халык язмышы хакында сүз барганда ул беркайчан да читтә калмады.Үзенең әсәрләрендә Туфан Миңнуллин тормышчан геройлары аша халкыбызның милли йөзен, гореф-гадәтләрен, иң матур сыйфатларын-хезмәтне ярату, өлкәннәргә хөрмәт,буыннар арасында рухи бәйләнеш, яшәү дәрте, әхлакый кануннарга тугрылык һәм башкаларны яктырта алды. Ул еллар үтеп тә югалмас, алтыннарга тиң зур мирас калдырды.Туфан Миңнуллиннын таланты милләт язмышын үз язмышы итеп яшәвендә, көчле-куәтле, серле-мәгънәле, шифалы-бәрәкәтле әсәрләр иҗат итүендә,үз халкының бәгырь кисәге, газиз баласы һәм яклаучысы була алуында!

Шулай итеп, беренчедән, Туфан Миңнуллин үзгәртеп корулар чоры тудырган проблемаларны, аеруча халкыбызның бүгенге язмышы, үткәне һәм киләчәге өчен борчылып, үз әсәрләрендә күрсәтә алды. Икенчедән, язучы кеше язмышын җәмгыять һәм милләт язмышы белән бәйләнештә карап, халкыбызның милли йөзен, гореф-гадәтләрен тасвирлау аша һәр кешенең үз алдындагы торган бурычларын онытмаска тиешлеген искәртте. Өченчедән, Т.Миңнуллин милләтнең бөтенлеген саклау – бүген безнең төп бурычларыбызның берсе икәнлеген аңлатты.

Әдәбият

Әхмәдуллин А.Г. Күңелләрне уятыр: – Казан: Мәгариф ,2007.-223б.

Вәлиев Р. Җанга уелган уйлар. – Казан, Татар. кит.нәшр., 2011.

"Дуслар җыелган җирдә" Туфан Миңнуллин турында замандашлары //Идел, 1995.-159 б.

Миңнуллин Т. Сайланма әсәрләр. 5том. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2002.

Миңнуллин Т. Утырып уйлар уйладым. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1997.

Нуруллин И. Кеше һәм драматург! // Мирас, 1995. — №19. – Б.53.

Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия, 2 нче том – Казан: ТаРИХ 2003.

# РАБИТ БАТУЛЛАНЫҢ “КЫЛДАН НЕЧКӘ, КЫЛЫЧТАН ҮТКЕН” РОМАНЫНДА Г.ТУКАЙ ОБРАЗЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

*Гаффарова Алсу,*
*КФУның Алабуга институты студенты*
*Фәнни җитәкче: Камаева Рима Бижҗан кызы*

Татарның бөек шагыйре Габдулла Тукай исән вакытында ук халык күңелендә үзенә бер аерым урын алды. Халык аны азатлык, мәгърифәт җырчысы, кимсетелгәннәрнең яклаучысы, караңгылыкка каршы торучы итеп яратты.

Ул шигърият телен хезмәт ияләренә якынайтты, әдәбиятны үз заманының иң үткен, иң авыр мәсьәләләрен һәм ихтыяҗларын хәл итүгә хезмәткә җикте. Тукай иҗаты татар әдәбиятын еракларга таратты.

Шуңа күрәдер, хәзерге заман язучы һәм шагыйрьләре дә Г.Тукай образына мөрәҗәгать итәләр. Бу шул чордагы тарихны чагылдыру, авторның бөеклеген ассызыклау белән бәйле.

Рабит Батулла Г.Тукайга багышлап биш әсәр язды. Болар: “Сират күпере”, “Кылдан нечкә, кылычтан үткен”, “Күк капусы ачылганда”, “Апуш – Тукай”, “Зәйтүнәкәй”.

“Кылдан нечкә, кылычтан үткен” романы шагыйрьнең соңгы көннәрен тасвирлый. Г.Тукай образы уңай яклардан гына ачыла. Романда Тукай һәм Шәүлә образлары арасында каршылык бара.

“Тукай. Төш күрдем бугай мин... Имеш, урамда мин, нәмаешта. Халык белән бергә каядыр барабыз. Шатланабыз, кычкырабыз. Кинәт күктән зур каракош кешеләрнең башларын, күзләрен чукырга тотынды. Мин кычкырам, каракошка ташлар атам. Аннан кинәт кенә үземне читлектә итеп күрдем... Читлектә, төрмәдә..." [Башкуров 1958 : 52].

Каракош образы символ буларак кабул ителә. Ул-Рәсәй хөкүмәте. Ә Тукай милләт сагында торучы, хакык бәхете өчен көрәшүче шәхес. Шагыйрь халыкка хезмәт итү өчен үзенең мәнфәгатьләрен икенче урынга куя.

Әсәрнең төенләнеш өлешен “Тукай каты авырый” дигән телеграмманың сугылу вакытын әйтеп була. Бу ялганнан соң Тукайның дуслары берәм-берәм аның хәлен белергә килә башлыйлар. Ләкин, бу алдан уйланып куелган, планлаштырылган эш булып чыга.

Ядкәр Хөрмәтовны (революционер Хөсәен Ямашев) Тукай янында булганнан соң тотып алалар.

Чыннан да, Габдулла Тукайның таянырлык дуслары бар. Күршесендәге Агабәк (Фатих Әмирхан) шагыйрьгә яшәргә көч биреп тора. Алар һәммәсе шагыйрьнең иҗтимагый тормышындагы, милләт язмышындагы урынын ачыкларга, аның әдәбиятка карашын, иҗат кешесенең җәмгыять тормышында биләгән урынын күзаллавына төшенергә, шагыйрьнең нинди граждан һәм патриот икәнлеген гәүдәләндерергә булышалар. [Батулла 2011: 147].

Тискәре образларга килгәндә исә бу - Шәүлә. Ул мәрхәмәтсезлекне, икейөзлекне һәм астыртынлыкны гәүдәләндерә.

Рабит Батулла романда Тукайны бай рухи дөнья һәм мәхәббәткә ия булган чын кеше итеп тасвирлый. Г.Тукай үтә дә туры сүзле, кыю, тирән белемле, халкы өчен терәк һәм кирәк булган образ рәвешендә бирелә. “Минем өчен түгел андый тормыш. “Мин тулаем халыкныкы! Башым, иҗатым, авыруым белән мин халыкка кире кайтарып алмаска тапшырылган. Мин гаиләдә вакланып бетсә, халыкка ни калыр? Шуңа күрә мин беркайчан да өйләнмәскә уйладым,” – ди Тукай [Башкуров 1958: 55]. Автор тарафыннан бирелгән соңгы сүзләр дә шул рухта яңгырый. “Кыйналып-суелып Бетмәгән Шигъри динем исән бул! Изелеп-кырылып Үлмәгән Татар халкым, исән бул!”

Тагын шуны билгеләп үтәргә кирәк: Г.Тукай хыял образ буларак түгел, ә киресенчә җир кешесе буларак ачыла. Аңа да дөньядагы бар хисләр таныш: мәхәббәт, сөю, уйлану, киләчәк турында тетрәнү һ.б.

Гомумән алганда, Рабит Батуллының “Кылдан нечкә, кылычтан үткен”романы Тукай образына, шәхесенә характеристика бирү белән генә тукталмый, ә, киресенчә, зуррак темага кагыла. Бу - тарих һәм аңа мөнәсәбәт. Автор Рәсәй хөкүмәте белән кәнәгать түгел, асылда менә шул проблема ята да инде.

Әдәбият


Батулла Р. Сират күпере. – К., 1990.

Батулла Р. Күк капусы ачылгандагы могҗиза // Идел. – 2011. – №1-4.

Башкуров Р. Тукай һәм рус әдәбияты. – Казан, 1958. –119 б.


## БҮГЕНГЕ КӨНДӘ ТЕЛ КУЛЬТУРАСЫ


*Гәрәева Диләрә,*

*Яр Чаллы шәһәре 4 нче урта мәктәбенең IX сыйныф укучысы*

*Җитәкче: Шиһапова Азалия Рәсим кызы*


Тел милләт белән бергә туа, бергә үсә һәм милләтнең иң ышанычлы юлдашы булып яши. Күп гасырлар буена телебез үскән, шомарган һәм әдәби тел нормалары барлыкка килгән.

Бүгенге көндә сөйләмә телебездә дә, язма телебездә дә төрле сәбәпләр аркасында шактый күп кенә ялгышлар хөкем сөрә. Тел хаталары күп төрле. Алар сүзләрнең кайбер авазларын әйтә белмәүдә, басымнарын дөрес куймауда да, сүзләрне ялгыш мәгънәдә һәм урынсыз куллануда, сүзләрнең һәм җөмләләрнең табигый төзелешен бозуда чагылыш таба.

Дөрес сөйләмгә ирешү өчен, беренчедән, хәзерге вакытта телдә урын алып торган ялгышларны күреп төзәтә белү кирәк булса, икенчедән, аларның барлыкка килү сәбәпләрен ачыклау әһәмиятле.

Телебез бозылуның төп ике сәбәбе бар. Беренчесе - балаларны гаиләдә туган телләрендә тәрбияләмәү, икенчесе, татар теленә уртак аралашу чарасы -

урыс теленең йогынтысы. Шулай да әлеге йогынтының уңай һәм тискәре яклары да бар. Уңай ягы шунда ки: татар телендә гомуми аралашу теле тәэсирендә яңа күренешләр барлыкка килә, ә тискәре ягы – үзара бәйләнештәге телләрдән аларны камил белмичә файдаланган очракта, табигый булмаган сүзләр, әйтелмәләр, грамматик формалар, сәнгатьлелек-сурәтләү чаралары үтеп керә, һәм нәтиҗәдә телебезнең меңнәрчә еллар буена формалашып, камилләшеп килгән табигый чаралары бозыла, гариплә нә яки юкка чыгарыла, алар урынына чит тел күренешләре килеп керә.

Тел мәсьәләсе барчабызга кагылса да, кулланырга тотынсак, чын мәгънәсендә проблемалар килеп чыгып тора.

Тел – гомуми төшенчә. Безгә – адәм балаларына газета, радио-телевидениегә ул, куллану өчен кирәк . Әлбәттә, тел - беренче чиратта аралашу чарасы. Ул аерым шәхесләргә дә, җәмгыятькә дә бәйләнгән, һәм – әйтмә сөйләмдә барлыкка килә.

Телебез бик бай, әмма ул байлыкны бозып түгел, ә кызыклы итеп кулланырга кирәк. Радиода ул үзенчә, телевидениедә, яки газета һәм интернетта үзенчә булырга мөмкин. Массакүләм мәгълумат чаралары, алар әйдәп баручы, анда ялгыш язалар, анда хаталы сөйлиләр икән, башкалар да шуңа иярә, шуны кабатлый. Халыкның телгә таләпчәнлеген үзебез үк тәрбияләргә тиешбез. Моның өчен куркып түгел, хата китмәс микән, дип алдан уйлау мөһим.

Мәсәлән:

1. “Шәһри Чаллы” гәҗитендә хаталарны табу һәм дөресләү.
2. “Күңел радиосы” ди джейлары җибәргән хаталарны карап үтү.

Хаталарны караганнан соң мин, аларны өч төркемгә бүлдем:

1. Грамматик хаталар.
2. Стилистик, семантик хаталар.
3. Җөмләдә сүз тәртибе.

**Грамматик хаталар**: -учы/-үче кушымчалы сыйфат фигыль. Мәгълүм булганча, бу кушымчалар бары тик кешегә карата гына кулланыла. Эш – хәрәкәтне, процессны субъект үзе башкарганда гына фигыльгә –учы/,-үчекушымчалары ялгана. **Мәсәлән**: *Автобуслар йөрүче 209 нчы маршрут тикшерелде (Шәһри Чаллы,* 2015). Автобуслар үзләре йөрмиләр. Аларны шоферлар йөртәләр. Шуңа күрә, кушымча дөрес кулланылмаган. Дөрес варианты: *Автобуслар йөри торган 209 нчы маршрут юллары тикшерелде.*

**Стилистик хаталар иң еш очрыйлар**: *Чаллы төрле диннәргә инанучылар тату яшәүче шәһәр (Шәһри Чаллы,2015 ел*). Бу җөмлә, минем уйлавымча гомумән мәгънәсез. Җөмләнең нәрсә турында хәбәр итүе бик үк аңлашылып бетми. Ул Чаллы шәһәрендә диннәрнең күплеге турында хәбәр итә, Чаллының тату шәһәр икәнлегенә ишарә ясый. *Шәһәр Уставы нигезендә шәһәр Думасы депутатлары арасыннан шәһәр мэры – Мәһдиев Наил Гамбәр улы сайланды (Шәһри Чаллы, 2015ел). Җөмләдәге “шәһәр” сүзе 3* тапкыр кабатлана, әгәр аны башка синонимнар белән алыштырсак, дөресрәк булыр. Стиль ягыннан бу бик ямьсез. Мәсәлән: *Устав нигезендә депутаталарыбыз*

*арасыннан шәһәр мэры- Наил Гамбәр улы Мәһдиев сайланды. Балаларны Мәләкәс аръягыннан ЗЯБбистәсендә урнашкан 4 нче мәктәпкә ташу өчен автобус билгеләнде("Шәһри Чаллы" 2015*). "Ташу" сүзе бу җөмләдә бик ямьсез яңгырый. Сүз балалар турында бара, алар бит предмет түгел. "Ташу" сүзе урынына "йөртү" фигылен кулланcак урынлырак булыр.

**Җөмләдә сүз тәртибе**. Гадәттә, татар телендә рус теленнән аермалы буларак, хәбәр җөмләнең ахырында килә. Матбугаттта, радио-телевидениебездә, кызганычка каршы, бу кагыйдәгә артык игътибар бирмиләр. *Радио каршына чакырабыз сезне, Фәрдия апа*. Беренчедән, җөмләдә сүз тәртибе дөрес түгел, хәбәр җөмлә ахырында булырга тиеш. Икенчедән, радио каршына түгел, радиоалгыч каршына. *Радиоалгычлар каршына, Фәрдия апа, сезне чакырабыз. Без тукталабыз чираттагы тәбрикләү сүзенә("Күңел радиосы"эфирыннан). Без чираттагы тәбрикләү сүзләренә тукталабыз.*

Рус теленең татар теле үсешенә уңай йогынтысы да зур, шул ук вакытта туган телнең табигыйлеген бозуга китерә торган тэсире дә бар. Хәзерге телебездәге хаталарның күбесе рус теле сүзләренең формаларын автоматик рәвештә татар теленә күчереп куюдан һәм ялгыш тәрҗемә итү аркасында килеп чыга.

Шулай итеп, бай тарихы булган, һәрчак камиллеккә омтылган татар телен хаталар, төрле кимчелекләр белән чуарлау телебезгә карата тискәре мөнәсәбәтне күрсәтә. Сөйләмебез камил, аңлаешлы булсын өчен без татар әдәби тел нормаларын дөрес итеп куллана белергә, язма сөйләмебезгә игътибарлы булырга тиешбез.

## ТӘРҖЕМӘДӘ МӘКАЛЬ-ӘЙТЕМНӘР

*Гибадуллина Гөлгенә,*
*Мөслим районы Түбән Табын урта мәктәбенең IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Әмирова Миләүшә Рөстәм кызы*

Мәкаль-әйтемнәр – төрле телләрдә уртак һәм охшаш яклары аеруча күп булган сурәтләү чарасы. Аларда халыкның тормыш тәҗрибәсе, фикер йөртүе чагылыш таба. Кешеләрнең яшәү шартларында, холык-фигыльләрендә, үзара мөнәсәбәтләрендә һәм тормышка карашларында, алар нинди телдә сөйләшүенә һәм кайсы җирдә яшәвенә карамастан, уртак нәрсәләр шактый күп. Шул уртаклык җирлегендә кайчак бер-берсеннән бик ерак торган, телләре төрле булган халыкларда да бер үк фикерне белдергән мәкаль-әйтемнәр барлыкка килгән.

Рус, татар телләрендәге мәкаль-әйтемнәрнең гомуми фонды шактый зур. Аны мәгънәләре дә, образлары да бер үк төрле мәкаль-әйтемнәр тәшкил итә һәм аларны тәрҗемә итү кыенлык тудырмый, чөнки әзер эквивалентлар ярдәмгә килә. Мәсәлән: *Семь раз отмерь, один раз отрежь. Җиде кат үлчә, бер кат кис. Кто не работает, тот не ест. – Эшләмәгән – ашамый. Яблоко от яблони не далеко падает. – Алма агачыннан ерак төшми.*

Уртак фонд мәгънәләре бертөрле, образлары төрле мәкаль-әйтемнәрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә итеп алу нәтиҗәсендә үскәннән-үсә бара. Русларда *Острый топор быстрее ломается* дигән мәкаль бар. Татарларда ул мәгънәдә *Җете кызыл тиз уңа* диләр. Тәрҗемәдә аларны бер-берсе белән алмаштырсак, оригиналдагы образ югалыр иде. Шуңа күрә мәкальне мәкаль итеп саклап булганда, ягъни ул җыйнак, үткен, төгәл, образлы, ритмлы, рифмалы һ.б. ш. булганда, тәрҗемә ителергә тиеш. Әлеге мәкальне *Үткен балта тиз ярыла (кителә)* дип тәрҗемә итсәк, әйтелгән шартлар нигездә үтәлә.

Шулай ук рус һәм татар телләренең уртак мәкаль-әйтем фондын тәшкил итәрлек потенциаль мөмкинлекләре зур.Телебезгә русчадан калькалаштырып һәм ярымкалькалаштырып йөзләрчә мәкаль-әйтемнәр кертелде. Аларның күбесе тәрҗемәләрдә генә түгел, оригиналь материалларда да кулланыла. Мәсәлән: *Не место красит человека, а человек красит место. – Кешене урын бизәми, урынны кеше бизи. На ошибках учатся. – Ялгыша- ялгыша өйрәнәләр; Что писано пером, не вырубишь топором. – Каләм белән язганны балта белән юнып булмый.*

Тәрҗемә ителгән матур әдәбият әсәрләрендә дә, матбугат материалларында да рус мәкаль-әйтемнәре үрнәгендә уңышлы төзелгән сурәтләү чаралары шактый күп, уңышсызлары да юк түгел. Бу өлкәдә мондыйрак җитешсезлекләр бар:

1.Мәкаль-әйтемнәрдә кирәкмәгәнгә *ләкин, әмма, һәм, ә* кебек алынма теркәгечләр кулланыла. Мәсәлән: *Голос- то твой, песня чужая. – Тавышың үзеңнеке, ләкин җырың кешенеке (Тавышың үзеңнеке булса да, җырың кешенеке* рәвешендәрәк кирәк). *Труд кормить, а лень портит. – Хезмәт тәрбияли, ә ялкаулык боза (Хезмәт тәрбияли, ялкаулык боза).*

2. Рус телендә дә, татар телендә дә мәкальләр еш кына рифмага корылган була: *Когда густо, когда и пусто.- Бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй.*

3. Кайбер мәкаль-әйтемнәргә кыскалык, шомалык җитеп бетми, артык сүзләр кулланыла. Мәсәлән: *Собака лаять устанет, а волк ходить не перестанет. – Эт өреп арса да, бүре йөреп туктамас (Эт өрер, бүре йөрер кирәк).*

4. Мәкаль-әйтемнәрдә сүзләрнең янәшәлек бәйләнешенә игътибар ителми. Мәсәлән, *Время работает в нашу пользу* мәкален *Вакыт безнең файдага эшли* дип тәрҗемә итү дөрес булмый, чөнки *вакыт эшли* сүзтезмәсендә сүзләр бәйләнешенең нормасы бозылган ( *вакыт эшләми, вакыт уза, үтә*).

Рус, татар телләрендә үзенчәлекле мәкаль- әйтемнәр дә бар. Алар бер үк моральне, күчерелмә мәгънәне төрле образлар ярдәмендә белдерәләр. Үзенчәлекле мәкаль-әйтемнәрне гадәттә бер телдән икенче телгә образларын саклап төгәл тәрҗемә итеп булмый, оригинал мәкале мәгънәсе, морале туры килә торган тәрҗемә теле мәкаль-әйтелмәсе белән алмаштырып куела.

Үзенчәлекле мәкаль-әйтемнәрнең компонентлары үзара ныграк береккән һәм аерым алганда мәгънәләрен күбрәк югалткан була. Гомуми сыйфатлары

булган мәкаль-әйтемнәр: *Где дружба, там и сила. – Кайда берлек, шунда көч; Хочешь знать человека, смотри на его друга. – Кешене беләсең килсә, аның дустына кара.*

Тәрҗемәләрдә мәкальләрнең оригинален гадиләштереп, мәгънәсен бозып бирүләр дә очраштыргалый. Мәсәлән, *Утро вечера мудренее. – Җан биргәнгә юнь бирә. Ни стыда ни совести. – Серкәсе су күтәрми* дип тәрҗемә ителгән.

Татар теленнән рус теленә тәрҗемә иткән вакытта мәкаль- әйтемнәрдә күп кенә менә шундый аермалыклар күренә.Мәкальләрне адәм чыгармый, заман чыгара. Чынлап та, мәкаль-әйтемнәр телбизәк кенә түгел, бәлки халыкның күпьеллык акыл-тәҗрибәсе, тарихы, киләчәк буыннарга әйтер сүзе.

Әдәбият

Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм тел культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 125б.

Әхмәдуллин А.Г. Әдәбият белеме сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1990.

Татар телендә мәкаль- әйтемнәр сүзлеге .– Казан: Татар. кит. нәшр., 1995.

## ГАРИФ АХУНОВ ИҖАТЫНДА ЗАМАН СУЛЫШЫ

**(авторның Әлмәт чоры иҗатына бер караш)**

*Гиздатуллина Назлыгөл,*

*Яр Чаллы педагогия көллиятенең II курс студенты*

*Фәнни җитәкче: Минһаҗева Резилә Әбүзәр кызы*

Гариф Ахунов исемен атау белән күз алдыбызга алтын басу-кырлар буйлап атлаучы, ачык һәм көләч йөзле, күпне күргән һәм кичергән олпат әдибебез килеп баса.

Менә аның «Чишмәләр белән сөйләшү» [Ахунов 1982: 256-257б.] китабыннан фотолар карыйбыз. игенчеләр, нефтьчеләр арасында булсынмы, яисә Үзбәкстанның мамык кырларындамы, Мурманск балыкчылары янында, я Мәскәүнең затлы залларында югары хакимият вәкилләре беләнме, Гариф Ахунов фотоларда һәрчак үзе булып төшкән! Йөз чалымнарыннан ук киң күңелле, халыкчан калебле үзеннән бөркелеп чыккан нур белән якын тирәдәгеләрне дә күңелен әсир итә алган сирәк шәхес, халык әдибе икәне күренә.

Ятимлекне, шәхес культын үз җилкәсендә татып, Себер якларында кырыс хезмәт мәктәбе узган Г. Ахуновның үз иҗатында хезмәт кешесенең якты образына дикъкать итүенең тамырлары әнә шулай, бик тирәннән киләдер ул...

Беренче зур әсәре «Яшьлек яме» повестенда ук ул, Таһир образында, үз көче белән тормыш алып баручы, хезмәт белән чыныккан, әхлакый яктан саф күңелле кеше образын иҗат итә.

Нефтьчеләр тормышын якыннан өйрәнү өчен Әлмәт каласына иҗади командировкага килеп төшкәч, Г.Ахунов әсәрләренең тематикасы да үзгәрә төшә. Ул хикәяләр, репортажга тартым документаль повестьларын җир алтынын табучылар тормышына юнәлтә. Нефть ягы – Кәлимәттә булган зур

үзгәрешләрнең берсе дә өлгер язучы каләменнән читтә калмый. Ул заман сулышын тоеп, ихластан иҗат эшенә керешә.

Әйтик, «Артышлы тау буенда» (1958) повестенда тыныч кына, үз көенә яшәп яткан авылга нефтьчеләр килүе, шул тәэсирдә анда зур социаль-рухи үзгәрешләр башлануы сурәтләнә.

Безне иң тетрәндергәне, әлбәттә, авыл тарихының мөһим шаһиты булган, күпне күргән басу капкасын җимерелүе. Әсәрдә ул символик мәгънәгә ия, авылга булган үзенчәлекле һөҗүмне гәүдәләндерә: «Ул да түгел, кузовның әллә нинди тимерләр, көпшәләр төягән коточкыч зур машина, җир селкетеп, урамга килеп керде. «...» Келәт чаклы машина, колхоз үгезе кебек башын бөгеп, үкереп килде дә авар-аумас торган басу капкасын чөеп тә атты. Тәпие астында иске такталар чатыр-чотыр сынып калды» [Ахунов 1985: 399-400].

Бүгенге көн күзлегеннән караганда, бу 1970-1980 елларда авылларны бетүгә, җимерелүенә китерә торган төп сәбәпләрнең берсе – кечәге авыл балаларының нефть өлкәсенә күчүе, авылдан читләшүләре түгелме соң?!

Күрәбез, авыл тормышына зур үзгәрешләр алып килгән нефтьле тормышны, яңа төзелешләрне күккә чөеп мактаган чорда, Гариф Ахунов, параллель рәвештә, авылның шәһәр тарафыннан йотылу, җимерелү, шәһәрләштерелү процессын да кыю күрсәткән.

Әсәрнең төп герое Хәсәннең әтисе дә бу нефтьчеләр һөҗүменнән өркеп куя: «Шәһәр салалар, имеш, ди. Җир астыннан көпшә үткәрәләр. Иген басуларын эштән чыгарып бетермәсәләр ярый инде...» [Ахунов 1985: 402]. Әсәрдә җирле халык, өлкән буынның, разведка машинасы алып ташлаган басу капкасы өчен, чирәме тапталган урамнар һәм бәрәңге басулары өчен әрнүләрен дә җан сыкравы белән биргән алган әдип. Бу фонда яшьләрнең уй-гамәлләре үзгә: алар «таш клуб салына икән, дип сөенештеләр» [Ахунов 1985: 406 б.], алар яңа һөнәр үзләштерә алуларына, шәһәрчә уңайлыкларда яши алуларына шатландылар.

Әйе, машиналар туктаусыз йөрүдән чирәм тәмам тапталып бетә, Әлмәш буеннан бакалар тавышы да тына, Зәй елгасында балык та капмый башлый... Кәлимәт өстеннән төн кача. Хәтта атларны бик яраткан, «ат чебене» кушаматлы Хәсәннең дә, аттан бизеп, нефтьчеләрнең корыч айгырлары – машина-техникалары белән кызыксына башлавын күрәбез.

Шулай итеп, Кәлимәт авылының зур индустриаль Әлмәт каласына әверелүе, авылның урбанлашу (урбанизация), йотылу процессын күзәтә төшәбез.

Гариф Ахуновның «Юллар чатында», «Хыялый Хәйрүш егетләре» җыентыклары, «Канатлар кая илтә?» повестьларының үзәгендә дә төп образлар, нигездә, авылдан чыккан нефтьчеләр.

Әйе, нефть кеше характерына гына түгел, әйләнә-тирәгә дә, табигатькә дә зур йогынты ясый. Кәлимәт кебек кечәге авыллар урынына чын нефть калалары калкып чыга. Авторның күләмле әсәрләреннән – «Хәзинә» (1963) романында да без кичәге авыл крестьянының яңа һөнәр үзләштерүе, шуның

белән бәйле холык-характер үзгәрешен күзәтәбез. Кәлимәт төбәгенең данлыклы вә хөрмәтлеләрдән саналган Шәвәли карт гаиләсенең дә нигезләрен нефть белән бәйле яңалыклар какшата төшә. Аның балалары Фәйрүзә белән Арслан да шул сәбәпле авылдан чыгып китәләр.

Нәтиҗә ясап, шуны ассызыклыйк: Г.Ахунов үз халкы, аның фидакарь хезмәт кешеләре белән эчкерсез горурланып, туган як табигате, илебез иминлеген тәшкил иткән игенчеләре, нефтьчеләренә мәдхия дә җырлый һәм, шул ук вакытта, соцреализм кысаларын «бозып», авылга янаган рухи инкыйразга, экологик проблемаларга да ишарә ясый. Автор иҗатының үзенчәлеге – әнә шул чор сулышын тоемлау, аны төрле яссылыклардан чыгып, уңай һәм җитешсез яклары белән дә сурәтләп бирүендә. Әлмәт чоры иҗатында бу тенденция калку чагылган.

Әдәбият

Ахунов Г. Әсәрләр дүрт томда. Икенче том. Повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 295 б.

Ахунов Г. Чишмәләр белән сөйләшү: мәкаләләр, очерклар, әңгәмәләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 462 б.

## МӘГЪРИФӘТЧЕ ЯЗУЧЫБЫЗ РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ КЫЗ БАЛАНЫ ТӘРБИЯЛӘҮГӘ КАРАШ

*Гыйнятуллина Сәлимә,*
*Әлмәт районы Мәмәт урта мәктәбенең IX нчы сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Ситдыйкова Ләлә Насыйх кызы кызы*

“Укыган вә холкын тәрбияләгән кыз – алтыннан да кыйммәтле вә энҗедән дә кадерле байлыктыр ки…»
Р. Фәхреддин

Соңгы елларда җәмгыятебезнең күпчелек өлешен тәшкил итүче яшьләренең, аеруча кызларның, әхлакый сыйфатлары кими бару турында кем генә уйланмый икән! Замана кызлары нинди булырга тиеш соң? Шушы сорауларга җавап эзләгәндә мин якташыбыз, күренекле фикер иясе, мәгърифәтче-галим Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләренә таяндым. Аларны тирәнрәк өйрәнгән саен, тормышка карата фикерем үзгәрә барды. Бу тәрбияви китапларга тормыш тәҗрибәсе, беркайчан да актуальлеген югалтмый торган тәрбия алымнары тупланган. Бүгенге әдәпсезлык, дорфалык, гамьсезлек, чәчәк аткан вакытта яшь буында кешелеклелек сыйфатларын саклап калучы бердәнбер юл – ул да булса әхлак тәрбиясе.

Бик еш кына әти-әниләр, укытучылар тарафыннан минем шәхсән үземә һәм яшьтәшләремә карата да шактый кырыс, кинаяле сүзләр ишетергә туры килә. Без, яшьләр, бу кисәтүләрне артык өйрәтү, искелекне тагу дип кабул итсәк тә, җәмгыятьнең тотрыксыз әхлагы, безне дә бик борчый. Минемчә, киләчәк кешесе алдынгы карашлы, белемле, милләте өчен җаваплы, толерант, дини белемле һәм теле камил шәхес булырга тиеш.

Тәрбияле кызларны һәркем ярата. Инсафлы булу – татар кызлары өчен аеруча хас сыйфат. Мин үзем дә барлык йолаларны, гореф-гадәтләрне үтәп яшәүче чын татар гаиләсендә тәрбияләнеп үсүем белән бик горурланам.

Әйе, кызлар – киләчәктә гаилә учагын саклаучы хатын, затлы нәсел калдыручы булачак әни дә. Гаиләдә ана – иң изге, иң олы шәхес. "Анаң өчен уч төбендә тәбә кыздырсаң да, бурычыңны кайтара алмассың", "Ана сүзен тотмаган олыгайганчы игелек күрмәгән" [Исәнбәт 2003: 3]. Халык анага булган мөнәсәбәтен, хөрмәтен шулай билгели. Шушы татар халык мәкальләренең асылын Р.Фәхреддин "Нәсыйхәт-2" китабының "Кыз балалар өчен генә" дигән бүлегендә бик яхшы тасвирлый. ..."Әй хөрмәтле кызлар! Сезгә мәгълүмдер ки, холкы гүзәл булган кыз бала – бөтен гаиләсе өчен олуг байлык вә бәхеттер, "Укыган вә холкын тәрбияләгән кыз - алтыннан да кыйммәтле вә энҗедән дә кадерле байлыктыр..." [Фәхреддин 2006: 125] – дигән сүзләре белән ул кыз баланың киләчәген билгеләп куя.

Хәзерге заманда балалар һәм әти-әниләр арасындагы мөнәсәбәтләр бик киеренке. Әти-әнигә хөрмәт белән карау, итагатьле итеп эндәшүрөхсәт сорап йөрү, сүзен бер әйтү белән тыңлау, хәленә керүдигән төшенчәләр бетеп бара. Аеруча кызларның дорфалыгы мине нык борчый. Моңа җавапны "Ата вә ана әдәбе" бүлеге бик яхшы бирә: "Хөрмәтле кызлар! Атагызны хөрмәт итегез, алдында вә артында камил ризалык белән аның әдәпләрен олылагыз, ана вә анагызны ихлас сөегез! Атагыз алдында утырганда әдәпле булыгыз, күп көлмәгез, артык тавыш белән сөйләмәгез. Атагыздан күп әйбер сорамагыз, сораганда да гаять әдәпле итеп сорагыз вә бирмәгәндә күп кабатламагыз". "Туганнар, кардәшләр, күршеләр әдәбе" [Фәхреддин 2006: 126-128] бүлекләреннән мин кардәшләрне олыларга, туганнар белән тату, шәфкатьле булырга,аларны яманлап сөйләмәскә, якын күршеләрнең хакларын ригая итеп – олылап, туганнарың кебек күреп яшәргә кирәклеген төшендем һәм аларны сыйныфташларыма да җиткердем. Бу кагыйдәләр безгә яңалык та кебек түгел, әмма остазыбыз Р.Фәхреддин язып калдырган гап-гади генә булган тормыш кагыйдәләре бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган.

Бу китап белән танышканда мин шәхсән үзем өчен бик күп файдалы мәгълүмат алдым һәм шуларны мисал итеп китерәсем килә. "Мәктәп әдәпләре" [Ибраһимов 2001: 22], "Мөгаллимнәр әдәбе" [Шаһиев 2005: 85-86] бүлекләре укытучыга каршы әйтү, үз фикерңне алга кую, рөхсәтсез видеога төшерү, телефонга яздыру, әти-әни белән куркыту кебек ямьсез күренешләрне чиксез тәнкыйтьли.

Мәшһүр галимебез кызларны эшкә өйрәтеп үстерүгә дә зур игътибар биргән һәм аны "Өй әдәпләре" бүлегенә туплаган. Яшьтән эшкә өйрәнеп үскән кызлар үз тормышларын коргач та, гаилә учагын саклаучы булачагына ышанган ул.

"Зиннәт (бизәнү), йөз һәм чәч әдәпләре" бүлекләрен һәр үзен хөрмәт иткән кызга өйрәнергә тәкъдим итәр идем мин. Косметиканы кайсы кыз гына дөрес куллана икән? Артык модага иярү, үзеңне башкалардан аерып күрсәтү өчен кызлар нинди генә буяулар кулланмыйлар! Ә бит гадилек – үзе күркәмлек,

зәвык билгесе. Озын чәч тә кызларга бик килешә. Бүгенге көндә кызларның күбесе чәчен кыска йөртергә тели. Мин моңа каршы. Кызларның бөтен матурлыгы чәчләрендә, ә татар кызы озын итеп толым үреп тә куйса, күзеңне алмаслык була. Чәч үрүнең хәзер искиткеч күп төрләрен уйлап чыгардылар, урынын белеп куллан гына. Остазыбызның тышкы һәм эчке матурлыкка ирешү, үз-үзеңне кеше янында тоту кагыйдәләрен үзләштерергә өйрәткән кагыйдәләрен мисал итеп китерәсем килә:

“Әдәпсез хатыннар кебек йөзләрегезгә, иреннәрегезгә, ак вә кызыл буяулар сөртмәгез, кашларыгызны йолыкмагыз, карага буямагыз!”

“...Үзегезне олы вә халык арасында игътибарлы итәчәк рәвештә мөлаем сурәттә бизәнегез!” [Шаһиев 2005: 87-88].

Р.Фәхреддин балаларга тәрбия бирүне иң беренче итеп гаиләгә йөкләгән. Мөселман кешесе өчен гаилә – бернинди көч белән дә какшата, җимерә алмаслык ныгытма ул. “Кемнең өч кыз баласы булып, әгәр ул аларга карата түземле, сабыр булып, аларга хәзинәсендә булганны ашатса, эчертсә һәм киендерсә шул кызлар аларга кыямәт көнендә уттан пәрдә булачак”, диелә Пәйгамбәребез хәдисендә.

Әйтеп үткәнемчә, безнең мәктәптә кызлар тәрбиясенә аеруча игътибар бирелә. Укучы кызлар өчен “Ягез әле, кызлар”, “Уңган хуҗабикә”, “Озын толым”, “Әбиемнең күңел сандыгы” бәйгеләре, әниләр катнашында “Бабайлардан килгән хакыйкать”, “Шушы яктан, шушы туфрактан без”, “Гаилә бәйрәме”, “Әнием-күз нурым” темаларына бәйге, конференция, очрашулар уздырыла. Әниләр көнендә күп бала тәрбияләп үстерүче, үрнәк әниләргә Рәхмәт хатлары тапшырыла.

“Хезмәтләрем киләчәк буын яшьләребез өчен шифа һәм якты нур булыр”, - дип зур ышанычын белдергән остазыбыз. Бу җәүһәрләр тезмәсенә тиң мирас мәктәпләрдә өстәл китабы булсын иде. Шушы теманың дәвам итеп, яшьтәшләремә түбәндәге әдәбият әсәрләрен дә укырга тәкъдим итәр идем: “Өч кыз”, “Үги кыз” әкиятләре, Һ.Такташның “Алсу” поэмасы, Ф.Әмирханның “Хәят”, Г.Ибраһимовның “Сөю-сәгадәт”, Р.Фәхреддиннең “Әсма, яки гамәл вә җәза”, “Сәлимә, яки гыйффәт”.

Чылтыр–чылтыр чишмәләрнең сафлыгы бар,
Күктә йөзгән болытларның аклыгы бар.
Күчкән сезгә чәчкәләрнең матурлыгы
Тулган айның һәм кояшның якты нуры
Әй, син гүзәл һәм инсафлы татар кызы!

Йомгаклап, шуны әйтәсем килә: ”...дөньяда иң бәхетле һәм рәхәт яшәүче кеше – ул башкаларга изгелек эшләүче зат”, дигән остазыбыз. Без, яшьләр, киләчәктә галимебез хыялланган, ул күрергә теләгән үрнәк кызлар булып җитешик һәм милләтебез горурланырлык шәхесләр булыйк. Иң асыл сыйфатыбыз булган инсафлы татар кызы булуыбызны онытмыйк!

Әдәбият

Ибраһимов Н, Бикчәнтәев К. Балаларга үгет-нәсыйхәт. – Казан: “Дом печати”, 2001.

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. – Яр Чаллы: “Идел-йорт”, 2003.

Фәхреддин Р.“Нәсыйхәт 2” – “Кыз балалар өчен генә”.

Шаһиев Р. Ризаэддин бине Фәхреддин. Тормыш юлы һәм иҗади мирасы. Дәреслек-хрестоматия. – Казан: РИЦ “Школа” – 2005.

## Ф.САДРИЕВНЫҢ “СОҢГЫ ДӘРЕС” ӘСӘРЕНДӘ РИЗАЭДДИН ФӘХРЕТДИН МИРАСЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ

*Гулиева Кулшэн,*
*Мөслим лицееның IX а сыйныфы укучысы*
*Фәнни җитәкче: Ситдыйкова Чулпан Индус кызы*

Татар әдәбияты – меңьеллык әдәби мирасы, бай язу культурасы, стиль үзенчәлекләре, жанрлар төрлелеге белән бөтен дөнья мәдәниятенә зур урын тоткан әдәбият. Менә шушы бай мираслы әдәбиятка өлеш кертү юнәлешендә зур көч куйган әдипләр арасында Фоат абый Садриев та бар. Без якташ әдибебез, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Габдулла Тукай, Р.Фәхертдинов һәм Р.Төхфәтуллин, С.Сөләйманова исемендәге премияләр лауреаты, Мөслимнең Мактаулы гражданины, Мөслим җирле үзидарә советы депутаты Фоат Садриев белән чиксез горурланабыз. Мөдәррис Әгъләм аны: “Фоат Садриев-татарның Шолоховы ул”, – ди.

Казанда 1908 нче елда икенче басма итеп бастырган “Әдәбе тәгълим” (“Укыту кагыйдәләре”) китабының исеме астына Ризаэддин Фәхреддин гарәп телендә Гали хәлифәнең “Балаларыгызны үзегезнең заманыгыздан башка бер заман өчен укытыгыз, чөнки алар сезнең заманыгыздан башка бер заманда яшәү өчен дөньяга килгәннәр!” – дигән бик хөрмәтле сүзләрен китергән. Дөньядагы барлык байлыклардан да өстен торган гыйлемне өйрәтүче, дәрес укытучы һәм балаларның җаннарын тәрбияләүче кешенең “мөгаллим” (укытучы) дип аталуын күрсәтә һәм аның иң беренче эше-шәкертләрне гыйлем белән тәрбияләү, изге шәригатьтә аңлатылган күркәм холыклар белән таныштыру һәм аларга гадәтләндерү икәнлеген аңлатып бирә. Аның фикеренчә, дөнья йөзендә үз вазифасын намус белән җиренә җиткерүче укытучыдан да файдалы һәм кирәкле кеше юктыр. Ризаэтдин Фәхретдин кешеләргә намуслы хезмәт итүче укытучыларны – Аллахы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән пәйгамбәрләр һәм илчеләр белән тиңли, укытучыларга йөкләнә торган кануни унөч вазифаны тәфсилләп төшендереп бирә. Ризаэддин Фәхреддинов укытучы кешедә булырга тиешле 13 сыйфатны “Әдәбе тәгълим” (“Укыту кагыйдәләре”) китабында ачык итеп аңлата. Аның фикерләре Фоат Садриевның “Соңгы дәрес” әсәрендә әйтелгәннәр белән тәңгәл килә.

Фоат Садриев – ике дистәгә якын сәхнә әсәре авторы. Ф.Садриев проза әсәрләре – хикәя-повестьлары, романнары белән дә киң җәмәгатьчелеккә

танылган каләм иясе. Әдипнең «Шаһзаманов эше», «Адәм әүлиясе», «Зөбәйдәнең күңел дәфтәреннән», «Өченче кеше», «Рәхмәт, әтием!..», «Көлми торган кеше», «Кыргый алма әчесе» кебек повестьлары, дистәләгән хикәяләре, драма һәм комедияләре кебек үк, тормышчан эчтәлекләре, үзенчәлекле кеше образлары, халыкчан юморга бай йөгерек тел-стиле белән җәлеп итәләр.Фоат Садриевның уникальлеге нәрсәдә? дигән сорауга болайрак җавап биреп биреп булыр иде

1. Язучы иксез-чиксез акыл байлыгына ия.

2. Кешеләрнең рухи байлыгын формалаштыру һәм камилләштерүгә бертуктамый йогынты ясый белә.

3. Бик зур талант иясе һәм әдәбият, сәнгатьтә батырлык күрсәтүче.

4. Фоат Садриевның тормышы туктаусыз эзләнүләрдән тора.

"Соңгы дәрес" әсәрендә вакыйгалар үстерелешенә күз салыйк. Табигать яңгыр көтә. Нәҗия исемле пенсионер укытучы өенә элекке укучысы-көтелмәгән кунак Яруллин килеп керә, мәктәп еллары турында укытучының кичерешләре бер-бер артлы күз алдыннан үтә, Дамир үз тормышы турында сөйли. Дамир укытучыдан ярдәм сорый, дөнья байлыклары, дәрәҗәгә ирешеп тә җан тынычлыгы таба алмый. Укытучы "Соңгы дәресе"н бирә, табигатькә җан өреп, яңгыр ява. Автор ретроспекция алымы аша Дамирның үткән тормышын тасвирлый. Дамир мәктәп елларында төрле вакыйгалар аша сурәтләнә.

1 нче вакыйганы "Аксак чәүкә"дип атыйбыз.

Укытучы 5 нче сыйныфка 14 кыз, 9 малай кабул итеп ала. Ябык, бәләкәй гәүдәле, кәкре агачны хәтерләткән "Аксак чәүкә" кушаматлы Яруллинны берәү дә үз итми.

2 нче вакыйганы "Тән ярасы төзәлә, күңел ярасы төзәлми" дип атыйбыз.

Дамир дәрескә өске иренен ярып килеп керә, укытучысы больницага җибәрә, тик укучы кача. Төн уртасында аны эзләп табып, "Ашыгыч ярдәм" бүлегендә үзе карап торып, яраны тектерә.

3 нче вакыйганы "Матди һәм рухи зыян" дип атыйбыз

Яруллин, кунак егетне поездга соңартмас өчен, сорамыйча гына бер пенсионерның "Ока" машинасын ала һәм юл һәлакәтенә эләгә. Укытучы, җинаять эше ачтырмыйча, укучыны яклап алып кала, машинаны төзәтүне дә үз өстенә ала, Яруллинның әти-әнисеннән нахак сүзләр ишетә.

4 нче вакыйганы "Авылдан качу яки "Барыбер кеше булачакмын!" дип атыйбыз.

Чыгарылыш кичәсендә егетне канга батырып кыйныйлар, укытучының кәефе кырыла, "Барыбер кеше булачакмын! Менә күрерсез!"дип, егетнең авылдан чыгып китүе.

"Беренче тормышында" тәртипсез, сугыш чукмары, "Аксак чәүкә" кушаматлы егетне автор "икенче тормышында" нинди итеп сурәтли? Төз гәүдәле, сабыр карашлы Дамир Себердә авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган, унлап шәхси кибете бар, сәүдәгәрлек аның хәзер төп шөгыленә

өйләнгән. Орденлы депутат. Яхүд кызына өйләнгән. Ике малайлары үсеп килә. Егет туктаусыз буталчык, коточкыч төшләр күрә. Соңгы төшендә ак эт күрә. Ак төс- яктылык, пакьлек, өмет символы. Эт кешенең дусты, юлдашы. Ак эт- буталчыктан чыгу юлын күрсәтүче."Үзем дә, яшәвем дә әрем шикелле әче".. дип егет үзенә бәя бирә, укытучысыннан ярдәм сорый. Аны нәрсә борчый, укытучы аңа нинди киңәш бирә соң? Дамир җитеш дөньяда яшәсә дә, җан тынычлыгын югалткан. Наҗия егетнең рухи халәтенә, оста табиблар кебек, диагноз куя, "Тормыш тәмен югалткансың" ди, "Менә мин кем булдым!" дияргә кайттың" дип егетнең күзләрен ача, "Сиңа хәзер өченче тормышны башларга кирәк" дип киңәш бирә."Өченче тормышны" автор тормыш тәмен югалтмыйча яшәү дип әйтергә тели.

Автор әсәрен "Соңгы дәрес" дип атаган, аңа нинди мәгънә салынган соң?

Автор өлкән яшьтәге укытучының чыгарган укучысына соңгы әхлак дәресе турында яза. Дамир тормышта күп нәрсәгә ирешсә дә, тормыш тәмен тапмаган кеше. Укытучысының "Соңгы дәресе" аша ул күңелендә йөрткән сорауларга җавап ала, хакыйкатьне аңлауга ирешә. Ул әле "билге алу өчен" укытучы янына кабат киләчәк. Ул вакытта инде "өченче тормышта" яшәячәк

Әсәр табигатьнең яңгыр көтүе белән башлана, яңгыр яву күренеше белән тәмамлана. Әсәрдәге яңгыр сүзенең мәгънәсен ачыклап үтик. Дамирның күңеле яңгыр көтеп арыган, сусаган җир кебек. Укытучысының сүзләре аның күңеленә яуган "шифалы яңгыр" тамчылары кебек

Мөгаллимә Наҗия безнең күз алдына илаһи бер зат булып килеп баса. Аның күңел төпкелләре дә буш түгел. Ул авариядә имгәнгән, врачлар да, әти-әнисе дә кул селтәгән оныгын аякка бастырырга тырыша. Соңгы йөрәк көчен оныгына бирә, билгеле бер нәтиҗәләргә дә ирешә. Аның тормышы-мәңгелек яшәү мәгънәсеннән гыйбарәт. Наҗиянең **"Бөтенебез бөтенебездә без"** дигән сүзләренә игътибар итик. Бер- берең өчен җаваплылык, беркайчан да түләп бетерә алмый торган бурычлар күз алдында тотыла.

Ә хәзер "Философик төшенчәләр" таблицасына игътибар итик.

1. Бик кечкенә һәм чиксезлек (яхшылык эшләү турында)
2. Яшәү һәм үлем (өлкән укытучы оныгының тормышы өчен көрәшә)
3. Мизгел һәм мәңгелек ( үзеңнән соң якты эз калдыру)
4. Җирдә мәгънәсез яшәү һәм кемнеңдер тормышы өчен яшәү-гармония.

Күрәбез, Фоат Садриев шушы 4 төшенчәне дә әдәби әсәр эчтәлегенә кертә алган. Без аның уникальлегенә, кешеләрнең рухи байлыгын формалаштыру һәм камилләштерүгә йогынты ясый белүенә тагын бер кат инанабыз. "Соңгы дәрес" әсәре укытучы һөнәренә зур хөрмәт белән карарга өйрәтә. Өлкән яшьтәге укытучының гаҗәеп көчле рухына, тормыштан тәм табып яшәвенә, башкаларга тәэсир итә белүенә, искиткеч педагог булуына сокланабыз

Кешелек җәмгыятен һәрвакыт борчып килгән әхлак мәсьәләләре: намус, гаделлек, дөрес яшәү, әти-әни һәм Ватан алдындагы бурычны үтәү кебек

төшенчәләр – мәңгелек, һәркем өчен уртак. Укучыларында әлеге сыйфатларны тәрбияләү өчен мөгаллим зур көч куя.

Әдәбият

Даутов Р. Н., Р. Ф. Рахмани. Әдипләребез: библиографик белешмәлек. 2 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009.

Садриев Ф.М. Дәверләр аһәңе. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2016.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЗООНИМ КОМПОНЕНТЛЫ ФРАЗЕОЛОГИК СҮЗТЕЗМӘЛӘР

*Дәүләтшина Айгөл,*
*Чирмешән лицееның IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Котбиева Миләүшә Вагыйз кызы*

Һәрбер телнең фразеологик системасы шушы телне өйрәнү өчен мөһим бер чыганак булып тора. Фразеологизмнарда халыкның буыннан-буынга тупланган тәҗрибәсе урын алган. Бу тотрыклы сүзтезмәләрдә хәзерге көндә кулланыла торган сүзләр генә түгел, ә элекке кулланылган иске сүзләр дә сакланып калган. Шуңа күрә фразеология ул – күпьяклы күренеш [Сафиуллина 1999: 67]. Аларны төрле аспектлардан чыгып тикшерергә мөмкин. Әлеге мәкаләдә без тотрыклы сүзтезмәләрне, составындагы сүзләргә карап, тематик төркемнәргә бүлеп тикшерүне максат итеп куйдык.

Тотрыклы сүзтезмәләр составында иң продуктив компонент сыйфатында йорт хайваннары һәм кош атамалары тора: *каз боты кимерү; кара сыер сөте; кәҗә койрык күтәрә дип сарык та койрык күтәргән; кысыр сыерны бозаулату; мәчесе дә куян тота; үгезе дә сөт бирә; үрдәк телен ашаган; үгез астыннан бозау эзләү; эт артыннан койрык, мәче артыннан йөгерек; эт баш сыер аяк; чыпчык биреп каз алмакчы; чебешләрне көз көне санныйлар; чебен җаны кадәр дә тормый; җыен сарык арасында бер бүре; дуңгызы да боламык ашый; әтәч белән ятып, сыер белән тору; саескан бүтәкәсен санап утыру; тавык чүпләп бетергесез; сандугачны каргага алыштырган; ике башлы каракош; карга җимгә төшмәс борын; күгәрчен сөте генә юк; күрше тавыгы күркә булып күренү; тилгән мие ашаган; тутый кош каурыена төренгән карга; ябалак үлгән урын.*

Әлеге фразеологизмнар арасында эт зоонимы кергән тезмәләр иң актив кулланылалар: *эт авызындагы сөяк; эт ассаң, муенына җитәр; эт дисәң койрыгы юк, сыер дисәң мөгезе юк; эт итеп сүгү; эт кадерен калдырмау; эт койрыгын болгаганчы; эт колагыннан талпан суыру; эт корсагына җылы су; эт күзе төтен белмәс; эт тиресен битенә каплаган; эт чаба дип бет чаба; эт – эткә, эт – койрыкка; эте дә баш, бете дә баш; эткә сөяк ташлау; этле-мәчеле тору; эттән алып эткәт салу; эттән ач, беттән ялангач.*

Әлбәттә, татар телендәге фразеологизмнарның компоненты рәвешендә җәнлек атамалары да очрый: *аю хезмәте күрсәтү; биш тиенлек куян; ун*

*тиенлек зыян; бүре дә тук, сарык та исән; бүре колагы ауда; елан булып эчкә керү; елан мөгезе; ике куян артыннан куу; ике куянны берьюлы ату; инәдән дөя ясау; ишәк төчкергәндә туу; карт бүре; кодам кодасы, куян шулпасы; колагына аю баскан; төлке мае сөртү; төлкене көлкегә калдырырлык; төлкесеннән бигрәк көлкесе.*

Зооним компонентлы фразеологизмнар лексик-грамматик билгеләре буенча төрле сүз төркемнәренә караган фразеологик әйтелмәләр составында киләләр. Мәсәлән исем сүз төркеменнән булган сүзтезмәләр: *мәхшәр сарыгы; мүкләк сыер; эт авыз; аю баш; аю беләк; беренче әтәч; бүре базы; елан мөгезе; ике әтәч; оя тавыгы; сукыр тавык; тавык күз; тиле күке; торна мамыгы; күке җан; каткан тавык.*

Зооним компонентлы фразеологизмнарда сыйфат сүзтезмәләр дә бар: *песи борынлы; арыслан йөрәкле; куян йөрәкле; күке җанлы; елан күзле, арыслан тырнаклы.*

Фигыль сүзтезмәләрдән торган фразеологизмнар да күпчелекне тәшкил итәләр. Еш кына иярттүче сүз булып сыйфат, хикәя фигыльләр килә: *елан ите ашаган; тавык мие эчкән; битенә ит тиресе каплаган; дуңгызны җизни дип әйтмәгән; елан йоткан; үгез үлгән, уртагы аерылган; үгез сөзгән; үрдәк телен ашаган; карга чукырлык та ите калмаган; колагына тычкан оялаган; песи битен юмаган; песи таптаган (борын); сандугачны каргага алыштырган; тавык йомырка салмаган, тавык түлендә йомырка бетмәгән.*

Ияртүчесе исем фигыль белән белдерелгән фразеологизмнар да күпчелекне тәшкил итәләр: *өтерге белән балык тоту; ат ачуын тәртәдән алу; ат җене кагылу; аю хезмәте күрсәтү; бер балык башы чәйнәү; берьюлы ике куянны ату; бүресе улау; еландай бөтерелү; җир астында елан кыймылтаганын да сизү; инәдән дөя ясау; ишәк кебек карышу; каз муен булу; кәҗә калдыру; сукыр чебен булу; тавык бәкәленнән йөзү; тавык кетәгенә кертү; торна борчагын сибү; торна йомыркасы тоттыру; чебеннән фил ясау.*

Шундый фразеологизмнар арасында җөмлә тибындагылар да мөһим урынны алып торалар: *чыбык кебек бер ботакта тормас; чыпчык күреп коты очкан; коры җирдә балык булып яши; кәҗәгә акчасы җитми, сыер сатулаша; койрыклы эт тә койрыгын болгамый; балык бирсәң бәйләп бир, башын-күзен чәйнәп бир; тавык чебие суга баткан ата казның борчылуы; тотылмаган аюның тиресен туный.*

Зооним компонентлы фразеологизмнар тел картинасын тудыруда әһәмиятле чара булып торалар. Бер үк зооним төрле мәгънә мөнәсәбәтләрен белдергән фразеологизмнарда кулланыла ала. Мәсәлән, эт зоонимын алып карыйк:

- авыр тормышны сурәтләү: эт булу; эт итеп сүгү; эт ботына бәрергә бер агач утын юк.
- ялкаулыкны белдерә: эт эткә, эт койрыкка; эт дагалап йөрү; эт сугарып йөрү; эткә печән чабып йөрү.
- тискәре мөнәсәбәтләрне белдерә ала: эт белән мәче кебек.

- кешенең холкын, кыяфәтен күрсәтә: эт күзе төтен белмәс; эт тиресен битенә каплаган.

Татар теле зооним компонентлы фразеологизмнарга бай. Алар сөйләмдә актив кулланылалар.

Әдәбият

1. Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001. – 335 б.

2. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле: Лексикология. – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.

## ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРДӘ ГИПЕРБОЛАЛАРНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ

*Дәүләтшина Диләрә,*
*Чирмешән лицееның IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Котбиева Миләүшә Вагыйз кызы*

Әйберләрнең һәм күренешләрнең күләмен, санын реаль чынбарлыктан зурайтып, күбәйтеп күрсәтү гипербола дип атала. Табигате белән гипербола бөтен күренешнең үзен зурайта. 1976 елда Г.Н. Поспелов редакциясендә чыккан “Әдәбият белеменә кереш” дәреслегендә “гиперболизм” төшенчәсеннән киң мәгьнәдә бөтен сәнгатьне аңларга мөмкин дип күрсәтелә.

Гипербола бер очракта тойгы-хисләрне зурайтса, икенче очракта әйберләрне, аларның сыйфатларын калкуландыра. Һәр очракта да гипербола укучыга тәэсир итә, сурәтлелекне көчәйтү чарасы булып тора.

Халык иҗатында, мәзәкләрдә гипербола турыдан-туры көлке ситуация китереп чыгаруга катнаша. Бер юлаучы, танышына кергәч, табындагы барлык сый-хөрмәтне ашап бетерә дә шуннан соң, кабат китереп, ике чүлмәк катык белән унбиш икмәкне бөкләп куя. Гиперболаны көлкенең бер элементы дип карарга була. Ул икенче бер хәл белән реакциягә керә, шуннан көлке барлыкка килә.

Вак әйбергә нигезләнеп, хыялга бирелүне дә гипербола рәтендә карарга була. Мисал итеп “Буй җитмәслек хыял” мәзәгендә хыялның күләм ягы чиктән тыш артып китә, ә сыйфат үзгәрешсез кала. “Әгәр мин патша булсам, – ди бер авыл агае, – иң элек Кәрәкә күлендә тәртә белән болгата-болгата боламык пешерер идем дә шуны беткәнче ашар идем”. Монда болгату өчен кулланылган әйбер дә, боламыкның суы да чамадан бик нык артып киткән.

Гипербола безнең әдәбиятта бик борынгы дәвердән бирле турыдан-туры романтик күтәренкелеккә хезмәт итүче бик отышлы алым булып тора. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасында Йосыфның гүзәллеге, Зөләйха мәхәббәтенең кайнарлыгы романтик рухтагы арттырым аша бирелгән:

Ул хатыннар көрсиләргә утырдылар,
Берәр пычак һәм әфлисун китерделәр,
“Әфлисунны турагыз!” – дип боердылар,–

Нәкь шул вакыт Йосыф килеп керер имди.

Йосыф таба борылып бер карадылар,

Гүзәллеген күреп аны таң калдылар.

Һәммәсе дә күз алалмый карап аңар,

Әфлисун дип, бармакларын кисәр имди.

Язма әдәбиятта күпертү күп очракта сатирик типиклаштыруда хезмәт итә. Мәсәлән: Г.Тукайның “Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш” поэмасында Кисекбаш үзенә тупланган сыйфатлар турында болай сөйли:

Чикмәсен бушка газапны – булмый да,

Чөнки *мең пот тәгассыб бу мидә,*

Бу мидә *йөзләп гыйнад амбары бар,*

Бу *мидә мең пот сыраның пары бар.*

Бу мидә *бардыр җәһаләт ун вагон,*

“Мин беләмек” дәгьвасы – бер мең вагон.

Күпертү ярдәмендә автор персонажның бик күп тискәре сыйфатларын бер ноктага, фокуска җыеп күрсәтә.

Г.Тукай “Сорыкортларга” шигырендә татар байларының корсагын түбәндәгечә тасвир итә: Боларның һәрберсе Каф, яки Кавказ, таулары микъдар, – дип сурәтли, ягъни зурайтучы чагыштыру куллана.

“Шагыйрь” шигырендә ул:

Күкрәгемдә минем шигырь утым саумы?!

*Күтәрәм* мин, карт булсам да, *авыр тауны;*

Күңлемдә көн һаман аяз – һаман да яз,

Шагыйрь күңлендә кыш булмый да кар яумый,–

Шулай ук гиперболалар абстракт исемнәрнең, кешенең эмоциональ кичерешләренә бәйләнешле сүзләрнең “иң югары нокта” сын да күрсәтә ала, мәсәлән: “метри башлы, мең күзле” (Уймак) [Хаков 1999: 304].

Би-би баласы,

Бикә солтан анасы,

Аның да бар мазасы,

*Йөз мең алтын бәһасы* (Әдрәс камзул).

Гипербола – халык иҗаты әсәрләренең яраткан сурәтләү алымы. “Агыйделнең аръягында бер инәгә бер сыер”, “Бүдәнәнең унике пот мае бар” кебек мәкальләр моның ачык мисалы.

Көндәлек тормышта да без гиперболаларны бик еш кулланабыз: *“җилкәмнән тау төште”, “түбәм күккә тиде”, “бу эше белән ул мине бөтенләй үтерде, суйды”* кебек әйтелмәләр җанлы сөйләмдә бик күп кулланылалар.

Шулай итеп, әдәби әсәр телендә иң актив кулланыла торган махсус сурәтләү чаралары ул – гиперболалар. Шуңа күрә аларның кулланылу үзенчәлекләрен, җөмләдәге вазифаларын билгеләү бүгенге көндә актуаль темаларның берсе булып тора.

Әдәбият

Әдәбият теориясенә кереш: Урта мәктәпнең тел-әдәбият укытучылары өчен кулланма. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1987. – 303 б;

Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. – Казан: Раннур, 2002. – 352 б.

Хаков В.Х. Татар әдәби теле (стилистика). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 304 б.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘРНЕ ЧАГЫШТЫРМАЧА ӨЙРӘНҮ

*Дюмеева Гөлназ,*
*КФУның Алабуга институты студенты*
*Фәнни җитәкче: Камаева Рима Биҗан кызы*

Бүгенге синтаксис фәнендә ике телне чагыштырып өйрәнү – филологиянең актуаль һәм шул ук вакытта бәхәсле мәсьәләләрнең берсе. Бу әлеге эштә зур каршылыклар, авырлыклар булуга бәйле.

Татар һәм рус теле грамматикаларын чагыштыру элементлары XIX гасырда күренә башлый. Әлеге хезмәт авторлары – татар теле укытучылары. Алар татар телен рус теле мисалында аңлатырга тырышканнар. Әлеге хезмәтләрдә синтаксис бүлеге буенча да материаллар булган.

Бүген рус телендә кушма җөмләнең төрле аңлатмалары кулланыла: Сложное предложение – это предложение, состоящее из двух или более простых предложений, объединенных в одно целое грамматически, по смыслу, интонационно [Рогачева 2013: 60].

Ә инде татар телендә кушма җөмләнең мондый аңлатмасы бирелә: аерым җөмләләре үзара тезү юлы белән бәйләнгән кушма җөмлә тезмә кушма җөмлә дип атала [Зәкиев 2002 : 32].

Әлеге күренешне махсус рәвештә өйрәнүче беренче галим – Каюм Насыйри. Ул “Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах” хезмәтендә татар һәм рус синтаксик категорияләрне мисаллар ярдәмендә чагыштырып өйрәнә.Татар һәм рус телендәге җөмләләрне чагыштыру буенча беренче хезмәт А. Вагабовның “Үзи-үзидән өйрәткеч”е була. Шулай итеп, татар һәм рус теленнәрен чагыштырып өйрәнү тел белемендә күптәннән билгеле.

Кушма җөмләләрне чагыштырып өйрәнүнең тарихы – 1958 елда басылып чыккан “Хәзерге татар әдәби теле: синтаксис” (М.З. Зәкиев) хезмәтеннән башлана. Биредә галим татар телендәге иярченле кушма җөмләләрнең рус телендәгеләрдән аермалы якларын күрсәтә.

Бүген бу теманы өйрәнү мөһим. Беренчедән, татар телендәге әлеге темаларның өйрәнелешен, үзенчәлекләрен билгеләргә ярдәм итә. Икенче яктан, гомумән, татар һәм рус телләренең охшаш һәм аермалы якларын табу мөмкинлеген бирә.

Шулай итеп, аерым җөмләләре үзара тезү юлы белән бәйләнгән кушма җөмлә тезмә кушма җөмлә дип атала. Рус һәм татар телендәге тезмә кушма җөмләләр, компонентларның үзара бәйләнешенә карап, берничә төрле булалар: җыю мөнәсәбәтендәге җөмләләр (предложения с соединительной связью); каршы кую мөнәсәбәтендәге җөмләләр (предложения с противительной связью); бүлүче мөнәсәбәтендәге җөмләләр (предложения с разделительной связью); өстәлү мөнәсәбәтендәге җөмләләр (предложения с присоединительной связью). Алар бер-берсеннән мәгънә төсмерләре белән генә түгел, теркәгечләре, интонацияләре белән аерылып торалар.

Әлеге тема теоретик һәм практик мәсьәләләре фәндә шактый җентекләп өйрәнелгән. Бу турыда рус һәм татар галимнәре арасыннан А.Троянский, М.Иванов, М.Махмудов, К.Насыйри, А.Архангельский, А.Вагабов, М.Корбангалиев, Р.Газизов, М.З.Зәкиев, Г.С.Әмиров, Н.М.Хәсәнов, Л.К.Бәйрамова, Р.А.Юсупов, Р.Г.Сибгатов, Ф.С.Сафиуллина кебек галимнәрнең хезмәтләре бар. Хәзерге вакытта Ф.Г.Галлямов З.В.Шәйхразиева, К.З.Зиннатуллина тарафларыннан өйрәнелә, әмма шулай да тема система рәвешендә өйрәнелмәгән, тезмә кушма һәм иярченле кушма җөмләләрне аерым карап өйрәнелмәгән.

Түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. Рус синтаксисында кушма җөмләләр күптәннән барлыкка килсә дә, узган гасырның икенче яртысында гына аны нәкъ "кушма җөмлә" дип өйрәнә башлыйлар.

2. Кушма җөмлә гади җөмләләр җыелмасы гына түгел, чөнки бирелә җөмләләр аерым-аерым мәгънәви яктан да, төзелеше ягыннан да тәмамланган фикерне белдермиләр.

3. Рус телендә гади җөмләләр 2 зур төркемгә аерыла:

- Теркәгечле кушма җөмлә (Союзные предложения);
- Теркәгечсез кушма җөмлә (Бессоюзные предложения).

Теркәгечле кушма җөмләләр аерыла:

- Тезмә кушма җөмлә (Сложносочененные предложения);
- Иярченле кушма җөмлә (Сложноподчененные предложения).

4. Татар грамматикалары тарихында кушма җөмлә буенча теоретик яктан тикшеренүләрне беренче Каюм Насыйрида күрергә була. Аның "Әнмүзәҗ" хезмәтендә кушма җөмлә турында бүлек бирелә. М.З. Зәкиевнең "Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис" хезмәтендә, нигездә, кушма җөмләләрнең бүгенге бүленеше бирелгән.

5. Компонентларның үзара бәйләнеш төренә карап, кушма җөмләләр ике төрле булалар: тезмә кушма җөмләләр һәм иярченле кушма җөмләләр. Тезмә кушма җөмләләр теркәгечле һәм теркәгечсез кушма җөмләләргә аерылалар.

6. Аерым җөмләләре үзара тезү юлы белән бәйләнгән кушма җөмлә тезмә кушма җөмлә дип атала. Рус һәм татар телендәге тезмә кушма җөмләләр, компонентларның үзара бәйләнешенә карап, берничә төрле булалар: җыю мөнәсәбәтендәге җөмләләр (предложения с соединительной связью); каршы

кую мөнәсәбәтендәге җөмләләр (предложения с противительной связью); бүлүче мөнәсәбәтендәге җөмләләр (предложения с разделительной связью); өстәлү мөнәсәбәтендәге җөмләләр (предложения с присоединительной связью). Алар бер-берсеннән мәгънә төсмерләре белән генә түгел, теркәгечләре, интонацияләре белән аерылып торалар.

7. Компонентлары үзара ияртүле бәйләнештә торган җөмләне иярченле кушма җөмлә дип атала. Рус теле грамматикаларында бүген түбәндәге иярчен җөмләләр өйрәнелә: аергыч (определительные), изъяснительные (тәмамлык, ия, хәбәр), хәл (обстоятельственные), өстәлмә (присоединительные), янәшә куеп чагыштыру (сопоставительные).

Татар теле синтаксисында түбәндәгеләр өйрәнелә: ия, хәбәр, аергыч, хәл, тәмамлык, аныклагыч, кереш. Хәл җөмләләрдән вакыт, урын, сәбәп, нәтиҗә, максат, рәвеш, күләм, чагыштыру, шарт, кире төрләре өйрәнелгән. Әлеге җөмләләрнең нәтиҗә, чагыштыру дигән төрләре татар телендә аерым каралмый.

Әдәбият

Байрамова Л.К, Сафиуллина Ф.С. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. Учебное пособие. – Издательство Казанского университета, 1989. – 200 с.

Валгина Н.С. Современный русский язык: Синтаксис: Учебник. – 4-е изд., испр. – М.: Высш. шк., 2003. – 416 с.

Галләмов Ф. Кушма җөмләләрне чагыштырып өйрәтү // Мәгариф. – 2002. – № 9. – 12-14 б.

Татар грамматикасы. 3 томда. Т. III. / Ред. колл. М.З.Зәкиев һ.б. – М.: Инсан, Казан: Фикер, 1999. – 512 б.

Харисова Н. Кушма җөмлә һәм катлаулы төзелмәләр // Мәгариф. – 2005. – № 5. – 21-23 б.

Рогачева Е.Н. Русский язык: синтаксис и пунктуация: учеб. пособие. – М.: ФЛИНТА, 2013. – 117 с.

## ГАЙНӘ ИЛЕ СӨЙЛӘШҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Заитов Айрат,*
*Пермь крае Каенавыл урта мәктәбенең X класс укучысы,*
*Фәнни җитәкче: Заитова Гөлназ Рамил кызы*

Хәзерге вакытта Пермь татарларының килеп чыгышы турында төрле гипотезалар бар. Шулар арасыннан Д.М. Исхаков фикере бигрәк тә игътибарга лаек. Ул Пермь татарларының формалашуында өч этник компонент барлыгын әйтә: Идел буе татарлары, ногай-кыпчак һәм борынгы төрки-угор катламнары. Пермь төбәгендә төркиләр борынгы заманнан ук яшәгәннәр һәм аларны җирле халык итеп күрсәтү фарыз.

Болгарлар катламы, бәҗәнәкләр катламы, кимәк катламы, кыпчак катламы, башкорт катламы, татар катламнары билгеле. Күп галимнәрнең фикеренчә,

Пермь төбәгендәге татарлар Болгар чоры, Казан ханлыгы чорыннан ук яшиләр. Алар Шауба, Ирән, Бөрмә, Тор, Сөлил елгалары буенда укмашып утырганнар. Казан ханлыгы җимерелгәч бу якларга күчеп килүләр ташкыны башлана. Хәттә төньякка, Чердын һәм Соликамск өязләренә күчеп утыручылар да була. Татарларның ул якларда яшәве турында кайбер авыл, елга, тау исемнәре дә күрсәтеп тора.

Пермь татарлары сөйләшенә карата галимнәр арасында төрле фикерләр йөри. Халыкның формалашуында төп компонент буларак катнашкан мишәр-мадьярларның урынын һәм ролен диалектологлар ачыклый. Галим Сарманаева Дания “Урта Урал татарлары теленең диалекталь үзенчәлекләре” дип аталган кандидатлык диссертациясендә Пермь татарлары сөйләшен өчкә – Барда, Уинск һәм Красноуфим-Мачаж сөйләмнәренә бүлеп тикшерә. Беренчесен ул татар теленең урта диалекты, икенчесен көнбатыш (мишәр) диалекты, өченчесен – барлык диалектларның да үзенчәлекләрен үз эченә алган катнаш диалект итеп карый.

Пермь татарлары сөйләшенең мишәр диалекты белән уртаклыгына диалектолог Д.Б. Рамазанова да игътибар бирә. Ул уртаклыкның сәбәбен XVI гасыр азагында Оса дәругының көньяк өлешенә йомышлы мишәрләр күчерелүдә күрә [Рамазанова 1983: 141].

Без, Пермь краенда туып үскән кеше буларак, үз телебезнең казан татарлары теленең бер диалекты икәнен таныган хәлдә, аның әдәби телдән нык аерылуын, мишәрчә сүзләрне күп куллануыбызны (*бөгөн, тимә, өй* диясе урында ү, буяу урынына *сырлау,* сөлге урынына *тастымал* дип әйтү һ.б.), кайбер очракларда бөтенләй бүтәнчә (мишәрчә) “сүләшә” башлавыбызны үзебез дә сизми калабыз.

Телче-диалектологлар Пермь татарларының теле мишәрләр һәм Себер татарлары телләренә якын дип тә язалар. Безнең халык бу якынлыкны читтән көчләп күчерелгән йомышлы татар-мишәрләр алып килгән үзенчәлек итеп түгел, ә борын-борыннан шушында гомер кичергән, Идел буеннан һәм Себердән килгән кавемнәрнең көчле йогынтысына карамастан, үзләренең иске (архаик) сыйфатларын саклап киләләр, дип кабул итәргә тиешбез [Фатыйхов 2002: 19]. Галим, тарихчы Әмир Фатыйхов, венгр-мадьярларның мишәр-маҗарлардан булуын яхшырак аңлау өчен Суфиян Поварисовның “Эҗеләр кайда ята?” дигән кызыклы мәкаләсен) укырга тәгъдим итә.

Фатыйхов Ә. фикеренчә, Пермь татарларын формалаштыруда тагын бер зур компонентның йогынтысы да булырга мөмкин: Пермь якларына монгол яулары, Алтын Урда чорында килеп чыккан кыпчакларның эзләре топонимикада җиңел күзәтелә: охан (чуртан) сүзеннән ясалган Оханск, Куеда районындагы Кыпчак авылы, Төй, Карагаш, Кумыс, Ябалак, Алтын, Казаклар, Каракүл, Урак кебек һәр авыл тирәсендә диярлек вак күлләрнең, чишмә, тау, үрләрнең атамалары кыпчак сүзләреннән ясалган булырга мөмкин.

Алтын Урда заманында язылган Йосыф һәм Зөләйха мәхәббәтенә багышланган “Оҗмахка ачык юл” әсәреннән бер өзекне карап үтик. “Килең, бу

Йосыфка су бирең”, “моны үлтермәң, монда бер коог бар, шул козогка ташлаң”. Бу әсәрдәге “бирең”, “килең”, “үлтермәң”, дөньяда күпме татар булып, тик Пермь төбәгендә (Гайнә һәм Боре сөйләмендә) генә шушы сүзләр сакланган икән.

Гайнә иленең борынгы заманнар белән бәйләнешен иске ай исемнәре (хут, хәмәл, сәүер һ.б.), көн исемнәре (туган көн, атлаган көн, канн көн һ.б.) күп төрле ырымнар, йолалар да искәртеп тора.

Пермь татарлары, аларны формалаштыруда катнашкан аерым кабилә-ырулар турында күп хезмәтләр язган этнограф Дамир Исхаков кыпчакларны нугайларның бер кабиләсе булган дип исәпли, “кый”ылдап сөйләшүче бу нугайларның Кара диңгез буеннан, Кырымнан килүләрен конкрет мисаллар белән раслый [Пермьские татары 1983: 176].

Гайнә иле Россиягә кушылгач, халыкның бер өлеше (Пермь, Куңгер якларындагылар) ясаклы татарлар дип, Уфа провинциясе-губернасындагы калган кечерәйтелгән Гайнә, олысындагылар күбесенчә башкортлар дип атала башлаганнар. Кайчандыр дистәләгән исем белән аталып йөртелгән ыруг кабиләләр вәкилләре ике генә исемне саклап калганнар. Перепись вакытында берәүләр башкорт булып, икенчеләр татар булып языла.

Әдәбият

Пермские татары./ под ред. Халикова А.Х., Мухамедова Р.Г., Исхакова Д.М. – Казань, 1983. – 164 с.

Рамазанова Д.Б. Пермь татарлары сөйләшенең формалашу тарихына карап./ Пермские татары. – Казань, 1983. – С.141.

Фатыйхов Ә. Гәйнә иле: борынгы Гәйнә олысы. – Барда, 2002. – 433 б.

Хабибуллин А.А. Народы Среднего Поволжья и Приуралья: история и культура. – Казань: Экоцентр, 2005. – 284 с.

## Г.ИБРАҺИМОВНЫҢ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ГЕРОЙЛАРНЫ СУРӘТЛӘҮ ОСТАЛЫГЫ

*Заитова Гүзәл,*
*КФУның Алабуга институты студенты*
*Фәнни җитәкче; Хәйруллина Әлфирә Сәлихҗан кызы*

Г.Ибраһимов һәр күргән төс-бизәкне, һәр ишеткән тавыш-авазны бик оста сиземли, тотып ала белә. Ул һәр персонажның үзенә генә хас тавышын, кыяфәтен эзләп таба белә: аның һәр персонажының сөйләшүе, көлүе, елмаюы, елавы үзенчә. Персонаж тавышына хас эмоциональ төсмерләр, тембр бизәкләре аша без ул персонажның характер сыйфатларын – темпераментын, кәефен ачыклый алабыз, аның психологик портреты тудырыла. Нәтиҗәдә һәрбер образ-персонаж индивидуаль шәхес, җанлы кеше булып безнең күз алдына килеп баса һәм хәтердә кала.

“Безнең көннәр” романындагы кайбер персонаж бирелешен карап үтик. Шәһәр мулласы Габдулла һәм Әхмәт Нурый кебекләрне язучы “*сүзгә шома, тавышы да ягымлы иткән, бераз гына Истамбулча катнаштырып, күтәренке, бик шома яңгырак, бераз әрнегән, бераз гаҗәпсенгән, шулай да юлга төшерергә өметләнгән тавыш белән... кайта-кайта сөйләде, сайрады*” кебек сүзләр ярдәмендә, үзләренең белемнәре, сүзгә осталыклары белән политик аңы үсмәгән катлауларны дин һәм милләт бердәмлеге турындагы ялган лозунгларга ышандырып, алдалап, халык бәхетенә каршы баручы дошман итеп сурәтли.

Менә прокурорга каршы каты усал талашлары белән билгеле булган адвокат Абрам Моисеевич Соломонов. “*Чәчрәп яңгыраган нечкә тавыш, “р” хәрефен йота-йота, ачык, кискен яңгыратып ... сайрау*” кебек сүз-тәкъбирләр персонажның тышкы портрет сызыклары (урта буй, ябык йөз, үткер, кара ялтыр куз, һ.б.) белән бик туры килеп, аның милләтенә һәм кайбер эчке сыйфатларына да ишарә итеп торалар.

Г.Ибраһимов персонажлар тавышының характеристикасы сыйфатында тел чараларыннан файдалана. Ул чараларны мәгънәви-стилистик функцияләре буенча түбәндәге төркемнәргә бүлергә мөмкин:

1. Тавышны персонажның эмоциональ халәтен чагылдыру ягыннан тасвирлаучы чаралар: *шат, оялчан, иркәләгән, гаҗәпсенгән тавыш, эчке мәхәббәтле, һ.б.* 2. Тавышны акустик билгеләре (көч, тембр, озынлык, югарылык, һ.б.) ягыннан тасвирлаучы чаралар: *калын, тирән, көчле, күәтле, яңгыравык, музыкаль, күтәренке, чәчрәп, гөрләгән, һ.б.* 3. Тавышны әйтелү рәвеше ягыннан тасвирлаучы чаралар: *кеше аңламаган тавыш, яшерен, бераз серле, тиз, акрын, һ.б.* 4. Тавышны ясалу урыны ягыннан тасвирлаучы чаралар: *тамак төбеннән чыгарылган, бугаз төбеннән чыккан, йөрәктән чыккан, йөрәкнең әллә кай җиреннән килгән; артык түбәнсетелгән, артык хурландырылган йөрәктән чыккан сыман; калын трубадан чыккандай, һ.б.*5. Тавышны персонажларның кире эмоциональ-физиологик халәтен чагылдыру ягыннан тасвирлаучы чаралар: *елаугa охшашлы, өметсезлеккә тулы, сызланган, акылын югалтып барган, аптыраулы, истерияле кимсетүле, изелгән, һ.б.* 6. Тавышны персонажның башка кешеләргә карата эмоциональ-ихтыяри мөнәсәбәтен чагылдыру ягыннан тасвирлаучы чаралар: *сак, ышанулы, таптап юк итәргә баргандай, бик зур афәттән сакларга тырышкан, кыюлык бирер, һ.б.* 7. Тавышны персонажның яшь үзенчәлекләрен чагылдыру ягыннан тасвирлаучы чаралар: *бөтенләй яшь, кипкән карт, һ.б.* 8. Тавышны персонажның чынбарлыкка мөнәсәбәте ягыннан тасвирлаучы чаралар: *ихлас чыгарырга тырышкан, чын, ялган, уенмы-чынмы икәнен аеру читен тавыш, һ.б.* 9. Тавышны персонажның башка кешеләргә ни дәрәҗәдә якын-таныш булуы ягыннан тасвирлаучы чаралар: *бераз салкынча, моңарчы таныш булмаган тавыш, иске, ят, һ.б.* 10. Тавышны персонажның характер үзенчәлекләрен чагылдыру ягыннан тасвирлаучы чаралар: *тупас, оятсыз, иркәләнгән, усаллык һәм каһарманлык тулган, батыр тавыш, һ.б.*

Г.Ибраһимов бер үк персонаж тавышын төрле билгеләр буенча характерлау алымын киң куллана. Мәсәлән, *“акрын әмма кискен тавыш; ачык, саф тавыш; әче, кискен тавыш; карлыккан каты тавыш”* кебек мисалларда тавышның акустик үзенчәлекләре ягыннан тасвирлануы күренә.

Шул рәвешчә, художестволы-эстетик сыйфатларын оста файдаланып, Г.Ибраһимов перснажларның психологик портретларын тудыра; язучы, тавышның эмоциональ төсмерләрендә, тембр бизәкләрендә хис-тойгыларны һәм катлаулы кичерешләрне чагылдырып, персонажларның күңел дөньясына үтеп керә һәм “җан диалектикасын” ача. Бу яктан да без Г.Ибраһимовның атаклы рус язучылары Л.Толстой, М.Горький шикелле психологик анализ остасы булуын күрәбез.

Әдәбият

Ибраһимов. Г. Әсәрләр. Сигез томда. Икенче том – Казан: Татар. кит. нәшр, 1974.

Нигъмәти Н. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1958.

Шамов А. Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр – Казан: Татар. кит. нәшр, 1966.

## УКУЧЫЛАРДА ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНУ УЯТУДА ТЕАТР ТҮГӘРӘГЕНЕҢ РОЛЕ

*Заитов Рөстәм,*
*Пермь крае, Барда районы,*
*Каенавыл урта мәктәбенең X сыйныф укучысы*
*Җитәкче: Заитова Динә Габдуллаҗан кызы*

Соңгы вакытта укытучыларның “Яшьләр китап укымый”, “Хәзерге балалар өчен компьютер, интернет, кәрәзле телефон китапны алыштыра” дип зарланганын еш ишетергә туры килә. Өлкәннәрнең тел төбеннән “Балалар әдәбият белән кызыксынмыйлар” дип әйтергә теләгәннәрен аңлап була. Мондый проблеманы тудырган сәбәпләрне барыбыз да беләбез. Ә моны ничек чишәргә ? Рәсәйнең аерым алынган мәктәбендә, аерым алынган сыйныфында аны хәл итеп буламы соң?

Моның өчен әдәбият дәресләрен сыйныфтан тыш чаралар, шул исәптән театр түгәрәге белән үреп алып барырга кирәк. “Театр+Без”” дип аталган актер түгәрәгендә бөтен сыйныфыбыз белән 5 ел шөгыльләнгәннәрдән чыгып, шундый нәтиҗәгә килергә була: түгәрәкнең эшен укытучы балалар һәм әти-әниләр белән берлектә оештырса, спектакльләр кую үзмаксатка әйләндерелмичә, киңрәк эш төрләрен үз эченә алса, укучыларда әдәбият белән кызыксыну уятырга, бу өлкәдә әйләнә – тирәне танып белүләрен киңәйтергә мөмкин.

Түгәрәкнең эше “Театраль уен”, “Ритмопласстика”, “Тел культурасы һәм техникасы” дигән бүлекләрдән тора. Ул әдәби әсәрләр белән эшне, әңгәмәләр, репетицияләр, спектакльләр карауны һәм куюны үз эченә ала. 5-6 нчы

сыйныфларда спектакльләр кую (Туфан Миңнуллинның "Авыл эте Акбай", Галимҗан Гыйльмановның "Конфетлар патшалыгында", "Кыш бабайда сер бар" пьесалары буенча), сәнгатьле уку юнәлешендә эш алып барылса, 7-8 нче сыйныфларда зур булмаган пьесалар иҗат итү, театрлаштырылган уеннар үткәрү, спектакльләргә афиша, реклама уйлау, ә инде 9 нчы сыйныфта әдәби кунакханәләр, тематик кичәләр үткәрү, Программада бирелгән әсәрләр буенча төшерелгән спектакльләрне видеоязмаларда карап, режиссер варианты белән автор вариантын чагыштыру, хәтта видеофильм төшерү кебек алымнардан тора.

Түгәрәк утырышларында татар театрының тарихы, татар драматургларының, танылган татар артистларының тормышы һәм иҗаты, әдәбият теориясе белән танышу да урын алган. Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, педагог,композитор, артист, авылдашыбыз Мәсгут ага Имашев, Татарстанның атказанган халык артисткасы, Тукай премиясе лауреаты , райондашыбыз Дамирә Кузаева иҗатлары белән танышу, районыбыз горурлыгы – халык театры артистлары белән очрашу, аларның репертуары белән танышу, спектакльләрен карау – иң отышлы алымнар. Казаннан килгән театрларның уйнавында "Көмеш беләзек", "Бер тамчы ярату" кебек спектакльләрен карау әдәбиятның иң катлаулы төре булган драманың , Н.В.Гоголь сүзләре белән әйтсәк, "...сәхнәдә генә яши башлавын, аннан башка ул тәннән аерылган җан кебек" икәнлегенә төшендерә.

Шулай итеп, дөрес һәм күпьяклы итеп оештырылган театр түгәрәге укучыларда татар әдәбиятына кызыксыну уятуда мөһим чара булып тора. Ә ул, үз чиратында, икетеллелек һәм урта диалектның көчле йогынтысы, татар теле һәм әдәбияты дәресләренең елдан-ел башка фәннәр белән кысрыклануы шартларында туган телебезне сакларга да ярдәм итә.

## Әдәбият


Әхмәдуллин А.Г. Әдәбият белеме сүзлеге: – Казан: Татар. кит.нәшр., 1990. – 172 б.

Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 128 -152.

Хәйруллина А.Г. Дөрес сөйләргә өйрәнегез. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1992.


## Р. ВӘЛИЕВ- КҮПКЫРЛЫ ТАЛАНТ ИЯСЕ


*Зарипов Камил,*
*Түбән Кама шәһәренең Баки Урманче исемендәге*
*2 нче гимназиясенең VII сыйныфы укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Зарипова Әнисә Газизулла кызы*


Разил Вәлиев Түбән Кама төбәге язучысы, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, дистәләгән китаплар авторы, шигърияте аша яшь буында туган

илебезгә, телебезгә, табигатебезгә мәхәббәт, горурлык хисләре тәрбияләүче, бүгенге көнебезнең, яшәешебезнең төрле өлкәләрен үз тормыш юлы аша күзаллап, хәзерге буын кешеләренең уй-кичерешләрен, теләк-омтылышларын, яшәү мәгънәсен шәхсән үз кыйблаларыннан чыгып аңлауларын бөтен тулылыгы белән иҗатында яктырткан шагыйрь.

Шагыйрьнең балалар тормышын, аларның уй-теләкләрен шагыйрь йөрәге аша уздырып үтемле итеп укучыларына җиткерүе, шигырьләренең бик күп темаларны яктыртуы, дөнья халыклары әкиятләре белән татар балаларын таныштыруы, балалар өчен көйгә салынган шигырьләре, яшь каләм ияләренә илһам ялкыны салучы шәхес булуын тагын бер кат раслый.

Аның иҗаты күпкырлы, балалар дөньясын бөтен тулылыгы белән ачып бирүгә ирешкән талантлы шәхес буларак, гимназиябездә Р. Вәлиевнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү; Г. Тукай, К. Гали исемендәге китапханәләрдән язучы турында өстәмә мәгълүмат туплау; балалар тормышын, аларның уй-теләкләрен һәм гомумән бала характерен шагыйрь йөрәге аша уздырып укучыларына җиткерүен ачып бирү; балаларның сәләтен ачуга керткән хезмәтен өйрәнү; Разил Вәлиевне тәрҗемә остасы буларак ачу, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә һәрдаим алып барыла.

**А**вторның басылып чыккан китаплары, замандашлары тарафыннан иҗатына, китапларына карата әйтелгән фикерләр, матбугат битләрендә басылган мәкаләләр, кулъязмалары:

балалар тормышын, аларның уй-теләкләрен һәм гомумән бала характерен шагыйрь йөрәге аша уздырып укучыларына җиткерә;

яшь каләм ияләренә илһам өстәүче, балаларның сәләтен ачуга зур хезмәт куйган шәхес ул Разил Вәлиев;

тәрҗемә остасы, балаларга дөнья халыклары әкиятләре белән танышу мөкинлеге биргән язучы;

балалар дөньясын җыр сәнгате аша ачуга үзеннән өлеш керткән язучы;

аның шигырьләре – тәрбия чыганагы. Шигырьләре изгелеккә, яхшылыкка өндиләр, олы тормышка туры һәм дөрес юл күрсәтәләр.

Йөрәгендә шигырь утын саклап яшәүче Разил Вәлиев кебек шәхесләребез барында изге чишмәләр саекмас, аларның шифалы суы киләчәк буыннарның җанын саф хисләр белән гел сугарып торыр, дигән ышаныч бар.

Әдәбият

1. Вәлиев Р. Кышкы учак: Шигырьләр, җырлар. − Казан: Татар. кит. нәшр., 1994 нче ел ,”Без- кояш балалары” – Б.230.

2. Вәлиев Р. Кояшлы җыр: балалар өчен җырлар. − Казан. Татар. кит. нәшр., 2007. – Б. 77.

3. Вәлиев Р. Әдәби-нәфис басма. Мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен// “Ирек мәйданы” газетасы, 2 нче апрель, 2009.

4. Иң яхшы бүләк: Түбәк Кама шәһәре һәм районы балалары иҗаты/Төз.Р. Муллин; Мөх-ре Н. Гамбәр. – Казан:"Милли китап" нәшрияты, 2005.-108 б.

## ТАРИХ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

*Землянова Мария,*
*Минзәлә районы Кадрәк төп белем бирү мәктәбе укучысы*
*Фәнни җитәкче: Ибраһимова Альбина Әбелгаян кызы*

Тарих... Үз эчен күпме гасырларны, елларны, язмышларны сыйдырган. Кешелек башланганнан бирле бүгенге көнгә кадәр күпме сулар аккан, күпме буыннар алмашынган. Һәркем үзе өчен дә, киләчәк буыннар өчен дәниндидер нәтиҗәле эш калдырырга тиеш. Чөнки үткәнен белмәгән милләтнең киләчәге юк. Милләт белән бергә гореф-гадәтләр дә, йолалар да, тел дә , аның геройлары да саклана. Киләчәк буыннар өчен, авылың, мәктәбең турында мәгълүматлар калдыру бик мөһим. Безнең җөмһүриятебездә күп саны авыллар, мәктәпләр бар. Аларның һәркайсының үз язмышы, үз тарихы. Ә менә бүген 50 яшьлек Кадрәк төп белем бирү мәктәбенең чишмә башы кайда икән?

Белем йорты –мәктәп – туган җирнең бер өлеше. Кадрәк мәктәбе тарихы ерак дәверләргә барып тоташа. Гомер-гомергә төрле милләт вәкилләре дус-тату яшәгән бу төбәк элек-электән мәгърифәткә, белемгә тартылуы белән аерылып торган. 19 нчы гасыр ахырында Кадрәк керәшен татарлары мәктәбе ачылган булса, Җәмәк авылындагы мәдрәсәдә мөселман татар балалары белем алганнар, дин нигезләре белән беррәттән дөньяви фәннәрне дә өйрәнгәннәр. 1910 нчы елны «Церковно-приходская школа" ачыла. Ул мәктәптә Минзәлә районныннан тыш, Сарман районы балалары да килеп укыйлар. Бу мәктәп 30 нчы елларга кадәр эшли, аннан 4 еллык башлангыч мәктәпкә әйләнә. Биредә 1 нче сыйныфта 8 яшьлек бала да, 18-20 яшьлек егет-кызлар да укый. 1931 нче елда Кадрәктә эшче-яшьләр мәктәбе үз ишекләрен ача. 1933 нче елда ул җидееллык мәктәп итеп үзгәртелә. 1932-1933 нче елларда Кадрәк җидееллык мәктәбендә пионер һәм комсомол оешмалары төзелә. Тарих сәхифәләре безнең көннәргә кадәр беренче пионерларның исемнәрен дә саклап калган. Менә алар: Абдуллина Һаҗәр, Абдуллина Нурдидә, Сафиуллин Вәгыйз, Камалов Бижан [Юсупов 2016: 147].

Кадрәк җидеелык мәктәбенә нигез салып, 12 ел буе аның директоры һәм татар-рус телләре укытучысы булып эшләгән мөхтәрәм зат – Миргаяз Әхмәтхан улы Әхмәтханов була. Коллектив булып оешып, эшләп киткәнче укытучыларга да, укучыларга да шактый уңайсызлыкларга җайлашырга. кыенлыкларны җиңәргә туры килә. Эш шунда: элеккеге мәктәп бинасын кулаклар яндырганга, яңасы салынганчы иркенрәк хуҗалыкта (Гермагентов Л., Афанасьев Л., Григорьев А.) бүленеп укыйлар. Ятим балалар өчен интернат ачыла, анда 17 укучы тәрбияләнә [Юсупов 2016: 204].

Яңа мәктәп бинасы төзелешендә дә эшлиләр. Җәйге мәктәп оештырыла, анда яшелчә, җиләк-җимеш үстерәләр.Директор Әхмәтханов М. үз тирәсенә көчле коллектив туплый. Садертдин Шабаев (Марс Шабаевның әтисе) – завуч, Исламов Вәгыйз – тарих, география; Харитонова Елизавета – рус теле, Исламов Нурлый – алгебра, геометрия, Евграпов Кирилл – хезмәт, Шәйхетдинов Т. – фиология фәннәреннән белем бирәләр.

1944-1956 елларда мәктәп белән тарих укытучысы Авзалов Кәшиф Авзалович җитәкчелек итә. Газаплы сугыш еллары, сугыштан соңгы авыр яралар, юклык... Шулай да мәктәп коллективы бу сынауларны бирешмичә, горур рәвештә җиңә.Ә менә унъеллык мәктәп булып оешу, эшләп китү, районда алдынгы коллективлар рәтенә басу директор Нәҗмиев Мирзаян Биҗан улының исеме белән бәйле. Сугышның ачысын-төчесе үз җилкәсендә татыган Мирзаян абый 1958 елдан алып 1975 елга кадәр мәктәп белән җитәкчелек итә. Кадрәк төбәге җирлегендә”олы, таш мәктәп” салу тарихы да шушы мөхтәрәм зат исеме белән бәйле. Район авыллары тарихында беренче стандарт мәктәп була ул. Ә Нәҗмиевләрнең нәсел шәҗәрәсенең бөтен тармаклары буенча гомуми педагогик стажны санап чыксаң, 1200 елдан артып китә [истәлекләр].

1988 нче елдан башлап 2017 нче елга кадәр мәктәпне Рәхмәтуллин Идрис Нурмөхәммәт улы җитәкли. Оста җитәкченең армый – талмый тырышуы, үз вазыйфасына намуслы каравы нәтиҗәсендә мәктәбебез ел саен республика, район күләмендә уздырылган бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар яулый. Белем сыйфаты да югары. Мәктәпкә капиталь ремонт ясалды, спорт мәйданчыгы төзелде. Укучылар спортны бик тә яраталар. Безнең мәктәп татарча көрәш буенча 7 – “Спорт мастеры”, 8 – “Татарстан чемпионы”, 6 – “Россия чемпионы” тәрбияләгән мәктәп. Шулай ук бу мәктәптә тәрбияләнгән егетләр-кызлар спортның башка төрләре буенча да сынатмыйлар. Йөгерү, гер күтәрү, чаңгы, баскетбол, җиңел атлетика буенча район һәм республика күләмендә призлы урыннар яулыйлар. Кадрәк мәктәбе үзенең данлыклы уллары, кызлары белән горурлана. Төбәккә бәяне дә шуннан чыккан күренекле шәхесләрнең дәрәҗәсенә карап бирәләр. Җирлекнең данлыклы тарихы, күренекле, бөек, мактаулы исемнәр алган мөхтәрәм кешеләре бихисап. Аларның һәрберсе зур тарихлы Кадрәк мәктәбен тәмамлаган шәхесләр.

Сулар ага, ярлары кала. Гомер үтә, кешеләр кала. Кешеләр күчә, нәселе кала, эшләгән эшләре, кылган яхшылыклары, изгелекләре җирдә, киләчәк буыннар хәтерендә, күңелендә кала...Хәтер кеше аңында мәңге яши, яшәячәк һәм яңа буынны батырлыкларга, эзләнүләргә өндәячәк. Безнең, яшь буынның, төп бурычларыннан берсе - безгә белем һәм тәрбия биргән шәхесләрне данлап һәм хөрмәтләп яшәү, аларның исемнәрен мәңгеләштерү.Мәктәп тарихына кагылышлы документлар, истәлек -хатирәләр нигезендә мин аның үсеш тарихын күзәттем, мәктәп белән бәйле шәхесләрнең биографияләрен өйрәндем, укытучылары турында мәгълүмат тупладым.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: һәр яңа буын үзеннән соң килгән буынга мәктәпнең традицияләрен тапшыра, һәр яңа буын мәктәп тарихына яңа битләр

өсти, һәр яңа буын анда яңа сәхифәләр ача. Димәк, бу эш дәвамлы. Тарих ул эзләнгәнне ярата.

Әдәбият

Юсупов Ю. Ю. Мензелинский край. История и современность. – Мензелинск , 2006. – 495 б.

## Н. ФӘТТАХНЫҢ “ИДЕЛ СУЫ АКА ТОРУР” РОМАНЫНДА БҮРЕ СИМВОЛЫ

*Зиатдинов Булат,*
*Яр Чаллы шәһәре 7 нче урта мәктәбенең XI сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Камаева Рима Бижҗан кызы*

Әдәбиятта серлелеге белән аерылып торучы күренеш бар: ул – символизм. Мөстәкыйль агым төсендә XIX йөзнең 60-70 елларында Франциядә формалашкан дип саналса да, символлар системасыннан файдалану тәҗрибәсе борынгы һәм урта гасырлар әдәбиятында ук мәгълүм була. Европа әдипләре дә, суфи шагыйрьләр дә, бик теләп, символларга – теге яки бу күренешнең мәгънәсен башка формада белдерүче сурәткә мөрәҗәгать иткән.

Әдәбият белгече Д. Заһидуллина “символизм” төшенчәсенең ике яссылыкта кулланылуын билгеләп үтә. Бер яктан, ул – аерым бер мәдәни җәмгыятьләрдә генә формалашкан дөньяга караш, яшәешне таныпбелү системасы. Икенче яктан, әдәби (мәдәни) агым, милли иҗатчылар әдәбиятка алып килгән алымнар тупламасыннан файдалану [Заһидуллина 2003: 75].

Татар әдәби теленең төрле стильләрендә, сөйләм чарасы буларак, тасвирый билгеләр кулланылалар. Алар чынбарлыктагы күренешләрнең асылына төшенергә, төп фикерне дөрес аңлауга һәм күзаллауга ярдәм итәләр. Тасвирый билге иҗтимагый күренешләрне параллель кую җирлегендә барлыкка килә, чынбарлыкның күп якларын сәнгатьчә сурәтләп бирә. Шуңа күрә анда мәгънәнең киңлеге беренче урында тора. Бу алымның нигезендә күчерелмә мәгънәлек ята.

Әдәбиятта метафорик алыштыруларга нигезләнгән сүрәтләү чараларының бер төре – символ. Ул – нинди дә булса күренешне, предметны аңлата торган шартлы сүз яки билге.

Символ (грек. symboloh – билге, танытучы сыйфатлар) – күпсанлы ассоциатив сыйфатларны берләштерүче күпмәгънәле, гомуми образ [Әдәбият белеме сүзлеге 1990: 182]. Туры мәгънәсеннән тыш, символ аңа бәйле булмаган күчерелмә мәгънәне аңлата (мәсәлән, ак күгәрчен – тынычлык символы), ләкин шуның янәшәсендә башка мәгънәләр дә сиземләнә (ак күгәрчен – саф мәхәббәт, матурлык символы һ.б.)

Бик борынгы заманнарда кешеләрнең фикерләү рәвешендә хайваннар белән бәйлелек зур урын тоткан. Борынгы кеше үзендәге сыйфатларның хайваннарда да булуына ышанган. Хайваннарны ул үзе кебек ук сөйләшә һәм фикерле белә дип исәпләгән, үзен алар белән туганлык мөнәсәбәтендә тора дип

уйлаган. Хайваннар белән туганлык мөнәсәбәтенә ышану мәҗүсилек чорында һәр ыруның ниндидер бер хайванны яки кошны үзенең нәсел башы итеп санавына китергән. Ыруны саклаучы һәм яклаучы дип ышанылган әлеге хайванны үтерергә ярамаган.

Төрки халыкларның күбесендә бүре изге хайван былып саналган. Чөнки ышанулар буенча, төрек ыруларының нәселе, имеш, бүредән башланган. Н. Фәттахның "Идел суы ака торур" романында шуңа ишарә ителә. Әсәрдә Акбүре ыруы турында сүз бара. Акбүре ыруының нәсел башы булып бүре санала. Беркөнне, йолык туеннан соң, ыруының төп дин әһеле Утташ кам йолык туе үткәрелгән изге нарат төбендә үтерелгән бүреләрне күреп ала. Ул бик борчылып Күрән би янына килә.

*"– Эш чыкты, би... кияү! – дип кычкырды ул, чәрелдек тавышлар белән. – Ниндидер явызлар изге наратны... бөтен ыругның изге сакчысын, яклаучысын мыскыллаганнар! Тәүбә! Тәүбә! Изге аланны бозганнар!(...) Из-зге нарат төбендә... ч-ч- чүмәлә дисәң, ч-чүмәлә түгел... у-утын дисәң утын түгел... Йә тәңрем! Үле бүреләр өелеп ята! Кайсын ук белән, кайсын кылыч, сөңге белән... Унлап-унбиишләп! Бүре каны койганнар! Изге җиргә, изге нараткаебызга... изге бүре каны койганнар!"* [Фәттах 1980: 35]. Акбүре ыруы өчен бу беркайчан да булмаган, була алмастай яман бер эш иде. Бу эшне ыру башлыгы Күрән бинең улы Тотыш эшләгәне билгеле була. Романның башында ук менә шушы хәл тасвирлана һәм роман ахырына кадәр Тотыш бертуктаусыз бәлаләргә очрап кына тора. Ыру өчен күпме генә изге эшләр башкарса да, үзенең кайнарлыгы белән эшләнгән языгын ул юа алмый. Роман ахырында аның һәлак булуы моны раслый.

Әдәбият

Әдәбият белеме сүзлеге /Төз.- ред. А.Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 238 б.

Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 255 б.

Фәттах Н. Ител суы ака торур. Тарихи роман. – Казан: Татар кит. нәшр., 1980. – 399 б.

## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ БЕЗНЕҢ КУЛДА

*Ибраһимова Алсу,*
*КФУның Алабуга институты студенты*
*Фәнни җитәкче: Камаева Рима Бижҗан кызы*

Бүгенге көндә татар теленең киләчәге турындагы сораулар бер татар кешесен дә битараф калдыра алмыйдыр, мөгаен. Безнең менталитетка хас үзенчәлек шушы көннәрдә актив чагылыш таба. Юк ителү куркынычы барлыкка килгәч кенә, баш күтәрә башлыйбыз шул. Социаль челтәрләр, вакытлы матбугат, блоггерлар, татар җанлы гади кешеләрнең шәхси битләрендә

инде 1-2 атна шушы темага кагылышлы постлар гына урнаштырыла. Бу эшнең чишмә башы да шунда ята.

Татар теле язмышы турында соңгы дистә ел эчендә күпме язылды, күпме сөйләнде... Барлык язмалар һәм чыгышларны бәяли башласак, аларның төп юнәлешләре ачыклана. Ул – телебезне саклап калу һәм аны үстерү чаралары [Гыйләҗев, 2017].

Хәзерге катлаулы дөньяда без проблемаларга да “алсу күзлек”тән карап кына бәя бирәбез: үзебезнең шәхси тормыш, материаль байлый беренче урында килеп баса. Рухи байлыкларны акча мәсьәләсе тулысы белән каплап бетерә. Татар теле татарларга да кирәк булмаса, киләчәктә безне нәрсә көтә?

Искәндәр Гыйләҗев “Безнең мирас” журналының 7 нче санында татар телен саклап калу өчен хәрәкәт юнәлешләре тәгъдим итә:

1. Шәһәрдә чын татар мохитын булдыру.

2. Сыйфатлы, зәвыклы, шәһәр халкына да, авыл халкына да кызыклы, яхшы татар телевидениесен булдыру – телне саклауда зарури бер шарт.

3.Тагын бер актив үсә торган юнәлеш – интернет һәм компьютер технологияләре.

4. Мәгариф һәм милли мәктәп.

5. Татар телен оныткан, ләкин татар үзаңын югалтмаган, үзләрен татар дип саный торган милләттәшләребез белән эш алып бару бик тә актуаль бурыч булып күренә.

6. Татар теле, тарихы, мәдәнияте абруен арттыру өчен, тагын бер юл булып чит өлкәләрдә, чит илләрдә татар тематикасы белән шөгыльләнә торган галимнәргә игътибарны юнәлтү тора [Гыйләҗев, 2017].

“Азатлык радиосы” сайтында үткәрелгән сораштыруларга да аерым тукталып үтәсе килә. “Татарстан мәктәпләрендә татар теле ничек укытылырга тиеш?” дигән сорауга 35 % татар телен барысы да укырга, күләме урыс теленнән күбрәк булырга тиеш дигән булсалар, 59 % татар телен барысы да укырга, күләме урыс теле белән тигез булырга тиеш дигән җавап калдырган. 1% татар телен барысы да укырга, күләме урыс теленнән азрак булырга тиеш дисә, 5 % татар телен теләгәннәр генә укырга тиеш дип җавап биргән. Сораштыруда татар телен укытуны кире кагучыларга җавап бирү мөмкинлеге юк, менә шул җавапсыз кала, алар күпме булырлар иде икән?

Мәктәптә, югары уку йортларында яшьләрнең авызыннан еш кына татар теленең гомумән кирәкмәгән фән булуы турында ишетергә туры килә. Иң аянычлысы менә шул да инде...

Татар шагыйрьләре, блоггерлары белән бер рәттән эстрада артистлары да чаң сукты. “Татар-информ” җиткерүенчә, башкалабыз Казанда урнашкан Бауман урамында татар артистлары җыелып “Туган тел” җырын башкардылар. Әлеге җыр татар теленең гимнына әверелде дип әйтсәк тә ялгыш булмас. Флешмобтан соң алынган интервьюларда татар артистларының тел язмышы өчен борчылулыры, көрәшүләре ачык чагыла. Алар телне җыр аша пропагандалауны кулай дип таптылар. Ләкин бер яшь кенә ханым: “Тел бетсә

татар концертлары да бетә", – дип әйтеп куйды. Һәркем үз мәнфәгатьләрен кайгырта шул.

Татар филология студентлары тарафыннан да төрле флешмоблар үткәрелә. Мәсәлән, кайда гына керсәң дә, татар телендә исәнләшү, социаль челтәрләргә постлар кертү, "Туган тел" җырын җырлау һ.б. Бу күренешләр, әлбәттә, барлык татар кешеләрен дә куандыра. Ләкин болар һәрчак булып торса, тел алдында бернинди куркынычлар да булмас иде. Киләчәгебез ачык, билгеле булыр иде. Хәзер исә, тел һәм аның киләчәге безнең кулда. "Тамчыдан күл җыела", ди халык. Һәрберебез тел язмышы өчен тырышсак, һичшиксез, телебез үсәр, алга барыр, яңа үрләргә менәр!


Әдәбият

Гыйләҗев И. Татар теле язмышы турында кайбер уйланулар. http://matbugat.ru/news/?id=7120. Мөрәҗәгать итү датасы: 31.10.2017

Косолапин В. Флешмоб в защиту татарского языка провели звезды татарской эстрады. http://www.kazved.ru/article/83456.aspx. Мөрәҗәгать итү датасы: 31.10.2017

Мәгариф министрлыгы татар теле дәресләре кимү ихтималы хәбәрен кире какты. https://www.azatliq.org/a/28742122.html. Мөрәҗәгать итү датасы: 31.10.2017


## АЗНАКАЙ РАЙОНЫ ӨШЕГӘН ЯКИ ТАТШУГАН АВЫЛЫ


*Исхакова Рәзилә,*

*Әлмәт политехника техникумының 4 курс студенты*

*Фәнни җитәкче: Камалова Зөлфия Ахат кызы*


Туган як, туган җир, туган авыл! Якын да, газиз дә булган бу сүзләр һәркемнең йөрәк түрендә булырга тиеш. Кендек каны тамган, беренче тәпи баскан, икмәк исен, хезмәт тәмен татыган, тәүге хисләр, шатлык-борчылулар кичергән бу урыннар Һичкайчан истән чыкмый, телдән төшми. Үз җирен, авылын яратмаган кеше юктыр ул. Тик менә бик сирәкләр генә үз авылларының исеме, аның килеп чыгышы, тарихи үткәне, бүгенгесе белән кызыксына. Ә бит халыкта "Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк" дигән бик матур гыйбарә бар. Шуна хәзерге балалар үз туган авылын белмиләр, аны тарихын өйрәнмиләр. Минемчә хәзерге балалар өйрәнсә бик тә яхшы булыр иде! Шуны истә тотып, мин дә үз авылымның исеме, гореф-гадәтләрен, бабайларны бабалары өйрәндем, килеп чыгу тарихы белән кызыксынырга булдым, һәм шуңа үземнең авылыма багышланга шигырьне сезгә тәкъдим итәм.

**Газиз җирем!**

Татшуган - туган җирем,
Бик тә якын күңелгә.
Матур, ямьле табигате
Тартып тора үзенә.

Җәй көнендә тау битендә
Пешә кура, җирҗиләк.
Кышын чаңгы шуганда
Җилкенеп тора йөрәк.
Челтерәп ага чишмәләр,
Җанга якын болыны.
Сине алыштырырлык
Башка җир табылырмы?!

**Туган авылым урамы...**

XVI гасыр урталарында әле Татар Шуганы авылы (Азнакай районы) кеше кулы тимәгән хәлдә була. Урманнарында каен, имән, усак, чикләвек агачлары үсә. Бүре, кабан дуңгызы, кыр кәҗәләре, төлке, бурсык, куян... кебек җәнлекләр яшәгән. Җәй көне күлләрендә аккош, кыр үрдәкләре бала чыгарган.

Татар Шуганы авылына Чубар-Абдул авылыннан күчеп килгән Тәмәй исемле кеше нигез сала. Ул Корчый чокырының көнчыгыш өлешенә урнаша. Аның Ямәй исемле бер генә улы була. Бары тик биш бабайдан – Тәмәй –Ямәй – Кәчер –Йосыф – Мөәминнән соң гына авылда халык саны арта. XVII гасыр урталарында Корчыйның көнбатыш ягына Казан ягыннан кешеләр килеп урнаша башлый. Авыл халкы игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнә. Элегрәк авыл исеме белән бәйле шундый риваять яшәгән. Имеш, авылда бер татар кешесе өшеп үлгән, шуннан ул Татар өшегән авыл, ягъни Татар Шуганы дип йөртелә башлый. Рәсми документларда да авыл исеме Өшегән сүзе (авылның Өшегән елгасы буенча урнашуы) белән бәйләп аңлатыла. Аның халкын татарлар һәм башкортлар тәшкил итә. Авылда 106 хуҗалык була. Ир – атлар – 378 кеше (аларның 196 башкорт, 182 татар дип язылган). Хатын-кызлар – 309 (153 башкорт, 156 татар). Авылда мәчет һәм училище эшли.

Авыл кешеләре арасында тырышлыгы белән аерылып торган кешеләр була. “Әптерәмән буе” дигән урын бар. Бу элек Габдрахман карт тоткан җирләр. “Сәлим буе” дип йөртелгән чирәмлек Сәлим исемле кешенең милке саналган. Урман буендагы җирләргә Билап исемле кеше хуҗа булган.

Безнең авыл өч яктан да урман белән уратып алынган. Урман буенда Галәү каены дигән каен бар. Аңа багышлап шигырьдә чыгарылган:

Үзәнлеккә җитсәм,
Тарих тагын чигенә кирегә.
Галәү атлы буйдак карт утырткан.
Ялгыз каен үсә биредә (“Авылым юлы “)
“ Таллы кое” турында исә мондый шигырь бар:
Кем утырткан, кайчан утыртылган;
Белүчедә юктыр, тәгаен.
Бөреләре керфек чылатканда,
Авылыбызның кайсы агаен
Искә ала икән бу ялгыз тал-

Зур урамның олы бизәге.
Әнкәм сүзе: сабый чактан күрдек
Нәкъ шушындый итеп без аны.
Куенында, җиләс күләгәдә,
Иске кое, имән буралы,
Тал тамыры, бөдрә толымнардай,
Ниргәләргә үскән уралып, – дип яза шагыйрь.

Авыл уңайлы урында-ике елга – Өшегән һәм Корчый елгалары арасына урнашкан.

Иң борынгы чишмәләреннән берсе – "Колый чишмәсе". Авылны "Корчый чокыры" урталай бүлә. "Таш еа"дан кешеләр мунча ташы җыя торган булалар. Тәкәрлекләр оялаган сазлык " Тәкәрлек сазлыгы" дип атала.

Бүгенге көндә авылда мәчет, клуб, урта мәктәп, балалар бакчасы эшли. Авыл район үзәгеннән 41 километр ераклыкта. Авылыбыздан күп кенә күренекле кешеләр чыккан. Алар арасында Чаллыда яшәүче язучы Данис ага Хәйруллин, Кәрим Тинчур исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының директор урынбасары Халисә Исмәгыйлева бар. Авылым нык тормыш белән, матур яши.

Димәк, һәр авылның, шәһәрнең үз тарихы, йөзек кашы булырдай күренекле шәхесләре, өметле киләчәге бар. Хезмәттән тәм табып, булганын кадерләп саклап, булмаганын булдырырга тырышып яшәгән минем халкым бар. Тагын шунысы мөһим: авылымның иң зур горурлыгы – аның уңган-булган халкы. Шуңа да авыл халкы бер-берсенең уңышларына сөенеп, борчу-мәшәкатьләрен бүлешеп, иртәгәге көнгә өмет белән карап яши торган халык яши безне Өшегән яки Татшуган авылында.

Әдәбият

Галләмов Р.Ф. Русча-татарча тарих терминнарының аңлатмалы сүзлеге – Казан: Мәгариф, 2006.

Фәхретдинов Р.Г. Татар тарихы. – Казан: Мәгариф, 1999. – 111 б.

Ибраһимов М., Ахметзянов Г., Ибраһимов Г. Иске тел // Казан утлары. – 1978. – № 3.

Ибраһимов М., Әхмәтҗанов Г., Ибраһимов Г. Иске тел // Совет мәктәбе. – 1977. – № 5.

Һилалов. З. Кукурузның файдасы // СоветТатарстаны. – 1957. – № 35.

Лотфуллин А.Минометчик хәтирәләре // Маяк. – 1988. – № 23.

## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ НӘСЕЛ ДӘВАМЧЫЛАРЫ

*Йосыпова Зөһрә,*
*Пермь крае, Барда районы,*
*Сараш мәктәбенең VIII сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Туйгильдина Вәсимә Вәсих кызы*

Муса Җәлил – бу исемне телгә алуга, күз алдына ниндидер гадәттән тыш кеше килгәндәй була. Ул – ялкынлы шигырьләр язган шагыйрь дә, илнең азатлыгы өчен курку белмәс көрәшче дә, үлемне ирләрчә батыр каршылаган каһарман да.Җәлилне язучы, көрәшче буларак беләбез, ә аның шәхси тормышы безнең өчен моңарчы ябык булып торды. Шуңа курә мин бугенге эшемдә шагыйрьнең халыкка ачылмаган серләре турында сөйләп үтәрмен.

Белүегезчә, Совет заманында Муса Җәлилнең барлык балалары турында әйтергә дә, язарга да ярамаган. Муса Җәлилнең өч баласы һәм дүрт оныгы барлыгы кемнәргәдер сердер, бәлки. Иң олысы – Альберт, аннан Люция, кечкенәсе Чулпан. Бүген моннан ниндидер хәрби сер ясамаска кирәк дип уйлыйм. Советлар Союзы Героеның өч хатыны булуы, әлбәттә, ул заман өчен сәеррәк булгандыр. Әмма бүген моның белән берәүне дә шаккатыра алмыйсың.

Муса Җәлилнең беренче хатыны Рауза Хисмәтуллина. Ул Татар дәүләт академия театрында актриса булып эшли һәм Зифа Басыйрова белән дус була. Җәлилдән туган улы Альберт штанга, гимнастика белән шөгыльләнә, сыйныфларында иң яхшы йөзүче була. Ул очучылар училищесына керергә хыяллана. Күзенә зыян килү сәбәпле медкомиссияне үтә алмый. Әмма Саратов шәһәренә барып хәрби училищены тәмамлый һәм Кавказда хезмәт итә, үз частенда иң яхшы офицер була. Десант хәрби частенда химия хезмәте башлыгы итеп билгеләнә. Ниһаять, парашюттан сикерә башлый һәм күккә менү хыялына ирешә. Аннан соң унике ел Германиядә хезмәт итә. «Мин үз-үзем алдында зур җаваплылык тоеп яшим. Әти даны нурларында йөзү миңа хас нәрсә түгел. Мин бары аңа лаеклы булырга гына телим», – ди ул. Әтисе белән масаю дигән нәрсә аның башына да кереп карамый. Аның исендә, 1941 елны фронтка китеп барышлый әтисе-М.Җәлил,улын кочаклап: “Үс,улым,һәм авырлыкларны җиңеп чыгарга өйрән.Намуслы,чын кеше бул”,-дигән.

Муса белән аерылышкач, Рауза икенче кешегә тормышка чыга. Алар 1945 елда Украинага күчеп китә. Анда биш ел торганнан соң, Ижауга күчеп киләләр. 17 ел элек Рәмис Әймәт белән бер әңгәмәсендә әнисе хакында Альберт болай ди: «Әни бик горур иде. Аннан тыш, белмим ни өчендер, әти турында сөйләргә яратмый иде. Ә мин аның күңел яраларын кузгатырга теләмәдем. Тик гомеренең соңгы көннәрендә генә әни аз гына ачылды, аз гына...»

Рауза Хисмәтуллина гомеренең соңгы көннәренә кадәр Ижау шәһәрендә яши. Әмма театрга кабат кайтмый. Улы Альберт та инде вафат. Әмма аның 2 улы Олег белән Камилнең Казанда яшәве билгеле.

Язучының икенче хатыны Зәкия Садыйкова.. Шигырьләр язу белән мавыга башлаган кызның Муса белән танышуы бик табигый килеп чыга, Муса аңа киңәшләрен бирә, тиздән алар арасында мәхәббәт уты да кабына. Мәхәббәт җимеше булып, кызлары Люция туа. Ләкин Җәлилне Мәскәүгә җибәргәч, Зәкиянең анда барасы килми, Җәлил аңа акча салып тора һәм берьюллы Раузага да, аңа да алимент түли. Казанга кайтканда кызы белән очрашып тора.1936 елда язган “Кызыма” шигыре Люциягә багышлана. Зәкия 1939 нчы елда хатыны

үлеп, ике баласы белән тол калган иргә кияүгә чыга, педагогоия институтында укыта. Хәзерге көндә вафат.

Ә Люция Казан музыка училищесын тәмамлагач ВГИКка, танылган кинорежиссер С.А. Герасимов остаханәсенә укырга керә. Әтисе турында кино төшерү хыялы белән яна. Ленфильм «Моабит дәфтәре» фильмын төшерә башлагач, остазы: «Минем укучым – Җәлил кызы», дип аны фильм төшерүгә катнаштыра алган.. Люция бик күп талантлы татар артистларын фильмга катнаштыра ала. Шуңа күрә дә татар артистлары, татар шигырьләре һәм җырлары аша фильмда халкыбызның рухы чагыла. Монда Люциянең хезмәте бәяләп бетергесез.

Люция Муса кызы Җәлилова Казан дәүләт Мәдәният һәм сәнгать институты студентларына 1981 – 2002 елларда кино тарихын, журналистика нигезләрен һәм сценарий осталыгын укыта. Дөнья кинематографиясе шедеврлары – Феллини, Пазолини, Антониони, Боб Фосс, Милаш Форман, Бергман, Бунюэль фильмнары белән дә студентларны ул таныштыра иде.

Лилиан – Муса Җәлилнең дүрт оныгыннан берсе. Кызның әтисе рәссам, грузин Гурам Наврозашвили. Әмма Лилиан күбрәк Бистәдәге карт әбисе Зәкия тәрбиясендә үсә. Казан театры училищесында укып, өлгергәнлек аттестаты алгач, Петербургка китә, анда Санкт-Петербург Дәүләт театраль сәнгать академиясендә Талубеев курсын тәмамлагач, Петеребургның “Яшь тамашачы” театры труппасына кабул ителә, театрда дистәләгән үзенчәлекле образлар иҗат итә, кинофильмнарда төшә.

Зәкия әбисе аңа: – Син холкың белән нәкъ бабаң, дия торган була. Туры сүзле, бабасы сыман әдәбият сәнгать дөньясында кайнаган Лилиан Җәлил турында фильм төшерергә хыяллана. Люция ханым хәзерге көндә кызы Лилиан белән Петербургта яши, 11 яшьлек оныгы Баһрамны тәрбияли, аңа татар телен, татар рухын кечкенәдән тоеп, белеп үсәргә булыша.

Шагыйрь Әминә ханым белән 1936 елда өйләнешә. «Сугышка кадәр җиде ел без дус-тату яшәдек. Бәхетебезнең очы-кырые булмас кебек иде...» – дип яза ул үзенең истәлекләрендә. Ә Муса Җәлил тарафыннан сөекле хатынына багышлап язылган шигырьләрнең күплегенә исә исең-акылың китәр. Нәкъ менә шул юллар аша без бөек шагыйрьнең аңа һәрвакыт матур һәм йомшак итеп «акыллым» дип эндәшкәнлеге турында беләбез.

Әминәнең кызы Чулпан Җәлилова 1937 нче елда Мәскәүдә туа. МГУның филология факультетын тәмамлый. Үзе әйткәнчә: аны әдәбит үзенә җәлеп итеп торган, күрәсең геннар чагыла. Чулпан 36 ел “Матур әдәбият” нәшриятендә, рус классика редакциясендә эшли. Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек була. Рафаэль Мостафин белән, әтисенең берничә китабын бастыруга әзерли.

Татьяна Малышева (Чулпанның кызы) – Мәскәүнең Гнесиных исемендәге урта махсус музыка мәктәбе мөгаллиме.

Михаил Митрофанов (Татьянаның улы) П.И.Чайковский исемендәге Мәскәү консерваториясе каршындагы махсус музыкаль мәктәптә скрипка

классында белем ала. Бүгенге көнгә инде ул халыкара бәйгеләрдә лауреат исемен яулаган, Италиядә Гран-прига лаек булган. Сеңлесе Елизавета да музыка белән кызыксына, гаилә советы карары нигезендә Михаил ике фамилия- Митрофанов –Җәлилов фамилияләрен йөртә.

Гомумән, М.Җәлилнең оныгы һәм оныкчыгының музыка белән кызыксынулары бабаларыннан ук килә торгандыр. Махсус белеме булмаса да, ул мандолинада һәм пианинода уйнаган, балачагыннан ук сәхнәдә музыкаль спектакльләр оештырган, җырлар иҗат иткән, Мәскәү консерваториясе каршындагы опера студиясендә эшләгән һәм опера либреттолары язган.

Муса Җәлил, аның гаиләсе турында барын да беләбез, дип әйтеп булмый әле. Әмма шунысы билгеле – аның табигый таланты гаять зур тырышлык Һәм физик эш белән үрелеп барган. Моабит төрмәсендә язылган шигырьләр – шушы якты, бай гомернең иң биек Һәм иң бөек ноктасы ул. Бу шигырьләр татар әдәбиятында, тулаем татар халкына йөз аклыгы китерде.


Әдәбият

Даутов Р., Нуруллина Н. Совет Татарстаны язучылары: библиографик белешмә. – Казан: Татар. Кит.нәшр.,1986.


## КӘРИМ ТИНЧУРИН ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН


*Камалова Лилия,*

*Яр Чаллы педагогия көллиятенең IV курс студенты*

*Фәнни җитәкче: Минһаҗева Резилә Әбүзәр кызы*


Быел җәмәгатьчелек татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган, үзенең мәктәбен оештырган талантлы драматург, язучы, сәнгать белгече, артист, режиссер Кәрим Тинчуринның тууына 130 ел тулуны билгеләп үтте.

Белүебезчә, Кәрим Тинчурин әдәби иҗатка XX йөз башының унынчы елларында, татар әдәбияты үзенең Алтын чорын кичергән вакытта аяк баса һәм үзенең кабатланмас иҗаты белән аның Ренессанс үсешен тәшкил итә һәм Г. Камал, М. Фәйзи кебек күренекле драматурглар белән беррәттән татар театрына нигез салучылар сафына баса.

Драматург, прозаик, шагыйрь буларак ул һәр өлкәдә зур уңыш яулый. Үзенең әсәрләрендә ул иң элек газиз халкының уй-теләкләрен, киләчәккә булган уй-хыялларын чагылдырырга тырыша. Аның «Зәңгәр шәл», «Ил», «Кандыр буе» исемле мелодрамалары шул чор татар театрының төп репертуарына әверелә, аннан соң да, кабат-кабат уйналып, ничәмә-ничә буын тамашачыларның тирән мәхәббәтен казана.

«Зәңгәр шәл» музыкаль драмасы революциягә кадәрге татар авылының тарихын җанлы итеп күз алдына китереп бастыра. Бу әсәрнең геройлары – үз бәхетләре өчен көрәшкә күтәрелүче яшьләр. К. Тинчурин фикеренчә, татар халкының киләчәккә өмете − яшьләрдә. Алар, «йөрәкләрендәге курку хисләрен алып ташласалар, бәлки, тормыш дилбегәсен үз кулларына алырлар иде» – дип

өметләнгән әдип. К. Тинчурин әсәрләрендә сурәтләнгән холыклар һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, төркем психологияләрен хәзерге тормыш, бүгенге вәзгыять белән дә чагыштырып булыр иде. Мәсәлән, «Зәңгәр шәл» драмасында сүз шул замандагы хокуксызлык, хаксызлык һәм хакимияттән явызларча файдалану турында бара. Әсәрдә сурәтләнгән кайбер сатирик типларны без әйләнә-тирәбездә бүген еш очратабыз. Үз бәхетләре, якты киләчәкләре өчен көрәш мәйданына чыгучы качкыннарны да бүген саксыз, нахакка рәнҗетелгән милләт хадимнәре, татар мөгаллимнәре белән тиңләштереп булыр иде.

«Зәңгәр шәл»дә куелган проблема бүген дә актуальлеген югалтмаганга күрә, бу әсәр күп еллар сәхнәләрдән төшми, театр сезонын ачып җибәрүче, татар халкының рухын, идеалларын гәүдәләндерүче пьеса булып тора. Г. Камал исемендәге татар дәүләт драма театрының элекке баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов бу әсәр турында: «Үзебезнең яшәешебез турында бай, тирән эчтәлекле иң милли әсәр ул. Чит җирләрдә яшәүче милләттәшләребез аның милли аһәңенә бигрәк тә сизгер. Салих Сәйдәшев музыкасы күңелне җилкендерә торган дәртле дә, гаҗәеп моңлы да. Баш бирмәү – буйсынмау, иреккә омтылу безнең каныбызга сеңгән. Җор теллелелек, сүзгә тапкырлык, җыр – биюгә осталык та бабаларыбыздан килә. «Зәңгәр шәл» безнең яшәү рәвешебезне күрсәтә, яшеренеп, тирәндә яткан хис-тойгыларыбызны уята», − дип язган иде [Сәлимҗанов 2003: 17 б.].

Авторның «Сүнгән йолдызлар» драмасы сюжетында да яшьләр бәхет турында хыялланалар, тик сугыш аларның бөтен хыялларын чәлпәрәмә китерә. Тормышның аяусыз җилләре каршында яшьләр көчсез булып кала. Әлбәттә, Сәрвәр ничек тә Исмәгыйльне сугышка җибәрмәс өчен, ахыры ни белән бетәсен үзе дә күз алдына китермәгән адымга бара: имче карчык сүзләренә ышанып, сөйгәненең колагына дару сала. Бу яшьләрнең икесе өчен дә фаҗига белән тәмамлана. Бу пьесаның бүгенге көндә нинди актуальлеге бар дисезме?

Беренчедән, бүгенге көндә дә кайбер яшь егетләр, армиягә бармас өчен, төрле сәбәпләр табалар. Әлбәттә, армия сафларында да җитешсезлекләр, гаделсезлекләр күптер. Шуңа күрә, ата-аналар да үз балалары турында борчылалар. Әмма, чын егет кеше солдат хезмәтеннән курыкмаска тиештер, безнеңчә. Икенчедән, пьесадагы төп герой Исмәгыйльнең әсәрдә үз фикере юк кебек. Ул Сәрвәр әйткәннәргә риза була, агулы дару салдыра. Ахыры аянычлы тәмамланасын уйлап бетерми шул. Уйландыра: бәлки, сугышка киткән булса, ул исән калган булыр иде... Әмма ул күбрәк киләчәктә Сәрвәрне беркайчан да күрә алмавына ныграк кайгыра тоелды. Әйе, бүгенге көндә дә үзенең төпле фикере булмаган егетләр күп. Төрле тормыш авырлыклары алдында каушап калган, авырлыклардан чыгу юлын таба алмый, аптырап йөрүче кешеләр күп хәзер. Бу күренеш тагын ике яклы, чөнки илебез тормышында бүген гади халык өчен аңлашылмаган, көтелмәгән авырлыклар чыгып кына тора. Әүрәләр тарафыннан гади кешеләрнең яшәешен яхшырту турында кайгыртучанлык җитенкерәми дияр идек. «Ә мәхәббәт?», − диярсез сез. Әйе, хәзерге яшьләр үзләре теләгән кеше белән гаилә кора ала. Аларга, элекке замандагы кебек,

каршы торучы ишаннар юк. Ләкин яшьтәшләрем арасында да беренче урынга байлыкны куеп, тормыш корырга теләүчеләр юк түгел. Ә андый гаиләләр, белүебезчә, тиз таркала, яисә бәхетсез булалар.

«Сүнгән йолдызлар» – инсаннарның сүнгән бәхетләре ул. Ничек кенә көрәшсәләр дә, алар ул гаделсезлекне үзләре генә җиңеп чыга алмыйлар. Ә тормышта кем генә бәхетле булырга теләми икән? Барыбыз да шуңа омтыла, шуны көтеп яши.

Кәрим Тинчуринның әлеге ике әсәре мисалында без автор иҗатының һәрчак актуаль кала килүен, халкыбыз өчен ни дәрәҗәдә кыйммәт икәнен күрсәттек. «Сүнгән йолдызлар» дагы геройларның тормыш йолдызлары көтмәгәндә сүнгән кебек, Кәрим Тинчуринның да яшәеше иртә сүрелә. Әмма ул халкыбыз күңелендә, милләтебез тарихында мәңге сунмәс, заман белән бергә янучы йолдыз булып калачак.

Әдәбият

Сәлимҗанов М. «Зәңгәр шәл» сере (Журналист Гүзәл Камал белән әңгәмә) // Коллектив. Кәрим Тинчурин: истәлекләр, шигырьләр. − Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. − 159 б., рәс. б-н).

Тинчурин К.Г. Драмалар, комедияләр, хикәяләр / төз. Ф. Бәширов. – Казан: Татар кит.нәшр., 2007. – 351 б.

## ФОЛЬКЛОР – ХАЛЫК АКЫЛЫ

*Кәримова Айсылу,*
*Югары Яркәй 1нче гимназиясенең IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Фәррәхова Зөлфирә Хәләф кызы*

Татар халкының бик борынгы заманнардан, әби-бабайлардан, ата-аналардан балага, ягъни буыннан-буынга күчеп килгән әсәрләре бар. Аның бербөтен җыелмасы “фольклор” (халык авыз иҗаты) дип атала. Фольклор – инглиз теленнән кергән сүз, “халык акылы”дигәнне аңлата.

Фольклор, сүз сәнгатенең бер канаты буларак, әдәби иҗат кануннарыннан аерылып торган үз закончалыклары, тирәлекне үзгә танып-белү юллары белән дөньяга килә. Аның иң беренче үзенчәлеге итеп шәхсилек (индивидуальлек) сыйфатын аерып куярга мөмкин. Бу сыйфат иҗатчының «кабатланмас әсәр» иҗат итүе белән бәйләнештә карала, әсәрләрнең стилендә дә, образлылыкта да чагылыш таба. Икенчедән, фольклор әсәрләре моңа кадәр булган тәҗрибәне файдалану нәтиҗәсе буларак дөньяга килә. Аларда, яңаны тудыруга караганда, моңа кадәр тупланганны яңарту, шуны персонажлар, геройлар тарафыннан җиткерү сыйфатлары алга чыга. Өченчедән, фольклор әсәрләренең авторы билгеле булмый, күбесенчә, беренче башлап, аерым талантлар тарафыннан телдән иҗат ителә, бик күбесе язмача теркәлми кала, телдән-телгә күчеп бару юлында шактый гына үзгәрешләргә дә дучар була. Бу, аеруча, җыр, бәет, мөнәҗәт, әкият, дастан кебек жанрларга карый, алар гасырлар буена халык күңелендә сакланып, бүгенге көнгә килеп җиткән. Бу исә фольклор әсәрләренең

берничә вариантта яшәвенең бер алшартына әйләнә: мондый әсәрләргә вариантлылык хас. Дүртенчедән, халык авыз иҗаты синкретик иҗат төре булып тора. Татар фольклорына бер үк әсәр чикләрендә берничә жанрга туры килгән сыйфатларны берләштерү хас. Бишенчедән, фольклор әсәрләренә поэтик үзгәлек хас. Нигездә, аларның күбесе тыңлаучы өчен иҗат ителә, шуңа мөнәсәбәттә биредә тыңлаучыга мөрәҗәгать алга чыга.

Фольклорда киң таралган булып мифологик хикәят, әкият, дастан, риваять, легенда, мәзәк, мәкаль - әйтем, табышмак, җыр, такмак, мөнәҗәт,бәет жанрлары санала.

Халык иҗаты жанрларының бер ише тормыш күренешләренә, вакыйгаларга турыдан – туры бәя бирә һәм кешеләрне шул шартларга яраклашырга өйрәтә. Икенче төркеме киресенчә, тормышның үзен үзгәртә. Беренче төркемгә әйтемнәр, мәкальләр, табышмаклар, җырлар керә. Икенче төркем мәзәк, әкиятләр һәм героик дастаннар кебек жанрларны үз эченә ала. Җырны без җырлыйбыз, бәетне көйләп әйтәбез, әкиятне сөйлибез, такмакны шукланып, такмазаны җорланып әйтәбез, мәкальләрне сүзгә кыстырып җибәрәбез, табышмакларны табабыз. Беркем дә мәкальне  җырлап, җырны сөйләп утырмас. Димәк, авыз иҗатының һәрбер төренең үз үтәлеше, үзенә генә хас башкарылышы бар.

Татар халык авыз иҗаты белән кызыксыну, аерым кешеләр тарафыннан аны өйрәнергә тырышу инде күптән яшәп килә. Әмма гаҗәеп дәрәҗәдә бай, күп кырлы татар фольклорын фән буларак өйрәнә башлау, аның үсеп китүе бары тик Октябрь революциясеннән соң гына була. Татар халкы авыр тормыш шартларына, кимсетелүләргә, җәбер-золымнарга карамастан, үзенең авыз иҗаты әсәрләрен тудырып, иҗат итеп, аны саклап килә. Әлеге әсәрләрдә халыкның оптимистик карашлары, азатлык идеяләре, байларга карата нәфрәт чагыла.

Халык ижаты әсәрләре халык телендә үк төрле жанрларга бүлеп өйрәтелә, һәр жанр икенче жанрдан үзенең формасы белән генә түгел, бәлки эчке характеры белән дә аерыла. Татар халык авыз иҗаты әсәрләре башта ике зур жанрга: лирик һәм эпик жанрларга бүленә. Моның беренчесенә, ягъни лирикага, йола фольклоры, мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар, ырымнар, җырлар керә. Мифлар, легендалар, әкиятләр, бәетләр, тарихи җырлар һәм дастаннар эпик жанрлардан  санала.

Борынгы кешенең һәр гамәле, һәр адымы дини-мифик карашларга, ышануларга, йолаларга нигезләнгән булган. Бу карашларны, ышануларны, йолаларны дөрес аңлаганда, борынгы дәвердә гомер сөргән ата-бабаларыбызның уй-фикерләренә төшенү кыен түгел. Бары тик һәр ышану-мифның, сихер-тылсымның ачкычын, ырымын табарга һәм куллана белергә кирәк.

Җор телле халкыбыз иҗат иткән табышмаклар, санамышлар, такмаклар, әкиятләр, бәетләр, моңлы бишек җырлары – тел өйрәнүдә иң бай чыганак.

Татар халкының мең елларга сузылган тормыш тәҗрибәсе, уйлары, гадәтләре, кешене шәхси итүче сыйфатлары, аның телендә образлы сөйләмнәрендә, мәкаль-әтемнәрендә, җыр һәм әкиятләрендә чагылыш тапкан. Шуңа күрә ата-анасы татар булган балага татарча белү, уку мәҗбүри итеп каралырга тиеш.

Җирлектән тупланган материаллардан чыгып, шуны әйтәсем килә: халык авыз иҗаты әсәрләре гыйбрәтле фикерләргә, зыялы әйтемнәргә, тапкыр табышмаклар, милли тәрбиягә, үтемле мәкальләргә бай. Халык фикере – зирәк, акыллы. Күңелдәгесен тиешле итеп әйтеп бирә, шаянлыгын да онытмый. Халык авыз иҗаты әсәрләрен безгә җиткерүчеләренең сөйләме бай, аһәңле, сәнгатьле. Алардагы рухи байлыкка сокланмый мөмкин түгел.

Әлеге эшемдә фольклорның бүгенге тормышта бик кирәкле булуын аңлатырга тырыштым. Бүген мине кайбер иптәшләремнең гади генә мәкальләрнең дәвамын, кайбер әкият геройларының уңай һәм тискәре якларын күрсәтә алмаулары, электән килгән халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю белән шөгыльләнмәве борчый. Бу эш белән беренчеләрдән булып үзем шөгыльләнергә исәпләдем. Иптәшләремне дә әлеге эшкә тарту – минем бурыч.

Халкыбыз күңеленең бер генә кыйпылчыгын эченә алган әлеге язмам күңелләрегезне кузгатсын иде дә, шулар ярдәмендә туган телебезгә, туган җиребезгә булган мәхәббәтегез үссен иде.

Әдәбият

Әдәбият белеме. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: "Мәгариф" нәшр., 2007.

Балалар фольклоры. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

Татар халык иҗаты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.

## ФОАТ САДРИЕВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР

*Кәримова Чулпан,*

*Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбенең X сыйныф укучысы*

*Фәнни җитәкче: Гайнетдинова Гөлназ Фәнис кызы*

Телебездәге сүзләрне сәйләннәрдән тезелгән энҗе мәрҗәнгә тиңләр идем. Мәрҗәннең бер генә төймәсе төшсә дә, матурлыгы, зәвыгы югала. Сүзләрне дә дөрес һәм урынлы кулланмасаң, аның аһәңле яңгырашы, тәэсир итү көче кими. Ә сүзлек хәзинәсе, уй-фикерләрнең камиллегендә матур әдәбият нигезендә кулланылган тел берәмлекләрен өйрәнү дә минем өчен мөһим. Аеруча да фразеологик әйтелмәләр, аларның төрләре мине кызыксындыра. Чөнки алар телебезнең иң матур купшы бизәкләре сыман.

Фразеология үзенең мәгънәсе, төзелеше һәм функциональүзенчәлекләре ягыннан аерым сүзләрдән һәм гади сүз тезмәләреннән тора.

Фразеологик әйтемнәрне төркемнәргә аерганда шулай ук аларның мәгънәләрендәге төрле үзенчәлекләрне искә алып эш итәләр. Кайбер фразеологизмнардагы сүзләрнең аерым-аерым мәгънәләре белән шул әйтем белдерә торган гомуми мәгънә арасында бернинди эчке бәйләнеш булмый. Боларны фразеологик ныгымалар дип атыйлар. Мәсәлән: кот очу, сару кайнату, борчак ату, лаеш шулпасы эчү, ләчтит сату, сөмсере коелу,теңкәне корыту Һ.б. шуңа керә. Кайбер фразеологик әйтемнәр составындагы аерым компонентларның мәгънәсе белән фразеологик әйтемнең төшенчәсе арасында бәйләнеш булмаса да, шул төшенчәнең эчке мәгънәсенең нindидер охшашлыклар, тәңгәллекләр белән аңлатып бирергә була. Шуннан чыгып, без капчыкта ятмый, арыш боламыгы, кылны кырыкка яру, көймә комга терәлү, табан ялтырату,кәкре каенга терәтү, чүбек чәйнәү куенда таш саклау, койрыкны сыртка салу кебек бер төркем әйтемнәрне фразеологик бөтеннәр дип йөртү дә бар.

Татар тел белемендә фразеологизмнарны идиома дип тә атыйлар. Фразеологизмнарны бер сүз белән алыштырып була: куян йөрәк – куркак, башы күккә тию – шатлану. һ.б.

Фразеологик ныгымалар башка төр лексик фразеологизмнардан компонентлар составында мәгънәләре бөтенләй аңлаешсыз яки архаиклашкан сүзләр булу яки компонентлар арасында үзара логик бәйләнеше булмау белән аерылалар.

Фоат Садриевның әсәрләрендә фразеологик берәмлекләрне еш күрергә мөмкин: туры китерү, ис китмәү, җан чыгу, күз нурым, җан кисәгем... Болар – фразеологик ныгытмалар.

Фразеологик бөтеннәр мәгънә компонентларының үзара семантик нык береккән булулары белән аерылып торалар. Шулай ук аның әсәрендә фразеологик бөтеннәр дә кулланыла. Мисаллары: йөрәк сыкрау, кул селтәү, кулдан килү, күңел тулу, телгә алу, җиңел кулдан, тел төбе, борын төбендә, дүрт күз белән, күз колак булу, ярага тоз сибү, өскә чыгу, җилгә очу... Фразеологик тезмәләрдә үзара семантик мөнәсәбәткә кергән компонентларның берсе һәрвакыт туры мәгънәсен саклый.

Фразеологик тезмәләләр дә Ф. Садриев әсәрләрендә шактый гына урын алып тора. Йөрәгемне алдың, игелек кайтару, йозак салу, күңелдән кичерү, йөз көлү, акыллы баш, күзләр көлү, ачык чырай, күңел сере, колак салып тыңлау, җылы сүз кебек фразеологик берәмлекләрне очратырга мөмкин. Шулай ук синтаксик фразеологизмнарны, аеруча да , мәкаль һәм әйтемнәрне, фразеологик ымлыкларны аның әсәрләрендә еш күрергә була: азрак үсәсең бар әле, бар өстенә бар – май өстенә бал, эт эткә, эт койрыкка җибәрә; этнең өреп торуы береңә дә салават түгел; дөнья – мәшәкать йорты; бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга...

Соңгы чигенә чыккан усаллыкны, тәрбиясезлекне сурәтләгәндә дә, автор фразеологизмнарның иң уңышлыларын сайлаган: адәм актыгы, җен урынына күрү, каты бәгырьле һ.б.

“Рәхмәт, этием!” әсәрендә Шакиров болай ди: “ Кеше алдында миңа әйткән сүзләреңне җыеп алырлык итәм әле мин сине!” Бу җөмләдә геройның характеры тагы да ачыла төшә.

Гомумән, фразеологизмнарны “телнең җәүһәрләре” дип йөртәләр. Ф.Садриев әсәрләрендә дә алар, сурәтләү чарасы буларак, һәр вакыйганы, геройларның кәеф-халәтен төгәл сиздерү өчен куллана. Моның белән әдип адәм баласының бик нечкә төсмерләрен укучыга мөмкин кадәр ачык, үтемле итеп сиздерергә тели. Шул рәвешле, автор әсәрдәге геройларның сөйләмендә фразеологизмнарны гаять мул кулланган. Сүзнең иң кирәклесен, бердәнбер урынлысын табу өчен, әдип күңелебездә еллар буена туплана килгән бөтен байлыкны, лексик хәзинәне файдаланган. Сурәтләү чараларын мул кулланып, язучы геройлар сөйләмендә үз максатына ирешкән. Ә бу исә, үз чиратында әсәрнең идея-эчтәлеген тулырак аңларга ярдәм итә.Аның пьесалары халыкчанлыгы белән аерылып тора. Кешеләрне, мәхәббәтне, туган җирне ярату кебек хисләрне аның кебек итеп сурәтли белүчеләр күп түгел. Минемчә, бу фикерне раслау өчен, Ә. Еники сүзләре бик тә урынлы булыр. “Без әдәби осталык турында күп сөйлибез. Ләкин әдәби осталыкны беренче чиратта тел осталыгы, телгә байлык, телне дөрес куллана белү дип аңларга кирәк.

Ф.Садриев әсәрләрендә матур-матур чагыштыру, метафора, эпитетлар да күп очрый. Мәкаль-әйтемнәр дә бар. Мәсәлән, йөз сум акчаң булганчы,йөз дустың булсын; күршенең төтене күзгә керә; язмыштан узмыш юк;типсә тимер өзәрдәй; таш кебек тыныч; баскан туфрагың дөрләп яначак; сез әкияттәге кебек гүзәл; йөрәгең тимер кебек; кош кебек очканда; йодрык кадәр тавыкка тау кадәр тавыш; тынчыган күл суы кебек ямь-яшел; үзе егылган еламас.

Аларның барысы да аз сүз белән күп мәгънә белдерү, образ, җанлы картина тудыру, идея-эчтәлекне ачарга ярдәм итә.

Ф. Садриев әсәрләре фразеологизмнарга бик бай. Андагы халык теле, татар теленең сүзлек байлыгын кулланып язылганнары укучыга якын, күңеленә хуш килә. Әсәрләрдә барлык фразеологизмнарны тикшереп чыга башласаң,бер китап язарга булыр иде.Шуның өчен мин бик кызыклы,якын булганнарын, көндәлек тормышта куллана торган фразеологизмнарны гына аерып алып карадым.

Карап киткән мисалларга нигезләнеп татар халкының фразеологик әйтелмәләргә бай булуын раслап була.

Образлы сурәтләү чараларын мул кулланып, язучы геройлар сөйләмен һәм аларның хис-кичерешләрен бирүдә үз максатына ирешкән. Әгәр дә без бу тел бизәкләрен төшереп калдырсак, геройларның күңел дөньяларын, эчке кичерешләрен, аларга гына хас булган сыйфатларны күз алдына китерә алмас идек.

Әдәбият

Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.

Борханова Н.,Мәхмүтова Л.,Җәләй Л. Татар теленең фразеологиясе, мәкалъ һәм әйтемнәре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.
Виноградов, В.В. Стилистика. Поэтика художественной речи // Поэтика. – М.: Наука, 2013.
Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда.1 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.
Садриев Ф. Көлми торган кеше. – Түбән Кама “ Ихлас”. 2004, – 374б.
Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001. – 335 б.

## БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘКӘН РАЙОНЫНДАГЫ МИШӘРЛӘРНЕҢ КАЙБЕР ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Киямова Элиза,*
*БДУның Стәрлетамак филиалы, III курс студенты*
*Фәнни җитәкче: Мукимова Нәсимә Әнвәр кызы*

Аерым төбәкләрдә төрле сәбәпләр белән бәйле үзенчәлекле җанлы сөйләм барлыкка килә. Ул сөйләшкә башка телләр, иң элек күрше булган телләр йогынты ясый. Шушы төбәккә генә хас булган, гомумхалык теленә кермәгән сүзләрне һәм әдәби тел нормаларына карамаган фонетик, лексик, грамматик күренешләрне диалектизмнар дип билгелиләр.

“Милли телебезнең җирле сөйләшләре галимнәр җитәкчелегендә тулы эчтәлекле махсус программа нигезендә Россиянең егермедән артык өлкә һәм республикаларында экспедицияләр уздыру юлы белән өйрәнелде,” – дип яза күренекле диалектолог Д.Б. Рамазанова [Татар халык сөйләшләре 2008, I т.: 3].

Татар диалектологиясе фәнендә булган хезмәтләрне күзәтү Башкортстанның күп кенә районнары буенча диалекталь материалның тупланганын, җирле сөйләшләрнең тикшерелгәнен күрсәтте, әмма аларда әле Дәүләкән районы төбәкләренең сөйләм үзенчәлекләре телгә алынмый. Мишәр диалектының стәрлетамак сөйләшен билгеләүче Д.Б. Рамазанова буенча, әлеге сөйләшкә Башкортстанның көньяк-көнбатыш районнарындагы татар халкының җанлы сөйләме карый. Әлеге территориядәге сөйләшне галимә шартлы рәвештә өч типка бүлеп карый һәм III типта “XVI гасыр азагында йомышлы татарлар катламы буларак күчерелгән мишәрләрнең дәвамчылары сөйләше”н (Чишмә, Авыргазы районнарын) билгели [Татар халык сөйләшләре 2008, II т.: 124]. Безнең карашка, әлеге типка Дәүләкән районындагы мишәр сөйләшләре дә керергә тиеш. Беренчедән, әлеге өч район (Авыргазы, Дәүләкән һәм Чишмә) географик яктан күршеләр булып торалар; икенчедән, тарихи-этнографик материаллар һәм, өченчедән, районның Чуенчы һәм Бик Карамалы авылларында фольклор-диалектологик практика кысаларында тупланган тел материалы да моны раслый.

Бик-Карамалы авылы Яңа Карамалы, Карамалы-Биктимер, Биктәш-Карамалы атамалары белән билгеле булган. Кыркули-Минск җирләрендә

1748 нче елда башкортлар белән килешү һәм Җаек-Суби-Минск җирлегендә 1771 нче елда вотчинниклар белән килешү нигезендә әлеге авылда мишәрләр төпләгән. Монда 1795 нче елда 48 йортта 292 мишәр теркәлгән булса, 1920 нче елда 1334 мишәр исәпләнә [Асфандияров 2009: 473].

Чуенчы авылына да мишәрләр Җаек-Суби-Минск волосте башкортлары белән 1762 нче елдагы килешү белән нигез салалар. Монда 1870 нче елда 280 йортта 1843 мишәр яшәгән. Елдан ел аларның саны арта барган [Асфандияров 2009: 474].

Әлеге мәкаләдә төбәктәге җирле сөйләм үзенчәлекләренә тукталып үтәбез. Тупланган материалны фонетик, лексик-семантик диалектизмнарга аерып карауны кирәк дип таптык.

Фонетик диалектизмнар әдәби тел сүзләреннән үзләренең фонетик үзенчәлекләре белән генә аерылып торалар. Бу авыллардагы халык сөйләмендә аерым сузыкларның һәм тартыкларның әйтелешендәге үзенчәлекләргә, позицион үзгәрешләргә һәм тәңгәллекләргә караган фонетик диалектизмнар очрады.

Бу җирлектә әдәби телдә сүз башында *җ* авазы характерлы булган сүзләрнең *й* авазыннан башланып китүе хас: *йолпыч – җилпуч, йыр – җыр, йер – җир, йылы – җылы.* Мишәр һәм көнчыгыш диалектлардагы й позициясе күзәтелә. Шулай ук әдәби телдәге -өй дифтонгы башка мишәр сөйләшләрендә кебек үк монофтоглаша: *сүлә – сөйлә, өрәнеп – өйрәнеп.* Кайбер сүзләрдә, Стәрлетамак сөйләшендәге кебек үк, даими рәвештә -әй дифтонгы кулланыла: *әпәй – ипи; инәй – әни.* Увуляр тартыклар [къ], [гъ] урынына [к], [г] тел арты тартыкларын әйтү хас: [*мәкәл*], [*катык*], [*карга*]. Башка мишәр сөйләшләренә хас булган сузык аваз тәңгәллекләре дә күзәтелде: ө ~ ү (*бөгөн – бүген, көп – күп, төбә – түбә);* е ~ ө *(селге – сөлге*).

Әлеге сөйләштә саф лексик диалектизмнар шактый күзәтелде. Алар арасында түбәндәге сүзләр бар: *көрти – җиңсез күлмәк, тешекәй – башмак, телтәгән – эзләгән, ләвеш – бәлеш, фурман – арба, чыелдык – чаршау, күз шытымы – күзәнәк, кайната – ирнең атасы.*

Сөйләштә предметны, хәрәкәтне, билгене белдерүче диалекталь сүзләрнең актив булуын ассызыкларга кирәк. Предметны белдерүче сүзләрне берничә төркемгә аерып классификацияләү уңышлы булыр:

1.Туганлыкны белдерүче атамалар: *инә-әни, яшь килен-килен, әтәсе-әтисе, инәсе-әнисе, кайната-ирнең әтисе*

2. Ашамлык атамалары: *әпәй – ипи, күкәй – йомырка, бәрәнге ләпләмәсе – черегән бәрәнге, ләвеш – бәлеш, урнаш – аулакта пешерә торган аш, кишыр – кишер, белен – коймак*

3. Көнкүреш корылмалары, кирәк-яраклары: *табагач – таба тота торган әйбер, йолпыч – җилпоч (он сала торган савыт), киле – кисап (тары төелә) ,пич – мич, тәрәз – тәрәзә, бусага – ишек төбе, ихата – койма, ызба – өй, төбә тактасы – түшәм, пүгәреп – баз*

*4.* Җиләк-җимеш, үлән атамалары: *карган, карагат – карлыган, кырмавык – әрекмән, күз шытымы, күз – күзәнәк, аю камыры чәчәге – гөлҗимеш, үгез борчак, юл үләне – бака яфрагы, кечерткән – кычыткан*

Башкортстанның Дәүләкән районындагы берничә татар авылы халкының сөйләмен күзәтү, тарихи-этнографик материаллар белән танышу нигезендә бу җирлектә мишәр диалектының стәрлетамак сөйләшен, төгәлрәк әйткәндә, аның өченче тибын билгеләргә була.

Әдәбият


Асфандияров А.З. История сел и деревень Башкортостана и сопредельных территорий. Уфа: Китап, 2009. – 744 с.

Татар халык сөйләшләре / Төз. Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б.: 2 томда. – 1 т. – Казан: Мәгариф, 2008. – 463 б.

Татар халык сөйләшләре / Төз. Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б.: 2 томда. – 2 т. – Казан: Мәгариф, 2008. – 463 б.


## АГА ЧИШМӘ ЧЕЛТЕР-ЧЕЛТЕР, БЕЗГӘ НИДЕР СӨЙЛИДЕР...


*Комиссарова Виктория,*
*Алабуга шәһәре 4 нче гимназиянең IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Комиссарова Фәнҗия Гавис кызы*


Сугышта булып арыслан
Ватанга Җиңү яулаган,
Тыныч хезмәттә дан алган
Һәр ветеран – чын каһарман!

Мин шәһәрдә туып үскән кыз, ләкин җәй көннәрен әниемнең туган авылында үткәрергә яратам. Әнием Актаныш районында туып үсә.Хәзерге вакытта без гаиләбез белән Алабуга шәһәрендә яшибез.

Авылда бик тә рәхәт, саф һава,яшелллек! Иртән әтәчнең кычкырып уятуы да, мөгерәп сыерларның көтүгә чыгуы, казларның каңгылдашып буага китүләре-болар барысы да миңа бик тансык күренеш.

Ә андагы чәйләрнең тәмлелеге!... Авылда кешеләр көненә әллә ничә тапкыр чәй эчәләр. Минем бервакытта да шәһәрдә шулай күп итеп һәм тәмле итеп чәй эчкәнем юк. “Нигә шулай икән соң бу ?”-дип баш вата башладым, әниемнән дә сорадым. Әнием миңа эшнең нәрсәдә икәнен төшендереп бирде. Бар хикмәт чишмә суында икән .

Әйе, чишмә суы иң кадерле сыйлардан санала. Кунак-мазар килсә, берәрсе ерак юлдан кайтса чишмә суыннан чәй куйганнар.”Суыбыз бик тәмле безнең” дип чын күңелдән горурланып кунакны кыстый-кыстый сыйлаганнар .

Су-тормыш чыганагы.Чиста су, саф һава, икмәк кебек безгә яшәү өчен кирәк. Тәмле, салкын суны без гә бары тик чишмә генә бирә.Без чишмәне тормыш чыганагы дибез.Чыннан да, электән үк кешеләр чишмәгә теләк тели-

тели барганнар, үзләренә тазалык, саулык, бәхет сораганнар. Чишмә изге урын, шуңа күрә хәзер дә кеше аны матурлый, бизи, чишмә янына матур сөлгеләр эләләр, чүмечләр куялар.

Кызларга килен булып төшкәч тә су юлын, чишмә юлын күрсәткәннәр. Соңгы 2-3 елда әниемнең туганнарының балаларының туйлары булып узды. Һәр туй алдыннан яшьләр Актаныш районы үзәгендәге Хәмит чишмәсенә бардылар, аның саф суын эчтеләр. Барган саен әнием бу чишмә - безнең Хәмит җизнәй чишмәсе дип горурланып куя.Бу чишмә шундый матур җирдә урнашкан ки , мин аның белән кызыксына башладым. Кем ул Хәмит, нинди кеше булган, ни өчен чишмәгә аның исеме куелган? Әни миңа үзенең белгәннәрен сөйләде.

Әнием ягыннан туган Хәмит җизнәй Актаныш районында танылган мич чыгаручы булган. Ул елларда мич кешеләр тормышында зур роль уйнаган: ашаткан, җылыткан, үзенә сыендырган.Ул бик еш Такталачыкка килә торган булган. Хәмит җизнәй бик тырыш, кешеләргә ихтирамлы булган. Аның 6 баласы хәзер дә исән-саулар.

Авыр Бөек Ватан сугышы еллары Хәмит җизнәйнең матур яшьлек елларына туры килә . 1941 елда яшь ирне сугышка алалар, өйдә 2 яше тулмаган сабые белән хатыны кала. Җиңүне ул чит җирләрдә каршылый, исән-сау туган җирләренә әйләнеп кайта. Әнием сөйләүләренә караганда, Хәмит җизнәй үлгәнче гомере бу үзе белән бергә тәнендә тимер кисәге – снаряд кыйпылчыгын йөртә, ә бер кисәге йөрәккә бик якын урнашкан була.Сугыштан яраланып кайткан солдатка врачлар операция ясарга куркалар, чөнки бу тормыш өчен куркыныч була.

Сугыштан соң ул үзенең хезмәтен дәвам итә, кешеләргә мич чыгара, өйләргә нур кертә. Хәмит бабай гаиләсе белән Яна Кадермәттән 1951 елда Актанышка күчеп килә,1953 елда поселокка йорт салалар.Ул елларны су проблемасы бик көчле була. Урамнарда сирәк кенә кое, ә колонкалар бөтенләй булмый. Хәмит җизнәй "Бүләк"урманының тау астында чишмә бәреп чыкканын абайлап, бу урынны әйбәтләп чистарта,өеннән мичкә алып килеп куя, чүмеч белән су алмалы итеп көйләп куя.Бераз вакыттан соң ул чишмәгә улак та ясый. Шул еллардан башлап Хәмит җизнәй тау астындагы кечкенә чишмәне чистартып, су алырлык итә. Су чокырга бик озак җыелган, аны гел чүмечләп кенә чиләккә тутырганнар. “ Чишмәне исән чагында гел Хәмит карады”, – ди авылның олы апалары. Поселокның олы яшьтәге апалары бу чишмәне “Хәмит” чишмәсе дип йөртә башлыйлар. Шуннан бирле чишмә халык телендэ “Хәмит” чишмәсе булып кала. Әтиләре үлгәч, чишмәне олы улы Фәнис абый чистартып, карап тора.Шулай итеп күп еллар чишмә үзенең юлын югалтмый.

90 нчы елларда район нефтьчеләре чишмәне яңартып, матурлап куялар. Чишмәгә “Хәмит чишмәсе” исеме тантаналы рәвештә кушыла .Чишмә юлына асфальт салалар, яңа улаклар куялар, су алучыларга барлык уңайлыклар тудыралар.Чишмәне бик матурлап койма белән әйләндереп алалар. Үзе өлкән булса да, торган саен яшәреп, яңарыш кичерә “Хәмит” чишмәсе.Актаныш авыл җирлеге 6-7 ел элек чишмәгә ремонт ясый, самавыр, пар аккошлар

өстәлә.Сугышта һәлак булганнарның һәйкәленә чәчәк салганнан соң, гаилә корган яшь парлар чишмә янына килеп, аның хәер фатихасын алулары традициягә кереп китә.Күптән түгел райондашларыбыз Лилия Шәйгәрданова, Инсаф Хәбибуллин тарафыннан “Актаныш чишмәләре” дигән бик тә матур җыр туа.

Чишмәләрнең моңнары бар,
Җырлары бар барсында.
Башкаемны игәнем бар
Эчәр суым каршында.

Җырлыйлар Хәмит, Мәликә
Җидегән изгеләре.
Моңнары белән юата
Актаныш чишмәләре.

Һәркайсының үз холкы бар,
Һәрберсенең үз тәме.
Чишмәләр җырлап торганда,
Җиремнең бетмәс яме.

Һәр елны язгы эшләр беткәч үткәрелә торган Сабантуй бәйрәме дә ямьле чишмә буенда үтә. Сандугачлар сайраган, чишмә челтерәп аккан җирдә бәйрәм үткәрү күңелгә үзе бер ямь өсти. Районыбызда туып, Иске Идел елгасында су коенып, тәмле чишмә суын эчеп үскән һәм хәзерге вакытта чит җирләрдә яшәгән райондашларыбыз барысы да диярлек Сабантуй бәйрәменә кайтып, чишмә буенда ял итәләр.

Безнең буын сугыш авырлыгын фильмнардан карап, китаплардан гына укып белә. Тыныч матур илдә яшибез, яңа мәктәптә укыйбыз. Һәр туган иртәгә сөенеп, чишмәләрнең саф суларын эчеп, кошлар җырын тыңлыйбыз. Шундый тормышта яшәвебез белән без үзембезнең әби-бабаларыбызга бурычлы. Шәхсән минем өчен туганыбыз булган Хәмит җизнәй – илебезнең чын батыры! Сугышта да сынатмаган, тыныч тормышта да үзенең эзен калдырган, кешеләргә дә хезмәт иткән.

“Хәмит” чишмәсе көнен дә, төнен дә алты дистә ел буе челтерәп ага, ә аңа бәйле тормышлар да шулай чишмәнең үзе кебек гөрләп, буыннар алыштырып, алга таба дәвам итә. Үзенә карата ихтирам һәм игътибар булганда “Хәмит” чишмәсе яшәр дип өметләнәсе килә.

Бәхет, шатлык, куанычлар белән,
Үтсен сезнең һәрбер көнегез,
Якты тормыш безгә бүләк иткән
Олыларны искә алыгыз!

Әдәбият

Гарипов Ф. Аккошлар иле Актанышка сәяхәт. – Казан, 2010. – 97 б.
Хузин Ю. Актаныш-туган җирем – Казан,2010. –76 б.

## ТАБИГАТЬНЕ ТОЯМ ҖАНЫМ-ТӘНЕМ БЕЛӘН

*Костромина Дарина,*
*Алабуга районы Иске Юраш урта мәктәбенең IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Юнусова Лилия Мирза кызы*

Табигать белән дөрес аралаша белү – хәзерге заман кешесенең иң зур мохтаҗлыгы. Ә бу аралашуны балачактан ук тәрбияләргә кирәк. Бу – бүгенге көндә дә иң актуаль проблемаларның берсе. Төбәк язучылары иҗаты ярдәмендә балаларга экологик тәрбия һәм белем бирү, табигатькә сакчыл караштәрбияләү күпкә отышлырак.

Җирле язучыбыз Гөлзада Әхтәмова, шигырьләре белән, табигать матурлыгын, аның сәламәтлеккә файдасын, аны саклау турындагы фикерләрне яшь укучы күңеленә гади һәм аңлаешлы итеп җиткерә. Аның шигырьләре балаларга тирә-якны танып-белергә, матурлыкны күрә һәм саклый белергә өйрәтә. Шагыйрәнең табигать турында балалар өчен язган шигырьләренең идея-тематика ягыннан Г.Әхтәмова иҗаты аша рухи-әхлакый, экологик белем һәм тәрбия бирә, табигатьтә үзеңне тота белә, яклау һәм саклау күнекмәләре булдыру, культуралы шәхес формалаштыра.

Яшәргә дип килгәч, тик китимме?-
Шигыремә салам уемны...[Әхтәмова 1996: 15] – дип яза шагыйрә Гөлзада Әхтәмова, күңеленә тулган хисләрне барлап. Мондый юлларшагыйрәбезнең хис-кичереш, уй-фикерләр белән тулы йөрәгеннән саркып чыга. Аның барлык җиһанга әйтер сүзләре, фикерләре бар...

Иҗатыннан күренгәнчә, табигатьнең бер генә мизгелен дә игътибарсыз калдырмый ул, аларны җаны-тәне белән тоя, алар белән сөйләшә. Гүя аның табигать белән яшертен элемтәсе бар.

Г.Әхтәмованың шигырьләрен укыганда, без, үзебез дә сизмәстән, табигать дөньясына кереп китәбез. Үсемлек, җәнлек, бөҗәкләр белән танышабыз, алар белән сөйләшәбез. Алар турында белемнәр туплыйбыз, серләрен ачабыз. Дару үләннәрен таныргa өйрәнәбез, дәвалау серләренә төшенәбез. “Табигать сәйләннәре” исемле китабында ул унбиш дару үләненә, кечкенәләр дә аңларлык гади һәм кызыклы итеп, аңлатма бирә. Мәсәлән,

Тузганак ул туза диеп,
Җырлар җырласагыз да,
Бар бит әле кояш кебек
Сары чәчәк чагым да, - дип,

тузганакның килеш-кыяфәтен аңлатып китә [Әхтәмова 1998: 23]. Дәвалау үзлекләрен, бал кортларының аннан бал җыйганын, уңган хуҗабикәләрнең яфрагыннан салат, чәчәгеннән кайнатма ясаганын да яшерми.

Ә "Урман" шигырендә:

Яшел урман һаваларны

Сафландырып безгә бирә, – дип, автор урманның файдасы турында сөйли [Әхтәмова 2011: 143]. Урманнарны сакларга кирәк, алар кешелек дөньясының сәламәт киләчәге икәнен искәртә.

Табигатькә, матурлыкка гашыйк Гөлзада Әхтәмова нәфис сүз ярдәмендә табигать файдасын һәм матурлыгын язып кына калмый, әйләнә-тирә дөньяны саклау турында да чаң кага.

Ни эчәбез, ни сулыйбыз,
Ни ашыйбыз – кем белә?
Беркая да китә алмабыз,
Табигать безнең белән [Әхтәмова 2004: 223], – дип, табигатьнең безнең кулларда булуын, кешелек дөньясының беркая да качып китә алмаячагын искәртә. Ул шушы табигатьнең һавасын суларга, суын эчәргә, ризыгын ашарга мәҗбүр. Шулай булгач, һәркем табигатьне дә күз карасыдай сакларга тиеш, дигән фикер әйтә.

Гөлзада апа укучысын итәгатьле, әдәпле булырга чакыра. Начарлыклардан саклап калырга тырыша:

Начарлыкның запасы бай,
Бетерәм димә аны.
Аяк чалырга рәте бар,
Булса да юньсез даны [Әхтәмова 2004: 223].

Аның шигырьләре бездә әдәплелек, шәфкатьлелек, тырышлык кебек сыйфатларны тәрбияли. Бары тик саф күңелле кешеләрнең генә табигать белән дус һәм гармониядә (ярашып) яши алуына ишарә итә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: без барыбыз да табигать балалары, табигать – безнең туган йортыбыз. Туган йортыбызны яратыйк, яклыйк, һәм саклыйк.

Әдәбият

Әхтәмова Г. Бүләк. Шигырьләр. – Яр Чаллы, 1996. –15 б.
Әхтәмова Г. Йөрәгемдә яшен. Шигырьләр. – Казан, 2004. –223 б.
Әхтәмова Г. Күңел ашкынуы. Шигырьләр. – Казан, 2011. – 143 б.
Әхтәмова Г. Табигать сәйләннәре: Шигырьләр. –Яр Чаллы, 1998. – 23 б.

## Ф. САДРИЕВНЫҢ "РӘХМӘТ, ӘТИЕМ!" ХИКӘЯСЕНДӘ ШӘХЕС ПСИХОЛОГИЯСЕНЕҢ ТИРӘНЛЕГЕ

*Косых Анжелла,*
*Мөслим районы Салавыз-Мухан урта мәктәбенең IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Латыйпова Галия Хафазетдин кызы*

“Татар язучылары барысы да диярлек авылда туып үскән. Алар, авылларын сагынып, шәһәрләрдә яшиләр, авыл турында язалар, авылны яхшы беләбез дип саныйлар. Бәхәсләшмим, беләләрдер, беләбездер.Ә менә авылдан аз гына да аерылмаган, авыл кешесенең йөрәк тибешен даими тоеп яшәгән, шуңа бөтен иҗатын багышлаган хөрмәтле язучыбыз бар безнең. Ул – Фоат Садриев. Мөслимнең талантлы егете. Фоатның романнары, повесть-хикәяләре, пьесалары аша авылның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында һәрчак уйландык..Без инде күп әйберләрне күрмәскә, сизмәскә өйрәндек бугай. Фоат безнең җилкәбездән умырып тотып авылдагы мең төрле үзгәрешләргә игътибарлырак булыгыз, дип авылга йөзебезне борып күрсәтә. Аның шулай эшләргә хакы бар,” – дип язган безнең олуг язучыбыз Туфан ага Миңнуллин. Бу сүзләр белән килешмичә һич мөмкин түгел. Чынлап та, Фоат абый Садриевның нинди генә әсәрен кулга алсаң да, авыл, аның гади халкы, җанга якын табигате.

Фоат Садриевның проза әсәрләренә карата гомуми фикер рәвешендә шуны билгеләп үтәсе килә: алар, һичшиксез, татар реалистик прозасының соңгы еллардагы үсеш-үзгәреш юлында истә калырдай казаныш булып торалар. Образларның-характерларның әсәрләрдә күпъяклы һәм тулы канлы итеп, укучы күзалдына тере кеше кебек килеп басарлык дәрәҗәдә, үтә дә көчле тәэсир калдырыдай эстетик энергия белән сурәтләнүе дисеңме; конфликтларның реаль тормыш үзәгеннән “суырып” алынуы һәм бүгенге көн өчен дә, ерак перспиктива өчен  дә гаять мөһим һәм актуаль булуын әйтәсеңме; табигать күренешләрен тасвирлаганда әдипнең иң оста пейзажчы булуын рәссамнар сыман төгәл һәм ачык буялар - сүзләр таба алуы дисеңме; әсәр геройларның күңел җан каруманнарына кереп киткән очракларда әдипнең иң нечкә һәм сизгер күңел кылларында уйнавы һәм шул чагында кешенең үзәгенә үтәрдәй аһәңнәр тудыруын искә аласыңмы – менә болар барысы да Фоат Садриевның әдәбиятта “реализм” дигән ышанычлы юлдан баручы прозаик буларак зур талантын, күп еллар буе дәвам иткән иҗади хәзинә  нәтиҗәсендә ирешелгән осталыгын раслап торалар.

Тел-стильнең үтә дә нәфислеге,нәзакәтлеге,нечкәлеге;хис-кичереш дөньясының  мәгърур музыкаль симфонияләрдәге шикелле бөек бер гармония һәм драматизм белән агышы; вакыты-вакыты белән югары рамонтиканың, ә кайчак иң-иң трагик аһәңнәр өскә калкып кеше рухиятнең гаять киң диапазонда һәм тирәнлектә – биеклектә чагылу- болар барысы бергә проза әсәрләрен шигърият белән якынайта, алар арасындагы чикне җуйдыра.

Русның атаклы язучысы М.Шолохов гомер буена Дон буенда яшәп иҗат иткән шикелле безнең Фоат Садриев та әле дә булса үзенең Мөслимендә яшәп ята (сүз уңаеннан мәрхүм шагыйребез Мөдәррис Әгъләмнең бу яктан чыккан ике талант ияләренең күплегенә сокланып:”Уңдым мин Мөслимнәремнән!” диюе искә килеп төшә). Һәм бу авторыбыз шулай ук Шолоховтан һич калышмыйча роман арты роман, повесть арты повесть биреп бара.

Безнең Фоат абый Садриевның “Рәхмәт, этием” хикәясенә тукталасы килә. Ул монда глобаль проблемалар күтәрмәгән, геройлары да гадиләр, гадәтиләр.

Әмма безнең көндәлек яшәебезне халыкчан тел белән тасвирлап бирә, шуның белән укучы күңеленә үтеп керә дә. Иҗатта башка сукмак эзләп, сентименталь алымда язылган "Рәхмәт, әтием" зур осталыкка ирешкән язучы булуын тагын бер кат раслый.

Ана белән бала мөнәсәбәте турында без күп әсәрләр укып беләбез. Ә монда – ата белән ул, атаның ялгышы сурәтләнә. Хәтта иң битараф укучыны да тетрәндерә, үкси-үкси елата торган хикәя. Атаның кичерешләре, моңа кадәр алып барган тормыш рәвеше, кешеләр белән булган мөнәсәбәте барысы да күз алдыннан үзең кичергәндәй үтә. Камилнең үзенә икенче күзлектән карый башлавы, тормыштагы тайпылышлар укучыны нәфрәтләндерә, шул ук вакытта уйландыра.

Хикәя геройның мөрәҗәгате белән башланып китә.

"Кеше! Мин моны синең өчен язам, син ялгышма, минем фаҗигамне кабатлый күрмә, дип язам. Шуңа күрә, әгәр ул синең кулыңа килеп эләксә, зинһар, атып бәрергә ашыкма, укып чык. Бу аклану өчен язылмады, мин беркемнән дә гафу сорамыйм. Минем моңа бернинди хакым юк. Ник дисәң, мин үз- үземне күрә алмыйм, ә андый кеше гафу ителергә тиеш түгел."

Шулай гафу итә алмаслык нәрсә булган икән соң? Хикәяне укый-укый алга таба киткәч, менә бу юллар күпмедер дәрәҗәдә серне ача төшә: "Минем дөньядагы барлык нәрсәләрдән дә ныграк яраткан улым – куанычым һәм юанычым – корып кипкән хәлдә диспансер баскычында басып тора". Бу хәлгә кем гаепле? Ата бары үзен генә битәрли: эчтән яна- көя, ләкин ялгышны төзәтеп булмый, үкенүләр дә, башка гамәлләр дә аның сөйгән улын үлем тырнагыннан йолып ала алмый.

Әсәрдәге "мин" баш- аягы белән хуҗалык эшенә чумган. Барлык эшне дә җиренә җиткереп, намус белән башкара. Әмма аны тормышның башка сынавы көтә. Сынауның да нинди бит.

Улының үлеменә ата бары үзе генә гаепле икәненә төшенә, башта моңа ышанасы килми, әмма хакыйкать күз алдында. "Их, улкаем! Әгәр син белсәң! Әгәр әниең белсә! Нинди сүзләр белән каргар идегез микән мине?!" бу сүзләрдә күпме үкенү, күпме ачыну.

Әсәр беренче битеннән ахырына кадәр ата кешенең тирән психологик кичерешләренә багышланган. Гүяки без – әсәрне укучылар – баштан ахырга кадәр бер моңлы скрипканың үзәкләрне өзгеч сызлануын, сыкравын, әрнүен, газаплануын ишетәбез, шул фаҗигане бәгыребез аша үткәрәбез.

Хикәядә күздән яшьләр китерердәй күренешләр күп. Чөнки ата кеше улының тиздән якты дөнья белән хушлашасын белеп тора. Менә шушы күренешләрне тасвирлаганда язучының бер үк вакытта нечкә күңелле кеше дә, оста психолог та булуына һәм геройларның халәтен- портретын чын рәссамнарча күрсәтә алу сәләтенә дә шаһит булабыз. Диспансердагы бер күренеш "Шулчак аның кулы дерелдәп китте, ул күз яшьләренә буылып, минем муенымнан кочаклап алды. Мин аның ябык аркасын сыпырдым, икебез дә мышык- мышык еладык.

Әтием... китмә, әтием...- диде ул бертуктаусыз"

Улының соңгы сүзләре: "Рөстәмне кыйнама...гыз-"диюе ата кешенең соңгы өмет җепләрен дә өзә. Ул монда барсын да аңлый: Сәгадәтнең ниләр кичергәнен дә, нинди халәттә булганын да төшенә. Тормышта ялгышларның бервакытта да җәзасыз калмаганлыгы монда ачык чагыла.

Хикәядә кеше психологиясен ачып бирүдә язучы фразеологик әйтелмәләр бик оста файдаланган. Мәсәлән, "Йөрәк күпме янса да, тере тәнгә ут капмый икән тагын...", " Күңелем ачы хәсрәттән тәмам каткан булган", "Гомер буе усак яфрагы кебек калтырап яшәүче", "чәчләр үрә торырлык хәлләр бит" һ.б. шундый төзелмәләр кешедәге кичерешләрнең тирәнлеген ачып бирәләр.

Табигатьне сурәтләгәндә дә кеше холкы белән тәңгәл китереп сурәтли, мәсәлән, "Күктә кояш көлеп торса да, йөзгә бәреп язгы җил исә, ул кышның бәсле йөрәгенә соңгы мәртәбә батырып алынган хәнҗәр шикелле салкын иде." Ата күңелендә дә шундый ук халәт. Ул гаҗиз, ни эшләргә белми, чарасызлык аны баса. Мондый мисалларны бик күп китерергә мөмкин, алда әйтеп үткәнебезчә, автор кеше психологиясен иң нечкәлекләренә кадәр күрсәтеп сурәтләгән.

Фоат абый Садриевның "Рәхмәт, әтием" хикәясен һәркемгә укып чыгарга тәкъдим итәбез. Әсәр укучыны тетрәндерә , көендерә, кеше язмышы турында кат-кат уйланырга мәҗбүр итә.

Әсәрдәге Сәгадәт минем яшьтәшем. Бу хикәяне укыганнан соң миндә әллә нинди хисләр уянды. Тормыштан тәм – ямь табып яшәр вакытта, үлем белән көрәшеп яткан яшүсмер бик кызганыч. Балачакның иң гүзәл мизгелендә үлем белән тартышып яткан баланың кичерешләре күңелне әллә нишләтте. Төрле гаиләләр бар: балаларына артык таләпчән, усал алымнар кулланып тәрбияләүчеләр дә, балаларын үзләренең иң якын сердәшчесе иткәннәре дә, бу әсәрне укып һәрбер ата-ана үз кыйбласын билгели һәм тиешле нәтиҗәне ясасын иде.

Кыскасы, язучы Фоат Садриев хикәяләре тормышны тагын да мәгънәлерәк, яшәүне тагын да ямьлерәк , кадерлерәк итеп тоярга ярдәм итә. Фоат абый Садриевның иҗат чишмәсе саекмасын, яшьләрнең остазы, әдәбиятыбызның әйдәп баручысы булып калсын.

## ЧИШМӘ БАШЫ - ТОРМЫШ БАШЫ

*Кусякулова М.,*
*Алабуга шәһәренең 10 нчы урта мәктәбе укучысы*
*Фәнни җитәкче: Данилова Зөлфирә Сәләхетдин кызы*

Һәр шагыйрьнең үз моңы, әдәбиятта үз урыны булган кебек һәркем шигърияткә үзенең кабатланмас язмышын,үз тормыш тәҗрибәсен алып килә,халыкның рухи хәзинәсенә яңа бизәк өсти.Актанышта туып үскән, танылган татар шагыйре, Габдулла Тукай исемендәге премия лауреаты Гамил Афзалның туган илгә, анага, җиргә эчкерсез назлы мөнәсәбәт белән беррәттән

табигатьтәге,тормыштагы туктаусыз хәрәкәт һәм илнең иминлеге хакында уйлану хас. Шигырьләрен укыган кеше дә аның язу стилен башкаларныкы белән бутамый. Беренчедән, ул авыл, кеше тормышының башкалар язмаган якларын, проблемаларын күтәреп чыккан. Икенчедән, ул һәр сүзнең урынын, әдәби кыйммәтен төгәл белеп файдаланган. Язучы сүзнең яңгырашына һәм тәэсир итү көченә дә зур әһәмият биргән. Аның шигырьләре җиңел укыла, теләсә кайсы образ җанлы булып күз алдына килеп баса. Күптән түгел Г.Афзалның “Чишмә башы” шигыре белән танышырга туры килде.Ни өчен шигырь “Чишмә башы”дип аталган? Чишмә башы мәгънәсе белән кешенең яши башлавы белән уртаклыгы юкмы? Чишмә белән кеше тормышы ничек бәйләнгән соң? Мин үземнең әлеге эшемдә шушы сорауларга җавап эзләргә, үземнең фәлсәфи уйлануларымны җиткерергә тырыштым.

Кеше язмышын еш кына тау-ташларны тишеп, авыр-авыр җир катламнарын ерып якты дөньяга омтылган чишмә белән чагыштыралар. Чишмәнең җир өстенә тишеп чыгуы нинди тылсымлы булса, кешенең дөньяга беренче тапкыр аваз салуы да шундый ук могҗизага ия. Һәр чишмәнең үз тарихы, үз моңы, үз агымы, үз юлы бар. Бер ише шарлап ага, тавышы еракларга ишетелә, икенчеләре исә әкрен генә үзенә юл ала.Уйлап карасак, кеше дә тормышта төрлечә гомер кичерә .

Тау итәген ярып чишмә типкән
Салкын гына суы-саф көмеш.
Челтер- челтер итеп агып киткән,
Дөнья буйлап киткән, саф килеш.

Автор фикеренчә, кеше дә чишмә кебек саф килеш тормышка аяк баса, үз тормышын дәвам итә. Кешенең гомер юлы да бит чишмә сукмагыннан, аның саф суыннан башлана.

Ярларына яран гөлләр үскән,
Юлаучылар ятып су эчкән,
Төннәрендә ай шәүләсе төшкән ,
Иң кадерле нигъмәт – су икән.

Чыннан да, Гамил ага әйткәнчә,чишмә – бик кадерле нигъмәт. Шигырьдән күренгәнчә, кеше дә бик кадерле, җир йөзенә гөнаһсыз, саф булып килә.

Шагыйрь идеал сүзен берничә строфада кулланган. Нәрсә ул идеал? “Идеал” сүзенең мәгънәсен ачыклап китик. “Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә” сүзнең түбәндәге мәгънәләре бар:

1.Җәмгыяттә яки аерым шәхеснең алга куйган,шуңа омтылган иң югары максаты,кеше омтылышының теләк – максатының иң югары ноктасы.

2. Кемгә дә булса яхшы якларның, сыйфатларның иң югары гәүдәләнеше, иң камил үрнәге булып күренгән кеше турында [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге 1977: 362]

Югарыдан күренгәнчә,тормышта Идеал кеше ролендә дә һәм кешенең максаты буларак та күрсәтелә.

И хилафсыз.
И хәйләсез дөнья,
Һәр чәчәгең көләч шат була,
Талларыңа асыл кошлар куна-
Идеал да шулай саф була.

Шигыръдән күренгәнчә, идеал сүзе бу очракта кеше тормышы буларак сурәтләнгән. Идеал тормышын кеше тормышы белән чагыштырып карыйк.

Төрле чүп-чар җыеп бара-бара,
Килеп җитә чишмә елгага.
Һәр тармагы яфрак яра-яра ,
Идеал да шулай болгана.

Димәк, чишмә дә тормышта күп кенә каршылыкларга очрый- очрый елгага килеп кушыла.Кеше дә тормыш каршылыклары белән көрәшә-көрәшә гомер уртасына барып җитә. Минемчә, елга – гомер уртасы. Әхлакның башы-чишмә. Кеше тормышы символы – идеал. Аның тамырлары чиста булса,тормышның ахырында идеал булып кала.Автор моның белән нәрсә әйтергә теләгән? Кешелекле булып яшәсәң,иңнәреңә кошлар кунар. кадерең булыр.Димәк, Идеалың да шулай саф булып кала, даның, шөһрәтең киң була дигән сүз.

Еракларга агып киткән чишмә,
Гасыр-гасыр гомер буенча.
Ярларына тинтәк тирес түккән,
Аны-моны уйлап тормыйча.

Дөрестән дә күпме чишмәләребез ташландык хәлдә, чүп оясына әверелгән. Һаман да матур чишмәләребезнең дә тирә-юне ял итүчеләр тарафыннан рәнҗетелә, пычратыла. Аның суы агып төшә торган елгалар, инешләр дә корый, кибә. Су, дым булмагач үләннәр, куаклар, болыннар да корый, бу тирәгә кошлар да оя кормый.

Су образында яшәеш үзе сурәтләнгән.Ул табигать сурәте аша, кеше язмышы,кешелек идеалы турында уйлануларга килә, йөрәк серләрен тасвирлау аша фәлсәфи уйланулар юлына чыга. Чишмәнең поэтик урыны бар.Ул символ да булып тора, халыкның яшәү көчен, рухының сафлыгын чагылдыра.Чишмә башы – тормыш башы. Г.Афзал үзенең шигырендә шушы фикерне чагылдырган. Кеше гомере бик кыска, кадерле. Бәхетле, сау-сәламәт яшәү өчен эчәргә саф су, яшәргә иман кирәк.

Анда килеп намаз укыганнар,
Мөсафирлар дога кылганнар.
Чишмә башы - изге урын диеп,
Тәсбих әйтеп торган урманнар.

Әдәбият

Афзал Г. Талларым, тирәкләрем. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1979
Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Тат.кит.нәшр.,1977

## «БУБЫЙ ШӘКЕРТЛӘРЕ ДӨНЬЯГА ТУП-ТУРЫ КАРЫЙЛАР, АЯКЛАРЫН ҖИРГӘ НЫК БАСЫП ЙӨРИЛӘР...”

*Маннапова Гөлия,*
*Әгерҗе районы Иж-Бубый урта мәктәбенең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Маннапова Эльмира Назиф кызы*

Без яшәгән чорны гаять катлаулы дәвер дип атарга мөмкин. Бөтен дөнья масштабында бара торган глобальләшү, интегральләшү процессы, тормышыбызның төрле – сәясәт, икътисад, аеруча мәгариф өлкәсендәге реформалар тормышта үз урынынны табу өчен билгеле бер кыенлыклар тудыра. Әнә шундый эзләнү дәверендә үткәндәге уңай тәҗрибәне өйрәнү актуаль яңгыраш ала.

Халкыбызның мәдәнияте тарихында мәдрәсәләр зур урын биләгән. XX гасыр башында халыкны аң-белемгә тартып, милләтебезнең зыялыларын үстереп, укыту-тәрбиянең куелышы һәм эчке тәртип ягыннан алдынгы саналган, бөтен Русиядә дан-шөһрәт казанган татар мәдрәсәләре берничә генә. Алар – Казанда «Мөхәммәдия», Оренбургта «Хөсәения», Уфада «Галия», Әгерҗе төбәгендә Иж-Бубый мәдрәсәләре.

Иж-Бубый мәдрәсәсенең тарихы шактый зур һәм бай. Буби́ мәдрәсәсе́, Вятка губернасы Сарапул өязе, хәзер Татарстанның Әгерҗе районында, Иж-Бубый авылында, 1781 елда Габделгалләм Нигъмәтуллин тарафыннан Иж-Бубый мәчете каршында мәхәллә мәдрәсәсе буларак ачыла. 1895 тән, аның уллары Габдулла һәм Гобәйдулла Бубилар укыта башлагач, мәдрәсә җәдитчә белем бирү йорты һәм бөтен Россиягә мәгълүм мөселман мәгърифәт үзәге буларак таныла. Русиянең төрле почмакларыннан мәдрәсәгә укырга яшьләр килә. 1908-1911 елларда биредә һәр елны 500 шәкерт белем ала.Бу авылда Русиядәге мөселман хатын-кызлар өчен иң беренче уку йортларыннан кызлар мәдрәсәсе дә эшли. Хатын-кызлар мәдрәсәсенә Мөхлисә Буби җитәкчелек итә. Гарәп, төрек телләре һәм әдәбиятлары, француз теле, гомуми тарих, математика, физика, химия фәннәре укытыла. Рус теле сыйныфы эшли. Буби мәдрәсәсендә шагыйрь Н. Думави, шагыйрә З. Байчурина, шагыйрь Д. Гобәйди, язучы С. Җәләл, беренче халык җир коммисары Юныс Валидов, язучы Җ. Вәлиди, гарәп телләрен белгече З. Максудова, ТАССР мәгариф хезмәткәре Г. Балтанов һ.б. укый һәм укыта.

Мәдрәсәдә һәр атнада әдәби, фәнни кичәләр уздырыла. Мәдрәсәнең бай китапханәсе, махсус җиһазландырылган спорт мәйданчыгы була.

Мәдрәсәне тәмамлап чыгучылар тирән фикерле, белемле, киң мәгълүматлы шәхесләр булып формалаша. Иж-Бубый мәдрәсәсенең уңышларга ирешеп чәчәк ату еллары бертуган Габдулла һәм Гобәйдулла Бубилар җитәкчелек иткән дәвергә туры килә.

Әлеге уку йортын дөньяның төрле почмакларында беләләр. Аның турында мәгълүматлар Лондон, Хельсинки, Нью-Йорк архивларында, китапханәләрендә саклана, Сан-Францискодан Шәмсия Апакай белән ире Салих әфәнде Австралиядән Ләйлә һәм Сәгыйть Садрилар, Иж-Бубый мәктәбе белән даими элемтәдә тора, бирегә берничә мәртәбә мәдрәсә юбилейларына кайтып киткәннәр. Бертуган Бубиларның шәкертләре бөтен дөнья буйлап таралган.

Авыл музеенда мәдрәсә тәмамлаган шәкертләренең хатлары, истәлекләре саклана. Аларның күбесе укытучылар булып хезмәт иттеләр. Кайбер Иж-Бубый мәдрәсәсендә белем һәм тәрбия алган, җирнең төрле почмакларында тирән эз калдырган шәкертләр турында әйтәсем килә.

Нәҗия Бигашева Минзәләдә туа, Мухлисы Бубиның асрама алган кызы, мәдрәсәне тәмамлаганнан соң Старлитамак, Юнҗ, Мари АССР, Оренбург, Ташкент, Самарканд, Навои шәһәрләрдә хезмәт итте. Зәйтүнә Фахретдинова Керекешли авылында мәктәп ачты (Лениногорск), Бөгелмә укытучылар семинариясендә эшләде. Зәйтүнә Маулюдова Чистай - Курса – Казан шәһәрләрендә укучыларга белем бирде. Гайшә Хәсәнова Уфа, Казан, Сарытау губернасының Ново-Узекский өязе укытучы булып эшли.

Иж-Бубый мәдрәсәсен тамамлаган укучыларны Япония, Мексика, Польша, Финляндия, Кытай кебек чит илләрдә очратырга мөмкин булган. Халкыбызның бүгенгесе, киләчәге, дөньякүләм тоткан урыны, һичшиксез, аның аң-белем дәрәҗәсенә, рухи-әхлакый үсешенә турыдан-туры бәйле. Бүгенге көндә туган телебезне, тарихыбызны өйрәнү бик мөһим мәсьәләләр.

Без Бертуган Бубилар исемендәге Иж-Бубый урта гомуми белем бирә укучылары Һәм авылда яшәүче милләттәшләребез үзебезнең тарихка битараф түгел. Сакланган тарихи язмалларны, китапларны җентекләп өйрәнәбез. Тарихи эзләнүләрдә катнашып, конференцияләрдә, укучылар өчен оештырылган укуларда данлыклы Иж-Бубый тарихы турында белемнәрне таратабыз.

Әдәбият

Марданов Р., Миннуллин Р., Рахимов С. Бертуган Бубилар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе. Казан: «Рухият», 1999.

Махмутова А. Пора и нам зажечь зарю свободы! – Казань, Татарское книжное издательство, 2006 – М.: Академия, 2006.

## АССАЛАР ДА, КИССӘЛӘР ДӘ...

*Мәхмүтова Зилия,*
*Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең VIII сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Мәхмүтова Гөлшат Рәзин кызы*

Нажар Нәҗминең шигырь юллары күңелне айкый: “Ассалар да, киссәләр дә, үлмәдең син, калдың тере...” Нәрсә турында язачагым көн кебек ачык: Тел... Туган тел... Татар теле... Бүгенге көндә татар теленә карата барган вәзгыятьтән

мин дә берничек тә читтә кала алмыйм. Татар телебезне саклап, яклап калу өчен мин үземнән нинди өлеш кертә алам? Минә шушы хезмәтем газиз телем өчен кечкенә булса да, бер адым булыр, дип уйлыйм. Шушы көннәрдә интернет челтәрләрендә татар теленә кагылышлы нинди генә фикерләр, мәкаләләр укырга, видеороликлар карарга туры килмәде. Мин хезмәтемдә татар телен яклауга өндәүче шигырьләрне барларга алындым.

Шагыйрьләр көн кадагында булган "тема"га актив рәвештә шигырьләр иҗат итә башладылар. Рамис Әймәтнең "Тотса Мәскәүләр якаң..." шигырен алыйк. Аны "Тукай ютәле" дип атарга да мөмкин булыр иде.

Күпме сулар акты, җилләр исте
Син киткәннән бирле җиһанда.
Нинди генә шомлы гарасатлар
Кагылмады килеп бу җанга?!
Син киткәннән бирле бу татарым
Ничә тапкыр йоклап уянды.
Офыгында сихри мираж күреп,
Бер сабыйдай шашып куанды.
Һәм... офыклар "көлеп" чигенгәндә,
"Тотам!" – диеп, күпме абынды.
Якты хыялларын иңнәренә
Иске чикмән итеп ябынды.
Күкләрендә Ае сүнеп, халкым
Кереп барган чакта шом-төнгә.
Кар өстеннән яланаяк килеш
Йөгермәде чыгып беркем дә.
Йөгермәде... Тук елмаеп бар да,
Үз юрганын тартты үзенә.
Аларга ни? Тукай түгел, хәтта
Ак төшсә дә дөнья күзенә.
Ә син булсаң, йөгерәчәк идең,
Эчкә йотып рәнҗү, үпкәңне...
...Гасыр буе, әнә, кисекбаштай,
Тәгәри дә татар, тәгәри.
Яши шулай... Кылган гамәлләре
Бары хәлдән килгән кадәри.
Ишетәсеңме, тагын оран сала,
Нишләтәләр Туган телеңне?!
Газиз телең Рәсәй түмәрендә
Телем-телем күпме теленде?!
(Өмет эзеп бүген ятагында
Көтеп ята кара үлемне.)
Татарыма ясин чыкмакчылар,
Газиз сөттән - телдән аерып.

Бу Мәскәүләр якадан гынамы?!
Бугазлардан алды каерып.
Әнә тагын шомлы җилләр исә,
Еллар түгел, бәгырь үтәли.
Сискәндереп уята күк безне,
Уята күк Тукай ютәле...

Г.Тукайның С. Рәмиевкә язган хатыннан: *“Эчем, тышым... злоба белән тулды. Бөтен көтепханәләрне, матбагаларны вә газеталарны ябып бетерсәләр, бу көннән яңа киемнәремне җыртып ташлап, яланаяк чыгып йөгерәчәкмен. Күз алдым караңгыланды...” – дигән юллары искә төшә...*

Яраткан шагыйрьләремнең берсе Рүзәл Мөхәммәтшинның “Бер генә” шигыреннән өзекләр китерәм. Ул да үз сүзен җиткерергә тырыша.

Авызың тулы кан…
Бу җирдә
Диюләр теш коеп көн күрә…
Сытып чыгар ирен читеннән.
Тик өзек телеңне,
Кан, диеп, телеңне,
Ялгышып телеңне төкермә!..
...Исән-сау котылгач,
Иң соңгы орышта
Очрашып күзгә-күз, бергә-бер…
Хөрлекне дан итеп җырларга,
Хөрлекне дан итеп җырларга,
Җырларга кирәгер!

Ни генә әйтсәк тә, бүген модада булган ватсапны да читләтеп үтеп булмый. Кызганычка каршы, ватсаптан алынган алдагы шигъри юлларның авторларын билгеләү авыр. Авторлар үзләренең шигырьләрен үзләре укыйдыр дигән фаразым гына бар. Шулай булса да, бу шигырьләрне сезгә дә тәкъдим итәм. Бу аларның телебез өчен үзләренчә көрәшүедер...

Кая бара бу дөньялар?
Кысалар татар телен.
Күпме гасырларны кичкән
Татарның туган телен.
Зур башлыклар күптән качты,
Нинди кыю икәнсез...
Моңарчы “Якларбыз”,- диеп,
Безне алдап йөргәнсез.
Хурлык бит бу. Их, милләтем,
Хурлыкның иң зурысы.
Тату яши иде телләр:
Удмурт, мари, урысы...
Кемгә комачау иттек без?

Нигә дип кыланасыз?
Нинди сәбәпкә бу юлы
Сез зурлар сылтанасыз?..
...Кардәшләрем һәм дусларым,
Әйдәгез, бердәм булыйк!
Кыюлыкны учка җыеп
Бергәләп каршы торыйк!..
...“Әни” диеп тел ачыла,
“Әти” дип тибә йөрәк.
Һәр кешегә - сиңа, миңа,
Үз телен белү кирәк!
Үтерәбез, бетерәбез мени
Туган телне, анабыз телен?!
Татарларны күрә алмаганнар
Әзерлиләр телгә тик үлем!
Рөхсәтем юк! Тимә-кагылмагыз
Сөйләмемнең нигез ташына!!!
Маңкортларның эше барып чыкмас,
Җитә алмаслар телем башына!
Горурланам ТАТАР булуымнан!
Татар булып яшим һәм үләм!
Туган телем, атам-анам теленең
Киләчәген балаларда күрәм!

Татар теле... Тугач та иң газиз кешеңнән ишетә башлаган, күп гасырлык тарихы булган, Каюм Насыйрилар, Тукайлар нигез салган, 7 миллион халык сөйләшкән, дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, бүгенге көндә җитлеккән, камилләшкән, теләсә нинди катлаулы фәнне өйрәтергә мөмкинлеге булган, иң-иң авыр кимсетүләргә дә түзгән, сынмаган-сыгылмаган, баш имәгән горур татар теле! Синең бетәргә хакың юк!

Халкым теле миңа – хаклык теле.
Аннан башка минем телем юк.
Илен сөймәс кенә телен сөймәс,
Иле юкның гына теле юк...

## ТАТАР РАДИОТАПШЫРУЛАРЫНДА ГАРӘП-ФАРСЫ АЛЫНМАЛАРЫНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

*Мөхәммәтҗанова Илзирә,*
*КФУның Алабуга институты студенты*
*Фәнни җитәкче: Әхмәдгалиева Гүзәлия Гәбдрәуф кызы*

Тыгыз икътисади, мәдәни, дини бәйләнешләр нәтиҗәсендә татар телендә гарәп-фарсы алынмалары башка телдән кергән сүзләр арасында әйдәп баручы урынында тора. Шуңа күрәдер, мөгаен, алынмаларның бу төренә карата фәнни кызыксыну шактый күптән уяна, хәзерге заман тикшеренүчеләр, галимнәр аларның К.Насыйри, Г.Сәгъди, Җ.Вәлиди хезмәтләрендә күпмедер яктыртылуын искәртеп китәләр [Федорова 2003: 3]. Соңрак гарәп-фарсы алынмаларының татар телендә үзләштерелү үзенчәлекләренә Ш.Рамазанов, М.Мәхмүтов, И.Ш. Әүхәдиев хезмәтләрендә күзәтү ясала [Рамазанов 1966: 334]. И.Сираҗиевның диссертацион хезмәтендә кайчандыр актив сүзлек запасыннан кысрыклап чыгарылган, узган гасырның 90 нчы елларында күренекле язучылар тарафыннан яңадан кулланыла башлаган гарәп алынмалары өйрәнелә [Сираҗиев 2002: 177]. Шулай итеп, татар телендәге гарәп-фарсы алынмалары тел гыйлеме фәнендә җитди өйрәнелгән дип әйтергә нигез бар. Әмма аларның хәзерге массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән, радиотапшыруларда кулланылышы игътибардан читтә кала бирә. Әлеге мәкаләне язу дәвамында исә аларның ди-джейлар сөйләмендә киң таралыш алганы ачыкланды.

Радиотапшыруларны лексик, морфологик яктан анализлау барышында барыннан да күбрәк исем сүз төркеменә караган алынма сүзләр кулланылуы ачыкланды һәм бу күренешне без бик табигый дип саныйбыз: ешрак очракларда тормыштагы яңа реалия исем сүз төркеменә карый. Без аларны түбәндәге тематик төркемнәргә аердык:

*Кешене, затны аңлатучы алынмалар*: әфәнде, ханым, галим, шагыйрь, дус, дошман һ.б.

Мәсәлән: *Ә эфирда – мин, Рәмзия, дуслар* (“Татар” радиосы). *Илфар әфәнде, миңа элегрәк бөтенләй аерылышулар булмаган дип беләбез* (“Татарстан” радиосы).

*Абстракт төшенчәләрне белдерүче атамалар*: дөнья, зыян, тылсым, фикер һ.б.

*Бүгенге тапшыруыбызда наркотикларның зыяны турында, белгеч киңәше һәм ул юлга кереп китмәс өчен яшьләребез фикерләре яңгырар*(“Татарстан” радиосы).

*Кешенең эчке һәм тышкы торышына йогынты ясаучы төшенчәләр*: зарар, газап, бәхет һ.б. Мәсәлән: *Ышаныч, куәт, куркынычсызлык – бу Вольво*!(“Татар радиосы”). *Чынлап та, дуслар, мәхәббәт тормыш ваклыкларыннан өстен тора* (“Болгар” радиосы).

*Вакыт төшенчәләренә атама булып килгән алынмалар:* сәгать, заман, гасыр, җомга һ.б.: *Чөнки иртәгә безнең җомга, ә бүген пәнҗешәмбе генә* (“Татар радиосы”). *Ял сәгатьләрен башлап җибәрегез* (“Татар радиосы”).

*Урын төшенчәләренә атама булып килгән алынмалар:* шәһәр, мәктәп, мәйданчык һ.б.: *Казанда бу чара биш мәйданчыкта уздырыла* (“Татар радиосы”). *Бездә татар мәктәпләренең саны җитәме*?(“Татарстан” радиосы).

*Ризык атамалары:* ризык, нигъмәт һ.б. Мәсәлән*: Еланның берсе – удав, буар елан дибез аны, үзеннән күпкә киңрәк азыкны йотып җибәрә ала*("Татарстан" радиосы).

*Мәгариф, сәнгать белән бәйле атамалар*: китап, каләм, сәнгать, рәссам һ.б. Мәсәлән: *Россия халкы китап укудан бизгән*("Татар радиосы"). *Үз балаларына ана телендә милли белем, милли тәрбия бирә алган халык кына киләчәккә өмет белән карап яши*("Татарстан" радиосы).

*Дини лексикага караган алынмалар:* иман, дин, намаз һ.б. Мәсәлән: "*Иман нуры" программасының иганәчәсе – "Хәләл-туризм*" ("Татар радиосы").

*Иҗтимагый тормышны чагылдырган лексика:* милләт, халык, дәүләт һ.б.

*Украинада, шул исәптән, Кырымдагы социаль вәзгыятьнең авырлыгы шиксез* ("Татар радиосы").

*Ватаныбызның күп кенә атаклы җырчылары оркестр белән чыгыш ясыйлар*("Күңел" радиосы).

*Ялгызлык исемнәре, топонимнар*: Рәсим, Габделхак, Согуд Гарәбстаны һ.б. *Алдан сез оркестр башкаруында Фасил Әхмәтовның "Егетләр" композициясен ишетерсез* ("Күңел" радиосы).

Тикшеренүләребез күрсәткәнчә, гарәп-фарсы алынмалары телебездә тулы хокуклы лексик берәмлекләр булып киткәннәр, телнең үз исем сүз төркеменә караган сүзләр кебек үк, берлек һәм күплек санда килә алалар, килеш, тартым белән төрләнәләр, җөмләдә төрле синтаксик вазифа башкаралар.

Гарәп-фарсы алынмалары арасында сыйфат сүз төркеменә караган берәмлекләр дә очрыйлар. Мәсәлән: *Студиябезгә кунакка мөхтәрәм шәхес – шушы кануннарның үзәгендә кайнаучы, шушы кануннар белән эш итүче "Форпост" юридик оешмасы җитәкчесе Илфар Солтан улы Шиһаповны чакырдык*. ("Татарстан" радиосы). *Үз балаларына ана телендә милли белем, милли тәрбия бирә алган халык кына киләчәккә өмет белән карап яши*.("Татарстан" радиосы). Синтаксик яктан бу сыйфатлар аергыч вазифасында килгәннәр.

Гарәп-фарсы алынмалары арасында фигыль сүз төркеменә караган аерым очраклар шулай ук эш дәвамында теркәлделәр. Алар татар фигыльләренә хас булган бөтен үзенчәлекләрне шулай ук үз эчләренә туплаганнар. Мәсәлән:

*Уку йортын тәмамлагач кына гаилә кору модага керә* ("Татарстан" радиосы).

*Юридик яктан мисаллар китерсәгез иде*("Татарстан" радиосы).

Билгеле булганча, гарәп-фарсы алынмалары арасында ярдәмлек сүз төркеменә караганнары да шактый, һәм алар әдәби телдә дә, җанлы сөйләм телендә дә киң таралганнар. Бу факт радио ди-джейлары сөйләмендә дә аларның еш кулланылуына алшарт булып тора. Мәсәлән: *Гипертония һәм йөрәк-кан тамырлары авырулары да килеп чыгарга мөмкин* ("Болгар" радиосы).

Хәзерге татар әдәби телендә гарәп-фарсы алынмалары булган алмашлыклар да еш очрый. Кайбер очракта алар *һәр + бер, һәр + кайсы* кебек

модельләр буенча төзелеп, кушма лексик берәмлек хасил итә. Мәсәлән:*Һәрбер СМС хәбәр артында, һәрбер номер артында кеше бит, тере, үзенә игътибар сораган кеше* (“Болгар” радиосы).

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: эш барышында без “Болгар”, “Татар”, “Татарстан”, “Күңел” радиоларын тыңладык һәм радио ди-джейлары сөйләмендә гарәп-фарсы алынмаларның еш очравы, аларның телдә күптәннән үзләштерелүе, киң катлам халыкка мәгълүм булуы һәм сөйләмдә, кагыйдә буларак, иркен кулланылуы белән тыгыз бәйләнгән. Әлеге мәкалә очен фактик материал туплау дәвамында безнең тарафтан барлыгы 53 берәмлек теркәлде. Шуларның 67.9%ы – исем, 5.7%ы – сыйфат, 9.4%ы – фигыль, 3.8%ы – алмашлык, 13.2%ы – ярдәмче сүз төркемнәре булды. Алар татар радио ди-джейлары сөйләмендә кулланылган алынма сүзләрнең 31%ын тәшкил итә.

Әдәбият

Әүхәдиев И.Ш. Гарәп алынмаларының фонетик үзләштерелүе турында // Татар тел гыйлеме мәсьәләләре. – Казан: Казан ун.-ты нәшр, 1969. – Б.112-131.

Федорова Э.Н. Арабские и персидские заимствования в татарских народных пословицах (по трехтомному сборнику Н.Исанбета“Татар халык мәкальләре”): автореферат дис. канд. … филол. наук. – Казань, 2003. – Б.3.

Рамазанов Ш. Татар теле буенча очерклар. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 200 б.

Мәхмүтов М.И. Татар әдәби телендә гарәп алынмаларының фонетик һәм грамматик үзләштерелеше: филол. фән-ре канд. д-н гыйльми дәр. өчен тәкъдим ителгән дис.– Казан, 1966. – 334 б.

Сиразиев И.И. Арабский пласт лексики современного литературного татарсокго языка:дис. канд. … филол. наук. – Казань, 2002. – 177 б.

Мәхмүтов М.И. Татар әдәби телендә гарәп алынмаларының фонетик һәм грамматик үзләштерелеше: филол. фән-ре канд. д-н гыйльми дәр. өчен тәкъдим ителгән дис.– Казан, 1966. – 334 б.

Хайруллин М.Б. Лексикабыздагы чит тел сүзләре. – Казан: Мәгариф, 1998. – №9. – Б.82-83.

## ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУДА АКТУАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАР

*Нәбиуллина Айзирә,*
*Яр Чаллы шәһәре 4 нче урта мәктәпнең VII сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Батдалова Сания Әхмәт кызы*

Тел – кешеләрнең иң мөһим аралашу-аңлашу чарасы. Укырга-язарга өйрәнү, белем һәм тәрбия алу, дөньяны танып белү, һөнәрле булу, тәҗрибә туплау, фән,техника, сәнгать һәм башка яңалыклар белән танышу, уйлап табу, иҗат итү эшләре – барысы да тел ярдәмендә генә тормышка ашырыла – бар була.

Кеше нинди телдә сөйләшсә, шул телдә уйлый да. Туган тел – үз телендә сөйләшүче халыкларның күп гасырлар буе тупланган рухи хәзинәсен чагылдыручы тылсымлы сихри көзгесе дә. Укучыларның логик фикерләү, образлы уйлау сәләтләре үссен һәм нәтиҗәле өлгерешкә ирешсен өчен, укытучылар аларның туган телне яхшы белүләренә кече яшьтән үк зәвык белән нәфис итеп сөйләргә һәм язарга өйрәнүләренә омтылырга тиеш.

Башлангыч мәктәптә татар теле, нигездә, әдәби телнең практик курсы булып тора. Балаларны үзләренең фикерләрен, кичереш һәм хисләрен сөйләп, язып бирерлек итеп әдәби телгә өйрәтү аларның һәрьяклап үсүләренә дә ярдәм итә. Бала үз сүзләре белән дөрес, ачык, төгәл һәм аңлаешлы итеп сөйләп яки язып бирә һәм телне оста куллана алганда гына, белем үзләштерелгән булып санала.

Телне яхшы белүдә төп метод-сөйләшү һәм язу. Укырга, язарга өйрәнә башлау белән һәр баланың авазны, хәрефне, иҗекне, сүзне, җөмләне гамәли белүе зарурига әверелә.

Укучылар, татар теле дәресләрендә аңлап укырга, дөрес сөйләргә һәм язарга өйрәнәләр; әйтмә, язма сөйләм кагыйдәләрен үзләштерәләр. Укырга һәм язарга өйрәтү барышында балалар үзләрен чолгап алган табигатьне укытучы җитәкчелегендә актив күзәтәләр; үз кичерешләрен сөйлиләр; укытучы ярдәмендә уй-фикерләрен телдән һәм язмача эчтәлекле һәм грамоталы итеп әйтеп бирә белү күнекмәләре алалар.

Башлангыч мәктәптә татар теле программасы берничә бүлектән тора: грамотага өйрәтү һәм сөйләм үстерү; уку һәм сөйләм үстерү; фонетика, гамматика, дөрес язу һәм сөйләм үстерү; матур язу.

Татар телен өйрәнү балаларны мәктәптә уку хезмәтенә әзерләү- грамотага өйрәтү чоры белән башланып китә.

Әлифбаны өйрәнү чорында укый, яза һәм бәйләнешле итеп сөйли белүнең башлангыч күнекмәләре бирелә. Җөмлә, сүз, иҗек, аваз һәм хәреф белән практик таныштырыла.

Уку буенча программаның төп идеясе - кече яшьтән укучы балаларда Ватанны ярату, хезмәт сөю, дөреслек, намуслылык, дуслык тойгысы, ата-анага, өлкәннәргә, иптәшләренә ихтирам хисе тәрбияләү.

Дәрестә уку дәрестән тыш уку эше белән җиңеләйтелә, киңәйтелә. Укытучы балаларда китап уку гадәте тәрбияли, нәрсә белән кызыксынуларын билгели, мөстәкыйль укуларын оештыра.

Башлангыч сыйныфларда балаларның аңлап, дөрес, сәнгатьле һәм йөгерек уку күнекмәләрен булдыруга аеруча игътибар ителә. "Грамматика һәм дөрес язу методикасы"нда грамматика һәм орфографияне өйрәнүнең эчтәлеге ачыла, балаларны үзләренә хас системада өйрәтүнең методлары, төп методик алымнары бәян ителә. Балаларны яхшы укыта һәм тәрбияли белергә өйрәтү өчен, педагогик практика да кирәк. Педагогик тәҗрибә, бер яктан, укытучыга көндәлек эшендә ярдәм итсә, икенче яктан, методика хәл итәргә тиешле яңадан-яңа мөһим мәсьәләләрне дә көн тәртибенә куя тора. Мәсәлән, ни өчен кече

яшьтәге укучылар грамматик төшенчәләрне авыр үзләштерәләр, орфография кагыйдәләрен белә торып та, ни өчен язарга бик әкрен өйрәнәләр, балалар ни өчен аваз белән хәрефне, сүз төркеме белән җөмлә кисәген озак вакытларга кадәр бутыйлар, грамматиканы өйрәтүгә карамастан, балалар ни өчен логик эзлекле һәм дөрес итеп сөйли һәм яза алмыйлар, бала ни өчен сөйли белә, яза белми яки киресенчә, һәм башка шуның кебек мәсьәләләрне практика көн таләбенә әверелдерә, шуларга җавап эзли. Мәктәп практикасы белән методик теория балаларны туган телгә өйрәтү мәсьәләләрен иң нәтиҗәле юл белән максатка ярашлы итеп хәл итүдә бер-берсенә ярдәм итә.

Ни өчен туган тел дәресләрендә компьютер техникасы куллану кирәк, информацион технология чаралары кулланып дәрестә нинди мәсьәләләр чишеп була? Шундый сорауларга җавап биреп карыйк.

Беренчедән, укучыларда телебезне өйрәнүгә кызыксыну уяту.

Мәктәптә укытылган башка фәннәр арасында туган тел дәресләренең абруен күтәрүдә, компьютер техникасы куллануның да роле зур. Шулай ук: шәхес тәрбияләү; фикерләү сәләтен үстерү; эстетик тәрбия бирү; информацион культура тәрбияләү; укытуның сыйфатын күтәрү; предметара бәйләнеш булдыру; укучыларда эзләнү-тикшеренү теләге уятуда информацион технологияләрнең йогынтысы зур.

Компьютер программасы мөмкинлекләрен файдаланып төрле модель һәм таблицалар төзергә була.

Үз-үзеңне тикшерү булдыру. Мәсәлән, тест формасындагы бирем эшләтү. Укучылар экранга карап үз-үзләренең белемнәрен тикшерәләр һәм үз эшләрен бәялиләр. Шулай ук информацион технологияләр укытучыга: индивидуаль белем бирү; дифференциаль белем бирү; мультимедия һәм интернет аша зур күләмле мәгълүмат алырга өйрәтү; укыту процессында кирәк булган материалларны тупларга өйрәтү; үзаллы эшне булдыруда ярдәм итә.

Бүгенге көндә күпчелек мәктәпләрдә зур мөмкинлекләргә ия булган интерактив такталар, барлык мәктәпләрдә дә җиһазландырылган компьютер сыйныфлары бар. Әмма һәрбер дәресне дә информацион технологияләр кулланып үткәреп булмый, мондый дәрескә әзерлек укытучыдан күп вакыт та таләп итә.

“Укытучының тере сүзен бернинди компьютер да алыштыра алмый” дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә. Бу сүзләр белән килешәбез. Туган тел дәресләрен укучыларны мониторга каратып кына үткәреп булмый, чөнки дәреснең төрле этапларында урынлы, уйланылып кулланылган компьютер белән эш укучының укытучы һәм сыйныфташлары белән аралашуы һәм башка күп төрле эшләр белән үрелеп барырга тиеш.

Мәктәпләрдә балаларны дөрес итеп туган телебездә сөйләшергә өйрәтү, аларда татар теленә, сәнгатенә мәхәббәт уяту бик зур тырышлык сорый. Татар телен белүнең кирәклеге һәркайда чагылырга тиеш.

Әдәбият

Башлангыч мәктәптә татар телен укыту методикасы/ С.Г.Вагыйзов, Р.Г.Вәлитова. – Казан: “Мәгариф” нәшр., 2001.

Вәгыйзов С.Г. Матур язу дәресләре. – Казан “Мәгариф” нәшр., 1999.

Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфында эшләүче укытучылар өчен методик кулланма. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшр., 2015

## ШӘМСИЯ ҖИҺАНГИРОВА ИҖАТЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

*Нугаева Луиза,*
*Мөслим районы Вәрәшбаш төп мәктәбенең VIII сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Яхина Ләйсән Равил кызы*

Шәмсия Җиһангирова сүзләренә язылган җырларны җырламаган, һич тә булмаса үз алдына авыз эченнән көйләмәгән берәр татар кешесе бар микән?

Иҗат кешесе өчен үз моңыңны табу бер кыен булса, аны саклап калу икеләтә авыр. Кайлардан килә соң бу моң чишмәсе шагыйрәгә? Җыр кешенең эчке дөньясын, аның хисләрен һәм кичерешләрен чагылдыра. Хәзерге татар шигъритятенең күренекле вәкиле буган Шәмсия Җиһангирова өч йөздән артык җырлар авторы буларак билгеле.

Ш.Җиһангирова үзенең балачак турындагы истәлекләрендә җырлар турында еш искә ала. Җырлар аның күңеленә бик яшьли үтеп кереп иҗатында да урын алганнар. Шәмсия Җиһангирова – лирик шагыйрь. Лирик поэзиянең үзенчәлекле төре – җыр жанры һәрваккытагыча шигърияtнең һәм җәмгыятьчелекнең игътибар үзәгендә була. Җыр ул телдән, күңелдән башкарыла торган әсәр. Шуңа күрә җыр өчен махсус язылган шигырьдә рифма, гади дә, шул ук вакытта тирән дә булган шигъри эчтәлек, сюжетлылык, образлылык иң мөһим компонентлардан санала. Әлеге кагыйдәләрне шагыйрь яхшы тоеп эш итә белгәндә генә уңай нәтиҗәләргә ирешә ала.

Шәмсия Җиһангирова исеме музыка сәнгате белән кызыксынучылар, җыр-моңга гашыйк кешеләргә бик яхшы таныш, аеруча якын һәм кадерле. Радио, телевидение, бәйрәм мәҗлесләрендә яңгыраган җырларның һәр икенчесе диярлек шагыйрәнең каләменнән саркып чыгып, инде күптән халык күңеленә уелып, көнкүрешендә лаеклы урын алган. Аның шигырьләренә иҗат ителгән «Бураннар», «Ак күлмәгем», «Күрәсем килгән иде», «Минем кадерлеләрем», «Мәңге бергә», «Сөюем бакчасы», «Бер адымга гына»сын кем генә белми-ишетмәгән икән? Ә бит кукуруз басуында качып кына Салават ариясен, халкыбызның «Гөлҗамал»ын, «Кызыл төлке»сен сузган Шәмсия исемле нәни кызчык киләчәктә халкының бөек остазы, танылган, моңлы шагыйрәсе булырмын, дип уйлап та карамагандыр. Аның бары тик бер генә хыялы була-пианинода уйнау, җырчы булу. Тавыш дисәң- моңга чумдырырлык, сөйләм дисәң- шаккатырлык, бәгыреңне сыкратырлык сүз остасы, уңган-тырыш дисәң-искитмәле, бу кабатланмас сыйфатларга ия булган шагыйрәне гомер буе

җитәкләп, һаман алга, яңадан-яңа үрләргә таба этәреп килә [Җиһангирова 2012 : 3].

Шәмсия Җиһангирова шигырьләре табигый агышлы, халыкча әйтсәк, җырлап тора. Мөгаен шуңа күрәдер дә композиторларыбыз аның иҗатына аеруча еш мөрәҗәгать итәләр. Бу хезмәттәшлекнең гүзәл җимешләре булып бик күп мәшһүр җырчыларыбызның репертуарын баетырдай әллә никадәр җырлар туды. Алар камил эшләнеше белән генә түгел, тематик яктан да отышлы. Шул сәбәпледер бик күп шигырьләре көйгә салынган. Әнвәр Бакиров, Алмаз Монасыйпов, Рәшит Гобәйдуллин, Фасил Әхмәт, Луиза Батыр-Болгари, Резедә Әхиярова, Илфат Дәүләтшин, Рәис Нәгыймов, Ганс Сәйфуллин, Фәрит Хатыйпов, Азат Хөсәенов, Зөфәр Хәйретдинов һәм башка бик күп композиторлар аның шигырьләренә берсеннән-берсе матуррак җырлар иҗат итте һәм итәләр. Ул җырларны республикабызның иң танылган, таләпчән җырчылары, ул гына да түгел, Рәсәйнең төрле төбәкләрендә, чит илләрдә (аерым алганда, Америка, Австралия, Финляндиядә) яшәүче татарлар да башкара икән, бу аларның халыкка да, башкаручыларга да никадәр якын әсәрләр икәнлеген күрсәтә [Җиһангирва 2001: 4].

Җыр ничек туа соң? Чын җыр бик тә бәхетле чакта яки өзелеп юксынганда, нәрсәдәндер кинәт кенә күңел нечкәреп, ташып киткән чакта туадыр. Җыр болай гына, бер сәбәпсез тумыйдыр ул. Җырда сүз белән көй тәңгәл килү – бик зур нәрсә. Әгәр дә шуларның берсе җитешмәсә, җыр инде тулы, камил була алмый. Җырның тәэсир итү көче сүзнекенә караганда күпкә көчлерәк, шуңа да җыр кеше фикерен матур, нечкә итеп җиткерүче иң гүзәл, иң югары нокта ул. Композиторларыбыз Ш.Җиһангирова лирикасын көйгә җиңел ятуын ассызыклыйлар, моның серен шагыйрәнең үзенең дә яратып җырлавындадыр дип тә гоманлыйлар, ничек кенә булмасын, Ш.Җиһангированың җырчы-шагыйрә булуында берәүнең дә шиге юк. Әйтерсең лә бу атама нәкъ менә аңа атап әйтелгән кебек.

Әйе, Шәмсия Җиһангирова иҗат иткән җырлар халыкчан да, самими дә, күңелгә ятышлы булулары белән аерылып тора: шигырьләре җырлап укыла, ә җырлары шигырь кебек, һәр сүзендә фикер ярылып ята. Шагыйрәнең шигырьләренең йөгерек тел белән язылганлыгы күпләргә мәгълүм, һәм аның иҗатын укучыга ирештерү безнең бурычыбыз булып тора.

Әдәбият

Әюп Х. Якты моңнар иясе // Казан утлары, 2001. – № 2. – Б. 214.

Диндаров И. Мәхәббәт һәм шигърият // Казан утлары, 1986. – № 3. – Б.152–153.

Җиһагирова Ш. Җирсү: шигырьләр, җырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 191 б.

Җиһангирова Ш. Бәхетең үз кулыңда: җырлар.- Казан: Рухият, 2012.- 248 б.

# НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ ДРАМАЛАРЫНЫҢ АНТРОПОНИМИКАСЫ

*Нуретдинова Лилия,*
*Мөслим урта гомуми белем бирү мәктәбенең IX Б сыйныфы укучысы*
*Фәнни җитәкче: Даутова Гөлчәчәк Минсалих кызы*

Күренекле татар язучысы Нәкый Исәнбәтнең драма әсәрләрендәге кеше исемнәренә хас үзенчәлекләр бик күп. Аның һәр тарихи чорга багышланып язылган драмалары бар. Һәм шунысы кызыклы: кеше исемнәренең бирелеше дә эчтәлек мәгънәсенә карап сайланган. Болгар дәверен чагылдырган "Хуҗа Насретдин" комедиясендәге катнашучы персонаж исемнәренең чыгышында мәсәлән, **Насретдин** – гарәби чыгышлы, дингә ярдәм, куәт, диннең җиңүе; **Гөлбану** - фарсы сүзе, гөл(фарсы)+бану(фарсы сүзе) бикә, ханым, кәләш; **Сәлви** - гарәп сүзе, юаныч, шалфей чәчәге. "Җирән чичән белән Карачәч сылу" драмасында вакыйга XIV йөзнең урталарында бара. **Җирән чичән-** борынгы төрки-татар сүзе – "арсил"- җирән – кызгылт башлы, чәчле +чичән – телгә оста, яттан бик күп шигырьләр сөйли; **Карачәч сылу** – карачәч (борынгы төрки-татар сүзе) + сылу (гарәп сүзе) гүзәл,чибәр. Алтын Урда дәүләте таркалу чорын чагылдырган "Идегәй" әсәрендәге кеше исемнәренең килеп чыгышын, ясалышын, мәгънәви ягын карап үтәрбез.

Вакыйга Алтын Урдада XIV йөзнең ахырларында һәм XV йөз башларында Сарай шәһәрендә һәм аның җирләрендә бара .**Идегәй** – борынгы төрки-татар сүзе, иттекәй сүзеннән ясалган; **Туктамыш** – төрки-татар сүзе, үлем яки тууның тктавын теләү**; Нугайби** – монгол-төрки-татар сүзе, монголча "нокай" – эт мәгънәсендә + би. Алар мәҗүси инануларга, йолаларга нигезләнеп ясалганнар.Болгар дәүләтенең Урта Азия, Иран һәм башка Көнчыгыш илләре белән борынгы заманнардан ук башланган сәүдә һәм культура багланышлары аркылы болгар-татар теленә, ә соңыннан исә, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында байтак кына фарсы сүзләре һәм кеше исемнәре килеп кергән. Бу чорда антропонимиягә башка төрки халыкларның йогынтысы зур булуы күзәтелә. Н.Исәнбәт үзенең әсәрләренә кеше исемнәрен чорлар белән бәйләп сайлаган.Бу чорларны чагылдырган драма әсәрләрендә кеше исемнәре борынгы төрки-татар, гарәби чыгышлы. Автор хәтта кеше исемнәрен сайлаганда аларны холыкларына, килеш-килбәтләренә туры китергән.

Революциягә кадәрле татар крестьяныының фаҗигале язмышын чагылдырган "Миркәй белән Айсылу" әсәрендә вакыйга 1891 нче елда, хәзерге Татарстан җирендәбара. **Шәйхетдин** – гарәп сүзе, дин карты; **Гыйният** – гарәп сүзе, кайгыртучанлык, бушлык; **Әһли** – гарәп сүзе, өйдәге; туган илнеке, халыкныкы, милләтнеке.

Хезмәт иясенең сыйнфый азатлык максатындагы хәлиткеч көрәшен чагылдырган "Мулланур Вахитов" әсәрендә вакыйга 1918 нче елда Казан шәһәрендә бара. **Мулланур** – гарәп сүзе, мулла + нур; **Нәби** – гарәп сүзе, пәйгамбәр илче; **Габделбәр** – гарәп сүзе, Аллаһының колы**. Бу әсәрләрдәге** исемнәр ислам дине һәм шәригать кануннары йогынтысында ясалганнар. Совет

дәүләтенең беренче елларындагы вакыйгаларны чагылдырган “Портфель” драмасындагы кеше исемнәрендә исә, **Хизбулла** – гарәп сүзе, аллаһ тарафдары; **Хәсбиулла** – гарәп сүзе, аллаһының затлы бәндәсе; **Миргаян** – фарсы-гарәп сүзе, мир (фарсы) әмир +гаян (гарәп) билгеле, танылган. Драмадагы исемнәр гарәби чыгышлы. Кайбер исемнәрнең составында дин (инану, ышану) сүзе дә очрый. Бу ислам динен зурлау, аңа инану, табынуны аңлата. Бөек Ватан сугышындагы тиңдәшсез рухи ныклыкны, батырлыкларны чагылдырган ”Мәрди белән Нәфисә”һәм “Муса Җәлил” драмаларындагы кеше исемнәренең ясалышындагы үзенчәлекләр түбәндәгеләр: **Мәрди** - фарсы сүзе, батырлык, кыюлык, ирлек, егетлек, зыялылык; **Нәфисә** – гарәп сүзе, нәфис, күркәм ,чибәр, кыйммәтле; **Муса** – гарәпчә-яһүдчә, борынгы яһүд телендәге мешу (бала) сүзеннән. Күргәнебезчә,исемнәрнең мәгънәсенә ныклык, батырлык салынган,арасында дин белән бәйләнешләре дә бар. *Безнең көннәрдәге чынбарлыкны* чагылдырган “Зифа”комедиясендәге кеше исемнәре: **Зифа** – фарсы сүзе, чибәр, сылу; **Кәләмзә** – гарәп-фарсы сүзе, сүзендә торучы; **Гөлли** – фарсы-татар сүзе, гөлле, гөлдән гыйбарәт. Безнең көннәрдә язылган драмалардагы исемнәр дин, Аллаһы белән бәйле түгел. Бу исемнәр матурлык, туган ил, Ватан белән бәйле.Чорлар алмашынган саен кеше исемнәренең ясалыш-төзелеш үзенчәлекләре дә үзгәреш кичергән. Алар катлауланганнан катлаулана барган. Түбәндәге исемнәрнең килеп чыгышын, ясалышын караганнан соң мондый нәтиҗәләр ясарга мөмкин. Татар антропонимикасында меңнән артык ел дәвамында (Х гасырдан башлап) саф төрки-татар компонентлары белән гарәп, фарсы һәм башка төрки халыкларның телләреннән алынган исем компонентларының үзара кушылуы нәтиҗәсендә байтак кына катнаш төзелешле исемнәр барлыкка килгән һәм алар берничә катлам тудырган. Татар антропонимикасының катнаш катламнарын барлыкка китергән исемнәр түбәндәге калыплар буенча ясалганнар:

1) төрки-татар исем компоненты+фарсы исем компоненты: **Айдар;**

2) төрки-татар исем компоненты+гарәп исем компоненты**: Миңҗама**л һ.б.;

3) гарәп исем компоненты+фарсы исем компоненты: **Кәләмзә, Алиш;**

4) фарсы исем компоненты+төрки-татар исем компоненты: **Гөлли, Җанбай;**

5) төрки исем компоненты+фарсы исем компоненты+татар исем компоненты: **Илдархан**;

6) фарсы исем компоненты+гарәп исем компоненты: **Миргаян**;

7 )гарәп исем компоненты+гарәп исем компоненты: **Камәретдин**, **Шәйхетдин**;

8) монгол исемкомпоненты+төрки-татарисем компоненты: **Нугайби**;

9) борынгы яһүдчә исем компонент+гарәп исем компоненты: **Ибраһим, Муса;**

10) гарәп исем компоненты+яһүд исем компоненты: **Муса**;

11) гарәп и м компоненты+грекисемкомпоненты: **Алмаз**;

12)гарәп исем компоненты+төрки-татар исем компоненты: **Мөхәммәтхан**. Кеше исемнәрен ясалышы ягыннан төркемнәргә була.

1) тамыр исемнәр: Әҗем; Хәтми; Мәрди; Нәфисә; Идегәй.

2) кушма исемнәр: Миргаян; Камәретдин; Котлыкыя, Миңҗамал.

3) тезмә исемнәр: Җирән чичән; Карачәч сылу; Янгура би.

4)ясалма исемнәр: Илстан, Гөлли, Миркәй.Димәк, ислам дине, гарәп-фарсы культурасы һәм әдәбияты йогынтысында татар антропонимикасына кергән кеше исемнәре үзгәреш кичергәннәр һәм әлеге исемнәр Н.Исәнбәт әсәрләрендә дә чагылыш тапканнар.

Әдәбият


Исәнбәт Н.С. Сайланма әсәрләр. – Казан: “Хәтер” нәшр., 2007.

Исәнбәт Н.С. Әсәрләр. III том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

Исәнбәт Н.С. Әсәрләр. II том. Казан: –Татар. кит. нәшр., 1988.

Саттаров Г.Ф. Татар антропонимикасы. – Казан: Казан уни-ты. нәшр., 1990. – 278 б.

Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре ни сөйли? – Казан: Раннур, 1998. – 487 б.


## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕ, ТРАДИЦИЯЛӘРЕ


*Нуриева Резедә,*

*Әлмәт районы Яңа Кәшер урта мәктәбенең Х сыйныф укучысы*

*Фәнни җитәкче: Валеева Гөлнара Габделәхәт кызы*


Җир йөзендә 4 мең төрле халык яши. Аларның һәрберсендә үз теле, үз гореф-гадәтләре һәм бәйрәмнәре бар. Алар һәрберсе үзенең милләтен саклап калырга, аны алга таба алып барырга, үстерергә телиләр. Татар халкында бу темага бик яхшы бер әйтем бар: “Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк”. Чыннан да, тарихын, традицияләрен белмәгән халыкның вакытлар узу белән югалуы бик мөмкин.

Татар халкы гореф-гадәтләргә, йолаларга, уеннарга, җыр-биюләргә бик бай. Ул бик күп гасырлар үзенең пөхтәлеге белән, искиткеч матур йолалары белән бик күпләрне сокландырган. Уку-язу эшләрендә бик зур уңышларга күп вакытлар ирешә алмасалар да, үз бәйрәмнәрен онытмаганнар, һәрвакыт аларны үткәргәннәр, хөрмәт иткәннәр.

Безнең халыкны изү элек-электән үк булган, телне бетерү, халкыбызны тамырдан үзгәртү гамәлләре еш эшләнгән. Бүгенге көндә дә мондый проблемалар бар һәм безнең максатыбыз – аларны хәл итү, мондый гамәлләргә юк куймау. Әйе, алдап булмый, безнең чор яшьләре гореф-гадәтләргә артык игътибар итмиләр. Аларның хәтта онытылып бару куркынычын да күзәтәбез. Ләкин бу проблемага бармак аша гына карарга ярамый. Бу бик җитди сорау. Яшь буынга моны ничек аңлатырга соң? Милләтебезнең киләчеге нәкъ менә безнең кулда бит.

Күп кенә әдипләребез, язучыларыбыз, шагыйрьләребез бу сорауга бик җитди караганнар. Бу темага багышлап бик күп әсәрләр иҗат иткәннәр.

Кайберләре хәтта бар гомерләрен халкыбыз өчен кайгырып, аның бүгенгесе һәм киләчәге өчен көрәшеп яшәгәннәр. Гаяз Ихакый, Фатих Әмирхан кебек шәхесләр татар халкының язмышын – үз язмышлары итеп кабул иткәннәр. Аларның әсәрләре белем, тел, гореф-гадәтләр, әхлак темаларын ачыклап язылган. Бүгенге көндә яшьләргә нәкъ менә аларның әсәрләрен укып өйрәнергә кирәк.

Мәсәлән, Гаяз Исхакый әсәрләрен генә карап китик. Безгә калса, аны белмәгән кеше юктыр, мөгаен. Татар әдәбиятының күген яктыртып торучы йолдызларның берсе дип тә әйтеп булыр иде аны. Ул халкыбызның киләчәге өчен бик нык кайгырган, аның мөстәкыйль булуы турында хыялланган. Аның “200 елдан соң инкыйраз”, “Сөннәтче бабай”, “Җәберләнгән Зөләйха фаҗигасы” кебек әсәрләр моны бик яхшы күрсәтәләр.

“Сөннәтче бабай” әсәре нәкъ менә безнең халкыбыз йоласын, аның матур гадәтләрен сурәтләп язылган. Автор үз героен искиткеч матур алымнар белән, яратып сурәтли. Бу әсәрдә, исеменнән күренгәнчә, татар халкының йолаларының берсе – сөннәт йоласы сурәтләнә. Мөселманнарда ир баланы сөннәткә утырту йоласы – хуплана торган гамәл. Сөннәт – мөселманлык билгесе, шул ук вакытта ул пакълек, чисталык өчен дә бик әһәмиятле.

Билгеле, теләсә кем сөннәтче була алмый, ләкин әсәрдәге героебыз, әйтерсең, бу һөнәр өчен туган. Ул үз эшен бик ярата, халык та аны хөрмәт итә.

Бу әсәрдә татар халкының искиткеч матур бер сыйфаты – аның кунакчыллыгы да сурәтләнә: “...Гөлйөзем әби мичендә пәрәмәчләр, коймаклар кызу-кызу чатырдый башлый иде. Гөлйөзем әби самавырны өченче мәртәбә яңартырга теләгәндә, хәзрәт тә, остазбикә дә разый булмадылар...”. “Аш әзерли алмадым инде, бераз шурпа бар, шуны ашап китеңез инде,-дия. Ул бетәргә өлгерми, каз аягы-бүтәкәсеннән пешкән бәлеш куела иде. Сөннәтче бабай да сосла күтәреп керә. Шуннан соң өстәлгә пешкән үрдәк чыга” юллары моны укучыга дөрес күрсәтәләр.

Без игътибарны сөннәт йоласына гына түгел, ә гомумән алганда барлык гореф-гадәтләргә юнәлтер идек. Әйе, Гаяз Исхакый бу йоланы бик матур итеп сурәтләгән, ләкин сүз бит аның турында гына бармый. Атаклы язучыбыз бу проблеманы гомумиләштереп күтәреп чыга, ә сөннәт ул бер мисал гына. Ул бу әсәре белән укучыга татар халкының йолаларына хөрмәт уята.

Яшьләрне менә шундый әсәрләр белән тәрбияләү зарур. Яшь буын бу эшнең кирәклеген үзе аңларга тиеш. Халкыбызның гореф-гадәтләре, кагыйдәләре, җыр-биюләре, иҗат җимешләре балага ана сөте белән күчә дип тә әйтелә, ләкин бу гына җитеп бетми. Балага бу белемнәр әсәрләр, җырлар һәм биюләр аша керә. Кеше рухи яктан үсешне үзе өчен бик кирәк гамәл итеп күрергә тиеш. “Сөннәтче бабай” безгә аңлашырлык итеп, гап-гади тел белән, ләкин шул ук вакытта искиткеч бай итеп язылган әсәр. Халкыбызның йоласын шулай матур итеп беренче язган кеше булып, нәкъ менә Гаяз Исхакый тора.

Димәк, бу әдипләр инде ул вакытта ук киләчәк турында уйлаганнар. Алар халкыбызның юкка чыгуыннан курыкканнар. Нәкъ менә шушы әсәрләр безнең

киләчәгебезне коткарып калучылар. Яшь буын әле мөхтәрәм язучыларыбыз язган әсәрләрдәге гореф-гадәтләр, традицияләр белән генә чикләнмичә, үзебездән дә өлеш кертергә тиешбез. Чөнки халык үзенең гореф-гадәтләрен, традицияләрен саклаганда гына яшәвен дәвам итәчәк, хәзерге яшь буынга үрнәк булачак. Әйдәгез, халкыбыз данын яклыйк һәм саклыйк!

Әдәбият

Исхакый Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Тарих. – 2002.

Әдәбият (XX гасыр башы һәм 20 нче еллар татар әдәбияты). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.

## ХӘЗЕРГЕ ПРОЗАДА КОМПОНЕНТЫНДА “КҮЗ” ЛЕКСЕМАСЫ БУЛГАН ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

*Петрова Вероника,*
*Мөслим районы Тат.Шуран мәктәбенең IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Шаева Венера Мнахир кызы*

Татар теле – фразеологик әйтелмәләргә бай тел. Анда язма китап һәм сөйләү теленә хас әйтелмәләр, идиомалар һәм сәнгатьчә яңгырашка ия булган күчерелмә һәм туры мәгънәдәге тотрыклы сүз тезмәләре, кереш-модаль сүзләр функциясендә йөри торган тезмәләр, кайбер эмоциональ әйтемнәр төп урынны ала.

Язучы, әдәби әсәр иҗат иткәндә, телнең барлык чараларыннан, сүзлегеннән һәм грамматик формаларыннан мөмкин кадәр тулырак файдаланырга тырыша. Чөнки, билгеле булганча, фикер һәм идеяләр сүзләрдә, әйтелмәләрдә, грамматик формаларда гына үзенең реаль чагылышын таба.

Соңгы елларда тел белеменең фразеология өлкәсендә тикшеренүләр артты. Аларның күбесе чагыштырма характерда. Татар тел белемендә компоненты “күз” лексемасы бик нык өйрәнелмәгән. Шуңа күрә дә хәзерге проза әсәрләреннән алынган компоненты “күз” лексемасы булган фразеологизмнарны анализлауны күздә тотып, Н.Фәттахның “Ител суы ака торур”, М.Хәбибуллинның “Кубрат хан”, Галиуллинның “Сәет Сакманов” романнарына мөрәҗәгать иттек. Барлыгы 200гә якын фразеологик берәмлек җыйнап алынды һәм тикшерелде.

Без Н.Фәттахның “Ител суы ака торур”, М.Хәбибуллинның “Кубрат хан”, Т.Галиуллинның “Сәет Сакманов” әсәрләрендә “күз” лексемасы булган фразеологизмнарның кулланылу үзенчәлекләрен тикшердек, аларны төркемнәргә бүлеп карадык, фразеологик берәмлекләрнең структур-семантик төзелешен билгеләдек.

Фразеологик әйтелмәләрнең стилистик функцияләрен, кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнү бик зур әһәмияткә ия: нәтиҗәдә теге яки бу язучының

иҗат даирәсенә үтеп керергә, аның җанлы образлар, күренешләр тудыруда телнең нәфис чараларыннан файдалану осталыгын аңларга мөмкинлекләр туа.

Фразеологик берәмлекләр, сәнгатьчә һәм эмоциональ чара буларак, фикерне ачык, төгәл, шул ук вакытта образлы итеп бирүгә, сөйләмнең югары яңгырашлы булуына ярдәм итәләр. Фразеологизмнарда халыкның тормыш тәҗрибәсе, фикер йөртүе, милли үзенчәлекләре чагылыш таба. Язучылар үзләренең әсәрләрендә фразеологизмнарны киң кулланганнар. Аларның һәрберсе образларны, вакыйгаларны, күренешләрне сәнгатьчә төгәл һәм яңгырашлы итеп сурәтләүгә мөмкинлек бирә.

Романнардан җыйнап алынган компоненты “күз” лексемасы булган фразеологик берәмлекләрне тикшергәннән соң, без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. Фразеологизмнар – бердәмлеге, таркалмавы, компонентлары арасында мәҗбүри бәйләнеш булуы, бөтенлеге, сөйләмгә әзер килеш килеп керүләре белән аерылып торган тотрыклы сүз тезмәләре. Фразеологизмнарны, сүзләрне өйрәнгән кебек үк, өйрәнәләр, чөнки алар да, телнең үзенчәлекле атау берәмлекләре буларак, төшенчәләрне белдерәләр.

2. Романнарда кулланылган компоненты “күз” лексемасы булган фразеологизмнарның күбесе кешенең эчке психологик халәтен белдерәләр, кешегә характерлы сыйфатларны билгелиләр. Язучылар аларны геройларга характерлы сыйфатларны ачу, әдәби образны тулыландыру өчен кулланалар. Бу фразеологизмнарны тематик яктан без берничә төркемгә берләштердек:

1. Борчылу, дулкынлану, күңелсезләнү, сагышны белдерүче фразеологизмнар: *күзеннән йокы качу, күзләренә кайгы уртаклашу төсмере чыгару, күзләре генә сүнеп калу һ.б.* 2. Ачу, ярсуны белдерүче фразеологизмнар: *күзләре әйләнеп чыга язу, күзе акаеп чыгу, күзенә ак-кара күренмәү, күзләре уттай яну, күзләрен кан басу, күз буу, күзендә усал ут кабыну, күз аллары томалану, күзләренә иңгән явыз шатлык* һ.б. 3. Шатлык, куаныч, сөенеч, яхшы кәефне белдерүче фразеологизмнар: *күзен томалау, күзләре яна башлау, күз кыскандай тоелу, эчкә баткан күзләре уянып, җанланып, кучәрдән чыгардай булып балкый,* 4. Курку, хәвефләнүне белдерүче фреазеологизмнар: *күзе-башы акаю, күз аллары әлҗе-мелҗе килү, күзләрен читкә алу, күзгә йокы кермәү. күз уңыннан бер генә мизгелгә дә ычкындырмый, күзгә йокы кермәү, күз карашыннан өркеп, куркып тору.* 5. Икеләнү, шикләнүне белдерүче фреазеологизмнар: *күзләрен читкә алдылар, күз алдында тотасың, күзгә чалынып йөрергә яратмый, күзләреннән сизелеп тора, күзләрен әрле-бирле йөгертү.* 6. Гаҗәпләнү, кәеф китү, аптырауны белдерүче фреазеологизмнар: *үз күзләренә үзе ышанмыйча авыз ачып калды, күзләре маңгаена менде, күзен-кашын җимерде, күзләре дүрт булды, күзен ала алмый тик тора* 7. Кызыксынуны белдерүче фреазеологизмнар: *күзендә очкын уйнау, күз салу, күз карашларында кызыксыну билгесе күренү.*

8. Кешегә хас характерлы сыйфатларны белдерүче фразеологизмнар: 1) уңай сыйфатлар: *үткен күзле (җитез, елгыр), саф күзле (акыллы, алдан*

*күрәчән), күзне кыздырырлык, иркә күзле, йөгерек күзле, тәҗрибәле күзле; тискәре сыйфатлар: ач күз, ачудан көйрәп янган күзләр, төссез күзләр, күзе белән ашардай булып текәлү, күзендә усал ут кабыну.*

Язучылар тарафыннан ике, өч һәм аннан да күбрәк компонентлы фразеологизмнар кулланылган. Мәсәлән: ике компонентлы фразеологизмнар: *күз күреме, күз күрү, кузен алмау, күз чыгу, күзе юк, күздән кичерү, уткен күзле* һ.б. Өч компонентлы фразеологизмнар: *күзгә күренмәгән чирен, күзе - башы акайган, күз ачып йомганчы, күзләрен кан басу, күз явын алу, күзләре дүрт булу* һ.б. Дүрт компонентлы фразеологизмнар: *күз ачып йомган арада, күз алдыннан китеп тормау, күз аллары әлҗе-мелҗе килү* һ.б.

Фразеологизмнарны телнең җәүһәрләре дип йөртәләр. Алар телнең милли колоритын, үзенчәлеген билгелиләр. Шуңа күрә дә иҗат кешеләре үзләренең әсәрләрен фразеологик әйтелмәләр белән баеталар.

Әдәбият


Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

Әхмәтьянов Татар теленең кыскача этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 227 б.

Галиуллин Т.Н. Сәет Сакманов. Роман-трилогия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 656 б.

Заһидуллина Д.Ф. Ибраһимов М.И. Әдәби әсәр өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз. – Казан: Мәгариф, 2007. – 112 б.

Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 2005. – 848 б.

Фәттахов Н.С. Ител суы ака торур: Тарихи роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 398 б.

Хабибуллин М. Кубрат-хан. – Казань: Рухият, 2002. – 616 с.


## МӘКТӘПТӘ КУШМА ҖӨМЛӘНЕ УКЫТУ АЛЫМНАРЫ


*Ризванова Гөлнур,*

*КФУ ның Алабуга институты студенты*

*Фәнни җитәкче: Камаева Рима Биҗан кызы*


Сөйләм үстерүнең әһәмиятле бүлеге – укучыны җөмлә төзи белергә өйрәтү. Сөйләм ул гаҗәеп катлаулы күренеш, аны гомумән берьюлы өйрәнү мөмкин түгел. Шуңа күрә иң элек җөмлә төзелешен өйрәнәләр. Ә аннан соң җөмләләрнең сөйләмгә оешуы тикшерелә.Мөстәкыйль булмаган җөмләләр, үзара оешып, бер синтаксик бөтен – кушма җөмлә хасил итәләр [Саттаров 2000: 255].

Кушма җөмлә синтаксисы хәзерге татар әдәби телендә тирән тикшерелгән. Шулай да әлеге темалар укучыларга җиңел бирелми. Кушма җөмләләрне һәм катлаулы төзелмәләрне өйрәткәндә теоретик диктантлар яздыру, төрле сорауларга җавап табу, кроссвордлар чишү, тест сорауларына җавап бирү, матур әдәбият үрнәкләреннән мисаллар табу нәтиҗә бирә. Шундый күнегүләр бирергә була:

1. Кушма җөмләләр кулланып, “Китап-җан азыгы” дигән хикәя языгыз.
2. Схемалар буенча җөмләләр төзеп языгыз, кушма җөмләләрнең төрләрен һәм бәйләүче чараларын әйтегез.
3. Әдәби әсәрләрдән мәгънә ягыннан төрле иярчен җөмләләре булган 4-5 кушма җөмлә табып языгыз.
4. Текстны укыгыз. Аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне генә язып алыгыз.
5. Бирелгән җөмләләрдән иярченле кушма һәм тезмә кушма җөмләләр төзеп языгыз. Бәйләүче чараларның астына сызыгыз, иярчен җөмләләрнең төрен күрсәтегез.

*Мәсәлән*: Яңгыр явып үтте. Көн матурланды.

*Үрнәк:* Яңгыр явып үтте, һәм көн матурланды (тезмә кушма җөмлә). – Яңгыр явып үткәч, көн матурланды (иярчен вакыт җөмлә). – Яңгыр явып үткәнлектән, көн матурланды (иярчен сәбәп җөмлә). – Яңгыр явып үтсә, көн матурланыр иде (иярчен шарт җөмлә). – Яңгыр явып үтсә дә, көн матурланмады (иярчен кире җөмлә).

Кушма җөмләләрнең грамматик һәм функциональ төрләрен аеру буенча биремнәр башкару укучының сөйләмен баетырга мөмкинлек бирә, язма эшләрне башкарганда, фикер эзлеклелегенә ирешүдә ярдәм итә.[Саттаров 2000: 256]

Тезмә кушма җөмләләрне өйрәнгәндә презентация, плакат-таблицага мөрәҗәгать итү уңай нәтиҗә бирер. Укытучы иң башта үзе тезмә кушма җөмләнең билгеләмәсен әйтә, аның теркәгечле һәм теркәгечсез төрләргә бүленүен аңлата. Аннары дәфтәрләргә җөмлә яздырып, тезмә кушма җөмләне схемалап анализлау юлы өйрәтелә. Шуннан соң тактадагы таблица буенча (таблицаны экранга да куярга мөмкин) әңгәмә юлы белән теркәгечле тезмә кушма җөмләләрнең, тезүче теркәгечләрне төренә карап, өч төрле булуы ачыклана.

Белемнәрне ныгыту максатыннан төрле күнегүләр эшләнергә мөмкин. Мәсәлән: а) схема буенча җөмләләр төзү; ә) җөмләнең схемасын төзү; б) җөмләләрнең бәйләүче чараларын күрсәтеп, төрләрен билгеләү; в) синтаксик анализ ясау һ.б. Дәрестә әхлак сыйфатлары тәрбияли торган мәкальләр, әдәби әсәрләрдән җөмләләр файдаланылса, дәрес тагын да уңышлырак булыр.

Иярчен җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау дәресләрендә төрле күнегүләр ярдәмендә теоретик материалны искә төшерү, кабатлау, ныгыту,

гомумиләштерү эшләре башкарыла. Шул дәресләрнең кайбер күнегүләренә тукталып үтәбез:

1. Серле тартма. Укучыларның игътибарын сырлап ясалган, милли бизәкләр төшерелгән “серле” тартмага юнәлдерәбез. Тартмачыкның сере табышмакта. Башы булса, мие юк, биле булса, бавы юк, гәүдәсе булса, эче юк. (Җавап: читек. Тартмачыктан читек рәсеме алып күрсәтелә). Каюлы читек – татар халкының милли киеме. (Укучылар тугандаш халыкларның да милли киемнәрен атыйлар). Аннан соң табышмак дәфтәрләргә языла, кушма җөмлә анализлана.2. “Килешәсеңме?” Бер ягында “әйе”, икенче ягында “юк” дип язылган сигнал карточкалары белән эш.

Сораулар: а) Ике гади җөмләне чөнки теркәгече бәйли, шуңа күрә бу җөмлә синтетик иярченле кушма җөмлә була (“юк”); б) бәйләүче чара көттерү паузасы булганда, ике җөмлә арасына ике нокта куела (“әйе”) һ.б.

3. “Бишек җыры”. Бишек җырлары искә төшерелә. Бер җырдан өзек бирелә:

Гомерең булса, зуррак үссәң,
Күп укырсың, бәбкәем,
Сабагыңны матур белсәң,
Бик яратыр әткәең.

3,4 юллар дәфтәрләргә языла, җөмләнең схемасы төзелә: (...сәң), [ ].

4. “Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел”. Ш. Маннур сүзләренең мәгънә асылына төшенү.

Тәрҗемә өчен сүзлек диктанты яздырыла.

Художник, врач, семья, пол, лестница, пруд (рәссам, табиб, гаилә, идән, баскыч, буа). Бирем. Бирелгән сүзләрне кулланып, иярченле кушма җөмләләр төзергә.

Кушма җөмлә синтаксисын гомумиләштереп кабатлау дәресен интеграль (информатика һәм татар теле) дәрес итеп үткәрергә мөмкин. Дәрес укытучының кереш сүзе белән башлана. Аннары диктант яздырыла.

Диктанттагы җөмләләрне анализлаганчы, кайбер кагыйдәләр искә төшерелә. Бу эш сорауларга сорау-җавап формасында үткәрелә. Җөмләләрне анализлау барышында, русчага тәрҗемә итеп, кушма җөмләләрнең ике телдә охшаш якларын, аермалыкларын күзәтү уңышлы булыр. Дәрес ахырында компьютер буенча тест эшләнелә.

Бирелгән тема буенча алган белемнәрне гомумиләштереп кабатлау эшен дәресләрнең актив формаларыннан файдаланып оештыру, заманча технологияләр куллану уңай нәтиҗәләр бирә.

## Әдәбият

Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан: Раннур, 2000. – 455 б.

Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик алым-нар. – Алабуга: АДПУ нәшрияты, 2009. – 106 б.

# БИШЕК ҖЫРЫ ҖЫРЛАНСЫН...

*Сабирова Лилия,*
*Алабуга шәһәре 2 нче урта мәктәбенең IX A сыйныфы укучысы*
*Фәнни җитәкчеләр: Сәхәбиева Альбина Мансур кызы,*
*Әхмәтшина Айгөл Фәүкат кызы*

Җырлар... Җир шарында аларның саны санап бетергесез. Ул мөмкин эш тә түгелдер. Әмма һәр халык – аз санлысы да, күп санлысы да – үз җырларын иҗат итә. Халык ижаты әсәрләренең байтагы югары сәнгать әсәре үрнәге булып тора. Бишек җырлары белем һәм тәрбия бирүдә аеруча зур әһәмияткә ия. Әлеге әсәрләр моннан берничә гасыр элек ук барлыкка килгән. Аларның эчтәлеге еллар үткән саен камилләшә барган. Бишек җырларына мәшһүр татар классиклары Дәрдмәнд (Закир Рәмиев), Н. Думави (Нәҗип Тахтамышев), Габдулла Тукай, Муса Жәлил һ.б. мөрәҗәгать иткән. Хәзерге чор әдипләре ижатында да бу җырлар киң чагылыш таба.

Бишек җырларында нәрсә турында җырлана соң? Гадәттә, аларда баланың, бәхетле, гыйлемле кеше булуын теләү чагылдырыла. Бишек җыры - ананың үзенчәлекле догасы ул. Бу уңайдан Г. Тукай иҗат иткән «Бишек җыры»н искә төшереп үтик:

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу.
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып китәр бу [Татар халык иҗаты 2003: 97].

Татар халкының «Бишек янында» дигән җырында да анабаланың аңлы, белемле булып үсүен тели.

«Кызыма» дигән бишек җырында Муса Жәлил үзенең кызын – Чулпанны Таң йолдызына тиңли һәм кызына:

«Таң йолдызым...
Йөрәгемдә кабынган
Шатлык җырым син минем», – дип мөрәҗәгать итә [Татар халык иҗаты 2003: 98].

Бишек җырлары баланы тынычландыру, юату, тирбәтеп йоклату өчен хезмәт итәләр. Өлкәннәр юлда алып барганда, тирбәткәндә баланың тизрәк йоклап китүен беләләр. Ана куңеле бала тирбәткәндә салмак кына яңгырый торган, матур сүзле җырлар җырларга кирәклеген тоя. Һәм сабыйлар

әниләренең тыныч, салмак тавышына изрәп йоклап киткәннәр.

Бишек җырлары, баланы тирбәтеп тынычландырудан тыш, белем һәм тәрбия бирү көченә ия. Алар сабыйның тыныч холыклы булып үсүенә ярдәм итә. Шуны да онытмаска кирәк: бала әнисенең җырын тыңлап, аңа кушылып җырларга, үсә төшкәч, җыр сүзләрен кабатларга тели. Шулай итеп, бишек җырлары аша, сабый туган телендә сүзләрне әйтергә, тирә-якны танып белергә, фикерләү сәләтен, сөйләмен үстерергә өйрәнә, үзе дә сүзләрне әйтергә омтыла. Бишек җырларының тагын бер гаҗәеп үзенчәлеге бар: алар баланы ничек яшәргә, кешеләргә ихтирамлы, мәрхәмәтле булырга, ата-ананы, туганнарны хөрмәт итәргә һәм башка күркәм сыйфатларга ия булырга өйрәтәләр. Менә ананың үзенең сабыена тели торган шул сүзләре:

Имәндәй нык бул,
Чыршыдай биек бул
Каендай ак бул,
Чишмәдәй саф бул [Татар халык җырлары 2001:83].

Күренгәнчә, әлеге бишек җырының беренче юлларында ук ана үзенең баласының сәламәт, әхлакый саф булып үсүен тели. Аннары ул җырны болай дип дәвам итә:

Ата-аналы бул,
Алтын канатлы бул,
Бай дәүләтле бул... [Татар халык җырлары 2001:83].

Тормыш итү өчен кирәкле әйберләр булдырып, кайгы-хәсрәт күрмичә, әти-әниең белән бергә яшәргә язсын. – Бу юлларның төп мәгънәсе шул.

Бабайны күрсәң, «бабай»,— дип әйт,
Әбине күрсәң, «әби», - дип әйт,
Өлкәнне күрсәң, «абый», «апа», – дип әйт,
Кечене күрсәң, «сеңлем», «энем», – дип әйт.
Кечене кече ит, олыны олы ит.
Тәмле, татлы телле бул,
Ата-анаңа игътибарлы бул...[Татар халык җырлары 2001:85].

Димәк, әнисенең иң изге теләкләрен тыңлап, бала тирә-юньдәге кешеләргә ихтирамлы, игътибарлы булырга өйрәнә, үзендә әхлакый кагыйдәләр булдыра. Шулай итеп, бишек җырлары – бишектәге баланы тәрбияләү өчен иң мөһим чара.

Әдәбият

Кемдә моң бар, кемдә хис бар: Татар халык җырлары. – Казан: Мәгариф. – 2001. – 183 б.

Татар халык иҗаты: Энҗе чәчтем энҗе җыям. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 197 б.

## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КАБАТЛАНМАС БИЗӘКЛӘРЕ...

*Сәйфетдинова Алсу,*

*Кукмара 3нче урта мәктәбенең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Нәҗмиева Василә Госман кызы*

Кешелек дөньясы һәрвакыт матурлыкка омтылып яшәгән. Безнең борынгы балаларыбыз күңел матурлыгы белән берргәттән тирә-юндәге матурлыкка да бик зур игътибар биргән. Үзләренең нәфислеге, завыклыгы белән аерылып торган милли киемнәр тудырганнар, ювелир эшләнмәләр ясаганнар, төрле төсле мозаика күн аяк киемнәре теккәннәр, торакларының тәрәзә, капка, өй каршыларын төрле орнаментлар белән бизәкләп эшләгәннәр.

Милли орнаментлар белән бизәү мотивы бик борынгыдан ук килә, һәм ул, һаман камилләшә барып, теге яки бу формада хәзер дә кулланыла. Орнаментларның бүгенге көндәге роле – ул матурлык функциясе. Ә элек тә аларны матурлык өчен генә кулланганнармы, әллә нинди дә булса үзенчәлекле мотивы булганмы?

XV-XVI гасырларда ук инде татар өйләре үзләренең агачтан эшләнгән үзенчәлекле бизәкләре белән аерылып торган. Өйләр генә түгел, капка-коймалар да бизәкләп эшләнгән. Бизәкләп ромб, өчпочмак, түгәрәк, ярымтүгәрәк, ’’нурлар”, спираль мотивларында эшләнгән. Алар йорт хуҗаларының яшәешен чагылдыручы детальләр булганнар. Татар авылларын ерактан таныганнар. Алар матур йортлары, бизәкле тәрәзә йөзлекләре, өй кыеклары, капкалары белән аерылып торганнар. Башка халык вәкилләре моны ассызыклый. Мисал өчен, Иван Грозныйга хезмәт иткән рус князе А. М. Курбскийның Казан ханлыгы җирләре буенча сәяхәт кылгач язылган хатыннан бер өзек китереп үтик: “дворы княжат их и вельможей зело прекрасны и воистину удивлен по истории Казанского ханства” [Худяков 1990].

Торак йортларның агачтан кисеп эшләнгән орнаментлары - геометрик фигураларны, зооморф, соляр (кояштан тарала торган нурлар рәвешендәге) бизәкләрдән тора. Бизәкләрнең һәркайсы – кечкенә генә сәнгать әсәре. Аларның һәркайсында серлелек, һәркайсына үзенчәлекле мәгънә салынган, һәркайсы нәрсәнеңдер шартлы билгесе, символ буларак кулланылган:

- горизонталь, туры сызыклар белән - җир өслеген, дулкын белән суны билгеләгәннәр,

- түгәрәк, ярымтүгәрәк- кояш, айны,

- урталай бүленгән гранат җимешен сурәтләү уңдырышлылыкны, байлыкны белдерә һ.б.

Күргәнебезчә, бер генә бизәк тә юкка ясалмаган, һәрберсенең үзәгендә кешелек дөньясына, гаилә әгъзаларына яхшылык телүче мәгънә салынган.

Борынгы бизәкләр арасында киң таралганы кош сынына охшаган бизәкләр. Төрки бабаларыбызның кошларга мөнәсәбәте үзгә булган. Алар кошларны изге дип санаганнар, йорт һәм гаиләне саклаучы кош дип йөртелгән. [Потапов 1972 :265]. Кош рәсемен төшерү гасырлар дәвамында кабатланып, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән.

Борынгы бабаларыбыз кошларны бер-берсенә каратып урнаштырганнар. Шулай урнаштыру бердәмлекне символлаштырган. Бүген дә аны – татулык символы итеп кабул итәләр. Эзләнү барышында шуны да ачыкладык: 20 гасырның икенче яртысында ясалган кош бизәкләре арасында 100% якыны күгәрчен сурәте.

Еш кына татар авылларының тәрәзә йөзлекләре бизәлешендә каз башы рәсемнәрен дә очратырга мөмкин булган. Кайбер галимнәр фикеренчә, каз болгарлар культурасында, исламны кабул иткәнче үк (VIII–IX гасырларда), нәселне саклаучы символны аңлаткан. Хәзерге вакытта кош сурәтен гәүдәләндерүдә үткәннәр семантикасының кайтавазы да чагылуын билгеләп үтәргә кирәк.

Йорт хуҗасының горурлыгы – капка. Капканың ал такталары төрле чәчәкләр, чәчәк таҗы, кояш нурлары, геометрик фигуралар белән бизәлеп төрле төсләргә буялган.Һәр бизәк башта нинди дә булса сихерле мәгънәне аңлаткан. Мәсәлән, ишелгән бау, дулкын, нокталы сызыклар – чистарту көченә ия булган суны аңлаткан. Штрихлар я спираль – болыт я яңгырны, чәчәк таҗы кояш нурларын тасвирлаган. Ә кояш билгесе – нокталы түгәрәк- Тәңрене аңлаткан.

Агачтан ясалган тәрәзә, капка бизәкләренең һәркайсы – кабатланмас могҗиза, яшерен сер. Шуңа күрә без аны өйрәнеп, саклап калырга тиеш. Шушында Петр Ибаевның ялкынлы сүзләрен китерәсем килә:

“Тарихыбызга кагылышлы бер генә әйберне, бер генә бизәкне дә онытырга һәм югалтырга хакыбыз юк безнең. Болар – безнең әби-бабаларыбызның үзләреннән соң килгән буыннарга, безгә генә түгел, балаларыбызга һәм балаларыбызның балаларына да мирас итеп калдырган байлыгы. Әгәр боларның берәрсен хәтердән җуйсак, моның өчен безне йөз, мең елдан соң да гафу итмәячәкләр”.

Әдәбият

Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство Татарстана. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – 104 с.

Валеева Д.К. Искусство волжских булгар (X–XIII вв.). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. – 132 с.

Мухаметзянова Л.Х. Татарский эпос. Книжные дастаны. – Казань: ИЯЛИ им.Ибрагимова АН РТ, 2014. – 380 с.

Потапов Л.П. Умай – божество древних тюрков в свете этнографических данных // Тюркологический сборник, 1972. – М.: Наука, 1973.

Халит Н. Х., Альменова-Халит Н. Н. Стили и формы средневековой архитектуры Казани: историко-архитектурное исследование. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. – 351 с.

Худяков М. Очерки по истории Казанского ханство, 1990.

## ЯШЬ БУЫННЫ ӘХЛАКЛЫ ИТЕП ТӘРБИЯЛӘҮДӘ Р.ФӘХРЕТДИН ХЕЗМӘТЛӘРЕ

*Сарварова Розалина,*

*Әлмәт шәһәре 21 нче урта мәктәбенең VIII сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчеләр: Аглюкова Әлфия Әнәс кызы*
*Гыйльметдинова Алсу Азат кызы*

Шәхесне камилләшү һәм үсүендә әхлак тәрбиясенең ролен педагогика элек-электән ук исбатлап, раслап килгән. Әхлак ул – кешенең эш-хәрәкәтләрендә, көндәлек тормышында билгеле бер калыпка салынган, билгеле бер кыйммәтләреннән торган сыйфат.

Сүзләрендә эшләрендә, һәртөрле хәл вә хәрәкәтләрендә дөрес эш иткән кешегә әхлаклы кеше диләр. Баланың тәрбиялелеген, әхлагын анын тәртибенә карап бәялиләр. Яхшыны-начардан, начардан-яхшыны аера белү тәҗрибәсе кешедә яшьтән үк тәрбияләнә. Бала чакта барлыкка килгән әхлак нормалары кешене олыгайган чорына кадәр озата бара.

Балаларыгызны яхшы тәрбия итегез, ислам холыклары берлә холыкландырып үстерегез. Иң башлап, балаларыгыз өчен үзегез яхшы үрнәк булыгыз! Һич вакытта ялкауланмагыз, бөтен эшләрегезне тырышып эшләгез! Коры сүз белен генә мавыкмагыз, эш кешесе булыгыз, балаларыгызга гыйлеһөнәр өйрәтегез! Әдәпле, инсафлы, диянәтле итеп устерергә тырышыгыз! Мөселманлыгыгызны эшлеклек берлә, сүздә һәм эштә тугрылык берлә курсәтегез! Гает вә җомга көннәрнең һәм башка бәйрәмнәрнең хөрмәтләрен яхшы саклагыз! Малыгызны исерткеч, отыш уены кебек хәрәм урыннарга әрәм итүдән сакланыгыз,балаларыгызны да шул юлда тәрбия итегез!

Дөнья-ахирәт бәхетле булырсыз [Фәхретдин 1993 :22].

Һәр ата-ана үз баласының бәхетле булуын тели. Тик баланы һәркем үзенчә ярата, үзенчә тәрбияли. Әхлак тәрбиясенә нигез гаиләдә салына. Матур гадәтләр яшьтән үк ныгысын өчен ата-анага зур көч, тырышлык куярга кирәк. Ә ата-ана – үз баласына беренче тәрбияче ул. Хәзерге укучылар элеккеге чор балаларыннан аерылып тора: иртә өлгерәләр, таләп һәм омтылышлары да җитдирәк. Шуңа күрә яшьләрнен әхлакый принциплары формалашуда гаилә тәрбиясенең роле зур.

Һәр кешедә, аеруча үсмер чакта, үзенә генә хас нечкәлек, эмоциональ сизгерлек була. Балалар кечкенәдән гаделлеккә, игелеккә омтылалар. Алар бу үрнәкләрне өлкәннәрдән күреп кабул итәләр. Кеше башкаларга нинди мөнәсәбәттә булса, үзенә дә шундый мөнәсәбәттә булырлар. Кешегә бәяне иң элек аның әхлагына карап бирәләр. Һәр жәмгыятьнең, халыкның, милләтнең үз әхлак нормалары була. “Өмет вә милләт гаиләдән җыела. Һәрбер гаилә үзен төзәтергә тырышса, вә дөрес юллар белен йөрергә күңел куйса, күңелле максатларга ирешерләр вә төзәлерләр. Гаиләләрнең төзәлүе милләт төзәлүедер”, – дигән татар мәгърифәтчесе Р.Фәхретдин. Ә “Нәсихәт” дигән китабында Риза Фәхретдин казый әдәплелек, әхлак, күркәмлек сыйфатларын тәрбияләү турында кисәтә: “Әдәпле кешеләрне Аллаһы Тәгалә сөяр, халык та сөяр, исеме үзеннән соңнарга калыр, бәхетле булыр” [Фәхретдин 1993:13].

Мәктәптә шәхес тәрбияләүдә, балаларга әхлак тәрбиясе бирүдә бүгенге көндә халык традицияләрен, гореф-гадәтләрен, татар халкының әхлакый кыйммәтләрен үз эченә алган Р.Фәхретдиннең “Балаларга үгет-нәсыйхәт” китабы укытучылар, тәрбиячеләр, ата-аналар өчен өстәл китабы булып торсын, ә балаларны әхлаклы кеше итеп тәрбияләү – безнең һәрберебезнең бурычы.

Әдәбият
Фәхретдин Р. Балаларга үгет-нәсыйхәт. – Казан: «Дом печати», 2001.
Фәхретдин Р. Дини вәгазь//Мирас, 1993. – № 12.

## ТАТАР ТЕЛЕ ҮСЕШЕНЕҢ ТАРИХЫ

*Сафина Аидә,*
*Алабуга районы Иске Юраш урта мәктәбенең XI сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Гайнетдинова Клара Фёдор кызы*

Кеше тормышында аның бөтен гомере буена аерылгысыз төшенчәләр, була. Мин шуларның берсе дип, туган телебезне саныйм. Ул кешенең дөньяга аваз салган минутыннан соңгы сулышына кадәр янәшәдә яши. Кеше дөньяга беренче аваз салуга, аны тудырган ана үзенең сабыена туган телендә “балам” дип эндәшә. Баланың беренче әйткән сүзе дә туган телендә яңгырый. Кеше үзенең иң саф хисләрен бары тик туган телендә генә белдерә ала.

Туган телебез татар теле-борынгы төрки телләрнең берсе.Ул мул сүзлек хәзинәсенә ия. Белгәнебезчә, татар теле – ЮНЕСКО тарафыннан бөтендөнья халыкара аралашу теле дип саналган ундүрт телнең берсе. Бу – туган телебез белән горурланырлык мөһим фактор. Мин язмамны туган телемнең тарихына багышладым.

Мең еллар элек Идел белән Кама кушылган җирдә болгар кабиләләре яшәгән. X гасырда болгар кабиләләре дәүләт булып оешкан. 922 нче елда болгарлар ислам динен кабул иткәннәр. Болгар иле ислам илләре белән ты- гыз бәйләнешләр урнаштырган. Болгарларның инде бу вакытта үз язулары да булган һәм фән, мәгариф, мәдәният тә нык үсеш алган.

1236 нчы елда монгол явы Болгар дәүләтен басып ала. Болгар дәүләте җимерелә һәм Алтын Урда төзелә. Алтын Урда таркалганнан соң, XV гасырда яңа дәүләт - Казан ханлыгы төзелә. Казан ханлыгы Бөек Болгарның дәвамы була. Биредә яшәүчеләрне Казан татарлары дип йөртә башлыйлар.. Казан шәһәрләрендә гыйлем йортлары күп булган һәм аларда укырга-язарга, матур итеп китап күчерергә өйрәткәннәр.

XVIII гасырда Казан шәһәре Казан губернасы үзәгенә әверелгән. Ул хуҗалык үсеше ягыннан Россиядә алдынгы урында торган.

1920 нче елда Татар автономияле республикасы төзелә.1921 нче елда татар теле беренче тапкыр дәүләт теле дип игълан ителә. XVI-XVIII гасырларда Россиянең Урта Азия һәм Көнчыгыш дәүләтләре белән эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруда татарлар тылмач буларак зур ярдәм күрсәткәннәр.Татар теле

башка төрки телләрне белү өчен ачкыч булган. Россиянең Һиндстан, Кытай, Иран һәм башка күп кенә илләр белән рәсми эш кәгазьләре татар телендә алып барылган. Шунлыктан Россиядәге башка төрки телләр арасында татар теленең дәрәҗәсе югарырак булган. Ә бу исә XVIII гасыр урталарында ук күп кенә уку йортларында татар телен укыта башлауга китергән.

Екатерина II боерыгы буенча, гимназиянең беренче татар теле укытучысы итеп Сәгыйть Хәлфин билгеләнә. Гимназиядә татар телен укыту тәҗрибәсенә нигезләнеп, ул әлифба яза. 1778 нче елда бу хезмәт Мәскәүдә басылып чыга. Татар басма әлифбасы ның тарихы шушы китаптан башлана.

1812 нче елдан Казан университетында татар теле укытыла башлый. Бу чорларда Сәгыйть Хәлфиннең ике томлы беренче "Русча-татарча сүзлеге" дөнья күрә.

Тагын бер мәртәбә тарихка күз салсак, кыска гына вакыт эчендә Казан җир белән тигезләнә диярлек. Татарлар башкалаларыннан, яшәү өчен уңайлы булган урыннарыннан сөреләләр. Гасырлар буе җыелган рухи байлыгыбыз бөтенләе белән диярлек юкка чыга. Бәлки башка бер халык шушы сынаулар аша үтә дә алмаган, инде күптән үлгән-беткән булыр иде. Ләкин татар үлемне дә, кайгыны да җиңәргә өйрәнгән.

Татарларны чукындырырга никадәр тырышмасыннар, ул чукынмаган, урыслаштырырга тырышсалар да – урыслашмаган.

Татарлар XIX һәм XX гасырларда үз мәгариф системаларын булдырып, Россиянең иң укымышлы халкына әвереләләр, 20дән артык газет-журнал, миллионлаган тираж белән китаплар чыгарып, аларны барлык төрки халыкларга да җиткерә алуга ирешәләр. Язучылар, шагыйрьләр үсеп чыга, театрлары барлыкка килә, музыкаль сәнгатьләре туып тора.

1920 елның 27 маенда Татарстан автономияле республикасын төзү турындагы декрет барлыкка килә. Татарлар республика төзүгә әзер булалар. Татарстан 67.126 квадрат километр мәйданда республика барлыкка килә. 43 район төзелә.

Республикада 2892 мең кеше булып та, аның 51,6 процентын татарлар, 40,4 процентын руслар, калганнарын чуашлар, марилар һәм башка халык вәкилләре тәшкил итә. Республикада төрле милләт вәкилләре дус тату яшиләр.

Ул гына да түгел, татар телебез гасырлар буеннан-буена башка илләргә дә таралып, үзенең үсешен тизләтә. Хәзерге заманда да ул киң таралыш алган. Татарлар Төркиядәдә, Америка Кушма Штатларында да, Канадада да, Австралиядә дә, Финляндиядә дә яши. Милләттәшләребез чит җирләрдә, чит төбәкләрдә яшәсәләр дә, үз телләрен алтын бөртегедәй саклап тоталар.

Рәсми чыганаклардан караганда, татар телендә 7 млн. кеше сөйләшә дип санала. Бу – без Россиядә сан ягыннан икенче урында торабыз дигән сүз.

Фикеремне үз туган ягыма, мәктәбемә төбисем килә. Бүгенге көндә мәктәбебездә укучыларның 20% ын башка милләт балалары алып тора. Шулай булуга карамастан, без дус, тату яшибез. Ул балалар татар телендә белем ала.Ә без аларга көчтән килгәнчә, ярдәм күрсәтәбез: үзебезнең гореф-гадәт,

йолаларыбыз белән таныштырабыз, хәтта, рус теле белән чагыштырып, телебезнең грамматикасын да өйрәтәбез. Димәк, теләк булганда, барлык проблемаларны да чишәргә була икән.

Туган тел туган җир кебек кадерле һәм газиз. Чөнки ул – кеше күңелендә иң нечкә мөкатдәс хисләр, иң күркәм сыйфатлар тәрбияләүнең иң куәтле чарасы. Ул әби-бабай, әткәй-әнкәй теле, дөньяга күзең ачылырга, әйләнә-тирәне танып белергә, чиксез матурлыкларны аңларга-тоярга ярдәм итә торган тел.Үз телеңне белмәү, аны санламау-ул кимчелек кенә түгел, зур мәрхүмлек тә. Шуны онытмыйк!

Без туган телебезне күз карасыдай сакларга, сүзләрне бозмыйча, саф татар телендә сөйләшергә тиешбез. Телебезне сакласак, халкыбыз да яшәр! Туган телебез безгә васыять булып буыннан-буынга тапшырылып килергә тиеш.

Әдәбият


Гараев Ф.М. Языковая политика на современном этапе // Татар теле һәм этносы тарихи мәсьәләләре. – Казан: ИЯЛИ, 2000.

Зәкиев М.З.Татар халкы теленең барлыкка килүе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977 .

Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни – методик нигезләре. – Казан: “Хәтер” нәшр., 2001. – Б. 15.

Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татар.кит. нәшер.,– 1987. – Б. 16.


## НӘЗИФӘ КӘРИМОВА ПРОЗАСЫНДА МАМАДЫШ РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛЫ ХАЛКЫНЫҢ ҖИРЛЕ СӨЙЛӘМ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ


*Сибгатуллина Лилия,*

*КФУның Алабуга институты студенты*

*Фәнни җитәкчесе: Галләмов Филүс Гатиф улы*


Нәзифә Харис кызы Кәримова 1947 елның 22 маенда Татарстанның Мамадыш районы Арташ авылында туган. Күрше авылда сигезьеллык мәктәпне тәмамлап, Алабуга культура-агарту училищесына укырга керә. Әдәби иҗат белән 1974 нче елдан бирле шөгыльләнә [Кәримова 2004]. Бүгенге көндә Нәзифә Кәримова “Җәнлекләр кайта” (1986), “Сагынасыңмы дип сорыйлар” (2004), “Карурманнан чыккан юлчылар” (2013), “Ак әрем чәчәге” (2013), “Йолдыз ява” (2017) исемле нәшер ителгән китаплар һәм дистәләгән повесть-хикәяләр, шигырьләр, җыр сүзләре авторы. Язучы - журналист Н.Кәримованың йөгерек, җор телле, тормышчан иҗатында туган якны сагыну, балачак хәтирәләре, үзенчәлекле шаянлык белән бергә халык авыз иҗатына хас тапкырлык, милләтебезгә хас булган башка асыл сыйфатларны күрергә мөмкин.

Н.Кәримованың иҗатында авыл кешеләренә мәхәббәт, үзенең туган ягын сагыш-моң аша эчкерсез ярату, тирә-яктагыларга игътибарлылык, авылдашларына хөрмәт (күпчелек авылдашлары аның әсәрләрендә үзләрен таныйлар) ярылып ята. Гаҗәеп матур Мамадыш төбәгенең җирле сөйләме кушылган бу әсәрләр гади авыл халкының чынбарлык көндәлек тормышын акыллы юмор аша, мавыктыргыч һәм гади итеп сурәтлиләр. Аның әсәрләре җиңел укыла, теләсә кайсы образ җанлы булып күз алдына килеп баса. Кайсы гына хикәясен, повестен алсак та андагы геройларның сүз байлыгы һәм сөйләм үзенчәлекләре игътибарга лаек.

Арташ авылы халкының тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре, кешеләренең эш-гамәлләре һәм хис-тойгыларын сурәтләгәндә язучы бик оста итеп җирле сөйләмне кулланып кына калмый, ә авыл тарихы өчен дә мөһим, әһәмиятле истәлекләргә туктала. Автор бик оста итеп Мамадыш төбәгенең рухын чагылдырган җирле сөйләш үзенчәлекләрен әсәрләренең тукымасына кертеп җибәргән. Алар нигездә персонажлар сөйләменә хас булалар һәм теге яки бу образның шәхси сыйфатларын – аның белем дәрәҗәсен, фикерләү үзенчәлеген, характерын күрсәтү өчен дә хезмәт итәләр. Җирле сөйләм үзенчәлекләрен җыйнап атау өчен диалектизм терминын кулланалар. Җәйге практика вакытында язучы-прозаик, журналист Нәзифә Харис кызы Каримованың үзе белән очрашу, аралашу мине аның иҗатындагы җирле сөйләмнең чагылышын тирәнрәк анализларга, өйрәнергә этәрде. Фәнни-тикшеренү эшебезнең темасын да “Нәзифә Кәримова прозасында Мамадыш районы халкының җирле сөйләм үзенчәлекләренең чагылышы” дип атадык.

I. Нәзифә Кәримованың хикәяләрендә, проза әсәрләрендә фонетик диалектизмнар һәм рус сүзләренең татар теленә җайлаштырып куллану очраклары:

Апирасия – операция

Бүлнис – больница (хастаханә)

Военный веремендә – в военное время (сугыш вакытында)

Лудыр – лодырь (ялкау, эшлексез)

Нимес шпионнары – немецкие шпионы (алман шпионнары)

Тәтә – тәти (ә-и тәңгәллеге) [4]

II. Нәзифә Кәримованың хикәяләрендә, проза әсәрләрендә морфологик диалектизмнар: аңар – аңа, тегесесе – тегесе.

III. Нәзифә Кәримованың хикәяләрендә, проза әсәрләрендә лексик диалектизмнар: беркавым – берникадәр вакыт, кенәген – кичә, кордый – кордаш кешегә эндәшү сүзе, яшьти – яшьтәшләр [11]

VI. Нәзифә Кәримованың хикәяләрендә, проза әсәрләрендә фразеологизмнар:

Авыз тәме бетү – ашау-эчү, ризык ләззәтен тоймау [6]

Башка чыгу – аерым йорт салып, ата йортыннан бүленеп чыгу, аерым яши башлау [6]

Зәһәрен чәчә – кешегә явызлык белән каныгып, тенденциоз бәйләнеп, үтен сытып сөйли [6]

Каты тору – үз идеалың өчен көрәштә, үз иманында чигенми нык тору; бирешмәү, таләпчәнлек күрсәтү [6]

Коры калу – өлешсез, түләүсез калу, буш кул белән калу, мәхрүм калу [6]

Кот алыну – кинәт бик каты курку [6]

Тел төбе – әйтергә теләгән уй, төп теләк, максат [7]

Теш агарту – ыржаеп көлү [7]

Әдәбият

Әхәтов Г. Х. Татар диалектологиясе. Югары уку йорты студентлары өчен дәреслек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 216 б.

Йолдыз ява: шигырьләр, җырлар, хикәяләр, истәлекләр / Нәзифә Кәримова. – Казан: Татмедиа, 2017. – 222.

Исәнбәт Н. С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. I том. – Казан, Тат. кит. нәшр., 1989. – 495 б.

Исәнбәт Н. С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. II том. – Казан, Татар. кит. нәшр., 1990. – 365 бит.

Кәримова Н. Ак әрем чәчәге: хикәяләр, повесть, пьеса, җырлар, шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 224 б.

Кәримова Н. Җәнлекләр кайта: хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 32 б.

Кәримова Н. Сагынасыңмы, дип сорыйлар...: повесть, хикәяләр, пьеса. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 159 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф .С. Баязитова, Д. Б. Рамазанова, З. Р. Садыйкова, Т. Х. Хәйретдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.

Интернет ресурлар:

http://matbugat.ru/enc/krimova-nzif-168/
http://syuyumbike.ru/medeniyat/proza?id=2561

## РИЗА ФӘХРЕТДИНОВ ИҖАТЫНДА ДӨНЬЯВИ-ДИДАКТИК ҺӘМ РУХАНИ ЭЧТӘЛЕКЛЕ ХЕЗМӘТЛӘРНЕҢ РОЛЕ

*Ситдыйкова Ләйлә,*
*Мамадыш политехник көллияте студенты,*
*Фәнни җитәкче: Әхмәтшина Айгөл Дамир кызы*

Риза Фәхретдинов (1858–1936) – күренекле фикер иясе, мәгърифәтче-галим, педагог, язучы, философ, тарихи, әдәби һәм педагогик хезмәтләр авторы, милләтебезнең сизгер күңелле әдәби тәнкыйтьчесе, мөселман дөньясында мәшһүр дин белгече. Риза Фәхретдинов (псевдонимы Риза казый), катлаулы

тормыш юлы уза. Тумышы белән мулла гаиләсеннән була. Мәдрәсәдә гарәп, фарсы телләрендә сөйләшерлек һәм язарлык белем ала. Аны тәмамлап ул, берничә ел авылда укыта, төп игътибарын фән, иҗат эшенә бирә [Фәхретдинов 1990: 34].

Риза Фәхретдинов үзенең иҗатында дөньяви-дидактик һәм рухани эчтәлекле хезмәтләрне шактый күп яза. Әйтергә кирәк, Риза Фәхретдинов иҗаты өчен тәрбияле бала мәсьәләсе зур роль уйный. Димәк, бу проблема астына милләт, киләчәк, тәрбия сыман темалар да кереп китә. Чыннан да, тәрбияле бала, милләт турында да, киләчәк турында да, "аек акыл" белән эш итәрлек шәхес булып үсә. Риза Фәхретдинов беренче хезмәтләрендә үк татар халкының культурасы мәсьәләсен кузгата. Татар мәктәп-мәдрәсәләренә реформа кертү турында уйлана [Татар әдәбияты тарихы, 2 том: 320]. Шул рәвешчә, Риза Фәхретдинов беренче адымнарында ук яшь буынны тәрбияләүгә, яңа тәртипле мәктәпләр булдыруга игътибар итә, башка милләтләрдән үрнәк алырга чакыра. Шулай ук, ул яңа тип дәресләр булдыру мәсьәләсен дә күтәрә, фән һәм әдәбият укыту кирәклегенә басым ясый [Госманов 1990: 22].

Безнең уйлавыбызча, бу гаять киң планда күтәрелгән мәсьәләләр, бер яктан, бу яшь укытучының халыкны үстерү хыяллары булып яңгыраса, икенчедән, алар барлык мәгърифәтчеләргә характерлы сыйфатлардан берсе булган тарихи оптимизмны күрсәтәләр. Шулай ук, Риза Фәхретдинов борынгы һәм үз заманы каләм ияләренең тормышына һәм әдәби эшчәнлекләренә караган шактый бай мәгълүмат туплый. Тарихи, әдәби һәм дини мәсьәләләргә кагылышлы тәнкыйть фикерләрен дә белдереп бара [Госманов 1990: 25].

Остазыбыз Риза Фәхретдинов "*Бала чакта алган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас*", "*...бала тәрбияләүне бишектән үк башларга кирәк*", дип саный. Ул үзенең "Тәрбияле бала" исемле китабының иң башында тәрбияле баланың җәмгыять өчен нинди байлык икәнен күрсәтеп болай дип яза: "*...Ата белән ана өчен тәрбияле бала кебек олы байлык һич булмас. Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык һәм ахирәттә йөзгә аклык китерер. Тәрбияле бала - дөнья байлыгына да бирелмәс һәм бер дәүләт патшалыгы белән дә алмаштырылмас; аны һәркем яратыр һәм мактап телгә алып сөйләр, ни сораса да бирерләр. Тәрбиясез баланы бер кеше дә яратмас, йомыш кушмаслар, бәлки хурларлар вә кимсетерләр генә*" [Фәхретдинов 1990: 125].

Р.Фәхретдинов балага ни кыланса да ярый торган җавапсыз бер җан иясе итеп карамый (кызганыч, бүген бик күп эти-әни балаларын нәкъ шулай тәрбияли), ә кылган гамәлләре өчен җәмгыять алдында җавап тотарлык, зурлар белән бертигез хокуклы шәхес итеп карый. Һәр укучы бала үз алдына "Атам-анам минем белән горурлансын, шатлансын, кешеләр дә миңа рәхмәт әйтсен, мине яратсыннар һәм мине һәркемгә үрнәк итеп сөйләсеннәр!" дигән бурыч, максатны куерга, тырышырга һәм үз-үзенә күзәтчелек итәргә тиеш!

Адәм баласының иң зур байлыгы – аның тәне һәм җаны сәламәт булуда икәнлеген күрсәтеп, Р. Фәхретдинов кешене үзенең сәламәтлеген сакларга

чакыра. Әгәр кеше авырып китсә, авыру кешене карау, тәрбияләү вазифасы хуҗабикәгә, ягъни хатын-кыз җилкәсенә төшүен һәм шуңа күрә дә инде, кыз балага чирнең сәбәпләрен һәм сәламәтләндерү чараларын белергә кирәклеген аңлатып бирә [Фәхретдинов 1990: 20].

Шулай ук, Риза Фәхретдиновның рухани әдәбиятка караган “Коръән вә тәбәгать” (1900), “Мөхәммәд галәйһиәссәлам” (1908), “Җәвамигуль – Кәлим шәхре” (1911) һ.б. хезмәтләре нәшер ителә. Автор болай дип искәртә: *“...гарәбчә укырга башлаган шәкертләргә дәрес китабы һәм дә әхлакны тәрбия кылырга ярдәмче булсын өчен, “Җәвамигуль Кәлим” исеме белән бер рисалә тәртиб иткән идек”,* – ди [Фәхретдинов 1990:13 -14].

Әйтергә кирәк, Җ. Зәйнуллин фикере буенча: “*Риза Фәхретдинов иҗат иткән “Җәвамигуль Кәлим шәрхе” башка хәдис китапларыннан иң әүвәл үзенең тел байлыгы һәм уңышлы тәрҗемә ителгән булуы белән аерылып тора. Анда тупланган энциклопедик мәгълүмат һәр укучы өчен бик файдалы һәм кирәкле... Китаптагы һәр хәдистә тирән мәгънә бар... Күпкырлы гыйлем иясе талантлы әдип һәм галим ул хәдисләрне, күп чыганакларга нигезләп, тәфсилле рәвештә аңлатып бирә, сүз уңаеннан гарәп шагыйрьләре иҗатыннан үрнәкләр китерә. Бу китап, нигездә, татар халкының укымышлы катламы, беренче чиратта, мәдрәсәдәге шәкертләр өчен төзелгән. Мүәллиф бу хакта үзенең кереш сүзендә искәртеп уза*”, – ди ул [Зәйнуллин 1998: 97].

Сүзне йомгаклап һәм яшьтәшләргә мөрәҗәгать итеп, шуны әйтәсе килә: *“...дөньяда иң бәхетле һәм рәхәт яшәүче кеше – ул башкаларга изгелек эшләүче зат”,* дигән остазыбыз. Без, яшьләр, киләчәктә мәшһүр галимебез хыялланган, ул күрергә теләгән бөтен яктан да үрнәк балалар булып җитешик һәм халкыбызга лаеклы булып, милләтебез горурланырлык, зур шәхесләр булып үсик. Илен, телен, гореф-гадәтләрен, халкын хөрмәт итүче кеше генә шәхес дигән исемгә лаек була. Иң асыл сыйфатыбыз булган кешелеклелекне югалтмыйк! Безнең киләчәк – үзебезнең кулыбызда!

Әдәбият

Госманов М: Ризаэддин Фәхретдинов мирасы. – Казан: Татар. кит. нәшр. – 1990. – 32 б.

Зәйнуллин Җ. Г. 18 йөз – 20 йөз башында татар рухани әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 1998. – 205 б.

Татар әдәбияты тарихы, 6 томда. Т.2. – Казан: Татар. китап. нәшр., 1985. – 320 б.

Фәхретдинов Р. Тәрбияле бала. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1990. – 125 б.

## И.ЮЗЕЕВНЫҢ “ТАШ ДИВАРЛАР АВАЗЫ” ПОЭМАСЫНДА ТЕЛ-СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ

*Талипова Алия,*
*Яр Чаллы шәһәре 7 нче урта мәктәбенең VIII сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Камаева Рима Биҗан кызы*

“Матур әдәбият милли телнең барлык синтаксис җегәрен дә тулы файдаланырга тырыша. Әдипләр, гадәттә, табигый, төзек җөмләләр белән язалар. Олы художниклар гадәти синтаксик конструкцияләрнең дә зур шигъри мөмкинлекләре булганлыгын раслыйлар. Шуның белән бергә фикерне сурәтле, сәнгатьчә йогынтылы итеп әйтү нияте белән җөмлә төзелешенә үзенчәлекләр дә кертәләр, аны төрле фигуралар белән баеталар. Образлылык, тәэсирлелек максатында җөмләләрнең үзенчәлекле корылышын поэтик синтаксис дип йөртәләр” [Курбатов 2002: 131]. Илдар Юзеевның “Таш диварлар авазы” поэмасында синтаксик фигуралардан риторик сорау, риторик эндәшләр, кабатлау алымы еш кулланылган.

1. Риторик сорау һәм риторик эндәшләр әсәрдә тасвирны җанландыру, күренешкә игътибар юнәлдерү, кичереш тойгыларны тәэсирле итү өчен кулланылган:

Без – коллар, без төрмә төзибез,
Һай авыр,
Мөмкинме язмыштан качулар? [Юзеев 2002: 185]
Тәхетемне яндырырсыз,
Төзелгәнне кырырсыз,
Тәхет харәбәләрендә
Үзегез ни корырсыз? [Юзеев 2002: 201].
Бармы галәмдә гали зат?
Күктә? Җирдә? Әллә соң
Эзлиме адәм үзенә
Яшеренгән алласын? [Юзеев 2002: 200].

2. Кабатлау алымын автор төрле максатларда кулланган.

Камчылар үзәкне өзәләр,
Һай авыр.
Бергәләп күтәрик, әйдәгез,
Һай авыр.
Ташларны башларга тезәләр,
Нигезгә салынып гәүдәбез,
Һай авыр!..[Юзеев 2002: 185]

Бу өзектә автор коллар язмышының ни дәрәҗәдә авыр, фаҗигале булуын укучының күңеленә җиткерү өчен кабатлау алымыннан уңышлы файдаланган

Бу – соңгы көнем.
Бу – соңгы таңым.
Бәхил бул, тормыш,
Бәхил бул, җаным...[Юзеев 2002: 204].

Бу очракта автор кабатлау алымы белән геройның соңгы минутлары якынлашуын ассызыклый.

Илдар Юзеев “Таш диварлар авазы”поэмасында чагыштыру, сынландыру, метафора, эпитетлардан уңышлы файдалана.

1.Чагыштыру – сүзне күчерелмә мәгънәдә куллануның гади төре. Чагыштыруның ике төре бар: логик чагыштыру һәм сурәтле (образлы) чагыштыру [Курбатов 2002: 94]. Шагыйрь поэмада сурәтле чагыштыруларны киң кулланган:

Мин гүя өнсез-авазсыз,
Җилкәнсез-юлсыз кораб... [Юзеев 2002: 184].

Бу өзектә таш дивар үзен җилкәнсез, юлы булмаган тавышсыз корабка тиңли, чөнки ул сулар агышына карап, ничәмә-ничә еллар буе тын торган. Ә әсәр ахырында, киресенчә, таш дивар "телле-авазлы", "җилкәнле-юллы" корабка тиңләнә, чөнки ул гасырлар буе җыеп килгән серләрен ачып салды.

Диварны гөл белән бизибез.
Ә гөлләр кан сыман алсулар,
Һай авыр [Юзеев 2002: 185].

Монда автор гөлләрнең төсен кан төсе белән чагыштыра. Ул колларның төрмәне төзегәндә нинди авырлыклар, күпме югалтулар кичерүен ассызыклый.

2."Сынландыру метафораның бер кисәген тәшкил итә. Чөнки метафорада теләсә кайсы өлкәдәге күренеш, гамәл, сыйфатлар, үз сүзләре белән бирелмичә, башка сүзләр белән алыштырылалар. Сынландыру исә җансыз предметны җанландыру белән чикләнә" [Хатипов 2000: 113]. Сурәтләү чаралары кулланганда каләм остасы өч мөмкинлеккә игътибар итә: образлылык, идеялелек, эмоциональлек [Поварисов 2003: 166]. Илдар Юзеев та сынландыру кулланганда шул үзенчәлекләрдән тайпылмый:

*Ак каеннар язып алдылар,*
Җырларымны *көйләп калдылар.*
Идел ага торыр,
Дулкын кага торыр,
*Еллар* елга булып *агарлар* [Юзеев 2002: 189].

3.Эпитетны гадәттә ике төрдә дип күрсәтәләр: логик эпитет һәм метафорик эпитет. "Метафорик эпитет ул – күчерелмә мәгънәле сүз яки сүз тезмәсеннән торган аергыч, ягъни аергыч булып килгән метафора"[Курбатов 2002: 99]. Автор поэмада метафорик эпитетларны еш кулланган:

Гомеремнең бер елы
*Тәмле* бер *төш* кебек...[Юзеев 2002: 192].
Хыялыма алып китәр
Бу *алтын сүзләр* мине,
Синең кебек уйчан шагыйрь
Килер дә эзләр мине.
Тик мин булмам... *таш күкрәгем*
*Назлы дулкынга* куеп,
Агып китәрмен үземне
Шат, горур, азат тоеп [Юзеев 2002: 205].

Һәр авторның яраткан эпитеты була. Нинди эпитетны сайлау да шагыйрьнең, язучының иҗат методына, ул тарафдар булган әдәби юнәлешкә,

ул яшәгән чорга һәм, әлбәттә, әсәрнең идея эчтәлегенә бәйле. Бу поэмада *кара, зәңгәр* сүзләренең еш кулланылуын әйтергә кирәк:

Ах, кызганыч, бу уйларым
Тик *зәңгәр хыял* гына... [Юзеев 2002: 206] .
Туздырды ояны
*Кара йөрәк* – патша [Юзеев 2002: 190].

Илдар Юзеев үзенең әсәрләрендә милли тел байлыгын мөмкин кадәр тулырак файдаланырга тырыша, бар моңын, матурлыгын куллана.

Әдәбият

1.Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.
2.Поварисов С. Меңьеллык моң // Мәйдан. – 2003. – № 1. – Б. 163-168.
3.Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000. – 351 б.
4.Юзеев И.Г. Сайланма әсәрләр. 5 томда, 3 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 400 б.

## БАЛАЧАК ҖЫРЧЫСЫ…

*Фазлиәхмәтова Рузилә,*
*Алабуга шәһәре 10 нчы урта мәктәбенең VIII сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Рамазанова Диләрә Фәнәвис кызы*

Балалар белән шигърият елендә иң табигый һәм үз булып сөйләшүче булгангадыр, Роберт Миңнуллин иҗаты рус балалары өчен төзелгән мәктәп дәреслекләрендә зур урын алган.

Роберт абыйның һәр әсәре турында озаклап сөйләргә мөмкин булыр иде. Без бары тик кайберләренә генә күз салырбыз.

Каникулда рәхәт иде,
Ял итәсең, уйныйсың.
Үзең уйныйсың, ә үзең
Мәктәбеңне уйлыйсың.

Дуслар җыела – һәркайсы
Олырак, белемлерәк.
Каникулда рәхәтрәк тә,
Мәктәптә күңеллерәк [Нигъмәтуллина 2006: 7].

Бу шигырьнең рифмасы җырлап тора, аны бик тиз генә ятларга да була, һәм ул бик озакка хәтердә калачак. 1 нче строфада хәзерге заман хикәя фигыльләренең, 2 нче строфада чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатларның күп булуы грамматик кушымчаларны хәтердә калдыруда әһәмиятле урын тота. Гади кенә, кыска гына сүзләр кулланылган. Әсәр буенча сораулар төзергә, эчтәлеген сөйләргә, диалог төзергә була. Ул мәктәпкә мәхәббәт тәрбияли, “олырак”, “белемлерәк” сүзләрен кулланып, автор үзбәяне күтәрүгә, горурлык, дуслык хисләре тәрбияләүгә, үзеңә читтән күз ташларга өйрәтергә булыша.

Минем әби – бик тә кызык кеше ул.
Ләбибләргә, Хәбибләргә – күрше ул.
Ул – әтинең әнисе ,

Апамның дәү энисе.
Ул – минем дә дәү энием.
Ул инде – бик дәү әби.
Бабам:"карчык" , – ди аңа,
Ә энигә – биана.
Тик энием: "эни", – ди.

[Нигъмәтуллина 2006: 23].

Бу әсәрдә язучы татар телендәге колакны иркәләүче ягымлы сүзләргә игътибарыбызны тарта, татар кешеләренең милли үзенчәлегенә басым ясый. Безнең халык үзенең кадерле кешеләренә менә шундый матур сүзләр белән эндәшеп, аларга хөрмәтен, яратуын күрсәтә. Чөнки өлкәннәргә хөрмәт күрсәтү – халкымның милли йөзен ассызыклаучы сыйфат. Шигырьнең гади тел белән язылуы аны русларга да аңлаешлы итә, шуңа күрә дәреслекләрдә ул үзенең лаеклы урынын алган. Рус балалары бездән көнләшеп тә куймыйлармы икән әле?!

"Ак кыш" шигырендә Р. Миңнуллин ап-ак кыш турында сүз йөртә. "Яратам" дигән сүзе белән, бөтереп, автор укучысын ак буранлы кыш куенына алып кереп китә. Ирексездән ак кар арасына кереп югаласы, бар нәрсәңне онытып, рәхәтләнеп, балачакның ак карлы, ак хыяллы әкияти дөньясында уйныйсы килә. Шагыйрь кышның матурлыгын, ямен күрсәтә. Кыш вакытында куяннарның, агачларның, урамнарның, бар дөньяның ак карга күмелүен тасвирлый. Шигырьнең рифмасы һәм "ак", "ап-ак" сүзләренең еш кабатлануы аны искиткеч дәрәҗәдә матурлый, әйтерсең лә, ул шуның белән рус баласын татар телен өйрәнергә чакырып, кызыктырып тора.Эх, ничек рәхәт һәм күңелле ул кыш көне! Рус балалары бу шигырьне бик яраталар, чөнки авторның сөйләгәннәре һәркемнең күңел халәтенә якындыр. Кешеләрнең милләте булса да, аларның күңел халәтен, хисләрен, кичерешләрен милләтләргә бүлеп карау мөмкин түгел. Димәк балачакның да милләте юк: бала күңеле бертөсле. Балачакның һәр өлкәдә үз кануннары, кагыйдәләре. Анда мактану, шапырыну, арттырулар да уңай кабул ителә. Балачак фантазиясенең чиге юк.

"Спортның яңа төре" шигырендә дә күз алдына спорт белән шөгыльләнүче, аның бөтен төрен яратучы егет килеп басты дигәндә генә, сүз сөреше бөтенләй башка борылыш ала. Алмаз – спорт белән, диванда ятып, ягъни телевизор каршында шөгыльләнүче. Ул спорт төрләренең берсен дә калдырмый. Рус баласы бу әсәрне укып, спорт өлкәсенә караган сүзләрнең күбесе ике телдә дә бер үк яңгыравын күңеленә сеңдерә.

Шигырьләре гади тел белән язылганга, Р. Миңнуллинның һәр әсәрен гади җөмләләр рәвешендә сөйләп бирү рус баласы өчен дә бернинди дә авырлык тудырмый. Мөгаен, шуның өчен дә дәреслек авторлары аның иҗатына мөрәҗәгать иткәндер.

Тагын бер шигыренең герое – беркатлы авыл малае. Герой, беренчедән, шәһәр урамындагы хәрәкәткә таң калган, бераз курыккан. Шул ук вакытта ул

кагыйдәләрне үтәргә кирәклеген аңлый, үтәргә тырыша. Милиционер абыйга хөрмәт белән карый.

Йә сызгырта сыбызгысын
Милиционер абый.
Йөри белмәсәң урамда,
Ул әллә каян таный. [Нигъмәтуллина 2007: 36].

Мондый кызыксынучан, хәрәкәтчән, акыллы авыл малайларыннан үрнәк алсаң да була! Ә үрнәк алганда, үзең дә сизмәстән, әсәрдәге лексик, синтаксик, грамматик күренешләрне истә калдыруыңны сизми дә каласыңдыр!

Роберт абыйның һәр шигыре, алардагы һәр сүз, һәр җөмлә укучыларны аралашырга, сөйләшергә, фикер алышырга чакырып тора. Автор бала күңелендәге хисләрне, тойгыларны, кичерешләрне гади генә итеп алар күңеленә үк сала да куя. Рифмасының, теленең, фикеренең гадилеге аның әсәрләрен рус балалары өчен дә җиңел итә, шуңа күрә Роберт Миңнуллинның иҗаты – мәктәп программаларының аерылгысыз өлеше.

Әдәбият

Нигъмәтуллина Р.Р. Татарча да яхшы бел. // Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 5 нче классы өчен татар теле дәреслеге, ике кисәктә, беренче кисәк, икенче кисәк. – Казан: Мәгариф, 2006.

Нигъмәтуллина Р.Р. Татарча да яхшы бел. // Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 6 нчы классы өчен татар теле дәреслеге, ике кисәктә, беренче кисәк, икенче кисәк. – Казан: Мәгариф, 2007.

Нигъмәтуллина Р.Р. Татарча да яхшы бел. // Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 7 нче классы өчен татар теле дәреслеге. – Казан: Мәгариф, 2007.

## ГӨЛЛӘР ДӘ ЕЛЫЙМЫ?
## (Г.Гыйльманов иҗатында хикәя жанры)

*Фатыйхова Илзия,*
*КФУның Алабуга институты студенты*
*Фәнни җитәкче: Габидуллина Фәридә Имаметдин кызы*

Г.Гыйльманов Башкортстанда туса да, бүгенге көндә аның иҗаты белән күпчелек Татарстан халкы таныш. Аның иҗатын өлкән буын гына түгел, 21 нче гасыр балалары да яратып кабул итә. Г. Гыйльмановның Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге премиягә ия булуы, әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен.

“Шолохов Медале” белән бүләкләнүе, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе исеменә лаек булуы аның иҗатының яратып укылуын, әсәрләренең тирән эчтәлекле, шул ук вакытта җиңел укылуын күрсәтә. Күңеле белән үз эшенә кереп чумган язучы гына укучылары тарафыннан яратып укыла һәм хезмәте өчен лаеклы бүләкләнә ала!

Г.Гыйльманов иҗатының ике үзенчәлекле ягы бар. Беренчесе – ул студент елларда барыбызга да мәгълүм булган “Әллүки” түгәрәгенә йөри. Монда ул үзенең иҗади мөмкинлекләрен сыный. Минемчә, бу факт Г.Гыйльмановның хәзерге язучылык осталыгында зур роль уйный. Икенче үзенчәлек – ул мәшһүр шагыйрь Шәехзадә Бабичның туган авылында туып үсә, белем ала. Бу да аның язучылык талантын, минемчә, тагын да арттыра һәм яңа идеяләргә зур этәргеч бирә. Г.Гыйльманов күпләгән хикәяләр, новеллалар, повестьлар, бәяннәр авторы. Аның иҗаты бик кызыклы, шул ук вакытта фәлсәфи идеяларга да бай.

Беренче карашка гадәти ялгызлык темасын күтәргән хикәя – “Гөлләр дә елый”. Әйе, чыннан да, ялгыз сәер карчык, тирә-якта бернинди артык мәгълүмат белән дә кызыксынмаучан кешеләр... Хикәя нәкъ менә ялгыз карчыкның көн саен гөл тотып урамда йөрүе белән башланып китә. Хикәядә түбәндәге юллар бар: “Безнең ишегалдында мин белә-белгәннән бирле яши ул. Аның белән беркем дә аралашмый. Моның бик мөһим сәбәбе бар. Ул һәр көнне урамга бер гөл күтәреп чыга” [Гыйльманов 2005: 258].

Тирә-якта яшәүче өлкән, урта буын, хәтта балалар да бу карчыкка ниндидер җирәнгеч караш салалар. Ә бит шунда бер генә кешенең дә карчыкның туганнары, гаиләсе турында сорарга да, аның гөле серен дә ачыкларга теләми. Халык, кешенең рухи байлыгын белеп түгел, ә киресенчә, матди байлыгы ягыннан гына аның кем икәнен билгели. Ә болай фикерләү дөресме соң? Мондый адым дөньяны кайсы якка авыштырыр? Һәрберебез дә шушы фикердә булсак, тормыш ничек үзгәрер?! Шушы һәм башка күп кенә сорауларга җавапны Галимҗан Гыйльмановның “Гөлләр дә елый” хикәясе ачыкларга булыша.

Әсәрдә хикәяләүче тирә-якта яшәүчеләрдән үзенең рухи яктан бай булуы, өлкәннәргә хөрмәт һәм ихтирам белән каравы, кешеләрнең тормыш проблемалары белән кызыксынуы һәм башка бик күп уңай сыйфатлары белән аерылып тора. Ялгыз карчыкка самими, эчкерсез булуы аның чын йөзен ача. Нәкъ менә хикәяләүче гөл серен ачыкларга тели дә. Һәм ул үз дигәненә ирешә. Карчыкның һәр әйткән сүзеннән мәгънә эзли, һәр эшләгән эшенә хозурлана. Чөнки Җиһан әби – чын татар әбиләре кебек чиста күңелле, пөхтә, игътибарлы, сабыр, ягымлы, иманлы, сүзендә тора.

Шушы гөл, ире сугышта вакытта җибәргән орлыклардан шытып чыккан була. Шушы гөлне ире төсе итеп саклавы, ире алдында гомеренең соңгы көненә кадәр тугры булуы аркасында күршеләре аны Сәер карчык дип исемлиләр. Алар аның тормыш хатирәләрен сораштыруны кирәк дип тә тапмыйлар. Җиһан әби үзенең кызыклы фикерләре, динаятле булуы, ачык зиһене белән хикәяләүчене үзенә тарта. Язучы болай ди: “Аралашу ул – сөйләшү, серләшү генә түгел бит ул. Көне буе сөйләшеп йөргән кеше белән дә аңышмый, аңлашмый аерылырга мөмкин. Бер сүз катмыйча да рәхәтләнеп сөйләшеп, аңлашып була...” [Гыйльманов 2005: 261].

Хикәяләүче күпмедер дәрәҗәдә ялгыз карчык алдында башкалар өчен үзен гаепле итеп тоя. Бу да рухи байлыкның матди байлыктан бик күпкә өстен булуын ассызыклый.

Беренче карашка гына ялгыз булып тоелган карчык хикәя ахырында гомумән икенче, яңа яктан ачыла. Күп кенә ишле гаиләле яисә якыннары исән-сау кешеләргә караганда да бәхетлерәк бит ул Җиһан әби. Аның исеме дә бик мәгънәле. Исеме аша ук без аның киң күңелле, эчкерсез, үз сүзен ахыргача саклый торган кеше икәнен сизенәбез. Ә инде хикәяләүченең дә Җиһан әби кебек рухи байлыгы аша без алар белән якыннан танышабыз. Әдипнең әсәрләрендә вакыйгалар чынбарлык белән хыял кисешкән чиктә бара, шул сәбәпле образлар бирелешендәге серлелек көчәя.

Димәк, кешеләр еш кына үзләренә ошамаган кешеләрне кабул итмиләр, аңламыйлар. Бу үз чиратында ялгызлыкка китерергә мөмкин. Шуңа күрә дә кешеләрне тышкы кыяфәт, беренче караш буенча гына түгел, нәкъ менә рухи байлыклары, фикер йөртүләре, дөньяга карашлары буенча аңларга тырышырга кирәк [Фәхретдинов 2005: 87].

Г. Гыйльмановның шушы кечкенә күләмле хикәясе үз эченә бик күп проблемаларны алган. Аларның һәрберсе безнең чор өчен генә түгел, киләчәк буын өчен дә актуаль.

Әдәбият

1. Гыйльманов Г. Китек ай: Повестьлар, хикәяләр, парчалар – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 383 б.

2. Фәхретдинов Р. Р. Нәсыйхәт: Әхлак гыйлеменнән – Казан: Мәгариф, 2005. – 186 б.

## ТУФАН МИҢНУЛЛИН ӘСӘРЛӘРЕНДӘ АНА ОБРАЗЫ

*Фәрхетдинова Гөлназ,*
*Алабуга шәһәре 9нчы урта мәктәбенең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Нөркәева Гөлнур Флит кызы*

Сәхнә сәнгате – реаль чынбарлыкның үзенчәлекле чагылышы. Бу сәнгатьтә бүгенге көн, бүгенге сораулар, бүгенге кешеләр һәрвакыт аерым бер мөһим урын билиләр. Икенче төрле итеп әйткәндә, сәхнә сәнгате заман темасы һәм бүгенге геройлар образлары белән яши, шулар аның актуаль эчтәлеген, заман белән тиң адымда барырга омтылышын билгелиләр.

Бу турыда сүз чыккач, бүгенге көн турында язган, бүген туа һәм чишүне сорый торган проблемаларны яктырткан драматург дип без Туфан Миңнуллин исемен саныйбыз.

Драматург материалны тормышның төрле өлкәләреннән эзләгән, төрле-төрле темаларны кузгаткан, аның әсәрләрендә күтәрелгән проблемалар күп вакытта мөһим һәм тамашачыны дулкындыра торган булалар.

Туфан Миңнуллин тормышның кайсы өлкәләрен һәм нинди геройларны ятарып сурәтләгән? Драматург буларак, ул укучыга һәм тамашачыга нинди

яңалык алып килгән? Чынбарлыкны күрсәтер өчен, Туфан Миңнуллин төрле типтагы һәм төрле характерлы образлар иҗат иткән. Ул геройларын төрле шартларга куеп сынаган. Аның геройлары барысы да акыллы гына түгел, ә бәлки шушы шартларда чыныгып, тормышта үз юлларын табалар, бәхеткә омтылалар. Авторның иң беренче күзгә ташланып, күңелдә хөрмәт уята торган образлары – ул халыкчан хатын-кыз, гүзәллек һәм миһербанлык символы булуы белән бергә җәмгыятебезнең киләчәген тәрбияләүче аналар образы.

Ана образларын, татар әдәбиятында, төрле язучылар төрлечә итеп яздылар. Ә Туфан Миңнуллинның аналары башка. Без моны зур күләмле әсәрләреннән “Әниләр һәм бәбиләр”дәге Гөлфинә, “Моңлы бер җыр”да Рәхимә апа, “Нигез ташлары”ндагы Гөлҗиһан, “Әлдермештән Әлмәндәр”дә Хәмдебану, “Уйланыр чак”тагы Тәслия образлары аша күрә алабыз.

“Әниләр һәм бәбиләр” драмасындагы Гөлфинә образы драматургның олы табышы. Күп балалы бу ана күңелендәге шәфкатьлелек һәм күңел көрлеге, кешелелек һәм җан җылысы кемне битараф калдыра ала икән?! Гөлфинәләр кебек аналар булганда гына без киләчәк өчен тыныч була алачакбыз, бары шул очракта гына кеше кеше булып кала, ярата һәм сөелә белер.

Шушындый образларга якын торган сынмас рухлы, нык иманлы хатын-кызларның берсен “Ай булмаса йолдыз бар” драмасындагы Мәдинә образы аша күрә алабыз. Автор көчле ихтыярлы хатын алдында башын иярга мәҗбүр була, шул рәвешчә Мәдинә үз язмышына хуҗа була алган кешеләрнең җыелма образын гәүдәләндергән.

Ләкин дөньяда гел уңай гына түгел, ә тискәре, ямьсез яклары да булган кебек драматургның әсәрләрендә дә тискәре сыйфатлары булган хатын-кыз образларын күрә алабыз. Моны без “Әниләр һәм бәбиләр”дәге Дилемма, Вазыйфа, Римма, “Уйланыр чак”та Фирая кебек образларда ачык күрәбез. Шулай да автор шундый тискәре сыйфатлары булган геройларыннан да бөтенләй ваз кичми. Ул бу героиняларына өмет белән карый, төзәлерләр дип өмет белдерә.

Бала тудыру әле ул чын мәгънәсендә ана булу дигән сүз түгел. Яшь буынны ата-ана туган илгә файдалы, чын мәгънәсендә кеше булган лаеклы шәхес итеп тәрбияләргә тиеш. Бу мөһим эшне башкаруда аналарның роле аеруча зур.

Туфан Миңнуллин бер-берсенә охшамаган, бер-берсен кабатламаган күп драма әсәрләре язган. Ул үз әсәрләрендә тормышның әле моңа кадәр ачылмаган якларын күрсәтергә омтылган. Драматургның уңышы, иҗатының хикмәте дә шунда.

Әдәбият

Әхмәдуллин А. Ничек сүрәтләргә сине замандаш? – Казан: Татар.кит.нәшр., 1976. – 118 б.

Мөхәммәдиев Р. Тормыш дәвам итә//Казан утлары, 1983. – №1. – 137 б.

# АЙДАР ХӘЛИМ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ҺӨНӘРИ ЛЕКСИКАНЫҢ ЧЫГАНАКЛАРЫ

*Хадиева Алия,*
*Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкчесе: Смирнова Гөлназ Дикъкать кызы*

Гомумән татар сүзләре кебек үк, татар һөнәри лексикасы да чыгышы белән берничә чыгынакны үз эченә ала. Әби-бабаларыбыз арасында һөнәрчелекнең борынгыдан чәчәк атуын искә алганда, борынгы чордан ук барлыкка килгән һөнәри лексиканың күп булуына алшарт булып тора. “Археологик казылмалар Идел Болгары шәһәрләрендә кара металлургия, тимерчелек, зәркән, бронза кою, чүлмәк ясау, күн, агач эшкәртү кебек җитештерү өлкәләре һәм һөнәрләренең булуын раслый”, – дип яза И.Ә. Гафаров. – Археология мәгълүматларына караганда, болгар осталары аркылы балта ярдәмендә эшкәртелгән тактаны киң файдаланганнар, пычкыны да белгәннәр. Алар бүрәнәләрне чөй белән һәм терсәкле тоташтыру алымын да файдаланганнар һәм моны бик оста башкарганнар. А.Хәлим әсәрләренә мөрәҗәгать итеп, әдип кулланган профессионализмнарның чыганакларын билгелик. Татарның борынгыдан, гомумтөрки телдә үк формалашкан, берегеп калган сүзләрдән түбәндәгеләр теркәлде:

*Яктыдан яктыракка өндә!*
*Ян!*
*Соңлама, төнгә көн* ***сиплә!***
Ян!

Икенче мисал:

*Халык телендә “тастымаллык” дип аталган шадра тукымадан,* ***кулдан,*** *эре* ***атлатып тегелгән*** *һәм әле беренче тапкыр гына киелгән ак күлмәк, кызыл кизҗеле кыска киндер ыштан белән өстен-башын бөтәйтеп алган һәм шул ыштаны белән бодырдан торып барлык ихатаны кызыл әләм кебек кызарткан Канәгать, тәкате бетеп, ачык ишеккә кычкырды.*

Тагын бер мисал:

*Ул* ***сызымга*** *билгесен сала да,*
*Бөкләштереп тыга куенга.*

Телебезнең сүзлек составында урын алган һөнәри лексиканың бер өлеше тарихыбызның төрле чорларында килеп кергән һәм телдә берегеп калган *алынма сүзләр пластын* тәшкил итә. Мондый лексемаларны өч төркемгә бүләргә була: гарәп-фарсы атамалары, рус атамалары, көнбатыш европа телләреннән кергән атамалар. Мисалларга мөрәҗәгать итик:

*Орлык киптерү өчен* ***зерноскладларым, хранилищеларым*** *минем болай да җитәрлек.Күпләр сөрән салган иде, имеш,* ***горюче-смазочные*** *да җитәрлек булды.Бүген авылда кулак булу өчен* ***посевной площадь, удобрение, механизация*** *гынаҗитми.*

Күренгәнчә, һөнәри лексиканың күпчелек өлеше я татарның үз җирлегендә, үз сүз байлыгы хисабына ясалган, я рус һәм көнбатыш европа телләреннән кергәннәр. Гарәп-фарсы телләреннән кергән һөнәри лексика юк диярлек. Без моны шуның белән аңлатабыз гарәп-фарсы сүзләре теребезгә Шәрекъ илләре белән багланышлар нәтиҗәсендә кергәннәр. Бу мөнәсәбәтләрнең күбесе әдәбият, мәдәният, сәнгать, дин белән бәйле. Шуңа күрә мондый сүзләр дини, мәдәни тематикага караган әсәрләрдә, мәкаләләрдә еш очрый. Әйтергә кирәк, А.Хәлим әсәрләрендә дин әһелләре лексикасы шактый еш очрый. Мәсәлән:

*Аңа, **мәзин** баласына, **ислам кануннары** ана сөте, бишек җыры белән сеңдерелгән, **Иман шарты, Коръән Кәрим сүрәләре, догалыкларны** да яхшы хәтерли, **Аллага шөкер**, тел дә тидертми. Карчык, без **кыйбланы** дөрес сайлаган булганбыз микән? – диде Гарифулла, калушларын киеп, каз тәпиле **намазлыгын** җыештырып маташкан Өммегөлсемгә.*

Мәдәният, сәнгать өлкәсендә дә гарәп-фарсы алынмалары кулланыла. Боларны язучы, музыкант, журналист профессияләре белән бәйләнештә карарга мөмкин. Мәсәлән: *Хөрмәтле **баш мөхәррир**! Күптән түгел генә архивымны актарганда, бер кулъязмага тап булдым*

*Күңелләргә хуш киләсең,*
***Маэстро.***
*Күгең – кояш, баш өсләрең*
*Аяз тора.*

Кайбер профессионализмнар *алынма сүз + татар сүзе* моделе буенча ясалганнар. Мәсәлән:

*Гомере буе **процент исәбенә** колхозны сауган Процент Галләм, авыл батракларыннан бердәнбер азамат, моңа алданып, “Минем үз фикерем бар!” – диеп колхоздан аерылып чыккан иде, малай.*

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: А.Хәлим әсәрләрендә кулланылган һөнәри лексика чыганагы буенча берничә типка карый. Күп кенә сүзләр татарның үз сүзлек хисабына барлыкка килгән, алар арасында кушымчалау ысулы белән ясалган сүзләр, тезмә сүзләр өстенлек итә. Гарәп-фарсы алынмалары исә бары дини лексика һәм мәдәният белән бәйле сүзләр арасында гына очрыйлар. Һөнәри лексикага караган сүзләр арасында рус алынмалары күп очрый. Алар да кушымчалау я тамырлар кушылу юлы белән ясалганнар. Кайбер сүзләр алынма *көнбатыш европа сүзе + татар сүзе (*кайбер вакытта – *мөстәкыйль алынма сүз + ярдәмче фигыль)* калыбында оешканнар.

Әдәбият

Гафаров И.Ә. Болгар-Казан тарих көзгесендә. – Казан: Мәгариф, 2005. – 54 б.

Хәлим А. Колмак җыя кызлар: шигырьләр, балладалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – Б. 42 - 44.

Хәлим А. Кыйбла: Хикәяләр, новеллалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 278 б.

Хәлим А. Беренчеләр. Индустриаль эскизлар. – Казан: Матбугат йорты нәшр., 1998. – 35б.

Хәлим А. Татар моңы: хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 65.

Хәлим А. Яшисебез килә!: сайланма публицистика (1957 – 2008) // кереш сүз авт.Р.Бәшәр. – Казан: Рухият, 2009. – Б. 596.

Хәлим А. Татар моңы: хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 30.

## КЛАРА БУЛАТОВА ШИГЫРЬЛӘРЕНДӘ УКЫТУЧЫ ШӘХЕСЕ

*Хәкимова Лениза,*
*Мөслим районы Салавыз – Мухан мәктәбенең IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Латыйпова Галия Хафазетдин кызы*

Шагыйрә дөньяга укытучы күзләре белән бага, әйләнә-тирәне укытучы биз-мәне белән бәяли, хуплый, кире кага. Аның гади генә сүзләрдән тезеп язылган юлларынла мөгаллимә шәхесенең күңел тирәнлеге, үз хезмәтенә мөкиббәнлеге, иманы ярылып ята:

Миңа сорау бирсәләр:
– Сөенечең ни? – дисәләр,
Сөенечем –таңнан торып
Иртән килгән иртәләр.
Миңа сорау бирсәләр:
–Шатлыгың ни? – дисәләр,
Шушы мәктәп сукмаклары
Шатлыгыма илтәләр
Миңа сорау бирсәләр:
– Бәхет ни ул? – дисәләр,
Бәхет – шушы укучылар
Кеше булып үссәләр.

(«Укытучы бәхете»)

Гали Халит сүзләре белән әйтсәк,шагыйрьнең үз образыннан башка шигърият хакында сүз кузгатып торасы да юк. Шагыйрь образы шигърияттә романтизм поэзиясендә үк үз урынын алганлыгы һәм нәкъ менә шушы образда кеше һәм шәхес проблемасы үзенең социаль һәм психологик куәтен алуы хакында язган иде әдәбият белгече. Клара Булатова иҗатында да укытучы шәхесе шагыйрәнең үз образы, аның үз эшенә, балаларга мөнәсәбәте,бу һөнәрнең ро-мантикасы, борчу-шатлыклары, идеаллары аша чагыла.

Лирик герой – укытучы шәхесе бүгенге укучылар һәм галәм чиксезлеге арасындагы күпер булып тора, һәм ул яшь буынның барыр юлы, “аларның гомере,заман килере” өчен җавап йөкләгән.

*Унөч-ундүрт яшьтә...*

*Алтынчылар...*
*Тик башлана гына юлыгыз.*
*Киләчәктә сездән кемнәр чыгар?..*
*Кем булса да – Кеше булыгыз.*

Клара Булатова иҗатында исә гасырлардан килгән әлеге кайтаваз укытучы шәхесенең заманча чагылышын тәшкил итә.Укытучы,баланы гыйлемле итү белән бергә, аңа әхлакый тәрбия бирүне, чын кеше итеп формалаштыруны максат итеп куя.

Клара Булатова шигырьләрендә укытучы үз шәкертләренең юлбашчысы, аларны гаделлеккә, намуслыкка, әхлакый камиллеккә әйдәүче, үз көченә ышанган, карашы белән алга омтылган, заман җилләренә каршы күкрәген киереп баскан фидакарь зат булып та,төн йокысыннан бүленеп, һәр баланың өлгереше өчен борчылып, куанып яшәгән аналарча хәсрәтле, ягымлы, мөлаем зат буларак та күз алдына баса. Ягымлылык, һәр укучыны үз баласыдай якын күрү һәм нечкә шагыйранә юллар белән шушы тойгыны укучы күңеленә җиткерү – Клара Булатованың иҗат үзенчәлеге, шигъри почеркы. Мәсәлән, ”Укытучы апаң йокламаган“ шигырендә шагыйрә Азатның “өчле”ләре “бишле”гә әйләнүенә куанып, төн йокысын җуйган укытучының күңел халәтен гади генә юлларда гаҗәеп тирән итеп ачып сала. Шигырьнең тәэсир итү көче.аның лирик героеның олы җанлылыгы, кеше буларак рухи матурлыгы һәм кабатланмас психикасы белән билгеләнүе хакында Нил Юзиев та билгеләп үткән иде. Әдәбият галименең “Шагыйрьнең характеры, әйтергә яраса, шигырь характерын да билгели”, – дигән алтын хәрефләр белән язылырдай сүзләрен кабатлыйсы килә [Юзиев 1966 :53].

Әлбәттә, мәктәп тормышы аерым вакыйгалар чылбырында, лирик геройның күңеленә сеңеп калган хатирәләр, истәлекләр, сурәтләрдә чагыла. Шагыйрә тормышының һәм хезмәт биографиясенең тере шаһитлары булган бу шигырьләрдә укытучы шәхесе яңа сыйфатлары белән ачыла бара.Ә аның асылы – укытучыны укытучы иткән нәрсә – үз хезмәтенә чиксез мәхәббәте. Әлмәттән – Колшәрипкә, Әлмәттән-Нәдергә, Нәдердән-Яңа Кәшергә йөреп укытырга туры килә шагыйрәгә. Ялга киткәндә дә сагынып, ашкынып, җәяүләп узылган чакрымнарда яңа шигырьләр бөреләнә. Иҗатка мөкиббән укытучы балаларда да торган саен яңа сыйфатлар ача.

*Һәр дәрес монда олы юл* -
*Тормышка бәйләү кирәк.*
*Ә тормыш...тормыш матур ул,*
*Аңларга шуны өйрәт.*
(“Ә тормыш,тормыш матур ул”)

Белем бирүдән тыш, җәмгыятькә чын кешеләр үстерү, аларны тормыш ма-турлыгын танырга өйрәтү - менә нинди максатлар йөкли укытучы шәхесе. Данлы, җанлы вакыйгаларга нигезләнеп язылган “Һәйкәл ачты мәктәп”,

”Мәктәптә урак өсте”, ”Хәтерли микән үзе” кебек шигырьләрдә дә укытучы кичерешләре, мөгаллимә һәм шәкертләре арасындагы җылы

мөнәсәбәт, тулы канлы мәктәп тормышы, лирик геройның фидакарьлеге сурәтләнә.

Балалар укыту һөнәрен кара алтын чыгару хезмәте, укытучыны нефтьче белән янәшә куеп сурәтләгән “Унсигезенче маршрут” шигыре дә гыйбрәтле. Нефтьчеләр белән бергә таңнан торып бер үк вахтада эшкә ашыгучы һәм кич булгач, шул ук нефтьчеләр белән бергә вахтада эштән кайтучы укытучы сурәтләнә биредә.

Күзәтүләрне  шагыйрә иҗатында мәктәп темасы кысаларында гына да карарга булыр иде. Ләкин безнең игътибар үзәгендә лирик шәхеснең, бу очракта укытучы шәхесенең үсешен, психологик үзгәрешен күзәтү. Гегельнең “Чын лирика, шигъриятнең үзе кебек үк, кеше йөрәгенең асылын ачып салырга тиеш”, – дигән сүзләренә кыйбла тотабыз без.  Ә шәхес коцепциясе турында сөйләгәндә, рухи диалектиканы читләп үтеп булмый. Иҗтимагый- сәяси стресслар, икътисадый мөнәсәбәтләр үзгәреше, җәмгыятьтәге әхлакый тетрәнүләр шагыйрә күңеленә, әйләнә-тирәгә булган мөнәсәбәтенә кагылмый калмый.

Клара Булатова иҗатын шартлы рәвештә ике чорга бүлеп карасак, соңгысында лирик шәхеснең илдә барган үзгәрешләргә, укытучы горурлыгын таптаган сәясәткә, кичәге укучыларның бүгенге әхлаксызлыгына карата җан әрнүен күрәсең. Болар “Укытучы көндәлегеннән”шәлкемендә үзәк урынны алган.

“Рухи диалектика, Г.Халит сүзләре белән әйтсәк, тойгыларның һәм хисләр-нең, уйларның динамикасы, хәрәкәте, үсеше, үрелеше, сүнүе, тулаем алганда, аларны бер халәттән икенчесенә күчеше ул”.

Укытуч ы исемен гомере буе горур йөрткән лирик шәхес хәзер:

*Горурлана алмыйм Укытучы*

*Дигән атым белән...*

*Горурлана алмыйм үз теленнән*

*Бизгән халкым белән,* – ди. Заман тудырган мондый рухтагы шигырьләр “Әрнү” дигән җыентыкның тууына да этәргеч булды.Үзе укыткан укучыларының туган телдән йөз чөе-рүе, җинаятьчегә әверелүе, хәтта җитәкче булуга ирешүчеләрнең дә заман шаукымына бирелүе әрнетә шагыйрә - укытучыны. Шәхес үз горурлыгы, идеяләренә тугрылык хакына көрәшми түгел --- көрәшә, сынмаска, сыгылмаска тырыша. Ләкин заман фаҗигасе лирик шәхесне бөгә, пессимистик нотага күчәргә мәҗбүр итә.

*Өндәү билгеседәй туры*

*Калырга күпме тырыш,*

*Сорау билгесе шикелле*

*Бөгә дә куя тормыш.*

Хәзер безнең алда горур, чая, үзеннән илаһи нур сирпеп торган белем али-һасе урынына замана афәтләре: гаделсезлек, битарафлык, әхлаксызлык тара-фыннан кыерсытылган, рәнҗетелгән зат пәйда була.

*Бичара Шагыйрә апа,*

*Бичара Мөгаллимә...*
*Ходай биргән сәләтеңне*
*Югалтам җирдә,димә.*
*Бу хәерчелек биштәрен*
*Иңеңә элдең нигә?*
*...Белемең нигә кирәк тә,*
*Шигырең кемгә кирәк?*
*Ачыргаланып, ачынып,*
*Вакытсыз тынар йөрәк.*
*(“Авыл көндәлегеннән җәйге язмалар”)*

Ләкин бу әле шагыйрәнең укучысына әйтер соңгы сүзе түгел, һәм Клара Булатова иҗатын пессимистик ызанга төште дияргә ярамый. Бу – аның көрәш ысулы, заманага, җәмгыяткә протест белдерү акты гына. Мөгаллимә-шагыйрә – бүгенге көндә мәктәп укучыларының һәм студентларының гына түгел, төбәгебездәге яшь каләм тибрәтүчеләренең гаҗәеп таләпчән остазы һәм милләт киләчәге, ана теле, әдәбият-шигърият үсеше өчен барган көрәшнең кыю каһарманы да.

Алтмышынчы еллар уртасында поэзиягә килеп, күпләрнең игътибарын җәлеп иткән Клара Булатова бүгенге көндә шигъриятнең иң югары баскычында торучы шагыйрә. Аның иҗатында нинди генә геройлар, һөнәр ияләре юк. Әмма укытучы образы, аның фидакарьлеген күрсәткән шигъри тәлгәшләр бер генә укучыны да битараф калдырмас.

Шагыйрәнең тормышы һәм иҗаты белән танышкач, һөнәре буенча укытучы икәнлеген белгәч, кызыксынуым тагын да артты. Чөнки минем үземнең дә хыялым укытучы булу. Бу уй башлангыч сыйныфларда укыганда ук минем хыялымда. Елдан-ел бу фикерем ныгый гына бара. Бу темага тукталуымның сәбәбе дә шулдыр, мөгаен.

Әдәбият

Юзиев Н.Г.Традицияләр яңарганда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1966.–Б. 53.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

*Хәкимуллин Алмаз,*
*Алабуга шәһәре 4 нче гимназиянең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Гатина Миләүшә Наил кызы*

“И туган тел, и матур тел” дигән Габдулла Тукай һәм шунда ук, матурлыгын сиздереп: “әткәм-әнкәмнең теле!” – дип өстәгән. Бу сүзләрдә күңел назы, бөтен җаның - тәнең белән ярату, өзелеп әйткән тойгылар җанлана.

Бөек шагыйребез Г. Тукай халык авыз иҗатына зур бәя биргән. “Халык җырлары- безнең бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр... Белергә кирәк ки, халык җырлары халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рушан көзгеседер. Бу – бертөрле сихерле

көзгедер” – дигән ул. Әйе, халык авыз иҗаты – халыкның күңел көзгесе. Ул көзгедә тарих чагыла.

Татар халык авыз иҗаты әдәби һәм тарихи мирасыбызның гүзәл бер өлешен тәшкил итә. Анда без ерак гасырлар тавышын да, бүгенге көннәр аһәңен дә ишетәбез. Халык авыз иҗатының барлык төрләре дә кешеләрнең тормыш турындагы уйлануларын, тәҗрибәсен һәм хыял-омтылышларын чагылдыра. Шуңа күрә дә татар халык авыз иҗаты кебек олы мирасны читләтеп үткән, шул чишмәнең суын татымаган, аның гүзәллеге, тылсымлы көче белән илһамланмаган кеше юктыр дөньяда. Халык авыз иҗатын зур бер рухи йорт дип күз алдына китерсәк, әлеге йортның нигез ташларын бишек җырлары тәшкил итә.

Бишек җыры – ул табигатьтәге иң олы мәхәббәтне – ана һәм бала мәхәббәтен – чагылдыручы бер символ. Бишек җырлары белем һәм тәрбия бирүдә аеруча зур әһәмияткә ия. Әлеге әсәрләр моннан берничә гасыр элек үк барлыкка килгән. Аларның эчтәлеге еллар үткән саен камилләшә барган. Бишек җырларына мәшһүр татар классиклары Дәрдмәнд (Закир Рәмиев), Н. Думави (Нәҗип Тактамышев), Габдулла Тукай, Муса Җәлил һ.б. мөрәҗәгать иткән. Хәзерге чор әдипләре иҗатында да бу җырлар киң чагылыш таба.

Бишек җырларында нәрсә турында җырлана соң? Гадәттә, аларда баланың бәхетле, гыйлемле кеше булуын теләү чагылдырыла . Бишек җыры – ананың үзенчәлекле догасы ул. Бу уңайдан, Габдулла Тукай иҗат иткән “Бишек җыры”н искә төшереп үтик:

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу,
Галим булып җитәр бу.
Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син ,
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!

Бөек Тукаебыз язган “Бишек җыры”нда баланы укымышлы, акыллы, галим итеп күрү теләге ята. Аның җырында “йолдызым, бәгырем, гыйззәтем, кадерем, куанычым, шатлыгым” кебек иркәләү, назлау сүзләре урын алган. Кеше дөньяга беренче аваз салуга, аны тудырган ана үзенең сабыена туган телендә “балам” дип эндәшә. Баланың беренче әйткән сүзе дә туган телендә яңгырый. Кеше үзенең иң саф хисләрен бары тик туган телендә генә белдерә ала. Бөек Тукай юкка гына үзенең иң кадерле кешеләре әти-әниләренә рәхмәт сүзләрен, алар рухына багышлаган догаларын туган телендә белдермәгән.

И туган тел! Синдә булган
Иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
Әткәм-әнкәмне, Ходам!

Безнең халкыбызның күңел җәүһәрләре бары тик туган телдә генә сакланып калган. Бары тик туган телдә генә алар күңелнең иң нечкә кылларын

тибрәтә алганнар .

Тукай заманнарында еллар җиңел булмаган. Әниләребез һәм апаларыбыз. көннең-көн буена басудан кайтып кермәгән, урак урган, печән чапкан. Шулай да, аларның йөзләрендә һәрчак елмаю, авызларында уен сүз һәм җыр булган. Үзләренең балаларын да гореф-гадәтләргә таянып тәрбияләгәннәр.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,

Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

Һәр милләтнең халык иҗаты булган энҗе-мәрҗәннәрен оста башкаручы җырчы, уенчыклары булган кебек, татар халкының да урман-болыннарының, чишмә- елгаларының, басу-кырларының моңын сайрый торган үз тургайлары бар.

Аулак өйләр һәрчак уен-көлке, җыр-бию белән гөрләп торган. Анда егетләрнең тапкырлыгы, кызларның матурлыгы макталган, татар халкының шаян биюләре, уен-такмаклары җырланган.

Тау башына салынгандыр безнең авыл,

Бер чишмә бар , якын безнең авылга ул;

Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,

Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның бу шигъри юллары, балачагыбызның онытылмас хатирәләре булып, әле дә күңелебездә саклана. Җир куеныннан көмеш балдаклар чыгарып ургылучы чишмәләр кемгә генә кадерле түгел икән? Безнең бала-чагыбыз, гүя, шуннан башлана, яшел чирәмле чишмә юлы олы тормышка юл күрсәтә. Чишмәләр белән беррәттән гореф-гадәтләребез дә сакланган, чөнки алар бер-берсен тулыландырып, матурлап торганнар.

Авылларыбызда һәр ел саен гөрләп каз өмәләре үткән, казларны чишмәләрдә юганнар, су юлларына, казларның киләсе елда да күп булып уңуын теләп, каз каурыйлары сипкәннәр. Шулай ук бәрә ат кичендә зәм-зәм суы алу йоласы, чишмә янында изге теләк теләү йоласы, яшь киленгә су юлы күрсәтү, чишмә суына көмеш акча салу, сөлгеләр элү йолалары булган.

Елгаларга таба челтер-челтер йөгерә торган чишмәләргә карап, без хыял аша балачак иленә, үткәннәргә кайтабыз, халкыбызның гореф-гадәтләрен искә төшерәбез, чөнки алар халык тормышының истәлек хатирәләре һәм олы тарихы турында сөйлиләр.

Татар халкының иң гүзәл бәйрәмнәренең берсе – Сабантуй бәйрәме. Габдулла Тукай үзенең мәшһүр “Шүрәле”сендә мәйданны, сабан туе һәм җыен белән беррәттән, аерым бәйрәм дип атый:

Бу авылның мин җыен, мәйдан, Сабан туйларын

Язмыймын куркып, еракларга китер, дип, уйларым.

Тукай гади шагыйрь генә түгел, ул тәрбияче дә. Аның нәниләргә язылган шигырьләре һәммәсе дә диярлек тәрбияви әһәмияткә ия. Мәсәлән: олыларга ихтирам, олы мәхәббәте “Бабай” шигырендә чагыла. Бабай инде картайса да, үз якыннары өчен һәрчак матур, сөйкемле.

Шагыйрьнең иҗатында бердәнбер җылы кочагы, аны шатландыручы да, күңелен юатучы да булып - табигать тора. Аның табигатькә булган мәхәббәте чиксез, саф. Казан арты, Кырлай авылы...Ул Тукай йөрәгендә аерым урын алып тора. Г.Тукайның чын-чынлап гади крестьян тормышы белән танышуы да, табигатькә якынаюы да, туган илгә, аның гүзәллегенә мәхәббәт хисләре бөреләнә башлавы да нәкъ менә шушы авылдан башлана. Туган җирнең гүзәллеге, андагы барлык җан ияләренең дә күңеленә якынлыгы, аларга соклану аның шигырьләрендә зур урын алган.

Шагыйрь күңеле нигездә сабыйныкы сыман. Аның "Бәйрәм вә сабыйлык вакыты" шигыре бар.

Сабый вактын сагынмакта һәр шагыйрь дә,
Ачы-тәмле хыялдыр бу һәр шагыйрьгә;
Бәйрәм җитсә, минем дә исемә төшә:
Уйнамакчы булам сыйбъян берлән бергә.
Әнкәемнең тавышлары колагымда:
"Гает җитте, тор, аппагым! "

Бу шигырьне ныклап торып укып чыксаң, аның тирән мәгънәгә ия булуын беләсең. Тукай үзенең бала вакытта бәйрәм көннәрен, әнисенең җылы сүзләрен, ягымлы карашын, иртән уйнап йөргән чакларын искә ала. Кире әйләнеп кайтуларын сорый.

Шигърияте төп ике максатны күздә тота: тәрбияләү һәм танып-белергә өйрәтү. Тематик яктан бәяләгәндә, аның шыгырьләре күп төрле һәм үзенчәлекле. Бүгенге көндә балаларны тәрбияләүдә игътибар үзәгендә торырга тиешле татар милләтен, телен, туган җирен, аның гореф-гадәтләрен, фольклорын, әдәбиятын яратуы, горурлануы турындагылары аеруча әһәмиятле.

Татар бәхете өчен мин җан атармын,
Татар бит мин, үзем дә чын татармын, – дип яза Г. Тукай 1906 нчы елда "Үз-үзенә" шигырендә. Милләтенә булган мәхәббәте, туган теленә хөрмәте, телнең бала тәрбияләүдә тоткан урынын билгели алуы бүгенче көндә милләтнең гимны булып әвәрләнгән "Туган тел" шигырендә дә ачык чагыла:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Гомумән Тукай үзенең хезмәтләрендә матур әдәбиятның, халык авыз иҗаты һәм сәхнә әсәрләрен, рәсем сәнгатен, җыр һәм музыканы балага тәрбия бирүдә көчле чара дип исәпләвен белдерә.

## Ф.САДРИЕВНЫҢ "КЫРГЫЙ АЛМА ӘЧЕСЕ" ПОВЕСТЕНЫҢ ТӘРБИЯВИ ӘҺӘМИЯТЕ

*Ханова Рузилә,*
*Сарман гимназиясенең IX сыйныф укучысы;*
*Мәрданова Камилә,*
*Сарман гимназиясенең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Ханова Нурания Вәзир кызы*

Әдәби әсәр ул – сүз ярдәмендә әдип тарафыннан төзелгән бер аерым дөнья. Язучы әсәрен иҗат иткәндә, аңа бик күп рухи энергиясен сала. Әдипнең иҗат кодрәте, куәте эстетик энергиягә әверелеп, укучының күңел дөньясына үтеп кереп тәрбияли. Эстетик энергия югары сәнгатьлелек җирлегендә барлыкка килә, әсәрнең барлык компонентлары шуңа хезмәт итәләр. Талантлы язучы моны ачык тоя һәм рухи, иҗат сәләтен тагын да камилләштерергә омтыла.

Тәрбия – җәмгыятьтә кабул ителгән яшәү кагыйдәләре җыелмасы.

Ул, хупланган сыйфатларны формалаштыру өчен, кешелек җәмгыяте белән бергә хезмәт эшчәнлеге процессында туган һәм һәрвакыт яши. Шунлыктан тәрбия бирү һәрчак актуаль тема булып кала. Җәмгыять тарихында тәрбия эшенә битараф кеше булмаган һәм була алмый. Аның иң үтемле чарасы булып, әдәби әсәр тора.

Автор мәхәббәт, бәхет, хыял һәм чынбарлык, һөнәр, аның әһәмияте турында яза. Бу темалар әдәбиятта Г. Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар”, С. Җәләлнең “Дим буенда” повестьларында чагыла.

Ф. Садриевның “Кыргый алма әчесе” повестен тикшергәндә, әдәбият галиме Дания Заһидуллина хезмәтләреннән, Г. Саттаровның “Татар исемнәре сүзлеге” ннән, “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” ннән файдаландык

XX гасыр татар әдәбиятында романтизм юнәлеше яши һәм 1980 нче еллардан алып яңадан күтәрелеш кичерә, саф романтик әдәбият активлаша.

Ф. Садриевның “Кыргый алма әчесе” – романтик повесть. Төп сюжет сызыгын Вилданның үз эчендәге каршылыгы барлыкка китерә. Мәхәббәт һәм көнчелек, хис һәм акыл, үзеңне генә ярату һәм Әнвәрәне, артистлык һөнәрен ярату каршылыклары Вилданның күңелендә яши һәм көрәшә. Ул үзен генә яратучы, эгоист зат итеп сурәтләнә.

Ярдәмче сюжет сызыклары өчәү: Вилдан һәм Әнвәрә сызыгы – аларның мәхәббәте тарихы; Әнвәрә – Мансур сызыгы – гаилә тарихы; Әнвәрә – Нәсимә – дуслык тарихы. Бу ярдәмче сюжет сызыклары Әнвәрә белән Вилдан характерларын ачарга ярдәм итә һәм ике төрле тормыш моделе төзүдә катнаша.

“ Машина белән машина бәрелешсә – һәлакәт була. Бер-берсе өчен яралган ике йөрәк язмыш сызган борылмалы озын юллар аша очрашса, мәхәббәт туа”, – дип яза автор [Садриев 2007 :263].

Вилдан Әнвәрәгә гашыйк була, әмма ул тамашачының да аны яратуын кичерә алмый. Мәхәббәткә шарт куя: я мин, я сәхнә, ди. Беренче модель – мәхәббәт хакына Әнвәрәнең театрдан китүен таләп итү. Бу – ике кешенең бәхетсезлегенә китерә, мәхәббәтне юкка чыгара.

Икенче модель – мәхәббәттә үз-үзеңне “ онытып” башка кешене ярату, аны аңларга һәм сакларга омтылып яшәү. Мансур яраткан кешесен, аның мәнфәгатьләрен беренче планга куя. Әнвәрә белән Нәсимә дуслыгы да шушы модельгә керә. Нәсимә яраткан кешеләре – Мансур белән Әнвәрә хакына мәхәббәтеннән баш тарта.

Әдәби образлар ике төрле була: объектив һәм субъектив.

Объектив образлар – сурәтләнгән дөньяда, әдәби әсәр тергезгән тормыш моделендә хәрәкәт итүче, катнашучы. Болар: Вилдан, Әнвәрә, Мансур, Нәсимә, Газизә, Сабирҗан.

Субъектив образлар – хикәяләүче, “мин”, автор образы, лирик герой, лирик “мин”. Боларга авторны һәм укучыларны кертәбез.

Әдәбиятта тип – аерым бер төркем кешеләргә хас билгеле сыйфатларны үзенә туплаган герой. Ф.Садриев повестенда ике романтик тип иҗат итә. Алар Вилдан һәм Әнвәрә. Икесе дә талантлы, хис кешеләре булган артистлар. Әнвәрә – хис белән яшәүче, сизгер күңелле, үз хезмәтеннән тәм табып яшәүче гүзәл зат.

Ул театрдан башка тормышын күз алдына да китерә алмый. Мәхәббәте һәм яраткан һөнәре арасында сайлау шартына күнә алмый. Ул моны Вилданга турыдан аңлаешлы итеп әйтә. Әнвәрә талантын башкалар белән уртаклашып яши, шуннан ләззәт ала. Ә Вилдан аңа капма-каршы итеп куелган. Ул да талант иясе, рәссам, җырчы, фәлсәфәче. Әмма ул үзен яратучы эгоист, талантын башкалар белән бүлешергә теләмәүче зат. Мәхәббәттә дә ул үз-үзен җиңә алмаучы итеп күрсәтә. Көнчелек, үзен генә беренче итеп күрергә өйрәнгән Вилдан үзенең дә, Әнвәрәнең дә бәхетсезлегенә сәбәпче була.

Автор геройларына бик матур исемнәр сайлаган.Аларны ачыклау өчен Г. Саттаровның “Татар исемнәре сүзлеге“ нә мөрәҗәгать иттек һәм түбәндәгеләрне ачыкладык.

Әнвәрә – гарәп сүзе, бик нурлы, бик якты дигәнне аңлата. Вилдан – гарәп сүзе. 1. Ир балалар, угыллар. 2. Оҗмаһ хезмәтчесе. Мансур – гарәп сүзе, өстен чыгучы, җиңүче. Нәсимә – йомшак күңелле, мөлаем; йомшак җил, җиңелчә сулыш. Нәфис – гарәп сүзе, нәфис, күркәм, чибәр. Сабирҗан – гарәп-фарсы сүзе, сабыр + җан. Газизә – гарәп сүзе. 1. Бик кадерле, кыйммәтле; хөрмәтле, данлы. 2. Дәртле, көчле.

Геройларның исемнәре (Вилданнан кала) аларның холык, сыйфатларына туры килә.

Кеше образлары белән беррәттән табигать образлары да кулланылган. Аларга тау, әби чәче, кыргый алма агачы, кош тәпиенә уралган еланнарны керттек.

Тау – бөеклек, дәрәҗә; әби чәче – сагыш, кош – биеклеккә омтылучы җан, рухи ирек, илаһилык, хис; елан – акыл.

Әсәрдә Әнвәрәнең төшләр күрүе әһәмиятле. Әдәбиятны аңлау,төшенү, эчтәлегенең тирәнлеген тою өчен дә төшләрдәге образлар һәм символларның мәгънәсен белү кирәк. Боларны ачыклау өчен “Төшлек” (“Төшләрне юрау”) китабына мөрәҗәгать иттек. Тау – олы, мәртәбәле булу. Ай – дәрәҗәле булу.
Төн – яманлыктан саклану. Буран – бәла. Ялан кыр – бәхетсезлектән котылып, гөнаһтан кайту. Курку – бәладән имин булу.

Мансур тауга Нәфис белән бик тиз менеп җитә, әмма Әнвәрә ярты юлда көрткә батып, япа-ялгыз кала. Рухи биеклеккә ирешә алмый әле. Әнвәрәнең төшләре куркыныч булса да, Вилдан белән мөнәсәбәтләре ачыклана. Ул

Вилданның сәхнәне яратуын белә.. Вилдан беркайчан да Әнвәрәне бәхетле итә алмаячагын белә, чөнки Әнвәрә аның көндәше дә. Мәхәббәт ул – илаһи хис кенә түгел, ә бик зур җаваплылык та.

Әсәрнең исеменә чыгарылган кыргый алмагач – метафора. Ул – Вилдан. Ялгызлыкка омтылучы, һәр җирдә камиллек эзләүче герой. Кыргый алмагачның җимеше ачы, әмма Әнвәрә аны йота алырлык, бәхеткә лаеклы итеп тасвирлана.

Идея – әсәрдәге конкрет вакыйгалар һәм җанлы образлар сурәтләнешендә бирелгән төп фикер. Язучы мәхәббәтегезне саклагыз, яраткан һөнәрегез сезгә ләззәт бирсен, бәхетле һәм әхлаклы булыгыз, ди.

Әдәбият

Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007.

Садриев Ф. М. Көлми торган кеше. – Түбән Кама:, "Ихлас" нәшр., 2004. – 376 б.

Татар исемнәре сүзлеге. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1981.

Татар әдәбияты: Теория. Тарих/ Д. Ф. Заһидуллина, Ә. М. Закирҗанов, Т. Ш. Гыйләҗев, Н. М. Йосыпова. Тулыл. 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 316 б.

## ТЕЛ – БЕЛЕМ ЧИШМӘСЕ

*Хәбибуллин Илнур,*
*Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең XI сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Шакирҗанова Нурсинә Газинур кызы*

Туган тел! Һәркем өчен дә газиз бу сүз. Чөнки иң кадерле "әти", "әни", "әби", "бабай" сүзләрен туган телдә әйтәбез. Туган-үскән илнең якынлыгын, Ватанның газизлеген тоярга да безгә туган тел ярдәм итә.

Туган телен кадерләгән халык кадерле була. Әйе, безнең телебез – бик борынгы һәм бай телләрнең берсе. "Без татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул",- дигән телебезне үстерүгә гаять зур өлеш керткән Каюм Насыйри [Насыйри 1974 : 19].

Бу фикерне үстереп, Г. Ибраһимов 1913 нче елда ук болай язган иде: "Мәдәни халыкларның мәктәбләрендә иң әһәмият бирелеп, укытылуы лазем вә фарыз дәрәҗәсендә тотылган фәннәрнең иң беренчесе – тел вә әдәбият миллиядер. Тел вә әдәбиятның мәктәбтә рәсми дәресләр эчендә тотачак урыны мәдәни халыклар тарафыннан кубдән тәгаен кыйлынган, ачык, табигый вә уңайлы рәвешдә билгеләнеп беткән инде" [Ибраһимов 2007 :102].

Тел кешенең тормышында зур урын тота. Ул – тормыш чыганагы, белем чишмәсе. Ул кешеләр белән бер-берсе белән аралашырга, аңлашырга, бер-берсенең теләк-максатларын, уй-фикерләрен белергә ярдәм итә. " Халыкның теле - аның бөтен рухи тормышының иң яхшы, беркайчан да шиңми, мәңге

яшәреп тора торган иң матур чәчәге. Телдә бөтен халык һәм аның ватаны җанлы рәвештә гәүдәләнә”, – дигән бөек рус педагогы Г. Ушинский [Ушинский 1950 : 511]. Шуның өчен дә туган телне – ана телен – яхшы белү, аның бөтен нечкәлекләрен өйрәнү һәм өйрәтү – безнең бурычыбыз.

Г. Ибраһимов ассызыклаганча, “тел” дигән нәрсә сүз белән җөмлә генә түгел, тел дәресе димәктә имля вә сарыфның кагыйдәләрен ядлату гына түгел – болар тышкы як кына. Телнең эчендә халыкның рухы, моңы, уй вә тойгысы яшеренгән. Бу – бер хәзинә. Телнең камил алынуы нәтиҗәсендә бала ихтыярсыз шул хәзинәне сөя, шул рух белән сугарыла. Бала үзен халыкның угълы итеп хис кыла [Ибраһимов 2007: 110].

Шәхес – тел һәм мәдәният бәйләнеше үзәге, шуңа күрә телдә гәүдәләндерелгән шәхес турында гына сүз алып барырга мөмкин. Бала тел аша тирә - якны өйрәнә һәм үзен башкалар арасында таныта.

Тел дәресләре балаларны халкыбызның рухи-әхлакый идеалларына китерергә, аларда югары сөйләм культурасы формалаштырырга, иҗади сәләтләрен үстерергә, мөстәкыйль уйларга һәм эшләргә омтылышын канәгатьләндерергә тиеш. Бүгенге тормыш шартлары укытучыга бала шәхесен тирәнтен һәм һәрьяклап өйрәнү бурычын йөкли.

Укучыларны татар теленнән ныклы белемнәр белән тәэмин итүдә, сөйләм күнекмәләрен булдыруда, дәресләр белән беррәттән, класстан тыш эшләр дә зур урынны алып тора. Тиешле дәрәҗәдә оештырылган класстан тыш эшләрнең формалары һәм төрләре, бер яктан, дәрестә алган белем һәм күнекмәләрне ныгыту, татар теленең байлыгын ачу, дәрестә өйрәнелмәгән, әмма әһәмияте зур булган фактлар белән таныштыру мөмкинлекләрен ачса, икенче яктан, укучыларга әхлакый тәрбия бирүдә дә роль уйный.

Мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытучысының эше җаваплы һәм шактый ук катлаулы. Туган тел чаралары белән укучыларга тирән йогынты ясарга омтылу, тәрбия максатларында телнең киң һәм бай мөмкинлекләренә таяну укытучыдан киеренке рухи эшчәнлек, тирән белемнәр һәм педагогик осталык таләп итә. “Милли мәктәп бер агачка охшатылса, аның тамыр үзәге – ана теле. Әмма башка фәннәр шуннан үсеп чыккан ботаклар,яфрак вә җимешләр дип санала”, – дип язган иде Г.Ибраһимов 1918 нче елда ук “Татар телен ничек укытырга?” мәкаләсендә [Ибраһимов 1918 :46]. Димәк, татар теле укытучысы, үзенең укучыларына татар телендә белем бирү, аларны логик эзлекле, төгәл һәм матур итеп сөйләргә, грамоталы итеп язарга өйрәтү белән беррәттән, мәктәптә укытыла торган башка предметларны үз ана телендә үзләштерүгә җирлек әзерли.

Мәктәп балаларында туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, аның аша яшь буында патриотик омтылышлар булдыру, башка халыкларның да туган телен олылау, сүз ярдәмендә безне чолгап алган табигать һәм тормыш матурлыгын тою кебек олы хисләр тәрбияләү зарурлыгын да исәпкә алсаң, укытучы өстенә нинди җаваплы эшләр йөкләнүен сиземләү авыр түгел. Шуңа күрә дә аңа,

дәресләр уздыру белән генә чикләнмичә, системалы һәм планлы рәвештә класстан тыш эшләр дә оештырырга туры килә.

Уку-укыту процессында класстан тыш эшләр укучы шәхесен формалаштыру ягыннан да нәтиҗәле чара булып тора. Алар укучыга мөстәкыйльлек һәм иҗади активлык күрсәтү өчен дә мөмкинлекләр тудыра. Күп очракта нәкъ класстан тыш эшләрдә укучылар үзләрен таныталар, чөнки дәресләр өчен кабул ителгән катгый тәртипләр яшүсмергә хас булган хәрәкәтчәнлек, кызыксыну, барысына да омтылып катнаша алу мөмкинлеге табу, шаярышу-көлешүләр кебек гаять кирәкле эмоциональ ихтыяҗларның тәэмин ителүенә киртәләр тудыра.

Нәтиҗәдә дәрестә кемнең кем икәнен аңлап бетерүе кыен була. Укытучыга, дәресләрне сыйфатлы һәм нәтиҗәле алып бару өстенә класстан тыш эшләргә дә зур өметләр багларга туры килә: мәктәп балаларында туган телгә мәхәббәт, аны өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләү һәм тирәнрәк белергә омтылыш тудыру; сөйләгән һәм язган чакта һәр әйтелгән һәм язылган сүзең өчен җаваплылык хисе тоярга күнектерү; туган тел турында күп белү, аны олылауның, фикерне аңлаешлы, күңелдәге хисләрнең матур һәм үтемле итеп әйтеп бирә белүнең һәрбер мәдәниятле кеше өчен зарури икәнлеген төшендерү.

Әдәбият


Ибраһимов Г. Милләт. Тел. Әдәбият: сайланма хезмәтләр. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б.102

Ибраһимов Г. Татар телен ничек укытырга.– Казан:1918. – Б.46.

Ибраһимов Г.Г. Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма хезмәтләр. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б.110.

Насыйри К. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1974. – Т.1. – Б.19.

Ушинский К.Д. Собрание сочинений. – М., 1950. – Т. 10. – С.511.


## АНА ТЕЛЕННӘН КЛАССТАН ТЫШ ЭШЛӘРНЕҢ НИГЕЗЛӘРЕ


*Хөсәенова Гөлназ,*

*Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең XI сыйныф укучысы*

*Фәнни җитәкче: Агмалова Эльвира Эльбрус кызы*


Класстан тыш тәрбия эшләре алып бару – балаларга төп белем бирүнең, аларны шәхес буларак үстерүнең аерылгысыз бер өлеше.

Укучыларның белемен ныгыту һәм тирәнәйтү, эстетик зәвыкларын үстерү, аларда әхлакый сыйфатлар, коллективизм хисе тәрбияләү, гомумән, өстәмә белем бирү максатыннан, мәктәптә класстан тыш һәм дәрестән тыш вакытта фән атналыклары, декада һәм айлыклары, төрле олимпиада, конкурслар, диспут, әдәби-музыкаль кичәләр, эшлекле интеллектуаль уеннар һ.б. шундыйларны уздыру алар өчен бик файдалы.

Мондый чараларны үткәрүдә, гадәттә, укучылар үзләре дә, ата-аналар да, мәктәпкә шефлык итүче оешма вәкилләре дә катнашырга мөмкин. Спорт

сарайлары, китапханәләр, балалар һәм яшүсмерләрнең ял вакытларын оештыруга бәйле башка төр мәдәният учаклары ярдәмен файдалану мөмкинлеге турында инде сөйләп тору артык булыр иде. Тик шунысы бик тә мөһим: укучыларның мәктәптән тыш тәрбия сәгатьләрендә үз эшен, үз һөнәрен яхшы белгән, тәрбия эшенең барлык нечкәлекләрен тирән тойган кешеләр катнашырга тиеш.

Класстан тыш тәрбия эшенең тагын бер әһәмиятле принцибы – үткәрелгән һәрбер эшнең, чараның файдалы булуы. Нинди генә эш башкармасын, нинди генә шөгыль тапмасын – укучы үз эшенең, үз шөгыленең файдалы, кирәкле, мәртәбәле икәнен тоярга тиеш. Гомумән, кеше өчен иң зур җәзаларның берсе – файдасыз, кирәсез, мәгънәсез һәм нәтиҗәсез эш башкару, шул эшкә көч сарыф итү. Үз эшенең, үзе катнашкан, үзе башкарган эшенең файдасын, нәтиҗәсен ачык күргәндә генә, укучы бала үткәрелгән чараларга чын-чынлап күңелен сала.

Эшебездә тагын бер принцип, ул да булса – дәвамлылык: бер төрле чараларны икенчеләре белән үз вакытында чиратлаштыра, алыштыра белү, ирешелгән биеклектән алга күчү.

Класстан тыш эшчәнлек барышында сайлап алынган һәр төрле чараларның үзара бәйләнештә булырга тиешлеге – шулай ук иң мөһим принципның берсе һәм ул укучыларны тәрбияләүнең комплекслы алып барылуын тәэмин итә.

Югарыда телгә алынган принциплар – класстан тыш алып барыла торган чаралар өчен зарур булган принципларның әле бик азы, әмма шактый ук зарури булганы. Аңлашыла ки, алар үзара тыгыз бәйләнештә булырга тиеш. Әлеге принципларны аңлап, үзлегеннән тулыландырып эш итү укучыларны тәрбияләүдә матур-матур нәтиҗәләр бирергә мөмкин.

Тагын бер мөһим принцип: бу – бертөрле чараларны икенчеләре белән үз вакытында чиратлаштыра, аралаштыра белү, ирешелгән биеклектән алга күчү, һәрбер түгәрәктә, балаларның һәрбер иҗат төркемендә эзлекле үсеш алып барырга, сорауларны чамасын белеп кенә катлауландырырга, зуррак таләпләргә җавап бирерлек итә барырга мөмкин бит, ул укучыларны тәрбияләүнең комплекслы алып барылуын тәэмин итә.

Класстан тыш эшләрне үткәргәндә түбәндәге максатларны күз алдында тотарга кирәк:

- татар теле дәресләрен уздыру вакытында коммуникативлык принцибын киң җәелдерүне булдыру;
- класстан тыш эшләрнең өйрәнелә торган материалны тагын да ныграк үзләштерүгә ярдәм итүе, мөстәкыйльлекне, иҗади инициативаны арттыруы – төп максатларның берсе;
- класстан тыш эшләрне үткәреп, татар теленә, татар халкына, гореф-гадәтләренә карата мәхәббәт уятуны булдыру.

Бар яктан да камил булган шәхес тәрбияләгәндә, укытучылар укучыларның уйлау-фикерләү һәм иҗади мөстәкыйльлекләренә игътибар

итәргә тиешләр. Хәзерге вакытта татар теленнән класстан тыш эшләр бик күп үткәрелә.

Класстан тыш эш уздыру ул – яңа белем туплау да.

Класстан тыш эшләр өйрәнелә торган материалны тагын да ныграк үзләштерергә, мөстәкыйль эшләүне булдыруга, иҗади инициативаны арттыруга, шулай ук татар теленә мәхәббәт уятуга да зур этәргеч булып тора. Класстан тыш эшләрне үткәрү өчен, аның эчтәлеген ныклап уйларга кирәк. Шул вакытта гына ул кызыклы да, мавыктыргыч та булачак.

## ҖИРЛЕ ШАГЫЙРӘ ГӨЛЧӘЧӘК ЮСУПОВА ИҖАТЫНДА ТЕЛҺӘМ ӘХЛАК ПРОБЛЕМАЛАРЫ

*Хөснетдинова Әлфия,*
*Чуаш Республикасы Батыр районы*
*Шыгырдан урта мәктәбенең XI сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Мтеева Зәкия Шәйхулла кызы*

Батыр районы Шыгырдан авылы Чуашстанның үзенә бер татар утравы, үзенең эчке кануннары нигезендә яшәүче татар дөньясы. Бирейдәге халыкның динен, телен сакларга тырышып яшәве, замана шартларында яшь буынга әхлак, дин тәрбиясе биреп, милли кыйммәтләребезгә тугры калып яшәргә омтылулары күпләрне сокландыра. Шыгырдан халкы әүвәл-әүвәлдән әдәпле, эшчән, кешелекле булуы белән аерылып торган. Тормыштан ямь-тәм табып, берне биш итеп, булсын дип эшләп, дин, иман белән яшәгән. Авыл тырыш, эш сөючән халкы, туган авылга булган мәхәббәте аркасында инде әллә ничә гасырдан артык матур итеп яшәп килә.

Һәр якның, һәр халыкның тарихына игътибарны үзенә тартып торучы исемнәр була. Тарихның бер чорында алар белән кызыксыну аеруча үсеп китә. Моның сәбәбе андый шәхеснең теге яки бу халыкның мәдәниятенә керткән өлешенең зурлыгына бәйле.

Безнең дә туган як татар дөньясына бик күп талантлар биргән як. Фәтхи Бурнаш, Дамир Гыйсметдин, Ркаил Зәйдулла, Рөстәм Сүльтиләрне үстергән як ул. Алар турында горурланып сөйлибез, кылган гамәлләре хөрмәтләнә, иң әһәмиятлесе, яшь буын шулар үрнәгендә тәрбияләнә.

“Милләтен яшәтә алган шагыйрьнең, шагыйрен яшәтә алган милләтнең генә киләчәге бар“,– дигән мәкаль нәкъ безнең якның шагыйрьләре турында әйтелгәндер ул..

Без сезне үзебезнең якның, үзебезнең авылдашыбыз, үзебезнең укытучыбыз, шагыйрәбез Юсупова Гөлчәчәк Фәрәхетдин кызы иҗаты буенча таныштырырга булдык, чөнки туган телебезне саклау, бездән соңгы килгән буынга җиткерү, атаклы шәхесләребезнең иҗат эшчәнлеген өйрәнү – бик актуаль мәсьәләләрнең берсе.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә тарихыбыз битләрендә тирән эз калдырган, үз чорларының бөек шәхесләре булган һәм мең еллар элек яшәгән

каләм әһелләрен өйрәнү белән беррәттән, һичшиксез, бүгенге көндә иҗади сукмаклар буйлап атлаган җирле әдипләрне өйрәнү дә бик урынлы һәм кирәкле.

Беренчедән, җирле шагыйрьләребезнең, әдипләребезнең иҗат җимешләре балалар тарафыннан җиңелрәк кабул ителә. Әлеге иҗат шәхесләрен өйрәнү балаларның күңелләрендә әдәбиятка мәхәббәт уята һәм аларда яшеренеп яткан иҗат орлыкларын ача ала.

Икенчедән, без туган ягыбызнының үз төбәгенә генә хас булган кабатланмас матурлыгын күрергә, бай тарихын өйрәнергә, күренекле шәхесләре белән танышырга бурычлыбыз. Чөнки соңгы елларда яшүсмерләр арасында әдәби китап укуга игътибар нык кимеде. Балаларны китап укуга тартуда, әдәбият белән кызыксындыруда, патриотик тәрбия бирүдә, туган якның үткәне, бүгенгесе, киләчәгенә кызыксыну уятуда әдәби туган як материалларын өйрәнүнең әһәмияте бик зур.

Милләтнең киләчәге – аның мәгърифәтле булуында икәнлегенә инанган шәхесләребезнең берсе – авылыбызның шагыйрәсе Юсупова Гөлчәчәк Фәрәхетдин кызы. Ул 1932 елда Чуаш Республикасы Батыр районындагы Шыгырдан авылында туган. Гөлчәчәк апа авыл мәктәбен 1946 елда уңышлы тәмамлап, укытучы теләге белән Батыр педучилищесына укырга керә. Укып бетереп, башлангыч классларда укытуга хокук алгач, укуын Канаш укытучылар институтының филология факультетында дәвам итә.

Гөлчәчәк Фәрәхетдин кызы укыган вакытта ук шигъриятъ үзенең көчен сынап карый һәм үзенең әнисенә багышланган “Әнием” дигән шигырен яза.

Син тудырдың, әнием, син үстердең,
Көч бирдең безнең йөрәкләргә.
Тик синең аркаңда, әнием – бәгърем,
Ирештек изге теләкләргә.

Институтны тәмамлаганнан соң, Гөлчәчәк апа үзебезнең авылда ук рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлый. Башы – аягы белән мәктәпкә чума һәм үзенә яңа бер дөнья ача – балалар дөньясы. Балалар күңеле аның җанына яктылык биреп, шигырьләренә нур өсти. Аның “Шигырь дустыма” дигән шигырендә мондый юллар бар:

Шигырь – сулаган сулышым,
Шигырь – минем юлдашым,
Шигырь – минем тынычлыгым ул,
Шигырь – минем җан ашым.

Гөлчәчәк Фәрәхетдин кызы, дөрестән дә, үзенең күңеленә шигырьләрдән җан азыгы таба. Утыз елдан артык мәктәптә эшләп лаеклы ялга чykkаннан соң күңеленә, шигъриятькә иркенлек ачыла. Буш вакытларында иҗади эш белән шөгыльләнә, шигърият дөньясына чума. Гомере буена татар балаларына рус теле өйрәтсә дә, ул һәрвакытта да татар кызы, татар милләтенең сөекле кешесе булып калды.

Гөлчәчәк апаның тирән мәгънәле, халыкчан язылган шигырьләре һәм поэмалары Чувашстан Җөмһүрияте җирлегендә чыгып килүче Батыр районы

газетасы “Авангардта” һәм республика күләмендәге “Вакыт” газеталарында дөнья күрәләр. 2001нче елда Гөлчәчәк Фәрәхетдин кызының шигырьләре һәм поэмалар җыентыгы “Вәгъдә көче” дигән китабында бастырылып чыгарылды.

“Вәгъдә көче” – җан көче, илһам чишмәсе, – ди ул үзенең беренче китабы турында.

Гөлчәчәк ханымның шигырьләре үзе туган, яшәгән һәм әсәрләрен иҗат иткән урыннан аерылгысыз, чөнки ул иҗаты өчен азыкны үзенә яхшы таныш булган җирлектән ала. Шагыйрәне сокландырган туган табигать, аның кешеләре, тормыш – көнкүреш йолалары әсәрләренә күчәләр. Туган авылыбызга булган кызыксыну хисләрен тәрбияләүдә аның өлеше бәяләп бетермәслек дәрәҗәдә зур.

“Шыгырданым” дигән зур күләмле поэмасын ул үзенең халкына эндәшеп болай дип башлап китә:

“Сөекле халкым, туган җирем,  
Сезгә багышлыйм бу шигырем”.

Шыгырдан авылының килеп чыгышын, аның искиткеч матур табигатен, күренекле кешеләрен һәм бүгенге көндә авылның үсешен шигырь юлларына салып бик үтемле, кызыксындыргыч итеп тасвирлавы гына ни тора. Бу шигырь туган җиребезне, авылыбызны тагы да яратырга, аның башка төбәкләрдән аермалы булган үзенчәлекле якларын ачарга ярдәм итә.

Шундый минем Шыгырданым,  
Шундый ул туган ягым.  
Җанга рәхәтлек бирүче  
Тынычлык чыганагым!

Гөлчәчәк апаның һәр әсәрендә кеше язмышы. Шул язмышлар арасыннан мин таныш йөзләрне эзлим. Менә аның “Солдат улыма”, “Шофер улыма”, “Мәк чәчәге”, “Исән чакта әйтим әле улым” шигырьләре аның ике улына багышланган икәнлеге әллә каян күренеп тора. “Рәхмәт” шигырендә ул үзенең кызы белән сөйләшә. Ана кызы бүләк иткән чәчәкләргә шундый сөенә һәм кызына булган чиксез рәхмәтен белдерә.

Эх, шатландым да соң, кызым,  
Син биргән бүләкләргә;  
Күзем алмыйм, һаман карыйм  
ак тюльпан – чәчәкләргә.

Әхлакый тәрбия бирү – кешелек дөньясы алдында торган иң мөһим проблемаларның берсе. Кешенең әхлагы булмаса, ул үзе дә, тирә -ягындагылар да бәхетсез була. Кызганычка каршы, бүгенге көндә бу проблема көн кадагына сугылган проблемаларның берсе. “Үкенү” поэмасында нәкъ шул проблема күтәрелгән дә. Шагыйрәнең Назлыгөле образында хәзерге көндә үз балаларыннан кадер-хөрмәт күрмәгән ата-анага карата ихтирам хисе юкка чыгуын күрсәтә. Әйе, кадер-хөрмәттә, ата-ана назын тоеп үскән балалар да “бозыла” кайвакыт. Назлыгөл дә картаеп барган әнисенә ихтирам күрсәтми, җилбәзәк булып, әхлак бозып яши. Шул дәрәҗәгә җитә, тапкан баласын

шифаханәдә ташлап калдыра. Мондый күренеш хәзер еш кабатлана, ата- аналы ятимнәр саны арта бара. Поэмада шундый үтемле юллар бар:

Яшьлек хатасын ясара
Берничә минут җитә.
Ләкин аны төзәтергә
Бик озак вакыт китә.
Җибәрмәскә тырышыйк без
Андый зур хаталарны.
Киңәш сорап, тыңлап яшик
Аналар – аталарны.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсебез килә: Гөлчәчәк апа һәр шигырендә тәрбияне гореф-гадәтләр, йолалар, әнкәйләргә хөрмәт, туган җирне ярату хисләре аша бирергә кирәклеген искәртә. Шигырь һәм поэмаларында сурәтләнгән гыйбрәтле хәлләр аша җәмгыятьтәге тәртипсезлекләребезнең сәбәпләрен күрсәтә. Аның иҗаты бүгенге көндә халыкны нык борчый торган мәсьәләләрне – туган җир, туган тел, милли тәрбия, әхлак темаларын яктыртуы белән кыйммәтле!

Әдәбият

Юсупова Г. Вәгъдә көче. – Батыр, 2000.

## М. МӘҺДИЕВНЕҢ «БЕЗ – КЫРЫК БЕРЕНЧЕ ЕЛ БАЛАЛАРЫ» ПОВЕСТЕНДА ТЕЛ-СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ

*Чигвинцева Зөлфия,*
*Әгерҗе районы Иж-Бубый мәктәбенең IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Хәлиуллина Лилия Равил кызы*

Мөхәммәт Мәһдиев үзеннең һәр әсәрендә диярлек сугыш алып килгән авырлыклар һәм корбаннар турында сөйли. Халкыбызның рухи дөньясында сугыш тудырган үзгәрешләр турында уйлана. Ул үзе дә яшьлекләре авыр сугыш елларына туры килгән буынның бер вәкиле. «Без – кырык беренче ел балалары» исемле повестенда да Бөек Ватан сугышы чорының авыр шартларында педагогия училищесында укучы яшүсмерләрнең көндәлек тормышы, аларның дөньяны танып белергә өйрәнүләре, үзенчәлекле кеше характерлары аша сурәтләнә. Повесть үткен, күп бизәкле тел белән иҗат ителгән. Җанлы сөйләм теленә нигезләнгән, беренче зат тарафыннан язылган.

М. Мәһдиев әсәрләренең кайсысын гына алма, һәрберсендә автор образы бар. Ул күбрәк «без» ди. Ләкин әсәрләрендә автор хикәяләүче генә, әйтә торган фикерләр, уйлар, искәрмәләр, лирик чигенешләр күп урын алган. Мәсәлән, «Без - кырык беренче ел балалары» повестеның ахырында ул риторик эндәшләрне бик яратып куллана. Әсәр гаҗәеп дәрәҗәдә халыкчан рухлы, олы хисле, зур яңгырашлы. Һәм, Мөхәммәт Мәһдиевкә генә хас булганча, повесть нindидер бер конфликтка нигезләнгән логик эзлекле хикәяләүдән баш тартып, бер-берсен

еш һәм көтелмәгәндәрәк алыштырып торучы аерым эпизод-новеллалардан тора дияргә була.

Автор бер вакыйгадан икенчесенә, бер урыннан икенче урынга бер дәвердән икенче дәвергә, күперләр салып тормыйча, җиңел күчеп йөри. Шуңа бәйле рәвештә аның язу стиленең характеры да үзгәрә: кырыс реализм, драматизм, юмор, лиризм, сатира үзара бер-берсе белән гел аралашып, чиратлашып бара. Гомумән, нечкә юмор, ирония, жорлык, халыкчан тапкырлык язучы стиленә хас төп сыйфатлардан саналалар.

Аның үзенчәлеге – поэтик хикәяләүдә, ягъни әсәрләренең җылы юмор белән өретелеп, кайнар лирика белән сугарылып тукылуында, аерым язмышларның, драматик һәм трагик хәлләрнең хезмәт героикасы, лирик күренешләр, уен-көлке белән чиратлашып баруда.

Язу стиленең кайсыдыр яклары белән ул иң элек А. Чеховны, аннан сүзләрнең җылылыгы, йомшаклыгы һәм төсенә кадәр сизелеп язуы, шигъри прозага йөз тотуы белән И. Тургеневны хәтерләтә. Тормышның нечкә детальләрен эләктереп алу һәм бер-ике штрих белән генә дә тулы һәм бөтен образны күз алдына китереп бастыра алу сәләте белән В.Шукшинга тартым. Үзебезнең әдәбиятта исә, аны барыннан да элек, Ә.Еникичә төгәллеккә, психологик тирәнлеккә һәм шигырь дәрәҗәсенә җиткерелгән стиль камиллегенә омтылган җорлыгы, шаянлыгы белән күпмедер дәрәҗәдә Ф.Хөснине искә төшергән прозаик. Шулайда Мәһдиев һичкемне кабатламый, ул барыннан да элек үзенчә, Мәһдиевчә яза. Аның стилен, ул тудырган образларны һичкем белән бутау мөмкин түгел. Һәммәсенең үз арабыздагы тормыштан икәнлеген танырга туры килә. Һәр очракта чама хисе һәм нечкә зәвык аны кабатлану һәм урында таптанулардан коткарырга әзер тора.

М.Мәһдиев әсәрләренең үзенә тарту көче нәрсәдә соң? Язучы халык мәкальләрен, әйтемнәрен, сынамышларын бик яхшы үзләштергән һәм аларны кирәк урында гаҗәп оста куллана. Әсәрләрдә халык җырлары, такмаклары, энҗе бөртекләре кебек мул сибелгән.

М. Мәһдиевнең повестен күптән онытылып бетә язган, ләкин көчле экспрессиягә ия булган идеаллар да бизәкли. Ата-бабаларыбызның телләрендә булган, хәзер сирәк очрый торган әйтем формалары да бик урынлы кулланылган. Һәр сүзнең мәгънәви төсмерләрен, башка күчерелмә мәгънәләрен нечкә тоеп язу, гомум халык теленең бөтен грамматик байлыгын урынлы куллану - кабатламас стиль тудыра.

Язучы бер дә бәйләнеше булмаган әйберләрне белдерүче сүзләрне янәшә китереп куя, укучыны ирексездән елмаерга мәҗбүр итә. «Без - кырык беренче ел балалары» нда ата кара тараканның кан әйләнешен өйрәнәләр, укучылардан берсе «Гренландиядә тәмәке үсә» дип «ачыш» ясый, «Онегин су алырга чират тора». Рәсем ясап харап булган Әркәшә урынына Әлтәфиның нәкъ Әркәшә кебек борын авазларыннан башка гына әйткән «пид» («мин») сүзе өчен, завхоз тарафыннан «шовинист» дип аталуыннан килеп чыккан. «Шулай горур кыяфәттә шовинист Әлтафи коридорга чыгып китте. Класста иң арткы партада

натуралист Әркәшә генә ятып калды» дигән җөмләне укыгач ничек елмаймыйсың? Менә тагын бер картина. Җыр дәресе, эвакуацияләнеп килгән латыш хатыны балаларга ноталар өйрәтә до-ре-ми-фа-соль... Менә шул илаһи авазлар белән янәшә өзелеп-өзелеп ашыйсы килгән ач балалар... Янә тагын баш килештәге һәм иялек килешендәге куяннарны искә төшерик.

Аның прозасында көлкеле алымнар бик күп. «Без - кырык беренче ел балалары»нда рәсем укытучысы укучылары тарафыннан көлү объектына әйләнә: «Әтисе потомственный дворянин булган икән». Моны ишетүгә, безнең колаклар торды. Әлтәфи һич тә риза булмыйча, бөтен класска ишетелерлек итеп татарча:

–Череп таркалган сыйныф, – диде.

Әркәшә дә моңа кушылып:

–Алайса, безде алпавыт калдыгы укыта икад, – дип куйды».

«Без – кырык беренче ел балалары»нда арттыру алымы көлү эффектын көчәйтә: «Гренландия бик зур җир кисәге, – дип алып китте ул. Андый зур җир кисәге бик сирәк очрый. Анда бик суык, анда аюлар, жирафлар, кыр кәҗәләре һәм моржлар яши... Гренладиядә хуш исле тәмәке үстерелә».

М.Мәһдиев юморы шактый моңсу да. Менә дәрестә Ян Амос Каменский, Йоганн Генрих, Песталоцци карашлары турында сүз бара. Ач, ялангач балалардан шактый ерак бу төшенчәләр. Зарифуллинның уенда болар белән янәшә икенче уй, «тузып юкәсе чыккан чабатасын берөзлексез идәнгә ышкып» болай дип уйлана ул: «Кичә урамда эт тизәгенә басылган булырга тиеш. Юкәне харап итә инде ул. Авылга кайтканчы таралып китсә, нишлисе булыр?».

М. Мәһдиев геройлары узләренең сөйләм галәмәтләре белән дә күңелгә кереп калалар. Теге яки бу персонажны башкача сөйләтеп тә булмас иде кебек. «Без-кырык беренче ел балалары» педагог, һәрвакыт борыны тыгылган булганга, «борын авазларын әйтеп мәшәкатьләнмәгән Әлтафи», һәр җөмләдә «пнимаешь» сузен калдырмыйча сөйли торган завхоз-зоология укытучысы Исмәгыйль агай, китапчарак тел белән һәм мишәрчәрәк сөйләшүче немец теле укытучысы, «хуч ичле тәмәке», «чин нәрсә» дип сөйләүче география укытучысы; балаларны яратып, «ребятки» дип дәшә торган рус теле укытучысы. Болар һәммәсе тормышчан, хәтердә сөйләмнәре белән дә яшиләр.

Исемнәре үлемсез шәхесләр була. Үзләре бу якты дөньядан китсәләр дә, әсәрләре, моңлы бер жыр кебек, халык күңелендә яши. Шундыйларның берсе - Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, үткен каләмле тәнкыйтьче һәм күренекле әдәбият галиме Мөхәммәт Сөнгат улы Мәһдиев. Әдип арабыздан вакытсыз китте. Ләкин безгә ядкәр булып аның кабатланмас мирасы – уналты китабы, гыйльми хезмәтләре һәм публицистик мәкаләләре калды.

М.Мәһдиев - күп укыла торган авторлардан берсе. Мәһдиев теле - милли байлыгыбыз. Аның сурәтләү чараларның палитрасы, тел бизәкләре безнең кабатланмас вә тутыкмас көзгебез. Тел милләтнең какшамас байлыгы.

Язучының образлы фикерләү рәвеше, язу юнәлеше туган халкыбызның меңнәрчә еллар буенча тудырылган авыз иҗаты әсәрләренә бик тә якын. Хәтта М.Мәһдиев әсәрләренең халкыбызның, халкыбыз иҗатының бүгенге үзенчәлекле дәвамы дип тә карарга мөмкин сыман. Бу – икенче төрле итеп әйткәндә, меңләгән, миллионлаган кешеләрнең рухи дөньясында, аларның уйлау фикерләү рәвешләрендә якынлык дигән сүз.

Димәк, әдипнең үзенчәлекле үз язу стиле бар. Бүгенге көндә татар халкы тормышын, аның гореф-гадәтләрен, иманын, күңел серләрен тасвирлау, персонаж сөйләмен индивидуальләштерү кебек сыйфатлар М. Мәһдиев прозасының үзенчәлеген билгеләп торалар да инде.


Әдәбият

Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр: 5 томда /Төз. Г.Хәсәнова. III т.: повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 480 б.


## ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ – МӘҢГЕ СҮНМӘС ЙОЛДЫЗ


*Шакирова Гөлфинә,*

*КФУның Алабуга институты студенты*

*Фәнни җитәкче: Габидуллина Фәридә Имамутдин кызы*


Язучы күңелен борчымаган, аны дулкынландырмаган берәр мәсьәлә бармы икән дөньяда?! Мөгаен юктыр, аның күңеле әйләнә-тирәдә булган вакыйгаларга битараф кала алмыйдыр. Битараф булган очракта ул бөек язучы, халыкчан әдип була алмый. Ш.Галиев үзе дә: “Әдипне исә тормыштагы һәр актуаль һәм әһәмиятле мәсьәлә бердәй кызыксындыра, шәхси эшедәй күңеленә кагыла, җанын борчый. Шагыйрь үзе дә – тынгысызлык баласы” [Галиев 2006: 5], – дип әйтә.

Шәүкәт Галиев үз эшчәнлеген иң элек лирик шагыйрь буларак башлап җибәргән булса, алга таба балалар өчен шаян-шук шагыйрь буларак дәвам итә. Ул шигырь ярдәмендә күп кенә тормыштагы актуальпроблемаларны күтәрә, аларны чишү юлларын тәгъдим итә. Аның 1962 елда балалар өчен язылган беренче шигырьләр җыентыгы “Камырша” басылып чыга. Әлеге китап беренчесе булса да, соңгысы булмый, ә балалар әдәбиятының чишмә башы була. Чөнки алга таба әдипнең балалар өчен язылган яңадан яңа шигырьләре туа, китап булып басылып чыга тора: “Тамаша” (1964), “Шәвәли” (1965), “Көлке бүлмәсе” (1970) һәм башкалар. Аларның барында санап бетерү әлеге хезмәт барышында мөмкин түгел. 1982 елны “Заяц на зарядке” дигән рус теленә тәрҗемә ителгән китабы өчен Г.-Х. Андерсын исемендәге Почетлы Дипломга лаек була.

“Ш.Галиевныңбалалар әдәбиятына килүе нәниләр шигъриятен бер баскычка югарырак күтәрде” [Миңнуллин 2003: 12], – дип билгеләп үтә Р.Миңнуллин, әдипнең балалар язучысы буларак матур әдәбиятка керткән өлешен. Аның балалар өчен иҗат иткән шигырьләре үзләренең гади, әмма шул

ук вакытта кызыклы һәм үтемле булуы белән аерылып тора. Мәсәлән: “Рус казлары: га-га-га”, “Витаминлы хәрефләр”, “Светофорның өч сүзе”, “Алтын куллар”, “Рәхмәтләр хакында”.

Балалар язучысы Р.Корбан “Балачакта безне Ш.Галиевның Камыршасы тәрбияләде. Аннары аңа шаян-шук малай Шәвәли кушылды” [Корбан 2003: 148], – ди. Аның шигырьләре балаларны тәрбияли, ләкин үгет-нәсихәт сөйләү аша түгел, ә балаларның үз тормышларыннан алынган кызыклы мисаллар аша. “Камырша” шигыре ярдәмендә ялкауланмаска, эшчән булырга чакыра, “Алтын куллар” шигырендә тырышып эшләгән, укыган сурәттә гап гади кулларында гаҗәеп матур әйберләр ясый, үстерә алуы турында сөйләнә:

Ул кулларда
Юк сер, тылсым...
Алтын түгел,
Гади куллар –
Синдә дә бар
Андый куллар![Галиев 1987: 122].

“Яхшы мин-минлек” шигырендә Зөлфия исемле кызның тырышыпмы тырмашып үзенең ботинка киюе турында сөйләнә, ягъни мөстәкыйльлеккә өйрәтә. “Рәхмәтләр хакында” дигән шигыре белән эшләгән яхшылык, күрсәткән ярдәм өчен рәхмәт сүзен әйтергә кирәклегенә. “Физзарядка ясый куян” дигә шигыре ярдәмендә балаларны спорт белән шөгыльләнергә чакыра. “Телле телсез” дип аталган шигырендә үзеңнең туган телеңне онытмаска, аны кадерләп сакларга кирәклегенә басым ясый.

Шулай итеп, шагыйрь балаларга әхлакый тәрбия бирә, аларны эш сөяргә, туган телне, туган илне, ата-ананы хөрмәт итәргә өйрәтә. Табигатькә, җәнлекләргә карата миһербанлы булырга өнди. Ул балаларны әхлаклы булырга гына түгел, дөньяны танып-белергә дә өйрәтә. Ш.Галиев балалар психологиясен яхшы аңлаучы буларак, катлаулы әйберләрне гади итеп, җитдиләрен мавыктыргыч итеп, балалар телендә сөйли. Мөгаен шуңа күрәдердә ул балалар күңеленә ачкыч таба ала, алар аны үз итеп якын күрәләр шигырьләрен укып кына калмыйча, ятлыйлар, сәхнәләштерәләрдә.

Аның шигырьләре замана белән бергә атлый: “Сыбызгылы чәйнек”, “Инкубатор күргәч”, “Телевизор булды баш”. Шул рәвешле сабыйларның кызыксынуын канәгатьләндерә. Чөнки кечкенә генә балаларда мең дә бер сорау туа, алар барында бер юлы белергә телиләр, сорыйлар, эзләнәләр һәм еш кына үз сорауларына җавапны Ш.Галиевның иҗат җимешләреннән табалар. Мисал өчен:

Әни, әни, редискада
Бик күп, диден, витамин;
Тешләп карадым, эчендә
Витамин юк бит аның? [Галиев 1987: 87].

Монда баланың сорауларына җавап табарга теләве, әйткәнне эшләп, тикшереп карарвы сурәтләнә. Алдагы шигырьдә исә атасы улыннан нигә шул

хәтле күп сорау бирүе белән кызыксына:

Гел- гел, улым, Шәвәли,
Сорау бирәсең нигә?
Үсеп җиткәч, синең күк
Җавап бирәсем килә! [Галиев 1987: 88] – дип әйтә улы.

Шәвәли турында да бер сүз кузгаткач, аңа җентекләбрәк тукталып китмәү мөмкин түгел. Ул бер генә минутта урынында тормый, гел хәрәкәттә, мөгаен шунадыр да төрледән-төрле маҗараларга очрый. Шуңа да карамастан алардан шаян, тапкыр чыгу юлларын таба. Мисал өчен, "Шәвәли хәйләсе" дигән шигырен генә алыйк:

Усал эт күргәч
Ул болай диде:
Мин тәмле түгел,
Ашама мине!.. [Галиев 1987: 87].

Ләкин шуны онытмаска кирәк, Шәвәлинең хәйләкәрлеге, шуклыгы, тапкырлыгы Ш.Галиевның үзеннән килә. Күренекле шагыйрь, драматуг И.Юзеев та Ш.Галиев турында: "Балаларның шаян табигатен һич тә ясамыйча-нитмичә бирә белгән, мәктәп турында язса да үгет-нәсыйхәттән шигъри хәйләләр ярдәме белән котыла алган шаян Шәүкәт"[Юзеев 2006: 55], – ди.

Ш.Галиев – балалар өчен тормыш маягы булып тора. Диңгезчеләргә йолдыз юл күрсәткән кебек, улда балаларга аңлаешлы мисаллар ярдәмендә дөрес яшәү үрнәге күрсәтә. Без карап үткән шигырь өзекләреннән чыгып без болай дия алабыз: шагыйрь үзенең әсәрләренә бар җанын биреп үз эшен җиренә җиткереп эшли. Ул балаларга әхлак дәресләре генә биреп калмый, ә аларны мөстәкыль фикерләргә өйрәтә. Чөнки ул үзенең төп фикерен турыдан-туры әйтмичә, балаларга үзләренә уйланырга урын калдыра. Аның бу язу осталыгы мөһим һәм җитди фикерләрне балаларга кызыклы, мавыктыргыч итеп тапшырырга мөмкинлек бирә. Димәк, чыннанда Ш.Галиев балалар өчен матур әдәбиятта зур маяк һәм мәңге сүнмәс якты йолдыз булып балкый.

Әдәбият


Галиев Ш.Г. Илһамым-мәхәббәтем: Лирик язмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 447 б.

Галиев Ш.Г. Сайланма әсәрләр: Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 423 б.

Миңнуллин Р. Кадерен белгәннәргә... // Мәйдан. – 2003. – №12. – Б. 12-13.

Юзеев И. Көлке бүлмәсенә сәяхәт // Шәүкәт Галиев: Тормыш юлы һәм иҗаты: укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б. 54-55.


## ТАТАР ХАЛЫК ТАБЫШМАКЛАРЫНДА СЫЙФАТ ДӘРӘҖӘЛӘРЕ


*Шакирова Сөмбел,*

*Мөслим районы Түбән Табын мәктәбенең IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Шакирова Әлфия Мөнир кызы*

Табышмаклар халыкның афористик иҗаты составына керәләр. Алар тыңлаучылар алдына асылы читләтеп әйтү аша белдерелгән билгесез әйбер яки күренешне эзләп табу бурычын куялар. Читләтеп әйтү өчен төрле алымнар һәм чаралар кулланыла. Бер төр табышмакларда әйбер яки күренешнең тышкы билгеләре турында хәбәр ителә. Бигрәк тә форма, төс, тәм күрсәткечләре еш файдаланыла. Эзләп табылырга тиешле билгесез нәрсәне төрле яктан характерлауда аеруча сыйфат сүз төркеме киң кулланыла. Тыңлаучы бирелгән билгеләргә таянып кирәкле җавапны таба ала.

Әйбернең сыйфат белән белдерелгән билгесе төрле дәрәҗәдә булырга мөмкин. Дәрәҗә белән төрләнү – сыйфатларга хас бердәнбер грамматик категория. Татар телендә дәрәҗә категориясе, башка төрки телләрдәге кебек үк,билге чамасының һәртөрле үзгәрешен – уртача дәрәҗәсен, билгенең чагыштырмача артыграк яки уртача дәрәҗәдән кимрәк булуын, иң югары дәрәҗәсен – чиген белдерә. Дәрәҗәнең бу рәвешле белдерелүе белән татар теле башка телләрдән, әйтик, рус теленнән аерылып тора. Рус телендә сыйфатлар билгенең чагыштырма дәрәҗәсен генә белдерәләр [Тумашева,1964:84]. **Утро вечера мудренее.**

Татар телендә сыйфатларның дүрт дәрәҗәсе аерып өйрәнелә: төп дәрәҗә, чагыштыру дәрәҗәсе, артыклык дәрәҗәсе, кимлек дәрәҗәсе. Төп дәрәҗәдән башкалары махсус кушымча яки кисәкчәләр ярдәмендә белдерелә. Будәрәҗәләр барысы да татар халык табышмакларында киң кулланыш тапкан.

*Төп дәрәҗәдәге* сыйфат бернинди өстәмә кушымча алмый:

**Ак** ябалак **ак** киезгә ятыр. (*Кар)*

**Озын** буйлы, **зәңгәр** күзле. (*Җитен*)

Аягында **кара** ката,тәпиеңдә **кызыл** оек, **яшел** күлмәкле**, ак** яулыклы. (*Карабодай*).

**Йомры, йомшак сары** йомгак
Йөгереп йөри чирәмдә.(*Чеби*)

Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфат бер әйбердәге билгенең, башка әйбергә караганда, чагыштырмача артык булуын белдерә. *Чагыштыру дәрәҗәсе* –рак/-рәк кушымчасы ярдәмендә формалаша:

Ачыдан **ачырак**, татлыдан **татлырак**, усалдан **усалрак**, дөрестән **дөресрәк** Нәрсә бар дөньяда? (*Тел*)

**Кечерәк** кенә күл эчендә дөрли-дөрли ут яна, уты суны киптерми, суы утны сүндерми. (Самавыр)

*Артыклык дәрәҗәсендәге* сыйфат бер әйбердәге билгенең башка шундый ук әйбердәге билгедән бик күпкә артык икәнлеген белдерә:

Артыклык дәрәҗәсе төрлечә формалаша:

1) билгенең артыклыклыгы сыйфат алдындагы 1-2 аваз кабатлану юлы белән белдерелә:

Кап-караңгы бүлмәдә ашъяулык бәйли кыз бала. (Бал кортының кәрәзгә бал җыюы).

Үзе кып-кызыл, күлмәге ямь-яшел. (*Карбыз*)

Мамык юрган, кат-кат сырган, үзе суп-суык. (Кояш һәм ай).

Урманда бөккән,
Өйдә теккән,
**Яп-яңа** савыт
Тишелеп беткән. (*Иләк*)

2) иң, җете, үтә, дөм кебек кисәкчәләр ярдәмендә: иң зур, дөм караңгы, җете кызыл.

**Чем - кара** – елан түгел, мөгезле – сөзгәк түгел, канатлы – песнәк түгел, очканда мыш-мыш килә, туфракка яшеренә, бу нәрсә, йә, кем белә? (Ат коңгызы).

*Кимлек дәрәҗәсендәге* сыйфат әйбердәге билгенеӊ уртача дәрәҗәдән ким булуын белдерә. Мондый мәгънә төс белдерүче сыйфатларда морфологик юл белән, ягъни махсус кушымчалар ярдәмендә белдерелә. Кимлек дәрәҗәсе – гылт/-гелт, -кылт/-келт, -сыл/-сел, -су, -елҗем, -сел,-кылтым/-келтем, -ча, -мса кушымчалары ярдәмендә формалаша: кызгылт, аксыл, зәңгәрсу, яшькелт [ Хисамова, 2015:122].

Үзе түгәрәк, урыны түрдәрәк, эче тулы күзәнәк; **эчкелтем** дә **төчкелтем,** бар нәрсәдән дә кадерлерәк. (Икмәк).

Бер карасаң-**күксел** төсле, бер карасаң — ай сыман. Үткән чакта көлә төсле, өзеп ал дигән сыман; гөрли-гөрли җырлый ул, кызыл читек кия ул. Күлмәкләре **күгелҗем,** татулыкны сөя ул. (Күгәрчен).

Якташ шагыйрь Мөҗәһит Әхмәтҗанов та балалар өчен язган табышмакларында сыйфат дәрәҗәләренә аерым урын бирә.

Урманда мин **иң эре** кош
Куркытмый мине **салкын** кыш (Суер).

Күзәтүләрдән чыгып шундый нәтиҗә ясарга була: табышмакларда кулланылыш ягыннан күбрәк сыйфатның төп һәм артыклык дәрәҗәләре урын алган.

Әдәбият

Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: – Казан: “Мәгариф” нәшр., 1992. – 256 б.

Татар халык иҗаты: Табышмаклар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – 272 б.

Хисамова Ф.М.Татар теле морфологиясе. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2015. – 335 б.

## МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ ҺӘМ ШӘХЕС

*Шакурова Гөлназ,*
*КФУның Алабуга институты студенты*
*Фәнни җитәкче: Саттарова Гөлназ Глүс кызы*

“Татар кил. Әйе, ат өстендә татар гына үзен шулай горур, җиңел, кылтыкланып тота белә. Татар гына атны бар хәзинәләрдән дә өстен күрә. Фәкать татар гына башын аямыйча яуга баса” Бу юлларны без Марат Әмирханның 2003 ел башында “Казан утлары”ның өченче санында басылган “Тояк эзе романыннан укыдык. Ымсындыргыч һәм өметләндергеч ике сүз: татар килә! [Шәрәфиев 2006: 3].

Кайчандыр “татар килә” сүзеннән куркып торганнар. Хәзерге вакытта горур, көчле, милли җанлы, хөр фикерле татарлар югалып килә түгелме? Ф.Латыйфиның “Хыянәт”, Н.Фәттахның “Ител суы ака торур”, “Сызгыра торган уклар” һәм башка төрле әсәрләрдән без татарларның язмышын күрәбез. Бүгенге көндә дә милләтебезнең торышы бик актуаль проблема. Татар телен укытуга бәйле сорауларны гына алсак та, безнең аяныч хәлебез күренеп тора. Милләтебез авыр юл кичкән, көрәшкән, ireккә омтылган, электән үк безне һәряклап чикләргә, сынарга тырышканнар. Моның чагылышын М. Галәүнең “Болганчык еллар” һәм “Мөһаҗирләр” исемле тарихи романнарында да күрергә була. Без шушы әсәрләр аша милләт язмышы һәм шәхес арасындагы бәйләнешләр нинди, М. Галәү әсәрләрендә алар ничек чагыла, шулай ук, хәзерге әдәбиятта бу мәсәлә күтәреләме дигән сорауларга җавап табырга булдык. Безнең тикшеренүебезнең максаты куелган проблемаларны хәл итү булып тора. Алдыбызда торган бурычларны да билгеләп үтик:

1) Милләт язмышы һәм шәхес арасындагы бәйләнешләрне өйрәнү

2) М.Галәү әсәрләрендә милләт язмышы чагылышын тикшерү

3) М. Галәүнең “Болганчык еллар”, “Мөһаҗирләр” һәм М.Кабировның “Бердәнбер һәм кабатланмас” әсәрләрен чагыштыру.

М. Галәү – 19нчы гасыр язучысы, шәхес культы корбанына дучар булган, тормышы да иҗат юлы да бик катлаулы булган әдип. Үз чорында ул журналист, китап чыгару өлкәсендә типография эшенең остасы буларак танылa. Аның иҗат биеклеге – “Канлы тамга” дип гомуми исем биреп, дүрт китаптан дип планлаштырган роман-эпопеясы. Кызганычка каршы, М. Галәүнең ике китабы гына рус телендә дөнья күрә һәм бүгенге көнгә кадәр сакланып кала. “Болганчык еллар” һәм “Мөһаҗирләр” романнары безнең өчен тормыш энциклопедиясе кебек булды. Чөнки автор бу әсәрләрдә дистәдән артык проблема күтәрә, берничә сюжет линиясен алып бара, һәр геройның психологиясын, характерын, ачы язмышларын бәйнә-бәйнә сурәтли. Без авторның ни кадәр талантлы рәссам икәнен күрәбез, ул һәр геройның бит-йөзен, ни кигәнен, ни белән шөгыльләнгәнен, барлык детальләрне күрсәтә һәм бу безгә шул чор атмосферасына кереп, һәм эпизодны күз алдыбызга китереп укырга ярдәм итә. Хикәяләү дә бер вакыйга тирәсендә генә әйләнми, башта Мәүлә Колы авылында бара, аннары Казанга, хәтта Төркиягә күчә. Тарихта да 19нчы гасырда татарларның Төркия җирлекләренә күчеп киткән дигән реаль фактлар бар. Әсәргә килгәндә, М.Галәү милләт язмышы авыр хәлдә булганда кешеләрнең ни дәрәҗәдә милләтпәрвәр, тырыш, кыю, милли җанлы булып калганын күрсәтә. Төркиягә күчеп китүнең төп сәбәбе ул чорда татарларны

чукындыралар дигән хәбәр таралу, авылның торышы авыр хәлгә төшү була. 1897 елның башы иде. Халык шау килде:

– Бөтен халыкны көчләп чукындырасылар, имеш... [Галәү 2002: 235].

Чит илгә чыгып китсәләр дә, Мәүлә Колы кешеләре үзләренең татарлыкларын онытмыйлар, башкаларга ияреп начар юлга басмыйлар, киресенчә, бердәмләшәләр.

– Мөэмин-мөселман түгелдер болар, җеннәрдер... Моны әйткәндә аларның күзләре уттай яна, ә иреннәре чит-ят ил кешеләре исеменә каргышлар яудрып селкенә иде [Галәү 2002: 506].

Әсәрдән күрергә була: һәр тормыш этабында да кешеләр Сабан туе, туйлар, Каз өмәләрен үткәргән. Төркиядә булганда да алар татар җырлары җырлап утыралар, авыл төзелгәч, өйләрдә Коръән ашлары үткәрәләр. Бу, әлбәттә, кешеләрнең үз милләтенә, халкына хөрмәт белән карауын, гореф-гадәтләрен онытмауын күрсәтә. Милләт язмышы бүгенге көндә нинди хәлдә соң? Бүген, белгәнебезчә, мәктәпләрдә татар телен укыту-укытмау проблемасы тора. Кайчандыр без бер  Республика булып “аерылып чыкканбыз” һәм безгә үз суверенитетыбызны “биргәннәр”. Шулай да телебез һәм милләтебез юкка чыгу процессында.

“Гасыр капкасы ябылыр алдыннан безнең татар милләтен салып бәйләгән “капчык”ның авызын ачып алдылар. Бераз һава керде. Иркен сулыш алып җибәрдек. Ул янә ныклап каты итеп бәйләп куелды. Сулап калган һавабыз күпмегә җитәр?!” – роман каһарманының һәм авторның урак борчуларыдар бу. Сулап калган һавабызның бик озакка бармаячагын бик күпләр чамалыйдыр, чөнки татарның тынын кысу гомер-гомергә ике яктан – Мәскәүдән һәм үзебезнекеләрдән килә [Шәрәфиев 2006: 13].

Хәзерге әдәбияттагы Марат Кәбировның “Бердәнбер һәм кабатланмас” әсәрендә дә бу процесс һәм шулай ук безнең заман торышы чагыла. Карт татар әбисе остановкада хәер сорап утыра. Бу ситуация үзе үк балаларның әниләрен авыр хәлдә калдыруын күрсәтә, бу безнең милләт кешесенә бик үк хас түгел дип әйтер идек без. Аннары әсәрдә шул ананың төрле якта булган балалары күрсәтелә. Михаил – татар малае, динен саткан. Хәзер ул поп. Хәлил – чит илдә, Хәмит анасының барлыгын белми, гөнаһ кылып йөри. Автор аларны тупларга, аларның нинди милләт кешеләре булуларын искә төшерергә, белгертергә тели. Ничек итеп милләт, тел сакланып кала алсын әгәр дә  туган үзенең туганының кайда икәнен белмичә яши, мөселманнар динен алыштыра, балалар әниләрен ташлап, үз телләрен онытып чит илдә тормыш кичерә, гореф-гадәтләр сакланмый икән???  Әлбәттә, бу – фаҗига. Тарихка күз салыгыз, аек акыллы берәр татар үз теләге белән христиан диненә күчкәнме? Алар курыкканнар, Аллах Тәгаләдән курыкканнар. Рәфыйк Шәрәфиев та моны ассызыклап үтә. Алдыбызда бөек Тукаебыз күрсәткән идеал – Алла – каядыр югалды, әдипләребезнең байтагы “сихерле божра”дан чыга, гаҗизлектән арына алмый [Шәрәфиев 2006: 5]. Әлбәттә, мондый кешеләр белән милләт тә бердәм, тулы, үз матурлыгы белән яши алмый.

Шәхес һәм милләт. Уйлап карыйк әле, безгә боларның кайсысы әһәмиятлерәк? Әлбәттә минем үз тормышым, гомерем, язмышым дибез һәм дөрес әйтәбез. Ләкин без үз милли җәмгыятебездә, татарлар арасында яшибез. Ә безнең җәмгыять үзебездән төзелә. Без нинди – җәмгыять тә шундый. Күз алдыгызга китерегез: милләт – ул агач, без – ул агачның яфраклары. Агачның хәлате яфракларның торышыннан да тора. Әгәр дә аның яфраклары чирләп, коелып бетсә, агач та авыру була. Тамырларының ныклыгына да бәйле диярсез сез, әлбәттә хаклы булырсыз [Галәү 2002: 6]. Беренче әсәрләрдә кешеләр үз милләтен, татарлыкларын саклап кала алалар, ләкин икенче очракта, бүгенче көндә, күргәнебезчә, кешеләр әкеренләп татарлыкларыннан ваз кичә.

– Балаң туныда кайгырту анаң турында кайгыртудан башлана. Анасы бәхетсезнең баласы бәхетле булмый [Кабиров 2013: 365]. Аналар һәм балалар бәхетле булмаган җәмгыятьтә милләт сәламәт яши аламы? Һичшиксез, бу безне уйланырга мәҗбүр итә.

Йомгаклап, шуны әйтәсем килә: тарихи юл озын, катлаулы, кабатланып тора торган, ләкин без бердәмлекне югалтмаска, шушы Мәүлә Колы авылы кешеләре кебек бердәм булып, авыр заманнарга карамыйча, милләтебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калырга тиеш. Безнең бу процесста ролебез бик зур.

Әдәбият

Галәү М. Сайланма әсәрләр. – Казан: ТаРих, 2002. – 576 б.

Кабиров М.Р. Бердәнбер һәм кабатланмас. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 382 б.

Шәрәфиев Р. Татар эзләү: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 158 б.

## ТАТАР, РУС ҺӘМ ИНГЛИЗ ТЕЛЛӘРЕНДӘ КЕШЕНЕҢ ЭМОЦИОНАЛЬ ХАЛӘТЕН ТАСВИРЛАУЧЫ ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘР

*Шәйхетдинова Азалия,*

*Яр Чаллы шәһәре 7 нче урта мәктәбенең VII сыйныф укучысы*

*Фәнни җитәкче: Камаева Рузана Равиль кызы*

Җәмгыять тормышының мәдәниятендәге һәм тормыш көнкүрешендәге вакыйгалар телдә үзенең чагылышын таба. Фәннең бер мөһим тармагы булган фразеология мәсьәләләренә тукталыйк. Фразеология ул тотрыклы сүзтезмәләрне, ягъни фразеологизмнарны өйрәнә торган фән.

Фразеологизмнар телдә гаять әһәмиятле роль уйный. Алар, гади сүз һәм сүзтезмәдән аермалы буларак, төшенчәне, фикерне сурәтле, бизәкле, тәэсирле итеп белдерәләр, димәк, коммуникатив вазифа башкарудан тыш, эстетик бурыч та үтиләр. Сүз күрке – мәкаль, ди халык. Кеше үзенең сөйләмендә мәкаль-әйтемнәрдән, фразеологик берәмлекләрдән ни дәрәҗәдә мул һәм уңышлы

файдаланса, аның фикере кешеләргә шул дәрәҗәдә җиңелрәк, тизрәк һәм тәэсирлерәк барып җитә

Без бу эшебездә төрле структуралы телләрдә (бу очракта татар һәм инглиз телләрендә) кешенең эмоциональ халәтен тасвирлаучы фразеологизмнарның охшаш һәм аермалы якларын ачыклауны максат итеп куйдык.

Кешенең эмоциональ халәтен тасвирлаучы фразеологизмнар мәгънәләре ягыннан күптөрле. Алар шатлыкны, яхшы кәефне, гаҗәпләнүне, борчылуны, ачулану, битарафлыкны, оялуны һ.б. белдерергә мөмкин.

Татар һәм инглиз телендәге сүзлекләргә күзәтү ясау барышында җыйнап алынган фразеологизмнарга анализ ясаганнан соң, без кешенең эмоциональ халәтен тасвирлаучы фразеологизмнарны түбәндәге төркемнәргә берләштердек.

1. Шатлык хисен белдерүче фразеологик берәмлекләр: *тат.* авызы колакка җитү (авызы колакта), *рус.* рот до ушей, *ингл.* grin from car to ear; *тат.* башы күккә (түшәмгә)) тию, *рус.* прыгать от счастья (до потолка), *ингл.* to be overjoyed (jump with joy); *тат.* күңел ачылу, *рус.* приходить в хорошее настроение, *ингл.* get into a good mood; *тат.* күңел күтәрелү, *рус.* воспрянуть духом, *ингл.* hearten up, *тат.* күңеле үсү, *рус.* поднялось настроение, *ингл.* become inspired, *тат.* йөзе кояштай булу, *рус.* просиять лицом, *ингл.* (her) face lit up.

2. Күңел газабын, сагышлануны белдерүче фразеологизмнар: *тат.* бәгырь телгәләнү, *рус.* душа разрывается; *ингл.* heart is breaking; *тат.* йөрәген телгәләү; *рус.* ранить сердце; *ингл.* wound smb's heart; *тат.* йөрәк урынында түгел, *рус.* душа не на месте, *ингл.*he is anxious; тат. йөрәгенә чыдый алмау, рус. сердце не вынесло, англ. his heart failed him; *тат.* йөрәк сыкрау, *рус.* сердце болит, *ингл.* his heart aches; *тат.* йөрәккә кан сава, *рус.* сердце кровью обливается; *ингл.* heart is burning; *тат.* үзәк өзгеч, *рус.* раздирающий душу, *ингл.* heart-rending.

3. Курку хисен белдерүче фразеологизмнар*:* *тат.* йөрәк алыну, *рус.* сердце оборвалось, *ингл.* my heart failed me; *тат.* йөрәк аска төшеп китү, *рус.* сердце упало, *ингл.* his heart sank; *тат.* йөрәк жу итү, *рус.* сердце вздрогнуло, *ингл.* one's heart sank; *тат.* йөрәк уйнау, *рус.* сердце колотит, *ингл.* the heart thumps; *тат.* йөрәк үкчәгә китү, *рус.* душа в пятки ушла, *ингл.* his heart was in his boots; *тат.* йөрәкне өшетү, *рус.* леденить сердце, *ингл.* freeze one's heart.

4. Оялу, уңайсызлану хисен белдерүче фразеологизмнар: *тат.* йөзе комачтай кызару *рус.* покраснеть как вареный рак, *ингл.* turn red in the face; *тат.* чәч төпләренә кадәр кызару, *рус.* покраснеть до корней волос, *ингл.* to redden to the roots of one's hair; *тат.* җир тишегенә керердәй булу, *рус.* готов провалиться сквозь землю, *ингл.* he wished the earth could swallow.

5. Гаҗәпләнү, шикләнүне, икеләнүне белдерүче фразеологизмнар: *тат.* үз күзләренә үзе ышанмау, *рус.* не верить своим глазам, *ингл.* he could got believe his eyes; *тат.* үз колакларына үзе ышанмау, *рус.* не верить своим ушам, *ингл.* he could got believe his ears; *тат.* ис-акыл китү/ис китү, *рус.* диву даваться,

*ингл.* be wonderstruck/ be amazed; *тат.* аяз көнне яшен суккандай, *рус.* как гром в ясную погоду, *ингл.* like a bolt from the blue.

Өч тел фразеологизмнарындагы мондый зур гомумилекнең ике җирлеге бар. Беренчесе – фикерләү процессындагы төп эле-ментлар барлык халыклар өчен дә бердәм. Шул исәптән төрле халыкларның сәнгатьле фикерләвендә дә гомуми сыйфатлар күп. Тотрыклы әйләнмәләрнең иң зур күпчелеге сүзтезмә һәм җөмләләрнең күчерелмә мәгънәдә кулланылуына нигезләнгән. Бу исә кешеләр тормышындагы, аларның эшләрендәге, үз-үзләрен тотышындагы, иҗтимагый мөнәсәбәтләрдәге күренешләрне табигать күренешләренә охшатуга, чагыштыруга, шулай ук кешенең бертөрле эшләрен икенче төр- ләре белән, бигрәк тә физик эшләрен акыл эшләре белән чагыштыруга кайтып кала.

Әдәбият

Гарифуллин С.Ф. Татарча-русча-инглизчә фразеологик сүзлек. – Казан: Татарстан Республикасы "Хәтер" нәшрияты, 2010. – 296 б.

Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. 1 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 495 б.

Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. 2 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 365 б.

Кунин А.В. Курс фразеологии современного английского языка. – М.: «Высшая школа», 1996. – 381 с.

Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2003. – 223 б.

## ХАЛЫК КҮҢЕЛЕНДӘ ҖУЕЛМАСЛЫК ЭЗ КАЛДЫРГАН ИДЕГӘЙ

*Шәйхразиева Кадрия,*
*Алабуга шәһәре 9 нчы урта мәктәбенең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Гарданова Хәлимә Вәзир кызы*

.

И Идел-йорт, Идел-йорт,
Идел буе имин йорт,
Кендек каным тамган йорт,
Җаным булып калган йорт.

Әйе, Себердән алып Азов диңгезенә кадәр сузылган гаять зур территориядә Алтын Урда дәүләте яшәгән. Аның данлы-шанлы вакытлары булган. Вак-вак кенәзлекләргә таркалган Рус дәүләтенең берләшүенә, аның алга таба үсешенә дә көчле этәргеч биргән ул. XIV гасыр ахырларында бу куәтле дәүләт бик нык какшый. Морзаларның, ханнарның сугыш-талашлардан башлары чыкмый, алар үзәк хакимияткә көчәергә ирек бирмиләр: сәүдә юллары өзелә, дәүләт көчсезләнә.

Төньяк-көнбатышта Литва, Рус дәүләтләре бай җирләрне тартып алырга уңайлы вакыт кына көтеп торалар. Көнъяктан Алтын Урдага Аксак Тимер теш кайрый. Исеме дастаннарга кереп калган Идегәй нәкъ шул чорда яшәгән.

Дастанда Идегәй Котлыкыя улы дип бирелә, әмма тарихи чыганакларда аның Балтача улы булуы билгеле. Фарсы язучысы Хафиз Абру хезмәтендә аның әтисе Балынмак исеме белән телгә алынган. Дастанда без Идегәйнең Җантимер тарафыннан (ул Туктамыш ханның киңәшчесе, Котлыкыяның дусты итеп бирелә) коткарылуын күргән идек. Үз улы Кобогылны корбан итеп, Котлыкыяның бердәнбер улы Идегәйне коткарып калырга аны нәрсә этәрде икән соң? Моңа болайрак җавап бирергә идем. Мондый адымга бары тик ватанпәрвәрләр генә бара ала. Җантимер үз баласын ничек кенә өзелеп яратмасын, беренче чиратта аны ил язмышы борчый. Котлыкыя һәм аның баласы юк ителә икән, затлы нәсел дә юкка чыга дигән сүз. Ханнар нәселеннән булмаса да, ил язмышында әһәмиятле урынны алып торган әмир баласы яшәргә тиеш. Кобогыл исеме белән Туктамыш хан сараенда үскән Идегәйнең исеме, чыннан да, Алтын Урда тарихында ханнар исемнәре белән янәшә тора.

Идегәй – гаять каршылыклы шәхес. Җучи нәселеннән килмәгәнлектән, аның Алтын Урда тәхетенә утырырга хакы булмый. Шуңа да карамастан Идегәй – “таҗсыз хан” – күндәм ханнарны тәхеткә утыртып, Алтын Урданың чын хуҗасына әйләнергә тели. Ул 1397-1411 елларда (15 ел буена) ил белән идарә итә. Искиткеч кыю йөрәкле, хәрби осталыгы югары дәрәҗәдә булган Идегәй чорында дәүләт тагын бер мәртәбә үзенең көчен күрсәтеп ала. Моңа 1409 елдагы Мәскәү белән булган сугышны мисал итеп китерергә була. Идегәй бер яктан илне ныгыту өчен көрәшә, икенче яктан исә үзе үк илне таркатуда катнаша. Туктамыш тарафыннан эзәрлекләнгән Идегәй Алтын Урданың дошманы Аксак Тимер янына качып китә. Алай гына да түгел, аның Алтын Урдага сугыш белән килүенә каршы төшәсе урында үзе дә Аксак Тимер белән бергә Туктамышка каршы чыга. Ханнан үч алу теләге ил язмышыннан өстен чыга. Көчле сәясәтче саналган Идегәйнең моны аңлый алмавына ышанасы килми. Ни генә булмасын, халык үз героен аңлый. Дастанда бу вакыйгалардан соң аның бик үкенүен күрәбез: ул таланган илен күреп әрни, аның никадәр газиз булуын тоя.

Әтисенең үтерелүе аркасында, ул Туктамыш ханга гомер буе үч саклый. Алтын Урда ханына каршы сәясәт үткәрүенә төп сәбәпне тирәннәнрәк эзләргә кирәк. Мин моның сәбәбен Р.Фәхретдиновның “Аксак Тимер, Туктамыш һәм Идегәй” мәкаләсеннән табарга була. Галим фикеренчә, Идегәй үзендә ил белән идарә итәрлек сәяси сәләтне тойган һәм ул дәүләт белән идарә итәргә омтылган, ләкин хан буларак түгел, чөнки ханнар нәселеннән түгел. Ул моның өчен үзенә буйсынган күндәм ханнардан файдаланырга уйлаган. Алдагы укучы әйткәнчә, Идегәй моны эшли алган: озак еллар дәвамында, тәхеткә утырмыйча гына, ил белән идарә иткән.

Идегәй, беренче чиратта, халкына хезмәт иткән, аны хөрмәтләгән. Ә менә Туктамыш хан турында без ниләр әйтә алабыз? Туктамыш хан Алтын Урданың

бөек ханы булган, аны саклап калу өчен тырышкан, көрәшкән. Дөрес, дастанда ул тискәре характерда бирелгән. Моңа гаҗәпләнергә кирәкми, чөнки дастан – халык авыз иҗаты әсәре, ә халыкның үз ханнарын бик үк яратып бетермәве сер түгел. Халык вакыйгаларның өске ягын гына күрә, ә төп серләрне белеп тә бетермәскә мөмкин.

Туктамыш ханга үз илендә идарә итү бик җиңел булмаган, чөнки тәхет өчен көрәшкән үз якыннары – татарлар ук аңа каршы чыкканнар. Ә бит әле аңа урыс иле дә, Аксак Тимер дә гел куркыныч тудырып торганнар. Туктамышка үз иленең бердәмлеген, бәйсезлеген саклау белән бергә, төрле каршылыкларны да җиңеп чыгу өчен көрәшергә туры килгән. Ул гадел көрәштә һәлак булган.

Дастан тирән мәгънәгә ия. Һәр геройның эш-хәрәкәтеннән соң тулы нәтиҗә ясарга була. Дастанда татар халкының чын йөзе чагылыш таба. Бердәмлеккә ирешәсе урында – тарткалашу, бер-береңә юл куймау һәм шуның нәтиҗәсендә дошманнарга юл ачу, ил тикле илне югалту. Татарның төп фаҗигасе шунда түгелме соң?

Идегәйнең язмышы, татар иле Алтын Урданың таркалуы безнең халкыбызга сабак булырга тиеш. Мондый хаталарны һич тә кабатларга ярамый. Кызганыч, татар халкы моны оныта, һаман саен бер үк тырмага китереп баса тора. Идегәй дә, Туктамыш хан да ерак тарихтан аваз салалардыр сыман: татар халкы, безнең хаталарны кабатламагыз, татар илен-көнен күз карасыдай саклагыз.

Дастанның төп әһәмияте дә шунда: ул халыкларны, милләтләрне үз үткәненә әйләнеп карарга чакыра, мең елдан да артык тарихы булган татар халкын горур булырга, дус һәм бердәм булырга чакыра. Шулай булгач, бүгенге каршылыклы көндә дус һәм бердәм булыйк, дуслар!

Әдәбият

Татар әдәбияты: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәбенең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия (татар балалары өчен)/ Х.Й.Миңнегулов, Н.С.Гыймадиева. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2012.

## ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ҖЫР ХӘЗИНӘСЕ

*Шәфикова Васила,*
*Кукмара 3нче урта мәктәбенең X сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Яппарова Миләүшә Равил кызы*

Кеше күңеле җырлап ачыла диләр. Җыр сәнгатенең барлыкка килүе дә табигый. Шатлыкта, кайгыда һәрберебез татарга гына хас моңга тартыла. Татар халкының җыр мирасы күп төсле бизәкләрдә тукылган моңлы, шигъри бер дөнья булып күз алдына килә. Җырның хискә, мәгънәгә бай нәфис сүзләре һәм бай тылсымлы музыкасы халыкның тиңдәшсез талант иясе булуын раслый. Җыр хәзинәсендә чал тарих авазлары да тирән булып уелган.

Шигъри хәзинә буларак тикшергәндә, татар халкының җыр мирасы йола җырлары, тарихи җырлар, уен җырлары, лирик җырлар төркемнәренә бүлеп каралган.

Татар халкының гасырлар буена килүче эчтәлекле тематикасы 2 төрле:

-тарихи җырлар (болгар чорын, Казан ханлыгы чорын, крестьян сугышы, ватан сугышы, шәкерт садалары һәм җырлары, патша рекрутлары турында җырлар).

- лирик җырлар (туган як, хәсрәтле тормыш, чит илләрдә бәхет эзләүчеләр, гомер агышы, мәхәббәт җырлары).

Татар халык җырлары белән танышканда әти – әниләргә бәйле җырларда ачык чагыла. Җырлар аша ата – ананың мәрхәмәтлелеген, кече күңеллелеген, каядыр, хәтта, мескенлеген сиземлибез, шул ук вакытта миһербансызлыгына, салкын канлылыгына да тап булабыз.

Мәсәлән, "Качкыннар һәм тоткыннар турында" җырлар бүлегендә "Староста кызы" текстында әлеге юллар бар:

Беглыйлар урладылар
Әтиемнең үченнән.

Газаплар эчендә кыз бала бары тик әти-әнисен генә искә ала. Ата – ана иң элек баласына бәхет теләүче. "Кыз картка китте" җырында:

Ата: Кызым, сорыйлар сине бер байга,
Бирәмен сине Ихсан бабайга.
Кыз: Әткәй, көчләмә, бармыймын картка,
Көндәш өстенә, сакаллы акка.
Ата: Кызым, барырсың, баеп калырсың,
Теләгән кадәр мәһәр алырсың

Ата фикеренчә, "дәүләте булгач", кызына "һәркем яр". Заманына күрә тамак туклыгы зур проблемаларның берсе булганга күрә, ата кеше кызын карт байга биреп бәхетле итәргә тели.

Вакытыннан алда үлеп киткән әнкәйләр турындагы җырлар да йөрәкә үтеп керә:

Әни дә кәбәм, мине асрады
Шәмкә агачының бишеге;
Әни дә кәбәмне күрер идем,
Ачылмыйдыр ләхет ишеге. ("Ятим кыз җыры")

Татар халкының тарихи һәм лирик җырларында ата – анага багышланган аерым бүлек юк. Ләкин әлеге тема бк күп җырларның үзәгендә кызыл җеп булып сузыла. Нәтиҗә ясап әйткәндә, югарыда билгеләп үтелгән барлык җырларда, ата – ана темасы баласы белән булган вакыйгаларга бәйле ачыла.

Патша армиясе, рекрутлар, солдатлар, әсирләр моңы темасын яктырткан җырлар тарихи җырларның зур гына өлешен алып тора.

"Никрутлар йөкләнде муйныма" җырында лирик герой:

Бәне әткәй солдат итте,
Бер эскертен кызганып.

Сүз патша армиясенә хезмәткә чакырылган егет турында. Җыр эчтәлегеннән атаның баласын әлеге хезмәттән алып калырга мөмкинлеге булып та, берни дә эшләмәве аңлашыла. Әлеге тема "Наемщик" җырында да ачык чагыла:

"Бай булса да әти мине, әй, җибәрә",

чөнки " ике меңгә бер йөз тулмый", шуңа күрә әти-әни:

"...әй, бәбекәем бәхетең юк,

ахры кит син солдат булып, әй, үзең үк".- дип, улларын озаталар. Ул заманда да рекрутларның күбесе патша хезмәтенә "ут йотып" барганнар, чөнки соры казарма, урысчаны белмәү, ямансу бертөрлелек яшьегетнең күңелен өшеткән. ("Бәхетсез солдат килә")

Патшага хезмәт итү дәверендә аерылу сагышы, ана күз яшьләре – барысы да әлеге җырларда сурәтләнгән хисләр.

"Син китәсең инде"(никрут анасының җыры). Әлеге җырда ананың никрут улын сагынып елавы сурәтләнгән:

Син китәрсең инде, мин калырмын
Камышлардан күпер салырмын;
Син кайтасы юлга карый – карый,
Камышлардан сары калырмын.

Патша хөкүмәте ялгыз ананың хәленә керми. Баласының 25 ел хезмәт итеп кайтуы да икеле. Бу хәсрәт заманында малае булган һәр йортка да агылган.

"Хатын-кыз язмышы" турындагы җырлар кыз баланы теләмәгән кешегә кияүгә бирү, сатып җибәрүдән гыйбарәт. Бу темага караган җырларны анализлаганда, татарда да, ул чорда, шулай ук, хатын-кызның теләге, хисләре белән исәпләшүне кирәк үк дип тапмаганнар. Ата-ана кызларын кияүгә биргәндә, билгеле сәбәпләр аркасында, башкалары белән беррәттән, материаль якны да исәпкә алу ягын караган. Мәсәлән, "Фәрүзә кыз" җырында ата кеше кызын карт, мул яшәүче берәүгә киягә бирә. Кыз :

"Бирмәдең, әтием, үз тиңемә,

Бирдең картка, адәм кименә," – дип елый, ләкин язмышына буйсынмыйча нишләсен? Ничек аяныч булмасын, бу язмыш ул замандагы бик күп хатын-кызның башыннан кичкән. Шул ук тема "Әткәй мине картка бирде", "Кыз картка китте","Сабый кияү", "Ник үстердең буемны?", "Сөйгәнемә баралмадым", "Нигә тудым?" исемле һәм башка бик күп җырлар халык тарафыннан иҗат ителгән.

Халык ятимлек ачысын кичергән кыз баланың башыннан кичкәннәрен дә ачык чагылдырган:

Идел буе яшел таш,
Ник елыйсың, яшь туташ?
Мин еламый кем еласын –
Үзем ятим, үзем яшь. ("Син елама яшь туташ")

Җырлар, нигездә, моң, сагыш белән тугарылган. Тарихи җырлар тулысы белән үк, лирик җырларның туган якка, социаль тормышка, чит җирләрдә бәхет

эзләүчеләргә, яшәү кадеренә, хатын-кыз язмышына багышланган текстларында бу тема тулысынча ачыла. Мәхәббәт, дуслык, шаян җырларда исә әлеге тема яктыртылмый диярлек. Билгеле, сагышланып утырып кына тормыш бармый. Яшәү өчен күңелләрне җилкендererлек җырлар да кирәк. Җырларны һәркемнең күңелен тибрәндерерлек итеп, кешенең күңеленә кереп урнашырлык итеп иҗат итүдә халык үзенең тел, моң байлыгыннан оста файдаланган.

Татар халкының җыр чишмәсе чал гасырлар түреннән агып килә. Һәр җыр – ул тарихның бер кисәкчеге, чорның үзе. Аны өйрәнү, татар халкына гына хас моңны югалтмау киләчәктә җыр чишмәсене саекмавына өмет бирә.

Г.Тукайның халык иҗатына багышланган мондый юллары бар : “...менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман да халык күңелендә... калдылар, алар сәламәт әле, алар яңгырый әле”. Чынлап та, халык күңелендә моң барда, җырлар яшәүләрен дәвам итәчәк.

Әдәбият

Надиров И.Н. Татар халык иҗаты “Тарихи һәм лирик җырлар”. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1988. – 335 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. III томда – Казан: Татар. кит. нәшр.,1981. – 832 б.

Надиров И.Н. Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары . – Казан: Татар. кит. нәшр.,1980. – 319 б.

## ЯШЬ БУЫНГА ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ БИРҮДӘ МАТУР ӘДӘБИЯТНЫҢ РОЛЕ

*Шәфикова Сөмбел,*
*Мамадыш политехник көллиятенең 11 П төркем студенты,*
*Фәнни җитәкче: Әхмәтшина Айгөл Дамир кызы*

Һәрбер кешенең күңеленә дә кече яшьтән үк туганлык, гаилә, туган нигез, табигать, туган җир кебек төшенчәләр салына башлый. Үсә төшкән саен, кешенең аңында әлеге төшенчәләр киңәя бара. Әйтергә кирәк, баланы тәрбияләгәндә, яшьтән үк, эти-әни, туган җир, гаилә, туган ил өчен җаваплылык, икенчеләй итеп әйткәндә – патриотизм хисе тәрбияләргә тиешбез [Фәхретдин 2004: 34].

Кем соң ул патриот? Патриотизм нәрсә аңлата? Әлеге төшенчәләргә җавап табу өчен, без Татар теленең аңлатмалы сүзлегенә мөрәҗәгать итәргә булдык. Сүзлектә төшенчәләргә мондый аңлатма бирелә: “Патриот – үзенең туган җирен, халкын, илен, ватанын сөюче, шулар өчен һәртөрле корбаннарга да әзер булган кеше. Патриотизм – патриотларга хас булган күренеш (эш, теләк, хис); үз илеңә, халкыңа мәхәббәт” [ТТАС 1977: 347]. Ягъни, киңрәк итеп әйткәндә, патриотизм – үз илеңә, туган телеңә, халкыңа, табигатькә, милли традицияләргә, мәдәниятkә мәхәббәт ул.

Яшь буында патриотизм хисен уятуда матур әдәбиятның да роле бик әһәмиятле. Бигрәк тә, Бөек Ватан сугышы турындагы әсәрләр укучылар өчен тәрбияви яктан файдалы.Бөек Ватан сугышы чоры әдәбиятының үзенчәлекләре: яшәү һәм үлем, ирек һәм коллык, батырлык һәм куркаклык, фидакарьлек һәм хыянәт төшенчәләре арасына кеше җаны, аның рухы куела. Әйтергә кирәк, сугыш тыныч кына яши торган кешеләрне шушы сыйфатларның икедән берсен сайларга мәҗбүр итә [Татар әдәбияты тарихы 1989: 8]. Әдәбияткә шул чорның герое – совет кешесе, совет солдаты образы килә. Бу образ бик күп әсәрләрдә чагылыш таба, бер үк сыйфатларга ия булган кеше.

Патриотизмның иң матур үрнәкләрен биргән Муса Җәлил, Габдрахман Әпсәләмов, Фатих Кәрим иҗатлары аеруча игътибарга лаеклы.

Патриотизмның иң яхшы үрнәге – герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты. “Моабит дәфтәрләре” – Җәлил поэзиясенең иң югары ноктасы. Боларда исә, шагыйрьнең шәхси образы, кичерешләре, фәлсәфи уйланулары аша кеше рухының бөеклеге, куркусызлыгы, гуманистик табигате, гаделлек һәм хаклык тантанасына якты ышанычы, туган иле һәм халкына чиксез мәхәббәте гаҗәеп зур эмоциональ көч һәм сәнгатьчә камиллек белән гәүдәләнә [Мостафин 1988: 35].

Муса Җәлилнең шигырь җыентыкларына игътибар итсәк, аның җыентыкларының һәрберсендә беренче урында “Җырларым” шигыре тора. Шагыйрь әлеге шигырен, үзенең иҗат программасын тәшкил иткән, бөтен иҗат һәм тормыш юлын йомгаклый торган шигыре буларак санаган. Шунысы мөһим, шагыйрь бу шигырь юллары белән иленә һәм халкына биргән изге анты турында, соңгы минутларында рапорт бирә:

Үлгәндә дә йөрәк туры калыр,
Шигыремдәге изге антыма.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма [Мостафин 1988: 47].

Әлбәттә, Муса Җәлилнең әдәби мирасы күп милләтле совет әдәбиятының кыйммәтле бер казанышы булып тора. Аның иҗаты халкы арасында матур, гуманистик тойгылар уята, аларны тормышның матурлыгын күрергә һәм шул матурлык өчен көрәшергә чакыра.

Габдрахман Әпсәләмовның иҗатын алсак, аның геройлары аеруча тәвәкәллек, осталык таләп итә торган һөнәр кешеләре. Алар үзләренә тапшырылган барлык бурычны да намус белән башкарырга омтылалар. Ул бурычны үтәү өчен никадәр маҗаралы хәлләр, түземлек, батырлык, максатка ирешү теләге, рухи көч кирәк була. Габдрахман Әпсәләмов матур әдәбиятта үзенең беренче адымнарын шигырь язудан башлый. Аның язган шигырьләре, “Октябрь баласы” дигән татарча журналларда басылып чыга. Редакторы исә, Муса Җәлил була. Габдрахман Әпсәләмовның искиткеч таланты сугыштан соңгы елларда ачыла. Аның әсәрләрендә табигать төп герой ролен, әйтерсең җир – ана, туган җир образлары җанланып дошманга каршы көрәшә. Аның

әсәрләрендәге геройлары да, үзе кебек, тормышка, табигатькә гашыйк кешеләр [Татар әдәбияты тарихы 1989: 123].

Фатих Кәрим иҗатына күз салсак, шуны аңларга мөмкин, Бөек Җиңү өчен, туган иле һәм халкы өчен сугыш кырында баш салуны җырга тиңли:

Үләм икән, үкенечле түгел
Бу үлемнең миңа килүе,
Бөек җыр ул – Бөек Ватан өчен –
Сугыш кырларында үлүе [Татар әдәбияты тарихы 1989: 324].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк, патриотизм һәм илне саклау темалары, беркайчанда картаймый торган төп темалар. Болар – мәңгелек темалар. Сугышта булган салдатлар – геройларга әвереләләр. Ләкин, бу командир приказы белән башкарылмый, ә йөрәк кушуы белән. Илне хөрмәт итү хисе нәселдән нәселгә килә. Менә шушы хис инде, кешене күкрәге белән утны капларга мәҗбүр итә. Бу уңайдан олуг мәгърифәтче Риза Фәхретдиннең сүзләре бик тә кыйммәтле һәм урынлы булыр: “Дөньяда тора белү – зур һөнәр, әмма үлә белеп үлү – аннан да зур, вә кыйммәтле һөнәр”, – дип яза ул [Фәхретдин: 131].

Әдәбият

Мәшһүр мәгърифәтче – галим, педагог Ризаэтдин Фәхретдин мирасын укыту-тәрбия процессында файдалану. – Казан: РИЦ “Школа”, 2004. – 285 б.

Мостафин Р.Ә. Җәлилчеләр: очерклар, җәлилчеләр иҗаты. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. – 232 б.

Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Том 5: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941 - 1960). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 544 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. 3 том. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. – 652 б.

## ЧУАШ ЯЗУЧЫСЫ ЕВА ЛИСИНА ИҖАТЫНДА ТАТАРЛАР

*Юнысова Эльмира,*
*Чуаш Республикасы Батыр районы*
*Шыгырдан урта мәкәтбенең IX сыйныф укучысы*
*Фәнни җитәкче: Айзатуллова Роза Равил кызы*

Мин Чуашстанның иң зур татар авылы – Шыгырданда туганмын. Чуаш Республикасы җирлегендә 55 төрле милләт яши. Шулар арасында 35 меңнән артык татарлар. Татар авыллары Батыр, Комсомол, Шомыршы, Ялчек, Козловка районнарында бар. Иң күп татар авыллары Батыр районында урнашкан. Районда 7 саф татар авылы: Шыгырдан, Озын Куак, Кыр Бикшиге, Татар Согыты, Кызыл Чишмә, Татар Тимәше, Кызыл Камыш. Ә Имәнкисәге авылында чувашлар белән татарлар бергә яши. Районның 24 % татарлар тәшкил итә. Татар авыллары гомер-гомергә янәшәдә яшәгән чуваш халкы белән үзара дус, тату, тыгыз мөнәсәбәттә торганнар.

Район үзәге Батырда чуваш һәм татар телләрендә басылып чыга торган “Авангард” газетасы битләрендә 2016 елның октябрь, ноябрь, декабрь айларында чуваш язучысы Ева Лисинаның “Садрый абый, ягъни Фатыйманың елавын теләмим” исемле хикәясе басылып чыкты. Әдәби әсәрләр укырга яратканга, хикәяне укый башладым.

Ева Лисина турында беренче мәртәбә ишетүем булганга, интернеттан автор турында белештем.

Ева Николаевна Лисина 1939 елда Чуашия Республикасы Батыр районы Имән кисәге авылында туып үскән. Ул халык арасында язучы-прозаик, даматург, тәрҗемәче булып танылган. Аның чуваш һәм рус телендә язылган әсәрләре дә бар. Ева Николаевна шулай ук рус һәм чит илләр язучылары хикәяләрен дә чуваш теленә тәрҗемә итә.

Е. Лисина 1988 елдан бирле СССРның Язучылар берлеге әгъзасы. 1987 елда ул Бөтенроссия иң яхшы балалар китабы конкурсында лауреат, 1990 елда “Немецкая Волна” радиостанциясе конкурсы җиңүчесе. Конкурста катнашкан 1600 хикәя арасында аның «Çăкăр чĕлли» (“Икмәк кисәге”) хикәясе беренче урынга лаек була. Хикәя буенча немец телендә радиопьеса куела.

2002 елда Митта Васлей исемендәге премия лауреаты булган. Чувашия Республикасының милли культурасына лаеклы өлеш керткәне һәм озак еллар тырышып көч куйганы өчен 2001 елда Е.Лисинага “Чувашия Республикасының атказанган культура эшчәне” дигән мактаулы исем бирелгән.

Танылган язучы педагог һөнәрен дә үзләштергән, ул озак еллар Мәскәүдә Щепкин исемендәге театр училищесының сәнгать кафедрасында булачак артистларга чуваш телен өйрәткән. 1983 елда чуваш театрына милли кадрлар хәзерләгәне өчен Чуаш АССР Президиумының Мактау грамотасына лаек булган.

Хикәянең ахырында тәрҗемәченең электрон адресы бирелгән иде. Башкорт дәүләт университеты галиме, хикәянең тәрҗемәчесе Лилия Рәшит кызы Сәгыйдуллина белән элемтәгә кердек. Күңелемдә булган сорауларга ул җавап бирде.

“Садрый абый, ягъни Фатыйманың елавын теләмим” хикәясенең тормышта булган реаль вакыйгаларга нигезләнгән булуын автор әсәрнең беренче юлларында ук әйтеп китә.

Хикәядәге вакыйгалар 1912-1913 еллардан башланып китә. Автор бу вакыйгалар турында әнисеннән ишетеп белә. Шул вакыттан башлап, Синьял чувашы белән Шыгырдан татары гаиләләре туганлашып китәләр.

Ат карагы булуы белән дан тоткан Шыгырдан татары Садрыйны Синьял чувашлары тотып алалар һәм эштән чыгарганчы кыйныйлар.

Садрый кыймылдамый башлагач, аны үлгәнгә исәплиләр һәм барысы да куркуга калалар. Аны койма буена, кычытканлыкка сөйрәп китереп ташлыйлар да үзләре куркып таралышалар. Соңрак үле гәүдәне яшерергә теләп киләләр, ләкин гәүдәне таба алмыйлар. Шул көннән башлап, Синьял авылы өстендә курку хисе хөкем сөрә. Авыл халкы татарларның үч алуларын яки волость

кешеләренең килүен көтәләр. Чөнки кеше үтерүдән дә зуррак явызлык булмавын аңлыйлар.

Садрыйның тотылуы хакында авылда белмәгән кеше урманчы Ягур (Ева Лисинаның бабасы) була. Чөнки ул көнен кордонда үткәрә һәм авылга кич белән генә кайта. Юлда очраган яралы кешене арбасына салып кайта. Хатыны Марье бу яралыда Шыгырдан Садрыен таный һәм курка кала. Шул ук вакытта авылда үтереш булмавына да куанып куя. Инде хәзер нишләргә дигән соау туа. Ягур, бер дә шикләнмичә, яралыга ярдәм кирәклеген әйтә. Ул Садрыйны үзенең туганы итеп күрә, чөнки ул үзенең сулышы белән аны үлемнән алып кала.

Шул төнне мунчада Марье, төрле үләннәр белән дәвалап, Садрыйны үлем тырнагыннан алып кала. Ә Ягур төнлә 32 чакрым үтеп, Шыгырданга барып, Садрыйның исәнлеген Фатыймага җиткерә. Һәм ике көннән аны китерергә ант итеп кайта.

Ике көннән соң, Ягур Садрыйны Шыгырданга илтеп куя. Авыл халкын тынычландыру өчен хәйләсен дә уйлап таба. Базарга алып барган себеркене Шыгырдан Садрые йөге белән алып калды, дигән хәбәрне тарата. Садрыйның исәнлеген ишетеп, Синьял ирләре зур бәладан котылуларына куанып куялар.

Синьялдагы вакыйгалардан соң Садрыйның да күңелендә үзгәрешләр була. Аның җаны сүз белән аңлатып булмый торган ниндидер җылылык белән тулыша.

Садрый өчен Синьял авылы чувашлары бик кадерле кешеләргә әверелеп китә. Базарга барышлый очрасалар, ул аларны кунакка чакыра, базарда аларга товарларын ярты хакына сата. Чуашлар өчен Сайдрый "үзебезнең Садрыйга" әверелә.

Сугыштан соңгы ачлык елларында Садрыйның гаиләсе Ягур гаиләсенә ярдәм итүдән туктамый. Садрыйның 14-15 яшьлек онытгы Илгиз, 32 чакрым юлны җәяү үтеп, берничә мәртәбә Синьял авылына килә. Ул аларга көлчә, ярма, он алып килә.

Автор җидееллык мәктәпне тәмамлагач, авылларыннан 12 чакрым ераклыкта урнашкан урта мәктәптә укуын дәвам итә. Атна саен авылына кайтып йөри. Тик язгы юлсызлыкта, каты салкыннарда, буранда әнисе кайтмаска куша.

Автор Садрыйның оныгы Илгизнең тормышы белән кызыксынып тора. Аның институтка керергә теләвен дә Абдулла абыйдан ишетә. Ләкин берничә ел имтихан биреп тә аны үткәрмиләр, чөнки ул "халык дошманының" оныгы була.

Автор әсәрдә Садрый белән Фатыйманың үзара җылы мөнәсәбәтләрен, Фатыйманың уңганлыгын, балаларның олыларга хөрмәт белән карауларын да тасвирлап бирә.

2009 елда Чуаш китап нәшриятында "Сәяси репрессия корбаннарының хәтер китабы" бастырыла. Ева Николаевна шул китаптан Садрыйны эзли. Әмма ул аның фамилиясен белми. Бәлки аны туганнары да белмәгәндер. Алар аның исемен һәм йортын белгән, дистә еллар буе аралашу өчен шул җиткән.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсем килә, “Садрый абый, ягъни Фатыйманың елавын теләмим” хикәясе тарихи фаҗигаләрнең аерым кешеләр, авыллар, гаиләләр язмышында реаль чагылышы белән, авторның геройларына карата мөнәсәбәте белән игътибарны җәлеп итте. "Кеше теләсә нинди шартларда да кеше булып калырга тиеш" һәм "Үзеңә эшләнгән яхшылыкны унлата кайтара белү" кебек идеяләр дә хикәяне заманча итә.

## ЭЧТӘЛЕК


1. Абдуллин Раниль Р. (Әлмәт ш.). Кеше язмышында телнең роле........ 3
2. Айдашев Камил И. (Алабуга ш.). Балалар әдәбиятында Шәүкәт Галиев мәктәбе........ 4
3. Аркатова Анна А. (Алабуга ш.). Туфан Миңнуллин драмаларында җәмгыять........ 7
4. Әминов Фаил Ф. (Зәй ш.) “Идел” журналында эмоциональ-экспрессив сүзләрнең кулланылышы........ 9
5. Әхмәдиев Азат Ф. (Норлат ш.). Тел язмышы – милләт язмшы........ 11
6. Әхмәтҗанова Алсу И. (Әлмәт, Яңа Нәдер). Якташ язучыбыз Клара Булатова иҗатында безнең авыл каһарманнары........ 14
7. Әхметшина Ильвина Н. (Түбән Кама). Р. Миңнуллинның балалар өчен язылган шигырьләрендә тел-сурәтләү чаралары........ 17
8. Байбулатова Эльвира А. (Яр Чаллы). Юныс Әминов иҗатында югары әхлакый кыйммәтләр........ 19
9. Бакунова Эмилия Р. (Пермь крае, Бардым р-ны). Халык җырларының әһәмияте........ 21
10. Бибакова Ильмира И. (БР, Стәрлетамак). Земфира Муллагалиева шигырьләрендә төсләр........ 23
11. Бухарова Ирина (Алабуга институты). Татар язучылары иҗатында агачларның роле........ 25
12. Васильева Регина Е. (Мамадыш көллияте). Бүгенге көндә татар телен өйрәтүдә булган төп юнәлешләр, яшь буында милләтара дуслык тәрбияләү........ 27
13. Вәлиева Вилюза Ф. (Әлмәт, Яңа Кәшер). “Рәшә” әсәрендә тел-сурәтләү чаралары........ 28

14. Вәлиева Лиана (Алексеевск р-ны). Бар халыкны туган теленә булган мәхәббәт берләштерә. .................................................................. 31
15. Вәлирахманов Дәнис С. (Әлмәт, Яңа Кәшер). Татар әдәбиятында ат образы. ........................................................................................ 33
16. Вәлишина Алсу Ш. (Алабуга институты). Фәрит Имамов – юрморесткалар остасы. ......................................................................... 35
17. Габдинова Эльнара Д. (Пермь крае, Енапай). Гаяз Исхакый иҗатында милләт язмышы проблемасының куелышы........................... 36
18. Габделхаков Ильнур А. (Алабуга ш.). Халкыбызның үлемсез әсәрләре. ............................................................................................ 38
19. Гайнетдинова Индира Ф. (Яр Чаллы пед. көллияте). «Сәләт» – татар теле сагында. ........................................................................ 40
20. Гайнуллина Айгөл Ш. (Алабуга институты). Ленар Шәех иҗаты – милли тәрбиягә нигез...................................................................... 42
21. Гайнуллина Гөлия Ш. (Алабуга, Иске Юраш). Һәйкәл куяр идем... ......................................................................................... 44
22. Галиуллина Зәлия, Сәйфетдинова Алсу (Кукмара). Кеше тормышында һәм татар әдәбиятында йортның роле.......................... 46
23. Галәветдинова Диләрә Ш. (Алабуга институты). Татар, рус һәм инглиз фразеологизмнарында соматик атамаларның милли үзенчәлекләре. ............................................................................ 49
24. Гамиров Алмаз, (Яр Чаллы). Казан ханлыгы.............................. 51
25. Гарипова Наилә, (Яр Чаллы). М.Маликованың «Кар сулары», «Сары тюльпаннар» хикәяләрендә хатын-кыз образының бирелеше. ........................................................................................................ 53
26. Гарипова Элина Р. (Әлмәт ш.). Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләрендә табигать күренешләре. ..................................................................... 55
27. Гарипова Юлия Р. (Түбән Кама). Түбән Кама шәһәр музее тарихы...................................................................................................... 57
28. Гарифуллина Алия Т. (Әлмәт ш.) Татар халык экиятләре...................... ................................................................... 59
29. Гарифуллина Лия Р. (Алабуга институты). Тылсымлы экиятләрдә образлар системасы....................................................... 60
30. Гарифуллин Ришат (Яр Чаллы). Язучылар иҗатында татар теле һәм милләт язмышы. ...................................................................... 62
31. Гаффарова Алсу А. (Алабуга институты). Рабит Батулланың “Кылдан нечкә, кылычтан үткен” романында Г.Тукай образының бирелеше. .......................................................................................... 65
32. Гәрәева Диляра Ф. (Яр Чаллы). Бүгенге көндә тел культурасы............................................................................................ 66
33. Гибадуллина Гөлгенә Г. (Мөслим р-ны). Тәрҗемәдә мәкаль–әйтемнәр... .......................................................................................... 68

34. Гиздатуллина Назлыгөл И. (Яр Чаллы пед. көллияте). Гариф Ахунов иҗатында заман сулышы (авторның Әлмәт чоры иҗатына бер караш). ............................................................................................ 70
35. Гинятуллина Сәлимә Н. (Әлмәт, Мәмәт). Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләрендә кыз балаларны тәрбияләүгә караш.................................. 72
36. Гулиева Көлшән Р. (Мөслим). Ф.Садриевның «Соңгы дәрес» әсәрендә Ризаэддин Фәхретдин мирасының чагылышы........................ 75
37. Дәүләтшина Айгөл Ф. (Чирмешән р-ны). Татар телендә зооним компонентлы сүзтезмәләр.................................................................... 78
38. Дәүләтшина Диләрә Д. (Чирмешән р-ны). Әдәби әсәрләрдә гиперболаларның әһәмияте.................................................................... 80
39. Дюмеева Гөлназ (Алабуга институты). Татар телендә кушма җөмләләрне чагыштырмача өйрәнү................................................ 82
40. Заитов Айрат И. (Пермь крае, Каенавыл). Гайнә сөйләшү үзенчәлекләре. ........................................................................... 84
41. Заитова Гүзәл И. (Алабуга институты). Г.Ибраһимов әсәрләрендә геройларның сурәтләү осталыгы. .................................. 89
42. Заитов Рөстәм М. (Пермь крае, Каенавыл). Укучыларда әдәбият белән кызыксыну уятуда театр түгәрәгенең роле............................... 88
43. Зарипов Камил А. (Түбән Кама ш.) Р. Вәлиев – күпкырлы талант иясе. ............................................................................................ 89
44. Землянова Мария П. (Минзәлә р-ны, Кадрәк). Тарих эзләре буйлап…......................................................................................... 91
45. Зиатдинов Булат (Яр Чаллы). Н. Фәттахның “Идел суы ака торур” романында бүре символы. ..................................................... 93
46. Ибраһимова Алсу З. Алабуга институты). Татар теленең киләчәге безнең кулда. .................................................................. 94
47. Исхакова Рәзилә Ф. (Әлмәт политехника техникумы). Азнакай районы Өшегән яки Тат Шуган авылы атамалары. ................................. 96
48. Йосыпова Зөһрә Р. (Пермь крае, Барда р-ны). Муса Җәлилнең нәсел дәвамчылары... ........................................................................ 98
49. Камалова Лилия Ф. (Яр Чаллы пед. көллияте). Кәрим Тинчурин һәм хәзерге заман. ........................................................................ 101
50. Кәримова Айсылу А. (БР, Илеш р-ны). Фольклор – халык акылы.......................................................................................... 103
51. Кәримова Чулпан Р. (Мөслим р-ны).Фоат Садриев әсәрләренә кергән фразеологизмнар.......................................................... 105
52. Киямова Элиза Ф. (БР, Стәрлетамак институты). Башкортстан республикасының Дәүләкән районындагы мишәрләрнең кайбер тел үзенчәлекләре. ........................................................................... 108
53. Комиссарова Виктория Г. (Алабуга ш.), Ага чишмә челтер-челтер, безгә нидер сөйлидер... ........................................................ 110

54. Костромина Дарина В. (Алабуга, Иске Юраш). Табигатьне тоям җаным-тәнем белән.... ........................................................................ 113
55. Косых Анжелла Ю. (Мөслим р-ны, Салавыз–Мухан). Ф. Садриевның “Рәхмәт, этием.” хикәясендә шәхес психологиясенең тирәнлеге. ........................................................................ 114
56. Кусякулова М. (Алабуга ш.). Чишмә башы–тормыш башы........................................................................ 117
57. Маннапова Гөлия Р. (Әгерҗе, Иж Бубый). Бубый шәкертләре дөньяга туп-туры карыйлар, аякларын җиргә нык басып йөриләр......... 120
58. Махмутова Зилия И (Алабуга ш.). “Ассалар да, киссәләр дә...”.... 121
59. Мөхәммәтҗанова Илзирә, (Алабуга институты). Татар радиотапшыруларында гарәп-фарсы алынмаларының кулланылышы. .. 124
60. Нәбиуллина Айзирә И. (Яр Чаллы) Татар телен укытуда актуаль проблемалар. ........................................................................ 127
61. Нугаева Луиза Ш. (Мөслим р-ны, Вәрәшбаш). Шәмсия Җиһангирова җыр текстларының үзенчәлеге.................................... 130
62. Нуретдинова Лилия Р. (Мөслим). Нәкый Исәнбәт драмаларының антропонимикасы. ........................................................................ 131
63. Нуриева Резеда Р. (Әлмәт, Яңа Кәшер). Татар халкының гореф-гадәтләре, традицияләре........................................................................ 134
64. Петрова Вероника Н. (Мөслим р-ны, Татар Шураны). Хәзерге прозада компонентында “күз” лексемасы булган фразеологизмнарның кулланылышы........................................................................ 136
65. Ризванова Гульнур (Алабуга институты). Мәктәптә кушма җөмләләрне укыту алымнары. ........................................................ 138
66. Сабирова Лилия Д. (Алабуга ш.). Бишек җырлары җырлансын.... 141
67. Сәйфетдинова Алсу А. (Кукмара). Халкыбызның кабатланмас бизәкләре. ........................................................................ 142
68. Сарварова Розалина (Әлмәт ш.). Яшь буынны әхлаклы итеп тәбияләүдә Р.Фәхретдин хезмәтләре. .................................................... 144
69. Сафина Аида И. (Алабуга, Иске Юраш). Татар теле үсешенең тарихы. ........................................................................ 146
70. Сибгатуллина Лилия (Алабуга институты). Нәзифә Кәримова прозасында Мамадыш районы Арташ авылы халкының җирле сөйләм үзенчәлекләренең чагылышы........................................................................ 148
71. Ситдикова Ләйлә А. (Мамадыш көллияте). Риза Фәхретдинов иҗатында дөньяви-дидактик һәм рухани эчтәлекле хезмәтләренең роле. ........................................................................ 150
72. Талипова Алия Ф. (Яр Чаллы). И.Юзеевның “Таш диварлар авазы” поэмасында тел-сурәтләү чаралары. ..................................... 152
73. Фазлиәхмәтова Рузилә М. (Алабуга ш.). Балачак җырчысы........................................................................ 155
74. Фатихова Ильзия И. (Алабуга институты). Гөлләр дә елыймы?

(Г.Гыйльманов иҗатында хикәя жанры)................................................ 157
75. Фәрхетдинова Гөлназ И. (Алабуга ш.) Туфан Миңнуллин әсәрләрендә ана образы........................................................................... 159
76. Хадиева Алия Р. (Алабуга ш.). Айдар Хәлим әсәрләрендә һөнәри лексиканың чыганаклары. ........................................................................ 160
77. Хәкимова Лениза (Мөслим р-ны Салавыз-Мухан). Клара Булатова шигырьләрендә укытучы шәхесе............................................ 163
78. Хәкимуллин Алмаз И. (Алабуга ш.). Габдулла Тукай иҗатында халык авыз иҗаты. ........................................................................... 166
79. Ханова Рузилә; Мәрданова Камилә (Сарман р-ны). Ф.Садриевның "Кыргый алма әчесе" повестеның тәрбияви әһәмияте........................................................................................ 169
80. Хәбибуллин Ильнур И. (Алабуга ш.) Тел – белем чишмәсе......... 172
81. Хөсәенова Гөлназ Г. (Алабуга ш.). Ана теленнән класстан тыш эшләрнең нигезләре...................................................................... 174
82. Хөснетдинова Әлфия Л.(Чуаш республикасы,Батыр р-ны, Шыгырдан). Җирле шагыйрә Гөлчәчәк Юсупова иҗатында тел һәм әхлак проблемалары" ....................................................................... 176
83. Чигвинцева Зөлфия М. (Әгерҗе, Иж-Бубый). М. Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» повестенда тел-сурәтләү чаралары.................................................................................... 179
Шакирова Гөлфинә (Алабуга институты). Шәүкәт Галиев – мәңге сүнмәс йолдыз. ............................................................................. 182
84. Шакирова Сөмбел А. (Мөслим р-ны, Тамьян). Татар халык табышмакларында сыйфат дәрәҗәләре................................................... 184
85. Шакурова Гөлназ А. (Алабуга институты). Милләт язмышы һәм шәхес. ........................................................................................... 186
86. Шәйхетдинова Азалия Р. (Яр Чаллы ш.). Татар, рус һәм инглиз телләрендә кешенең эмоциональ халәтен тасвирлаучы фразеологик берәмлекләр. ........................................................................................ 189
87. Шәйхразиева Кадрия К. (Алабуга ш.). Халкыбыз күңелендә җуелмас эз калдырган Идегәй. ........................................................ 191
88. Шәфикова Вәсилә (Кукмара). Татар халкының җыр хәзинәсе...................................................................................... 193
89. Шәфикова Сюмбел Г. (Мамадыш көллияте). Яшь буынга патриотик тәрбия бирүдә матур әдәбиятның роле.................................. 196
90. Юнысова Эльмира Ф. (Чуаш республикасы, Батыр р-ны, Шыгырдан). Чуаш язучысы Ева Лисина иҗатында татарлар................ 198

**ТАТАР ТЕЛЕ ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ ТАРИХ:**

**ҮТКӘНЕ, БҮГЕНГЕСЕ, КИЛӘЧӘГЕ**

Укучыларның һәм студентларның VIII Бөтенрәсәй фәнни-гамәли конференциясе материаллары (Алабуга, 24 ноябрь, 2017 нче ел). – Алабуга: КФУның Алабуга институты нәшрияты, 2017 – 210 б.

Издательство

423600, Российская Федерация, Республика Татарстан

г. Елабуга, ул. Казанская, 89

Отпечатано ООО «ЕлТИК», РТ, г. Елабуга. Заказ __
Тираж 300 экз.